**Ф.Ю.Гаффарова**

# САДРИ МАКСУДИ



**САДРИ МАКСУДИ**
**(1878 – 1957)**

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

*Ф.Ю.Гаффарова*

# САДРИ МАКСУДИ
# (1906 – 1924 еллар)

КАЗАН – 2001

**ББК**

Фәнни редакторы: фәлсәфә фәннәре докторы **Ф.М.Солтанов**

**Ф.Ю.Гаффарова.** Садри Максуди (1906 - 1924 еллар). Монография. Казань: Изд-во «Школа», 2001. – 262 с.

Хезмәт XX йөз башы татар милли хәрәкәте идеологларының берсе, Россиянең II–III Дәүләт думалары депутаты, Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты рәисе, эмиграциядә – Төркиядә яшәгәндә дөнья күләм танылган юрист, галим, сәясәтче, дәүләт эшлеклесе Садретдин Низаметдин улы Максудиның иҗтимагый, сәяси эшчәнлеге турында. Китап киң катлау укучыларга, дәүләтчелегебез, үткән тарихыбыз белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

© Институт истории АН РТ, 2001
© Издательство «Школа», 2001

# КЕРЕШ

Татар халкының югалган дәүләтчелеген торгызу өчен алып барган милли бәйсезлек көрәше әле кабынып, әле сүрелеп гасырлар буе дәвам итеп килгән. Әмма вакытлар узган саен, илдәге яшәү шартлары үзгәрә бара: бик күп халыкларны, милләтләрне үз кул астына алып, Россия иксез–чиксез империягә әверелә. Патша самодержавиесе алып барган милли сәясәт XX гасыр башында әлеге халыкларда, бигрәк тә татар халкында, милли хәрәкәт күтәрелүенә китерә. Әлеге хәрәкәтнең төп максаты гадел җәмгыять төзү һәм хаким милләт белән бертигез хокукларга ия булып Россиядә хөр яшәү була.

XX гасыр башында яңа күтәрелеш алган милли хәрәкәт Февраль инкыйлабыннан соң әлеге максатка ирешүгә мөһим адым ясый: 1917 елның 22 июлендә Россия мөселманнарының Казанда уздырылган II корылтаенда Эчке Русия һәм Себер төрек-татарларының Милли–мәдәни мохтарияты игълан ителә. Ләкин 1918 елның апрель аена кадәр генә яшәп калган бу мохтарият совет хөкүмәте декреты белән юкка чыгарыла. Татар халкының Милли–мәдәни мохтариятын мәйданга чыгарган милләтпәрвәрләрнең күбесе эмиграциягә китәргә мәҗбүр була, ә илдә калганнарын исә ачы язмыш көтә.

Октябрь инкыйлабыннан соң башланган канлы тарих XX гасыр башында татар халкының авыр, өметсез тормышында чын мәгънәсендә милли–мәдәни инкыйлаб ясаган милләтпәрвәләребезнең исемнәрен генә түгел, алар башкарган эшләрне дә халык хәтереннән юды, тарихыннан алып ташлады. Шулай итеп революциядән соңгы буыннар аларның бар икәнен дә белмичә үсте, укыды, яшәде. Нәтиҗәдә, Россиядәге башка милләтләр кебек үк, ике капма–каршы сыйныфка бүленергә мәҗбүр ителгән татар халкы да үзенең иң асыл улларын – милләтпәрвәрләрен югалтты: байлары илдән сөрелде, атылды; зыялылары төрмәләрдә че-

ретелде; мәчет—мәдрәсәләре сүтелде, җимерелде һәм татар халкы бүгенге көнгә гасырлардан килгән гореф—гадәтләрен, динен, телен онытып беткән диярлек дәрәҗә дә килеп җитте.

Әмма, шулай да татар халкының хәтер тирәнлегендә, совет хөкүмәте тоткан милли сәясәтнең һәм яңа тарихны «ясаучыларның» өзлексез хурлап торуларына да карамастан, Сталин чорының дәһшәтле елларын узып, XX гасыр башында милләтебезнең алтын баганалары булган Гаяз Исхакый, Габделбари Баттал, Зыя Камали, Муса Бигиев, Һади Максуди, Фатих Кәрими, Һади Атласи, Фуат Туктаров, Галимҗан Шәрәф, Йосыф Акчура һәм Садри Максудиларның исемнәре, ә төрле архивларның яшерен фондларында алар турындагы документлар, аларның хезмәтләре дә сакланып калган икән әле.

«Бәхетсезләр кемнәр? Тарихын оныткан милләт. Үткәнен оныткан халык киләчәктә ялганларга мәҗбүрдер», дигән Миргазиз Укмасый*.

Соңгы ун елда халыкларның менә шушы оныттырылган чын тарихларын һәм шул тарихны тудырган шәхесләрне Россиядәге милләтләрнең үзләренә кире кайтару, ягъни тарихи дөреслекне торгызу процессы бара. Татар халкының чын тарихы XX йөз башы татар милли хәрәкәте җитәкчеләренең һәм татар зыялыларының: Рәшит Ибраһимов, Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Габдербари Баттал, Фатих Кәрими, Габдулла Буби, Галимҗан Шәрәф, Гомәр Терегулов, Гайса Еникеев, Һади Атласи, Һади Максуди, Ильяс Алкин, Зәки Вәлиди, Садри Максуди һәм башка бик күпләрнең милли, сәяси эшчәнлекләренә җентекле анализ ясалганда, аларга дөрес бәя бирелгәндә генә язылa ала. Шунлыктан, татар милләте тарихына яңа сәхифәләр өстәячәк, ягъни XX йөз башы татар милли хәрәкәте, аның идеологиясен барлыкка китергән, аны тормышка ашырырга омтылган зыялыларның, җәмәгать эшлеклеләренең милли эшчәнлекләренә бүгенге көн таләпләреннән чыгып, тарихи фактларга, материалларга таянып дөрес бәя бирү һәм XX йөз башы татар милли хәрәкәтен бөтен тирәнлеге, катлаулыгы белән ачып, аның чын, тулы тарихын язу бүгенге тарихчыларның бурычы булып тора.

Милли тарих фәненең соңгы еллардагы үзенчәлегенең бер ягы: XX йөз башы татар милли хәрәкәтендә катнашкан татар зыялыларының, бигрәк тә, хезмәтләре генә түгел, исемнәре дә халыкка билгеле булмаган шәхесләребезнең һәм эмиграциягә китергә мәҗбүр ителгән милләтпәрвәрләребезнең милли эшчәнлекләренә игътибар арту. Г.Исхакыйның, Г.Гобәйдуллин, Г.Баттал–Таймасның, Һ.Атласиның, З.Вәлиди – Туганның, С.Максудиның кайбер әсәрләре, хезмәтләре басылды инде. Алар турында мәкаләләр дә вакытлы матбугатта да чыгып килә. Әмма болар, безнең үткән тарихыбызга кире кайтып, тарихи дөреслекне торгызу юлындагы беренче адымнар гына әле. Алда аларның чит илләрдәге архивларын кайтару, Төркия, Франция, Финляндия, Германия һ.б. мәмләкәтләрнең вакытлы матбугатында, сәяси журналларда чыккан хезмәтләрен эзләп табып, шуларга да таянып, алар турында төпле фәнни хезмәтләр язу бурычы тора.

XX гасыр башы татар милли хәрәкәте идеологларыннан булган, халыкта милли аң уятучы, милли хис тәрбияләүче милләтпәрвәрләребезнең һәм Октябрь инкыйлабыннан соң «мөртәд»кә әйләндерелгән, соңыннан халкыбыз тарихыннан исеме дә сызып ташланган асыл затларыбызның берсе – Садри Максуди.

С.Максуди, XX гасыр башы татар милли хәрәкәтенә рухи һәм идея юнәлеше бирүчеләрнең берсе буларак, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, соңыннан, Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Әхмәдиев, Мулланур Вахитовлардан үзгәрәк, ягъни «Иттифак әл–мөслимин» партиясе программасына таянып эш иткәнә. «Иттифак әл–мөслимин» партиясе һәм мөселман фракциясенең Думадагы эшчәнлеге, татар милли хәрәкәтенең нигезе буларак, 1905 елгы революциядән соңгы чорда татар җәмгыятендә иҗтимагый–сәяси фикер формалашуда зур роль уйный. С.Максуди, Россиянең II–III Дәүләт думалары депутаты буларак, рус халкы белән бертигез хокуклар алып, татар милләтенең яшәешен бары тик законнар нигезендә генә үзгәртү, ягъни аны мәдәнияттә, мәгарифтә, икътисадта Европа халыклары дәрәҗәсенә күтәрү, дөнья аренасына чыгару турында хыялланган. Ул бу максатка татар халкын ике капма–каршы сыйныфка бүлмичә, бары тик бербөтен халык хәлендә саклап кына ирешеп булачагына нык ышанган, шуңа күрә дә

үзенең Дәүләт думаларында сөйләгән нотыкларында да, «Йолдыз» гәзитендә басылган күп санлы «Сөхбәтләр»** ендә дә шушы фикерен алга сөргән һәм сәяси эшчәнлеген дә шушы максатка багышлаган.

Хәзер танырга кирәк: XX йөз башы татар милли хәрәкәтенә шушы рәвештә юнәлеш бирүчеләрнең берсе булган Садри Максуди һәм, соңарып булса да, аның фикерен яклауга күчкән Фуад Туктаров, Гаяз Исхакыйлар хаклы булганнар. Бу турыда Г.Исхакый үзенең 1917 елдагы бер чыгышында болай дип әйтә: «1905 елгы революциядә без сыйнфый байрак астында бардык, хәзер исә милли байрак астына басарга тиешбез»*** Татар милләте милләт буларак үзенең бәйсезлегенә бары тик бердәм, бербөтен булганда, ә милли хәрәкәт җитәкчеләренең эшчәнлеге уртак фикергә корылганда гына ирешә алачак.

Кызганычка каршы, XX гасыр башы татар милли хәрәкәтенә рухи һәм сәяси юнәлеш бирүче бу татар зыялыларының ясаган ялгышларыннан, аларның ачы тәҗрибәсеннән бүгенге татар милли хәрәкәте җитәкчеләре сабак алырга тиеш булсалар да, милләтпәрвәрләребез аларның шул ук ялгышларын кабатлыйлар.

Илдә демократик үзгәртеп кору чоры башлангач, безнең галимнәребезгә дә татар милләтенең чын тарихын язу һәм шул тарихны ясаган, әмма исемнәре, хезмәтләре халык хәтереннән җуйдырылган шәхесләрне халыкка кайтару мөмкинлеге туды. Г.Исхакый, Г.Баттал, Һ.Атласи, М.Бигиев, З.Вәлидиләрнең кайбер хезмәтләре инде татар укучысына җиткерелде. Шулай ук үзенең татар милли хәрәкәтендә уйнаган роле белән алар арасында күренекле урын алып тора торган С.Максуди турында да вакытлы матбугатта И.Таһиров, Ә.Кәримуллин, З.Зәкиев, М.Гайнетдинов, Я.Абдуллиннарның мәкаләләре дөнья күрде; аның «Мәгыйшәт» романы, «Англиягә сәяхәт» исемле юлъязмасы «Казан утлары» журналында басылып чыкты. Шулай ук быел С.Максудиның Тарих институтының бер төркем галимнәре (Я.Г.Абдуллин җитәкчелегендә) тарафыннан тәрҗемә ителгән «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән милләтчелекнең нигезләрен ачуга багышланган соңгы иң мөһим хезмәте дә дөнья күрде[1].

1994 елның октябрь аенда[2] Татарстан Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм 1998 елның октябрендә Тарих институты С.Максудиның тууына 115 һәм 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни конференцияләр уздырды. С. Максудиның милли, сәяси, гыйльми эшчәнлегенә багышланган бу беренче зур сөйләшүләрдә Татарстан галимнәреннән тыш Төркиядән килгән галимнәр дә катнашты. Конференция материаллары, ягъни С.Максудиның киң кырлы эшчәнлегенә җитди анализ ясалган әлеге чыгышлар аерым китаплар булып басылып чыкты[3].

1925 елдан башлап, Төркиядә яшәгән чорда, Садри Максуди—Арсал инде төрек халкына, аның мәдәниятын, мәгарифен күтәрүгә, үстерүгә зур көч куя һәм ул үзенең бар көчен, вакытын, белемен төрек халкына хезмәт итүгә багышлый. Шунлыктан, С.Максудиның Төркия сәясәтендә, мәдәниятында тирән эз калдырган 32 еллык гомеренә башка ноктадан карап бәя бирергә кирәк. Аннан соң С.Максудиның Төркиядәге сәяси, фәнни эшчәнлеге турында анда зур—зур хезмәтләр язылган, гомумән, төрек халкы аның хезмәтләренә үзенең зур бәясен биргән. Профессор Ахмет Биҗан Әрҗуласун үзенең 1988 елда язган «Sadri Maksudinin millietciligi» дигән күләмле мәкаләсендә аның «Миллият тойгысының социологик әсәслары» хезмәтенә җентекле, җитди анализ ясаган һәм «Садри Максудиның телгә карашы» дигән мәкаләсендә исә аның төрек теле буенча хезмәтләренә, эшчәнлегенә зур бәя биргән. Шулай ук С.Максудиның кызы Гадилә Айда тарафыннан язылган һәм 1991 елда Анкарада басылып чыккан «Садри Максуди—Арсал» дигән китап турында да әйтеп китәргә кирәк. Чөнки әлеге китап, субъективлык, кайбер ялгышлар булуга да карамастан, С.Максудиның гомер юлын тулысынча сурәтләгән, аның сәяси, милли эшчәнлегенә бәя бирергә омтылган беренче хезмәтләрдән. Г.Айданың әлеге хезмәте күптән түгел генә Мәскәүдә рус теленә тәрҗемәдә дөнья күрде. Г.Баттал—Таймасның «Ике Максудилар» дигән китабы әлеге шәхесләрнең замандашлары буларак та, татар милли хәрәкәтендә катнашучы буларак та, Садри һәм Һади Максудовларның милли—сәяси эшчәнлекләренә объектив бәя бирергә тырышып язылган. Бу хезмәт ака-

демик Ә.Кәримуллин тарафыннан тәрҗемә ителеп, күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. З.Вәлиди–Туганның «Унҗиде күмелгән шәһәр һәм Садри бәй Максуди» исемле хезмәте С.Максудиның Төркия тарихы буенча язган хезмәтләре белән бәхәскә кереп язылган.

1917 елда Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты игълан ителүгә чит ил галимнәре дә зур игътибар бирә. Соңгы егерме–егерме биш ел эчендә әлеге вакыйгага багышлап язылган хезмәтләр арасында Т.Дәүләтшинның «Совет Татарстаны: ленинчыл милли сәясәтнең теориясе һәм практикасы», Г.Акышның «Idil–Ural dâvasi ve sovyet emperyalizmi», Н.Дәүләтнең «Rysya Turklinin milli mucadeletapihe» кебек хезмәтләре дә бар. Ә менә С.Максудиның Россиядәге сәяси–иҗтимагый эшчәнлеге, татар халкының милли хәрәкәте идеологларының берсе буларак шул хәрәкәттә тоткан урыны турында, моңарчы аерым хезмәтләр язылганы булмады. Егерменче елларда гына Г.Ибраһимовның «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» дигән заман таләпләреннән чыгып язылган хезмәтендә эмиграциядәге татар милли хәрәкәте җитәкчеләренә, шул исәптән, С.Максудига да, советчыл күзлектән бәя биреп кителә.

Шулай ук, 1918 елда А.Г.Тугрының «Вәкилләр көзгесе» исемле китапчыгында С.Максуди турында кызыклы фактлар китерелә, аның эшчәнлегенә бәя бирелә. Аннан М.–Ф.Усалның (Ф.Туктаров) «I–II–III Думаларда мөселман депутатлары һәм аларның кылган эшләре» дигән брошюрасы, С.Максудиның Дума депутаты буларак эшчәнлегенә бик субъектив һәм берьяклы бәя бирелүенә дә карамастан, безнең өчен файдалы әдәбият була ала[4].

Бу хезмәт XX йөз башы татар милли хәрәкәте идеологларының берсе булган, шул чорда Россия күләмендә татар халкы өчен хәлиткеч проблемаларны күтәреп чыккан, аларны хәл итәргә тырышкан һәм шушы юлда татар халкының милли аңын үстерүгә дә зур көч куйган С.Максудиның милләтенә хезмәткә багышланган сәяси эшчәнлеге турында.

Хезмәтнең максаты: XX йөзнең беренче чирегендә татар милли–азатлык хәрәкәте иделогларының берсе, 1907–1912 елларда II–III Дәүләт думалары депутаты буларак Россиянең рәсми сәясә-

тендә сизелерлек роль уйнаган сәясәтче, Эчке Русия һәм Себер төрек–татарлары Милли–мәдәни мохтариятының Милли Идарәсе рәисе Садри Максудиның татар халкы тарихында алып торган урынын билгеләү.С.Максудиның Россиядәге сәяси–иҗтимагый эшчәнлеге, XX йөзнең беренче чирегендәге татар иҗтимагый–милли тормышы, татар халкының язмышы шикелле үк катлаулы да, каршылыклы да һәм шул ук вакытта гыйбрәтле дә. Шунлыктан, бу шәхеснең сәяси–иҗтимагый эшчәнлегенә бәя биргәндә, ул чорның катлаулыгына да, милли хәрәкәтнең бүлгәләнүенә дә, ягъни аның җитәкчеләренең төрле мәсләктә булуларына да, С.Максудиның татар халкының беренче профессиональ сәясәтчесе булуына да игътибар итәргә, гомумән, ул елларда әлеге шәхескә карата татар вакытлы матбугатында әйтелгән тәнкыйть–бәяләргә сак килергә кирәк.

Әлеге хезмәт милләтче, сәясәтче, журналист, галим С.Максудиның кызыклы вакыйгаларга бай, катлаулы тормыш юлын өйрәнеп, аның сәяси–иҗтимагый эшчәнлегенә бүгенге көн таләпләреннән чыгып, моңарчы билгеле булмаган (С.Максудиның оныгы Гөнел ханым Пултарда сакланучы (Төркия, Анкара) архивы материалларыннан файдаланып, аның әлегә кадәр артык игътибарга алынмаган Дәүләт думаларында ясаган чыгышларын фәнни кулланышка кертеп, бүгенге гыйльми дөньяда билгеле булган фактларга яңа төсмерләр, детальләр өстәп, яңачарак бәя бирергә тырышып язылды.

Шунысын да әйтергә кирәк: С.Максуди милли хәрәкәттә ялгыз булмаган. Шунлыктан, әлеге хезмәттә аның эшчәнлеген бәяләгәндә С.Максудиның замандашлары, көрәштәшләре булган Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Галимҗан Ибраһимов, Йосыф Акчура, Габделбари Баттал, Зәки Вәлиди һәм башкаларның кайбер хезмәтләренә, фикерләренә дә игътибар ителде һәм кайбер фактлар фәнни әйләнешкә беренче мәртәбә кертелде.

Хезмәтнең беренче бүлегендә «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелү, ягъни татар милләтенең сәясәттә уяна башлавына – әлеге партия төзелүгә китергән сәбәпләргә тукталып кителде. Биредә С.Максудиның, әлеге партиянең өч съездының беркетмәләр басылып чыкканнан соң язылган «Милләтнең вөҗданы» исемле

күләмле мәкалә–бәяләмәсе анализланды, аның шул чордагы милли хәрәкәт җитәкчеләренә, татар зыялыларына булган мөнәсәбәте ачыкланды.

Шулай ук биредә «Иттифак әл–мөслимин» партиясе тәкъдиме белән Россиянең II–III Дәүләт думаларында депутат итеп сайланган С.Максудиның, Дәүләт думаларында әлеге партиянең программасына таянып, мөселман фракциясе җитәкчеләренең берсе буларак эшчәнлеге каралды, бәяләнергә тырышылды. Чөнки С.Максуди II Дума депутаты чагында ук инде үзенең сәясәттәге юлын билгели, үзенең татар милләтенә генә түгел, бәлки бөтен Россия мөселманнарының да хокукларын яклап фикер һәм эшләре белән милләтчелек мәсләгенә хезмәт итәчәген, шуңа үзенең бар гомерен багышлаячагын әйтә[5]. Әлеге бүлектә С.Максудиның дәүләт эшлеклесе, профессиональ сәясәтче буларак биш ел буе Дәүләт думасындагы эшчәнлеген ачыкларга тырышылды. Шулай ук, аның үзенең сайлаучыларына биргән хисапнамәләре аша да, мөселман фракциясе җитәкчеләренең берсе буларак эшләгән эшләрен, тоткан мәсләген күрсәтергә омтылыш ясалды. Кыскасы, беренче бүлек XX йөз башы татар милли хәрәкәте идеологларының берсе булган С.Максудиның милли хәрәкәттәге беренче адымнарыннан башлап Россия сәясәт мәйданында исемле сәясәтчегә кадәр үсүен һәм милли хәрәкәткә идея юнәлеше бирүчеләрнең берсенә әверелүен күрсәтүгә багышланды.

Икенче бүлектә исә С.Максудиның Русиянең II–III Дәүләт думасында ясаган чыгышлары анализланды. II–III Думаларда төрле закон проектлары каралганда, кабул ителгәндә ул, мөселман халыкларының хокукларын яклап, Дума утырышларында барлыгы унбишләп нотык белән чыга. Аның ул чыгышларында шул чорда мөселман халыклары, татар милләте өчен аеруча мөһим, хәлиткеч булган мәсьәләләрне хәл итәргә тырышкан күренекле милләтченең, сәясәтченең тирән акылы, төпле белеме, дипломатиясе, шул ук вакытта үзенең, үз халкының бәясен һәм тарихтагы лаеклы урынын белүе дә ачык сизелә. Биредә аның Россиянең киң җәмәгатьчелегендә яңгыраш тапкан, бәхәсләр кузгаткан нотыкларына игътибар бирелде. С.Максудиның ул чыгышлары татар халкы, мөселман дөньясы өчен мөһим мәсьәләләр:

мәгариф, мәдәният, дини иркенлекләр турында булганга күрә, аның теге яки бу мәсьәләгә карашын ачыграк белдерү, аңлату, ачу максатыннан чыгып, II–III Дәүләт думаларында ясаган чыгышларыннан күбрәк, тулырак өземтәләр бирергә тырыштык.

Хезмәтнең өченче бүлегендә С.Максудиның татар милли хәрәкәте идеологиясен формалаштырудагы ролен ачыкларга тырышылды. Аның милләтчелек, миллият турындагы фикерләре «Йолдыз» гәзитендә басылган «Милли сөхбәтләр», «Әфкяр миллиямез», «Ике төрле милләтчелек» кебек мәкаләләре аша күрсәтелде. Биредә С.Максудиның XX йөзнең беренче чирегендә татар милли хәрәкәте идеологларының берсе буларак милли көрәш юлындагы эшчәнлегенең төп максаты, тоткан мәсләге ачыклана. Ул – милли бердәмлек, милләт бөтенлеге. Татар милли хәрәкәте җитәкчеләре Г.Исхакый, Ф.Туктаров һ.б. дан аермалы буларак, С.Максуди татар милләтен сыйныфларга бүлмичә, бербөтен милләт булып кына көрәшкә күтәрелә һәм җиңүгә ирешә алачак дип уйлый һәм шуңа ышана. С.Максуди үзенең татар милләтенә багышланган эшчәнлегендә әлеге фикеренә, ахыргача, турылыклы кала.

Биредә шулай ук С.Максудиның дини оешмаларны үзгәртеп кору һәм мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыруга булган карашларына да игътибар бирелде. Татар халкына патша хөкүмәтенең милли сәясәтенә каршы торырлык көч биргән нәрсә – ислам дине. Ислам дине татар халкын бергә җыйнап, халык итеп тоткан, борынгыдан килгән гореф–гадәтләрен саклатып, әхлак кагыйдәләренә буйсындырып яшәтүче көч булган. Әмма инде XX йөз башында Европа сәхнәсенә чыгу, икътисадта, мәдәниятта алдынгы халыклар рәтенә басу өчен дөньяви белем алу, дини мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыру һәм дини оешмаларны заман таләпләренә туры китереп үзгәртеп кору зарур була. Бу ике өлкәдә хәлиткеч үзгәрешләр ясалмаса, татар милләте алга таба үсә алмаячагын яхшы аңлаган С.Максуди үзенең әлеге фикерләрен дини оешмаларны үзгәртеп кору турындагы программасына да кертә, нигез итеп ала. Әлеге параграфта С.Максудиның шушы өлкәдәге мәсьәләләрне хәл итәргә омтылып язылган берничә мәкаләсенә

игътибар бирдек һәм аның бу мәсьәләгә карата карашларын ачыкларга омтылдык.

Дүртенче бүлектә С.Максудиның Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтариятының Милли Идарәсе рәисе буларак. Ә алдан аның Февраль революциясеннән соңгы Россиядәге сәяси, аны Милли Идарә рәисе дәрәҗәсенә кадәр җиткергән милли–иҗтимагый эшчәнлегенә күзәтү ясалды. Аның Милли Идарә рәисе буларак эшләгән эшләре анализланганда совет чоры тарихчылары тарафыннан файдаланылмаган әдәбият һәм чыганакларга күбрәк игътибар итәргә һәм шулар аша бәя бирергә тырышылды.

С.Максудиның милли хәрәкәт идеологларының берсе буларак эшчәнлегенең иң югары ноктасы – аның Милли Идарә рәисе вазыйфасын башкарды. Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты игълан ителү – ул С.Максуди тоткан мәсләкнең җиңеп чыгуы, тормышка ашуы–шул чорда С.Максудиның татар милли–азатлык хәрәкәтенә төп идея юнәлеше бирүче икәнен дә раслый.

Бу бүлектә (§ 2) шулай ук Садри Максудиның Эчке Русия һәм Себер төрек-татарларының Милли Идарәсе рәисе буларак эмиграциядәге милли-мәдәни мохтарият рәисе буларак эшләгән эшләре дә каралды, бәяләнде.

С.Максудиның милли хәрәкәттә тоткан юлы, татар милли хәрәкәтенә булган карашы һәм фикерләре аның «Ике төрле милләтчелек», «Әфкяр миллиямез» кебек мәкаләләрендә ачык чагыла. Шунлыктан, әлеге мәкаләләрне анализлап, бер параграф язылды.

Аның дини оешмаларны үзгәртеп кору һәм мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыруга булган карашларын тикшерүгә дә игътибар ителде, чөнки 1914 елның июнь аенда Петербургта ачылган Киңәш мәҗлесендә төп доклад белән чыгыш ясаучы һәм шушы зур эшнең программасын төзүче дә С.Максуди була. Татар халкының яшәешен, мәдәни, икътисади үсешен бары тик әлеге оешмаларның яңаруы, үзгәртелүе генә хәл итә алачак дигән фикердән чыгып ул әлеге мәсьәләгә зур игътибар бирә. Бу мәсьәләләрне хәл итү юлларын тәкъдим итә: үсеш, үзгәреш ничек

барырга тиеш – шушы турыда аның «Йолдыз» гәзитендә күләмле өч мәкаләсе басыла. Менә шушы мәкаләләр нигезендә С.Максудиның XX йөз башында татар халкы өчен мөһим булган мәсьәләләрнең ничек хәл ителергә мөмкинлеге турындагы карашларын ачыкларга тырыштык.

XX йөзнең беренче чирегендә татар милли–азатлык хәрәкәте идеологларының берсе булган С.Максудиның сәяси–иҗтимагый эшчәнлегенең икенче этабы – аның 1917 елның Февраль революциясеннән соң Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтариятын төзү һәм шул мохтариятнең Милли Идарәсе рәисе буларак алып барган эшчәнлеге. Бу чор, бик кыска гына булуга да карамастан, С.Максудиның сәясәтче, милли лидер буларак эшчәнлегенең иң югары ноктасы.

С.Максудиның эмиграциядәге сәяси эшчәнлеге яктыртыла. 1919–1921 елларда Франциядә вакытта ул Европа дәүләтләренә Россиядәге совет власте кул астында калган татар халкының авыр язмышын аңлатырга, шулай ук төрле мәсләктәге рус эмиграциясе белән дә берләшеп, татар халкы өчен файдасы тиярдәй эшләр эшләргә тырышып карый. Төрле мәсләктәге рус эмиграциясе дә, күп милләтле башка оешмалар да эмиграциядә бердәм хәрәкәт итә алмыйлар. Шулай да С.Максудиның эмиграциядә Милли–мәдәни мохтариятның Милли Идарәсе һәм татар милли–азатлык хәрәкәте идеологы буларак алып барган эшчәнлеге Европа дәүләтләренә Россиядә азатлыкка омтылган татар халкының, олы тарихлы халыкның барлыгын аңлатуы белән дә әһәмияткә ия.

Садри Максудиның Париждагы бу эшчәнлеге Европа сәясәтчеләре тарафыннан да, рус эмиграциясе вәкилләре тарафыннан да аның татар милли хәрәкәте идеологиясен формалаштыручыларның, ягъни бу хәрәкәткә идея юнәлеше бирүчеләрнең берсе һәм Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтариятының Милли Идарәсе рәисе буларак башкарган эшләр итеп кабул ителә.

Әлеге хезмәт С.Максудига багышланган беренче хезмәтләрдән булганга күрә, автор, С.Максудиның киң кырлы эшчәнлеге бөтен нечкәлекләре белән тикшерелде, аның хезмәтләренә һәрьяклап анализ ясалды дип дәгъва итми. Гасыр башында татар милләте

тәрәкъкыяте күгендә якты йолдыз булып янган, әмма Октябрь инкыйлабыннан соң исемен дә телгә алырга рөхсәт ителмәгән милләтпәрвәребез С. Максудиның татар милләтенә багышланган эшчәнлеген күзалларга тырышу һәм татар халкы тарихына аның исемен кайтару юлында әлеге хезмәт беренче адым дип карала ала.

## ИСКӘРМӘЛӘР

* Яңа милли юл. - Берлин, 1937. - 9 сан.

** Әңгәмәләр

*** Ф.Әмирхан. Гаяз әфәнде шәрәфенә //Кояш. — 1917, 23 апрель.

1. Садри Максуди. Миллият тойгысының социологик әсаслары. — Казан. — 1999. — 137 б.

2. 1994 уздырылган фәнни конференциядә С.Максудиның туган елы 1879 ел дип алынды, чөнки төрле документларда төрле еллар күрсәтелгән. Оныгы Гөнел ханым Пултар да, 1879 елда туган дигән фикерне яклады. Ләкин, аннан соң, яңа документлар—метрикасы табылды, ә анда туган вакыты шулай күрсәтелгән.

3. Садри Максуди (1879—1997). — Казан. — 1996. — 255 б.

   Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман. — Казан. — 1999. — 159 б.

4. Искә алынган хезмәтләрнең тулы исемлеге әлеге хезмәтнең соңында бирелгән файдаланылган әдәбият исемлегендә күрсәтелә.

5. Йолдыз. — Казан. — 1907. — 29 июль.

# I БҮЛЕК
# XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ СӘЯСИ–ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫНДА САДРИ МАКСУДИ

## § 1. Татар милләтенең сәясәттә уяна башлавы: «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелү һәм Садри Максуди

Татар халкы өчен XX йөз башы чын мәгънәсендә яңарыш чоры: ул үзен Россиядәге милли хәрәкәттә барлык мөселман халыкларының әйдәп баручысы итеп таныта. 1905 нче елгы революциянең татар милләтенең милләт буларак оешуында әһәмияте зур була. Шушы революция биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдәге мәктәп–мәдрәсәләрнең уку–укыту системасына яңа агым – җәдитчелек килеп керә, дистәләгән исемдә гәзит–журналлар чыга, йөзләгән исемдә уннарча мең тираж белән дөньяви, фәнни, әдәби китаплар басыла башлый, беренче татар театры труппалары барлыкка килә. Бу революция татар халкының мәдәни үсешен генә түгел, аның милли аңын үстерүгә дә этәргеч була. Бу чорда алдынгы фикерле тел, тарих буенча галимнәр, язучылар, шагыйрьләр татар дөньясында инде XIX гасырда туган мәгърифәтчелек хәрәкәтен алга таба үстереп, җәелдереп җибәрәләр; яңа фикерле укытучы–мөгаллимнәр барлыкка килә, татар буржуазиясе катлавы үсеп мәйданга чыга. XX йөз башында инде үсеп, көчәеп киткән татар буржуазиясе җәдитчелек хәрәкәтенә ныклы нигез сала һәм ул моның белән татар милләтенең милләт буларак икътисадта, мәдәниятта, сәясәттә үсешенә зур йогынты да ясый. Бөтен татар халкын бербөтен халык санап һәм шул халыкның мәнфәгатен кайгыртып күтәрелгән әлеге хәрәкәт халыкның теге яки бу өлешенә генә хезмәт итә алмый. Шуңа күрә дә, гомуммилләт мәнфәгатен кайгырту милләтне сыйныфларга

бүлмичә, бөтен бер милләткә хезмәт итүне таләп итә. Яшь татар буржуазиясе, 1905 елгы революция биргән әлеге мөмкинлекләрдән файдаланып, үзенең максатларын тормышка ашыру эшенә керешә. Аларның үз алларына куйган бурычлары – мәктәп–мәдрәсәләрдәге белем бирүне реформалаштыру һәм татар халкының мәдәни, икътисади тормышын Европа мәдәнияты нигезендә үзгәртеп кору. Бу эшне башлап җибәрүчеләр И.Гаспринский, Р.Ибраһимов, М.Бигиев, Й.Акчура, рухи, милли яңарышны кайнар яклаучылар Ф.Кәрими, Ш. һәм З.Рәмиевләр, Һ. һәм С.Максудилар, Р.Фәхретдинов һ.б. була.

Җәдитчеләр мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыруны гына түгел, ә ислам динен заманча аңлау, дини оешмаларны үзгәртеп коруны да кирәк саныйлар һәм шуны тормышка ашыруда зур эшчәнлек алып баралар.

XX йөзнең беренче чирегендә татар милли–азатлык хәрәкәте бер яктан, Россиянең башка рус булмаган халыкларында кебек үк, патша хөкүмәтенең социаль–экономик изүенә каршу тору рәвешендә килеп туа, икенчедән, патша хөкүмәтенең милли сәясәтенә – руслаштыру, христианлаштыру сәясәтенә каршы чыга.

Татар милли–азатлык хәрәкәте үзенең социал–сыйнфый юнәлеше белән бер төрле генә булмый. Әмма татар милләтен милләт буларак саклап калу теләге әлеге юнәлешләрнең һәммәсен бердәм милли хәрәкәт юлына туплый. Шулай итеп, XX йөз башы татар милли хәрәкәте һәм аның идеологлары, җитәкчеләренең күбесе бертулы татар милләтенә хезмәт итү юлында торалар.

Кыскасы, XX йөз башында татар халкы, үзенең югалткан данын, азатлагын кире кайтарырга теләп, кабат бер күтәрелеп карый.

Дүрт йөз елга якын элек үзенең бәйсезлеген югалткан, изелгән, кимсетелгән татар халкы, бигрәк тә аның зыялылары, Беренче рус революциясе биргән мөмкинлекләрдән, үзләренең күңелсез хәятләре күгендә ялтырап киткән кечкенә генә өмет чаткысыннан файдаланып калырга, ягъни халык өчен аз гына булса да иркенлекләр алып калырга омтылыш ясыйлар.

Самодержавиенең мөселман халыкларына, бигрәк тә татар халкына карата алып барган милли сәясәтенә каршы көрәшкә

чыккан кешеләр инде XIX гасыр ахырларында ук булгалый: шуларның иң беренчеләреннән берсе (Г.Ибраһимов әйткәнчә) – «татар буржуа дөньясының тарихи кыңгыравы» ролен уйнаган Рәшид казый Ибраһимов. Аның бунтарь җаны Россиядәге сәяси читлеккә сыймый, һәм Рәшид казый 1893 елны Төркиягә китә. Ул анда яшәгән вакытта рус хөкүмәтенең татар халкына карата явыз Иваннан башланган чукындыру сәясәтен әле дә дәвам иткәнен һәм мөселман халыкларының авыр язмышларын сурәтләгән күп санлы мәкаләләрен Мисырда чыга торган «Әл–Нил» гәзитендә бастыра, ә 1895 елны Стамбулда, шуларны туплап, «Чулпан йолдызы» исемле китап та чыгара.

Октябрь инкыйлабыннан соң XX гасыр башында татар милли хәрәкәтендә катнашкан бер төркем татар зыялыларына советчыл күзлектән бәя биргән, һәм шуның белән Сталин тираниясе елларында аларның язмышларын хәл итәргә «булышкан» Г.Ибраһимов «тарихи кыңгыравык» Рәшид казый Ибраһимов турында үзенең хезмәтләрендә берничә генә булса да объектив фикер дә әйткән: «Рәшид казый мәгълүм бер тарихи дәвернең үткән басыкычының бер көрәшчесе – кадимнән җәдидкә чыгуга алга өстерәүче буларак урын алачак» һәм «Каты йоклаган кешеләрне уятуда мондый кыңгыравыкларның роле бер дәвердә зур була. Болар, уяныгыз, дип азан кычкырып йөриләр»[1].

17 Октябрь Манифесты чыгып, җыелышлар, партияләр, диннәр, милләтләр өчен мәгълүм «азатлык» көннәре башлану – иң туңган катлауларга да җан бирде, хәрәкәт бирде, дип яза бу көннәр турында Г.Ибраһимов.

Ул көннәрдә татар халкы һәм аның зыялылары өчен көн үзәгенә куелган иң мөһим мәсьәлә – татар милләтен милләт буларак бетүдән, юкка чыгудан саклап калу була. Алар шушы 17 Октябрь манифестыннан файдаланып, бер съезд ясап, мөселман халыкларының дини, мәдәни эшләрендә аз гына булса да иркенлекләр алып калырга уйлыйлар. Татар халыкының милләт буларак яшәешен, аның гореф–гадәтләрен, динен, рухиятен саклап калу фикере ул вакыттагы татар милли хәрәкәтен барлыкка китерә, һәм бу хәрәкәтнең иң мөһим бурычларыннан беренчесе була. Бер төркем татар зыялылары татар халкына, мөселман халыкла-

рына кадерле, газиз булган милли яшәешне, дини мәнфәгатьләрне, телне саклап, үз телендә дөньяви белем алып, икътисадта, сәясәттә дөньядагы алдынгы милләтләр белән бер дәрәҗәгә күтәрелү өчен көрәшкә вакыт җитте һәм бу көрәшне башлау өчен бөтен Россия мөселманнарын берләштерүче бер партия төзәргә кирәк дигән карарга киләләр. Бу идеяның идеологы булган Йосыф Акчура «Тәрҗеман» гәзитенең мөхәррире Исмәгыйль бәк Гаспринскийга һәм азәрбайҗанлы Галимәрдән Тупчибашевка хатлар яза, алары исә бу идеяны күтәреп алалар, әмма алар да, съезд уздыру өчен, патша хөкүмәтеннән рөхсәт ала алмыйлар. Беренче съезд яшерен рәвештә 1905 елның августында Түбән Новгород шәһәрендә җыела. Съездга килгән 150 вәкил «Густав Струве» пароходын өч көнгә яллап «народное гулянье» ясыйлар: съездларын шунда уздыралар һәм шул съезда бөтен Россия мөселманнарының «Иттифак әл—мөслимин» оешмасы төзелә.. Россия мөселманнарының бу берләшүе дини принципка нигезләнә, әмма «Иттифак» оешмасы милләтләрне милләт итеп саклау өчен мөһим булган барлык мәсьәләләрне дә хәл итәргә тырышуны үзенә максат итеп куя. Бу мөселман халыкларының I съездының рәисе Исмәгыйль бәк Гаспринский, ә фикери юлбашчысы Йосыф Акчура була. (Башта «Иттифак әл—мөслимин» оешмасы буларак барлыкка килгән әлеге берлек, соңарак, үзенең II съездында (1906 ел январь) партия булып төзелә). Съезда катнашкан Г.Исхакый, Ф.Туктаровлар әлеге оешманың сәяси партиягә әйләнүенә каршы төшәләр. Алар, социал—демократлар позициясендә торучылар буларак, «Иттифак әл—мөслимин»оешмасының мәдәни берлек булуын гына таныйлар.

Үзенең сәяси карашлары белән кадетлар партиясенә якын торган һәм бу партиянең үзәк комитеты әгъзасы һәм «1905 елгы революциядә татар буржуазиясенең иң төпле сәяси юлбашчысы булган»[2] Йосыф Акчура «Иттифак әл—мөслимин» партиясенең төп идеологларыннан санала. Ул бу партиянең I оештыру съездында ясаган докладында болай ди: «Партияләр тик сыйнфый карашлардан гына килеп чыкмый. Дин—милләт байрагы астында иң куәтле бер иттифак төземәк һәрвакыт мөмкиндер. Без дә Ислам нигезләренә корылган «Русия мөселманнары иттифакы»

исемендә бер сәяси партия тудыру юлында эшләдек»*. «Иттифак әл–мөслимин» партиясе Программасының I–П пунктларында исә болай дип язылган: «Иттифак» партиясенең максуды – сәяси, икътисади, дини, иҗтимагый эшләрне төзәтмәк өчен, шушы Программа һәм заманның теләвенә муафыйк рәвештә, сәясәте бер фикердә булган һәммә Русия мөселманнарын гамәли эштә берләштермәктәдер» һәм «Русиянең һәммә кешеләренә гражданлык, адәмлек хокуклары бирелеп, мәмләкәт идарәсе Конституция нигезендә булып, ягъни мәмләкәт эшләрен башкару, мәхкәмәләрдә хөкем итү халык кулында булсын»[3].

«Иттифак әл–мөслимин» партиясенең Уставын төзүчеләрнең берсе Муса Бигиев була. Шулай итеп, Р.Ибраһимов башлап җибәреп, милләтнең тынгысыз җанлы уллары күтәреп алган эшнең беренче нәтиҗәләре күренә: үзенең Уставы, Программасы булган бөтен Россия мөселманнарының беренче сәяси оешмасы – »Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелә.

Милли хәрәкәтнең актив әгъзаларыннан булган Ибниәмин Әхтәмов «Мөселман иттифакы» партиясенә биргән бәяләмәсендә: «Мин әлеге партиягә милли мәсьәләдә бер төрле фикер йөрткән, әмма сәяси карашлары төрле булган зыялыларның бер милли–сәяси союзы дип карыйм», ди.

Рус шовинистлары тарафдары булган «Казанский телеграф» гәзите дә бераз соңрак: «Бу партия үзенең программасы һәм сәяси йөзе белән үзенең юлбашчылары: Галиевләр (Г.Баруди), Максудовлар (Һ. һәм С. Максудилар), Г.Сыртлановлар, Р.Ибраһимовлар безнең кадетларга охшаган. Алар ачыктан–ачык эш итәләр: аларның Россиянең татарлар яши торган барлык регионнарында да комитетлары бар», дип язарга мәҗбүр булачак[4].

«Иттифак әл–мөслимин» партиясе иске тормышны нигезеннән җимереп ташларга чакырмый, ул бер сыйныфны икенче сыйныфка каршы кораллы, канлы көрәшкә әйдәми, ә бары тик мөселман халыкларының яшәешләрен, милли гореф–гадәтләренә буйсындырып, үзара тату, ярдәмләшеп яшәү юлы белән генә үзгәртү, яңарту, үстерүне яклый. Бу партия конституцияле монархия тарафдары була.

Шау итеп, дөнья туздырып иске мәгыйшәтне бетерү, динне дә, милләтне дә, милекне дә инкярь итү лязем түгелдер, дип яза С.Максуди соңрак.

«Иттифак әл–мөслимин» партиясе үзенең программасында «шәхси милек кагылгысыз» дип игълан иткәч, социаль–демократик «Урал» гәзите аның турында «чалмалы һәм түбәтәйле кадетлардан торган партия» дип язып чыга һәм бу партиядән ярлы халыкка бер файда да булмаячак, ди. Исмәгыйль бәк Гаспринский, Йосыф Акчураның чакыруы буенча «Иттифак» партиясенең 1906 елның 16–20 августында уздырылган III съездында әле генә Франциядән кайтып төшкән Садри Максуди да катнаша һәм Р.Ибраһимов, Й.Акчура, С.Алкин, И.Гаспринский, Г.Баруди, М.Бигиев, Г.Буби, Һ.Максуди, А.Топчибашевлар белән бергә бу мәҗлеснең сәясәт комиссиясендә эшли.

С.Максуди «Иттифак» партиясенең III съездында 15 кешедән торган Үзәк Идарәсенә сайлана. Идарә составында шулай ук Р.Ибраһимов, Й.Акчура, С.Алкин, И.Гаспринский, Г.Баруди, М.Бигиев, Г.Буби, Һ.Максуди, Г.Толчибашевлар була. Татар милләтенең һәртөрле яктан яңарышы бары тик дини голамәсенең һәм зыялыларының бердәм хәрәкәте белән генә мөмкин булачагына нык ышанган С.Максуди мәҗлеснең сәясәт комиссиясендә җиң сызганып эшли: Европадагы милли сәясәт һәм андагы вөҗдан иреге, мәдәни иркенлекләргә ирешүдә андагы халыкларның, дәүләтләрнең тоткан сәясәте турында җентекләп сөйли, аңлата һәм съездның да шул югарылыктан торып эш итәргә, үзенең киләчәккә эш планын да Европа дәүләтләре тәҗрибәсенә таянып төзәргә чакыра.

«Русиядә монархчы сәясәт җәһәтеннән бик артта калган мөселман халыклары да беренче тапкыр үзләренең сәясәт ягыннан уяна башлаганнарын күрсәттеләр: дине, теле, яшәеше бер булган төрки халыклар үзләренең мәнфәгатьләре дә бер булганны рәсми игълан иттеләр, ягъни Н.Новгородта җыелган бу мәҗлес сәясәттә бала булган милләтебезнең беренче эшедер»[5], дип яза С.Максуди үзенең «Милләтнең вөҗданы» дигән мәкаләсендә әлеге партия төзелүгә гаять зур бәя биреп. Ләкин, «Иттифак» партиясен оештыручыларның берсе – Г.Топчибашев күпме генә тырышса да,

партияне рәсмиләштерә алмый. Әмма шуңа да карамастан, «Иттифак» партиясе һәм аны оештыручылар милли хәрәкәтнең лидерлары һәм идеологларына әвереләләр.

Татар зыялыларының бер өлеше либераллар «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелүне татар милләтенең сәяси аңы уянуда беренче адым дип санасалар, икенче – радикаль өлеше исә аны «җирсез авыл халкы һәм эшчеләр өчен фәкать зарарлы бер партия», диләр. Шулай ук Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Вахитовлар да әлеге партиянең сәяси платформасын кабул итмиләр. «Таңчы»лар лидеры булган Гаяз Исхакый исә III съезда: капма–каршы сыйныфларга бүленгән мөселманнар бер партиягә керә алмый, дип бик кискен төстә усал чыгыш ясый. Әмма ул, соңрак, фикерен үзгәртә: татар халкы, сыйнфый бүленешенә карамастан, дин һәм мәдәнияттәге эшләрен хәл итү өчен берләшә ала, дип саный. Фатих Әмирхан да әлеге съезда, шәкертләр оешмасы исеменнән, бу сыйнфый берләшүне гаепләп чыга.

Боларга җавап итеп «Йолдыз» гәзитенең 1907 ел, 3 октябрь санында басылган «Миллият вә социализм» дигән мәкаләдә: «Социализм бик гади бер фикердер, әмма мин социалист дип йөрүчеләрнең бергә җыелып, шул фикерне раслап, үзләренчә – социалистларча мәгыйшәт итеп күрсәткәннәрен белмим /Германиядә генә булса да/», диелгән.

1907 елда «Иттифак әл–мөслимин» партиясе съездларының хисап дәфтәре, ягъни Муса Бигиев алып барган беркетмәләре басылып чыга. Г.Ибраһимов, соңрак, М.Бигиевнең әлеге эшчәнлегенә зур бәя биреп: «Татар буржуазиясенең сәяси–иҗтимагый хәрәкәтләре тарихын язучы бердәнбер мөхәррир – Муса әфәндедер»[6], дип язачак. С.Максуди үзенең «Милләтнең, вөҗданы» исемле мәкаләсен шуңа таянып, милли хәрәкәтнең башында торган, бу партиянең асылын тәшкил иткән татар зыялылары һәм аларның сәясәттә, милли мәгарифтә, мәдәнияттә тоткан кыйблаларын татар халкына аңлатырга теләп яза. Ул съезд беркетмәләренең аерым китап булып басылып чыгуын «Иттифак әл–мөслимин» партиясенең төзелүен бөтен Россиягә белдерү, ягъни «моңарчы сәяси җәһәттә бала хәлендә булган телсез, чукрак төрки вә мөселман кабиләләренең беренче тапкыр теле чыгуы»[7], дип бәя-

ли. «Әлеге китапны чыгарып алар бу эшләре белән Русия мөселманнарының сәясәт җәһәтеннән хәбәрдар булганлыкларын күрсәттеләр, ягъни моңа кадәр бер–берсеннән хәбәрсез яшәгән, әмма дине, каны бер булган төрки кабиләләрне бер–берсенә якынайттылар, дине, яшәеше бер булган бу халыкларның мәнфәгатьләре дә бер булганны рәсми игълан иттеләр. Съезда сөйләнгән сүзләр моңа кадәр сәясәттә бала булган милләтемезнең беренче эшедер, ә хисап дәфтәре исә милләтемезнең яңа тумыш «Вөҗдан сәясинең көзгеседер»[8], дип яза ул үзенең әлеге мәкаләсендә.

Партия төзелүне озак еллар буе ярым уяу, ярым йокылы хәлдә яшәгән, буйсындырылган, кимсетелгән мөселман халыкларының, бергә җыелып, беренче мәртәбә Русия патша хөкүмәтенә, аның хаким милләтенә иксез–чиксез Русия дигән дәүләттә егерме миллионлы мөселман халыклары яшәгәнне, аларның да башка халыклар кебек бертигез хокуклар алып, Русиянең тулы хокуклы гражданнары булып яшәү теләкләре барлыгын белдергән беренче сәяси чыгышлары булганга, С.Максуди үзенең әлеге мәкаләсендә «Иттифак әл–мөслимин» партиясенә һәм аның съездларында күтәрелгән мәсьәләләргә югары бәя бирә. Чөнки киләчәктә мөселман халыклары үсешенең нигезе булып торган тел, тәрбия һәм уку–укыту, сәясәт, икътисад, җир мәсьәләләрен хәл итү партиянең Программасына кертелгән була, ә съезд мәҗлесләрендә бу мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзләү буенча кайнар бәхәсләр куба.

Шулай итеп, ничек кенә булмасын, «Иттифак әл–мөслимин» партиясе үзенең барлыгын бөтен Россия халыкларына игълан итә һәм милләт тәрәкъкыяте юлындагы эшчәнлеген, бер сәяси калыпка салып, башлап җибәрә.

Татар зыялылары үз милләтләренең һәм гомумән, мөселман халыкларының динен, мәгарифен, мәдәниятен, яшәешен тәрәкъкый итүне аның руханиларына бәйләп карыйлар. Ә моның сәбәбе шунда: халыкның динен, телен саклауда, мәгарифен үстерүдә гасырлар буе төп рольне уйнаган һәм уйнарга тиеш булган имамнар үзләре дә заманча тәрәкъкыйпәрвәр булырга тиешле. «Мөстәкыйль милләт эчендә мәгариф берничә юл белән тарала ала, ләкин мәхкүмә милләтләрдә моның өчен мөһим шарт – имамнарның тәрәкъкыедыр. Безне берләштергән, алга барырга

мәҗбүр иткән иң мөкаддәс нәрсәләрнең берсе – динебез исламияттер, телебездер. Иң мөһиме, иң куәтлесе динебез исламияттер, ә исламиятнең төп тәгълиме исә имамнарыннандыр»[9]. Дөньядагы башка хаким милләтләр рәтенә басу, Россиядәге рус милләте белән бертигез яшәү хокукларын яулау мәгарифтә яңарыш, үсештән башка булмаячагын яхшы аңлаган С.Максуди, «Иттифак әл–мөслимин» партиясе әгъзасы буларак, аның Программасының иң мөһим пунктларын тормышка ашыруны үзенең Россия Дәүләт думасы депутаты буларак алдагы сәяси, милли эшчәнлегенә төп максат итеп куячак.

С.Максуди, милли хәрәкәткә кушылган татар зыялыларына, аларның нинди сәясәт тотуларына карамастан, тирән ихтирам белән караган дисәк тә ялгышмабыз, чөнки әлеге мәкаләнең исеме дә «Милләтнең вөҗданы» дип атала. Димәк, татар халкының милләт буларак киләчәге, язмышы, милли бәйсезлек өчен көрәш юлына басуы да шушы «Милләтнең вөҗданы» булган милләтпәрвәрләр кулында. Шушы фикеренә нык ышанган С.Максуди үзенең озын мәкаләсендә милләт тәрәккыяте юлында хезмәт итүче бу зыялыларны, сәяси кыйблаларыннан чыгып, дүрт төркемгә бүлеп карый. (1906 елдан башлап 1919 елларга кадәр, алга таба исемнәре еш телгә алыначак бу бер төркем зыялыларны нинди мәсләк тотуларына, бер–берсенә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, аларның һәркайсы, үзләре булдыра алганча, ягъни белемнәре, сәләтләре, йөрәкләре кушканча татар милләтенә хезмәт иткәннәр. Аларның күбесе, хәтта эмиграциядә дә, үзләренең мәсләкләренә хыянәт итмәгән, татар халкының бәйсезлеге, азатлыгы өчен көрәшүдән туктамаган).

С.Максуди үзе беренче төркемгә керткән милләтпәрвәрләрне «алкышлап, белемпәрвәр голамәдер» дип бәяли. Гарәпчә, фарсыча, бераз урысча да белгән бу зыялыларның «өмидләрендә нур бардыр», ди. Шушы төркемгә кертелгән Һ.Атласи дин һәм мәктәп эшләрендә русларны катнаштыруга, ягъни мәктәп–мәдрәсәләрнең Россия мәгариф министрлыгы карамагында булуга каршы чыга, ул безнең үз эшебез, ә менә хокук мәдәниятендә без руслар белән бергә эшләрбез, ди. Икенче төркемгә С.Максуди Фуад Туктаров белән Гаяз Исхакыйларны кертә һәм аларны бу төркемнең «иң

гаяр егетләре» дип атый. Үзләрен «без халык тарафдарлары» дип игълан иткән социалистларның әсасы бөтен җәмгыять инсаниянең хәяте, сәяси, икътисади хәлен яхшыртырга тырышудан гыйбарәттер. Алар милләтнең һәр эшенә социализм ноктаи назәреннән карап сөйлиләр, боларда социалистлык бер мәсләктер, болар яңа бер мәсләккә хезмәт итмеш бер нух ихласлы мөридләрдер»[10], ди ул алар турында. Татар инкыйлаби–демократларының иҗтимагый идеалы эволюциясе тарихын өйрәнүче галимнәрдән булган Т.Р.Камалов үзенең монографиясендә «Таңчы–эсерлар» «Иттифак әл–мөслимин» партиясенең икътисади һәм сәяси программасын бик кискен рәвештә кире кагалар, әмма милли мәдәният, тел, мәгарифне үстерү мәсьәләсендә аның белән теләктәш булалар», дип билгеләп үтә[12].

С.Максуди фикеренчә, өченче төркемгә керүчеләр исә икътисадны үстерүне беренче урынга куялар, шуннан соң гына милли–мәдәни мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкин булачак, дип исәплиләр. Соңгы, дүртенче төркемгә кергән милләтпәрвәрләрне С.Максуди икегә бүлә. Боларга ул русча яхшы белем алган, ләкин үз милләтенең телен, әдәбиятын, исламиятен белмәгән зыялыларны һәм милли әдәбиятны, телне дә яхшы белгән милләтпәрвәрләрне кертә. Әмма болар арасында белеме Европа, дөнья белеме дәрәҗәсендә булган, сөйләме гүзәл, фикеренең мөкаммәл булуы белән, үзенең гаять әсәсле бер милләтпәрвәр булганлыгы белән Йосыф Акчураның аерылып торганлыгын басым ясап әйтеп үтә. С.Максуди С.Алкин белән И.Гаспринскийны да шушы төркемгә кертә.

Күренә ки, С.Максуди үзенең мәкаләсен «Милләтнең вөҗданы» булган һәм татар милли хәрәкәтенең башында торган татар зыялыларын, милли яңарыш өчен көрәш юлында нинди мәсләктә булуларына карамастан, бердәм хәрәкәт итәргә чакырып, шуңа өметләнеп язган.

Бөтенроссия мөселманнарының «Иттифак әл–мөслимин» партиясен төзү – ул гасырлар буе кимсетелеп яшәгән мөселман халыкларының Россия патша хөкүмәтенә, аның хаким милләтенә «Русиядә без дә бар, без дә сезнең кебек үк хокукларга ия булырга тиешбез», дигән сүз була. Россиядәге егерме миллионлы

мөселман халыкларының, беренче Рус революциясе биргән иркенлекләрдән файдаланып, сыйнфый каршылыкларга карамыйча, төрки дөньяны байга–ярлыга бүлмичә, бер партиягә тупланып беренче мәртәбә сәясәт мәйданына чыгулары иде. Әлеге хәл бер яктан патша хөкүмәтен, рус шовинистларын борчуга сала, икенче яктан татар большевиклары һәм «таң»чылары да, үзләренең мәнфәгатьләреннән чыгып, бу берләшүгә кискен каршы төшәләр. Үз вакытында да, соңыннан да төрле кимсетүләр, тәнкыйть сүзләре ишетүгә карамастан, «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелү – XX йөз башы татар милли хәрәкәтенең юл башы дисәк тә дөрес булыр. Бу партиянең III съездына җыелган татар зыялылары милләт тәрәккъыяте өчен көрәшне алып барачак көчләрне барлыйлар, нәтиҗәдә, алар үзләренең шактый сәяси көчкә ия булганнарын аңлыйлар. Чөнки Бөтенроссия мөселманнарының «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелү ул, беренчедән, моңарчы Россия тарихында күрелмәгән сәяси вакыйга булса, икенчедән, әлеге партия мөселман халыкларының, бигрәк тә татар халкының XX йөз башында барлыкка килгән милли хәрәкәтенә юнәлеш бирүче көч тә әле ул. Шулай итеп «Иттифак» партиясе төзелү, аның Программасы, Уставы кабул ителү – татар милли хәрәкәтенә көчле сәяси җитәкче орган, идея җитәкчелеге бирә. Әмма, шул ук вакытта, татар милли хәрәкәтендә ике агым – «иттифакчылар» һәм «таңчылар» – ике идеология барлыкка килә. 1917 елга кадәр татар милли хәрәкәте ике агым булып барды һәм шушының белән үзен көчсезләндерде. «Иттифак» партиясе программасын милли көрәш программасы итеп алучылар – либераль агым – буйсындырылган, дәүләтчелеге юкка чыгарылган татар халкы өчен иң төп мәсьәлә булып милли тигезлек мәсьәләсе тора дип чыгалар. Алар, сыйнфый аерымлыкларга карамыйча, ике капма – каршы лагерьга бүленмичә, дин, мәктәп, мәгариф өлкәсендәге мәсьәлә – бурычларны хәл итү өчен бергә тупланып, милли бөтенлекне саклап, бердәм милләт булып эш итәргә, көрәшергә чакырдылар. Милләтнең икегә бүленүе милли көрәшне көчсезләндерүгә китерәчәк, диләр.

Ә «таңчылар» – радикаллар исә Россиядәге барлык милләтләр өчен уртак булган социаль тигезсезлек мәсьәләсенә өстенлек бир-

деләр һәм сыйнфый көрәш мәсьәләсен күтәрделәр. Милли көрәштә уртак тел таба алмау милли–азатлык хәрәкәтенә зур комаучаулыка итә. Дөрес, соңыннан татар эсерларының лидерлары (Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Ш.Мөхәммәтьяров) революцион эшчәнлектән читләшәләр һәм милли хәрәкәткә киләләр, милли–азатлык хәрәкәтенең лидерларына әвереләләр. (Партия, сәяси оешма буларак, 1914 елда үзенең эшчәнлеген туктата. Шушының белән татар милли хәрәкәтенең милли-демократик этабына нокта куела. Шушы вакыттан башлап, татар милли хәрәкәте милли–азатлык этабына күчә башлый). Татар милләте, мөселман халыкларының киләчәге өчен зур эшләргә өметләнгән, шуңа омтылган «Иттифак әл–мөслимин» партиясе үзенең III съездында Исмәгыйль бәк Гаспринский, Галимәрдән Топчибашевларның тәкъдиме белән С.Максудины Россиянең II Дәүләт думасына Казаннан депутатлыкка кандидат итеп күрсәтә. «Бала вакытларымнан бирле күңелемдә булган бөтен хәятемне, бөтен гомеремне Русиядәге мөселман кардәшләремнең тәрәкъкыятенә сарыф итү фикере бу сайлау кичәсендә бигрәк тә арткан иде»[13], дип язачак ул үзе соңыннан.

«Садреттин әфәнде милләтемезгә чын күңелдән хезмәт итәчәк бер фазыл адәмдер. Думага китәргә хокуклы иң лаеклы кешеләремезнең беренчеседер», дип яза Г.Камал «Быел Думага кемнәрне сайлыйбыз?»[14] дигән мәкаләсендә.

## § 2. Русиянең III Дәүләт думасында Мөселман фракциясе җитәкчеләренең берсе буларак Садри Максудиның милләтчелек мәсләгенә итәчәк хезмәтенең беренче адымнары.

Россиянең II Дәүләт думасы 1907 елның 20 февралендә ачыла һәм үзенең эшчәнлеген шушы елның 3 июненә кадәр генә дәвам итә ала: Дума патша тарафыннан таратыла.

С.Максуди үзенең сәяси карашлары белән кадетларга якын тора, ул Думадагы бу партия вәкилләренең күбесе белән якыннан таныш һәм аларның эшчәнлекләренә җылы караштa була, шунлыктан кадетлар белән бергә эшләргә мөмкин булыр дип уйлый. (Бәлки, аның бу карашларына дусты Йосыф Акчураның

кадетларга якын торуы да да тәэсир иткәндер). Әмма шулай да С.Максуди сәяси, милли мәсьәләләргә кагылышлы закон проектлары тикшерелгәндә тел, мәгариф, мәдәният һәм дин эшләре буенча законнар хәзерләнгәндә «Иттифак әл—мөслимин» партиясе программасыннан чыгып эш итә.

II Думага бөтен Россия мөселманнары исеменнән барлыгы утыз биш депутат сайланган була. «Бу Думадагы утыз биш депутатны бергә хәрәкәт итәргә торган куәт булмады. Икегә бүленеп Галимәрдән Топчибашев[15] рәислегендә «Мөселман фракциясе» төзелде һәм алты мөселман депутаты «Мөселман хезмәт таифәсе» исеме астында русларның трудовиклары химаясы астына керде. Мөселман фракциясе «Иттифак» программасын, «Мөселман хезмәт таифәсе» рус трудовиклары программасын кабул итте»[16]. С.Максуди Мөселман фракциясе исеменнән В.А.Харламов, Ф.А.-Головин, М.Е.Березин, Н.Н.Познанский, С.Н.Салтыков, М.В.Челноков, Л.В.Карташов, В.Н.Успенскийлардан торган Дума Президиумына секретарь итеп сайлана. С.Максудиның, Россия югары катлау җәмәгатьчелегенең элитасын тәшкил иткән аксөякләре белән бер дәрәҗәгә куелып Президиумга сайлануы II Думаның, чыннан да, күпмедер демократик рухлы булганлыгы дәлилли торган бер факт. Бәлки, шуңа да, С. Максуди Думада төп рольне уйнаган кадетларга ышаныч һәм хөрмәт белән карагандыр. «Россия Дәүләт думасының Президиумына бер татар депутаты сайлау мөселман халыклары өчен бик әһәмиятле булса да», дип яза Усал М—Ф. үзенең I–II–III Дума депутатлары турындагы инде телгә алынган китабында: «...эшлекле кешеләр булса, байтак файда чыгарып буладыр иде, әмма безнең депутатлар моннан файдалана алмадылар, бу вазыйфага сәләтсез адәмнең (С.Максудиның — Ф.Г.) хата сайлануыдыр, икенчедән, мөселман депутатларының мәмләкәт вә сәясәт хезмәтләренә сәләтсезлекләреннәндер»[17], — ди.

Думага, бөтен Россия халыклары тарафыннан депутатлар сайлау патша хөкүмәтенең үзе өчен генә түгел, бөтен Россия җәмәгатьчелеге өчен дә зур яңалык һәм прогрессив күренеш булган. Патша хөкүмәтенең бу демократия уенын чынга алган мөселман халыклары да рухланып, Думага үз араларыннан бай, исемле кешеләрне сайларга тырышканнар. Ләкин, нәтиҗәдә, II Думага күбе-

сенчә, имамнар, русча белмәгән сәүдәгәрләр сайланган. Шулай итеп, Петербургның П Думасы мәҗлесләре барган зиннәтле сараеның зур залында фраклы аксөяк депутатлар белән бергә чалмалы, түбәтәйле мөселман депутатлары да утырган һәм алар, үзләренең кулларыннан килгән кадәр, Дума эшләренә катнашканнар. Ә алар арасында иң укымышлысы һәм сәясәттә дә иң «өнлесе» булган С.Максудига бирелгән бу бәяне «таңчы» эсерларның үзләре кабул итмәгән «Иттифак әл–мөслимин» партиясе программасы нигезендә эш йөртүче депутат буларак, аның хаксызга кыйналуы дип аңларга кирәк.

Мөселман фракциясе II Думага өч ай эчендә ике закон проектына өстәмәләр хәзерли, шуларның берсен, ягъни Җомга көнен бәйрәм итү турындагысын хәзерләүдә Й.Акчура белән Г.Топчибашев зур эшчәнлек күрсәтәләр.

Думага утыз биш мөселман депутаты сайлау белән канатланган мөселман зыялылары, «Иттифак әл–мөслимин» партиясе әгъзаларының кайберләре Петербургка киләләр, фракциянең мәҗлесләренә катнашалар һәм алар фракциянең эшенә мөмкин кадәр ярдәм итәргә тырышалар. Ф.Туктаровча әйтсәк: «Мөселман депутатлары тирәсендә камчат бүрекле вә якасыз толыплы, Төмән вә Троицк ягыннан башлап, билендә киң каешлы, тишек чалбарлы, төпсез итекле мөселман эсерларына кадәр була. Монда Русия мөселманнарының һәммә сыйныф вә партияләреннән вәкилләр җыелганнар вә гомуми милләтнең файда вә хаҗәтләрен киңәшә вә сөйләшә иде»[18]. Халыкны да Дума һәм аның эшчәнлеге белән таныштыру, андагы күтәрелгән проблемаларны, бу проблемаларның Думада ничек хәл ителүен, мөселман депутатларының Думада ничек эшләүләрен халыкка аңлату максатыннан чыгып, «Мөселман хезмәт таифәсе» исеменнән 21 нче апрельдән башлап Дума депутаты Кәлимулла Хәсәнов нәширлегендә һәм аның редакторлыгында атналык «Дума» гәзите чыга башлый һәм аның барлыгы алты саны чыгып кала. (Гәзит II Дума куылганнан соң Петербург градоначальнигының әмере белән ябыла, редакторы К.Хәсәнов хөкемгә тартыла).

«Дума» гәзите Думаның килешүчән табигатьле сәясәтен тәнкыйтьли, аның хәзерге хөкүмәтнең чикләнмәгән сәяси тәэси-

ре астында яшәвен һәм бары тик киңәш хокукына гына ия булуын билгеләп үтә[19]. Бу гәзитнең үзе турында исә Г.Ибраһимов «Таң» туктагач, сүгенергә урын тапмый йөргән Фуад Туктаровка Садри Максудины эт итеп сүгеп мәкалә язарга урын булып торды», – дип язачак. «Дума» гәзите бюрократиянең, самодержавиенең кара якларын түгел, әнә шул И.Гаспринский, Й.Акчура, С.Максуди, Ф.Кәрими кебек татар буржуазиясенең каләмле–исемле идеологларын сүкте»[20], диячәк.

Әмма ничек кенә булмасын, әлегә II Дума бик демократик кылана: мөселман депутатларының барысы да диярлек Думадагы төрле комиссияләрдә үз фракцияләренең интересларын якларга җыеналар.

С.Максуди да Думада берничә комиссиягә әгъза булып сайлана. Ул кавказлы Х.Хайский белән бюджет комиссиясенә һәм үзе иң мөһим санаган «Диндә хөррият вә иркенлек эшләрен карар өчен» төзелгән комиссиягә керә. Шушы комиссиядә уңышлы эшләргә теләп ул «Йолдыз» гәзитенең 13 апрель санында «Барча мөселман кардәшләргә хат» белән чыга. С.Максуди, үзенең әлеге хатында барлык мөселманнарга мөрәҗәгать итеп, бу комиссия алдында торган иң төп җиде бурычны күрсәтә һәм шушы эш–бурычларны тормышка ашыру өчен «өч кешенең генә гакылы җитәрлек түгел» дип, бөтен Россия мөселманнарының үзләренә ярдәм итүләрен сорый. Россия законнарындагы диндә кысу турындагы һәм мөселман булган өчен генә дин ягыннан җәбер–золым күрү хакындагы мәгълүмәтләрне җыю кирәклеген һәм илдәге хәлләрне күзаллаганда, закон проектлары төзегәндә, тәкъдимнәр, өстәмәләр керткәндә үзләренең шул фактларга таянып эш итәчәкләрен аңлата. Шул рәвешчә Россиядә барлык мөселманнарны үз язмышларына битараф калмаска, үз милләтләренең киләчәге турында уйларга чакыра, аларда сәяси фикерләүне үстермәкче була.

Шулай да, С.Максуди кыска гомерле II Дәүләт думасының 15 май көнге мәҗлесендә Россия мөселманнарының мәктәп–мәдрәсәләренең аяныч хәле турында чыгыш ясарга өлгерә. Ул үзенең әлеге нотыгы белән патша хөкүмәтенең мөселман мәгарифенә карата үткәрелгән сәясәтенә каршы чыга. Бу – мондый юга-

ры дәрәҗәле мәҗлестә мөселман халыкларының, шул исәптән татар халкында хокукларын яклап, патша хөкүмәтенең милли сәясәтенә каршы ачыктан–ачык ясалган беренче чыгыш була. Мөселман халыклары арасында иң укымышлысы, иң алдынгысы булган татар милләтенең инде бу вакытта бары Оренбург духовное собраниесенә буйсынган өлешендә генә дә 6.000 ләп мәктәп–мәдрәсәләре булган. Моңа кадәр мәхәллә халкы тоткан мәктәп–мәдрәсәләр хөкүмәт карары белән 1873 елда Россия мәгариф министрлыгы карамагында бирелә, ләкин бу мәктәп–мәдрәсәләргә дә, халыкка да файда китерми. Мәгариф министрлыгы әлеге мәктәп–мәдрәсәләрне тоту өчен үз бюджетыннан бер тиен акча тотмый, хәтта шәһәр һәм земстволарга бирелергә тиешле акчаны да, әлеге мәктәп–мидерәсәләрдә русча укытылмаган өчен дип бирми. Мәшһүр Победоносцев үткәргән сәясәт буенча, әгәр әлеге мәктәп–мәдрәсәләрдә рус теле укытылмаса, яңаларын ачарга рөхсәт ителми.

Һәм менә инде II Думада тәгълим гомуми (гомуми белем) хакында закон проекты карала. Россиядәге барлык халыкларның уку системасына рус теле укытуны кертү турындагы әлеге закон проектын тикшергәндә, С.Максуди: һәр кавемнең балалары мәктәпләрдә үз ана телләрендә белем алырга тиеш, чөнки һәр кавемнең үз телендә укуның файдалы булуы турында дөньяның атаклы педагоглары тарафыннан гомуми кабул ителгән фикер бар, дип чыга.

«Без, мөселманнар, рус кавемен һич дошман күрмибез. Рус бюрократиясе илә рус кавеме арасында аерма барлыгын бик аңлыйбыз. Рус телен укытмаска, белмәскә димибез. Рус теле безгә мәмләкәт теле булганы өчен генә түгел, бәлки гыйлем вә мәгарифкә бер юл булуы өчен дә ляземдер. Хәзер тәгълим гомуми хакында закон хәзерләгәндә мин һәркайсыгыздан Русия дәүләте фәкать руслардан гына гыйбарәт булмыйча, бәлки бик күп төрле кавемнәрдән торуын хәтерегездән чыгармасагыз иде дим»[21], ди.

Кадетлар тарафыннан бик җентекләп тикшерелгән әлеге закон II Думада эшләнеп бетмичә кала. Думада кадетлар «эшнең хуҗасы»[22] булып җитә алмасалар да, монда алар «беренче скрипка»[23] булалар. Үзе дә карашлары белән кадетларга якын торган

Садри Максуди, мөселман халыкларына кагылышлы булган закон проектлары тикшерелгәндә, кадет депутатларның мөселманнарга каршы тавыш бирмәүләренә ирешә. Бу исә аңарда кадетларга карата, башка партия вәкилләреннән аермалы буларак, төрле закон проектларын тикшергәндә, кабул иткәндә, мөселман халыклары интересларын яклап тавыш бирерләр, алар ярдәме белән кирәкле законнарны үткәреп булыр дигән өмет тә уята.

«Патша хөкүмәтенең халыкка каршы алып барылган сәясәтен каплар өчен генә җыелган»[24] II Дума бары тик берничә ай гына эшләп кала. Зур эшләр эшләргә өметләнеп, эйфориягә биреләп, патша хөкүмәте мөселман халыклары белән дә исәпләшергә мәҗбүр булды, дип матур хыялларга чумган утызлап мөселман депутатын эченә алган һәм яңа гына төзелеп беткән, әле үз кыйбласын ныклап билгеләргә дә өлгермәгән Мөселман фракциясе татар большевиклары, «таңчы»лары тарафыннан да ачы тәнкыйть утына тотыла, эшсезлектә, наданлыкта гаепләнә. II Дума эшләгән айларда Петербургта чыга башлаган «Дума» гәзите бу өлкәдә барысыннан да уздырып җибәргән, күрәсең, «Йолдыз» әлеге гәзитне чыгаручы элеккеге «таңчы»ларга үзенең бер санында үтергеч характеристика биреп, түбәндәгеләрне яза:

«Бу дүрт кеше чыгарган «Дума» гәзитендә кешегә тимичә, сүгенмичә язылган бер мәкалә дә булмады. «Дума» гәзитенең асыл язучылары Петербургта эшсез йөргән берничә иске «таңчы»лар иде. Бу «таңчы»лар милләтемез өстендә үскән ашарга ярамый торган кызыл гөмбәдер. Әгәр дә бу хәл туктатылмаса, бу сәбәптән милли хәрәкәтемезгә зарары булуы ихтималдыр»[25].

С.Максуди үзенең депутатлык вазыйфаларына бик җаваплы карый. Ул, Дума таратылганнан соң, үз сайлаучыларына II Дәүләт думасында эшләгән эшләре хакында хисап бирә, чөнки ул депутат булып сайланганда аларга дүрт төрле эш эшләргә вәгъдә иткән була. Алар түбәндәгеләр:

«1. Мөселман фракциясе булып һәрбер мөселман депутатларының бергә оешып эш күрүләренә ирешү.

2. Мөселманнарга зарарлы кануннарның чыгуына каршы тору.

3. Мөселманнарга кирәкле эшләрне, кануннарны Дума аркылы чыгарырга тырышу.

4. Җае чыкканда, мөнәсәбәте килгәндә гомуми мәсьәләдә, бигрәк тә мөселманнарга гаид мәсьәләләрдә Дума мөнбәреннән сөйләү»[26].

С.Максудиның беренче вәгъдәсе: төрле яктан килгән мөселман депутатларын бергә оештырып, бергә эшләү була, чөнки, аның фикеренчә, мөселманнар бергә оешып гамәл кылмасалар, аларга илтифат итмәсләр, аерым мөселман депутатларының сүзләре игътибарга алынмас. «Куәт берлек вә иттифакта гына», ди ул.

«Фракциябездә иң күп хезмәт иткән, милләтне чынлап сөйгән, хакыйка хезмәт иткән адәмнәр шулкадәр аздыр», – дип ачынып яза ул соңыннан үзенең «Хисапнамә»сендә. Әмма, шулай булуга да карамастан, фракциянең тырышлыгы белән Думада булган һәр комиссиягә алар бер–ике кеше, ә инде иң зур комиссия булган Җир эшләре комиссиясенә хәтта биш мөселман депутаты кертә алалар. С.Максуди үзе мөселман халыклары өчен иң мөһим комиссия дип дин эшләре комиссиясен саный, чөнки башка комиссияләр барлык милләтләр өчен дә гомуми булган эшләрне тормышка ашыру өчен тырышсалар, бу комиссиянең эшчәнлеге исә бары тик мөселман халыкларының гына мәнфәгатенә кагыла. Комиссиянең рәисе итеп, Г.Топчибашев сайлана. «Аның бу комиссиядә эшләгән эшләре мөселманнар тарафыннан һичбер вакытта онытылырга тиеш түгел»[27]. Комиссия әгъзалары булып кыргызлардан Каратаев, Уфадан Тукаев, Казаннан С. Максуди керә.

Өченче вәгъдәсе: мөселманнарга зарарлы булган кануннарны бетереп, файдалыларын чыгару өчен тырышу. Болар арасыннан берсе – Төркестан мөселманнарын сайлау хокукларыннан мәхрүм иткән законны юкка чыгару булса, икенчесе – мөселманнарга Җомга көнне ял итү хокукын алу. Дүртенчесе: «Мөселманнарга гаид булган законнар файдасына тырышу», ягъни Думада тәгълим гомуми мәсьәләсе күтәрелгәч, С.Максуди: «Мин һәр милләтнең үз телендә укуның кирәклеге хакында французча язылган хезмәтләрдән мисаллар китереп, Русия мөселманнарының хәлен тәсхих итәргә багышлаган идем», ди. «Безгә үз телемездә тәгълим гарыз бер шәйдер. Үз телемездә тәгълимне кире кагуны без бер мөкатдәс нәрсәне кире кагу дип караячакбыз», дип чыга.

II Дәүләт думасы депутаты буларак, мөселман халыкларының хокукларын яклап үз сүзен әйтергә тырышкан С.Максуди, Дума таратылгач, үз өстеннән, депутат буларак, барлык вазыйфаларны төшергәннән соң да, милләткә хезмәттә кала һәм үзенең тотачак юлын, кыйбласын билгеләп болай ди: «Онытмагыз, даими милләт хезмәтеннән чыкмаячакмын. Казан губернасы өчен генә түгел, бәлки бөтен Русия мөселманнарының файдасына кулымнан килгән кадәр фикерем илән милләтчелек мәсләгенә һәрвакыт хезмәт итәчәкмен, чөнки милләтемезнең, халкымызның баласымын. Халкымызга хезмәт минем өчен бер вөҗдан бурычы гына түгелдер, бәлки искедән милләткә хезмәт итүдә бер ләззәт, бер сәгадәт тапкан бер кешемен»[28].

Бу – Садри Максудиның милләт өчен хезмәттә үз алдында куйган максатының асылы. Ул әле озак еллар буенча үзенең шушы сүзләренә, вәгъдәсенә тугрылыклы булып калачак һәм бар белемен, сәләтен, вакытын татар халкының милли аңын уятуга, милли хәрәкәтне үстерүгә, ягъни, җыеп кына әйткәндә, татар халкының дөньяда башка алдынгы халыклар, хаким милләтләр дәрәҗәсенә күтәрелеп, Россия дәүләтендә рус милләте белән бертигез хокуклы халык булып яшәве өчен көрәшкә багышлаячак.

III Дәүләт думасына сайлаулар вакытында «Иттифак әл–мөслимин» партиясе С.Максудины кабат Думага депутатлыкка кандидат итеп күрсәтә. Ләкин ул Казан шәһәреннән профессор М.Я.-Капустин белән бергә тәкъдим ителә һәм М.Я.Капустин күпчелек тавыш ала. С.Максуди исә Казан губернасы исемлегеннән уза.

Россиянең III Дәүләт думасы 1907 елның 1 ноябрендә ачыла һәм бу иң озын гомерле Дума була: ул 1912 елның 9 июнендә биш еллык срогын тәмамлап үзенең эшен төгәлли.

Ә II Дәүләт думасы, көткәнгә караганда сулрак булып чыга, чөнки анда «Хөррият тарафдарлары 320 дан артык була». Ләкин европача демократик юл белән идарә итү уенын уйнарга тырышкан патша хөкүмәтенең түземе озакка бармый. II Дума куып таратылганнан соң, мәгълүм 3 июнь законы чыга һәм бу закон нигезендә рус булмаган милләтләр яшәгән губерналар 82 депутат урыныннан мәхрүм калса, төркестанлылар һәм кыргызлар III

Думага бер депутат та сайлый алмыйлар. Шулай итеп, егерме миллионлы мөселман халыклары III Дәүләт думасына барлыгы ун вәкил сайлап җибәрә алалар.

III Дәүләт думасына сайланган бу ун депутатның сигезе берләшеп, Мөселман фракциясе төзиләр[29]. Фракциянең рәисе М.Тәвкилев була, секретаре итеп С.Максуди сайлана. Гомумән, III Думада барлыгы 422 депутат була, алар ун төрле партиядә әгъза булып торалар (шулар арасында кадетлар – 55, социал–демократлар – 20, рабочая партия вәкилләре – 13), арада иң күп санлы һәм көчле партия – «17 Октябрь союзы» партиясе (154 депутат) була һәм III Думада инде октябристлар идарә итә. «Октябристларның күзләре бар, егерме миллионлы мөселманнарны күрмиләр, аларның тавышларын ишетмиләр. Хәлләремез уңай түгел, без мөселманнар да кызганыч, ләкин алдын–артын уйламый сукыр кеше шикелле кул белән кармаланып закон төзүче булырга көчәнүче октябристларның да хәлләре кызыгырлык түгел. Безнең, мөселманнарның хәле киләчәктә бер рәтләнер. Мин буңа ышанам, ләкин октябристлар кадәр истикбальсыз (киләчәксез) бер фирка юк»[30], дип язачак С.Максуди бераз соңрак алар турында. Сигез кешедән торган Мөселман фракциясенә әнә шул көчле партия вәкилләре белән көрәшергә, төрле закон проектлары тикшергәндә татар халкына, мөселман халыкларына тулы тигез хокуклар таләп итеп, аксөяк депутатларны шаккатырган калдырган чыгышлар ясарга туры килә. Ләкин буйсындырылган, әмма азатлыкка омтылган татар милләтенең, мөселман халыкларының бүгенгесе, киләчәге өчен борчылып, Дума мәҗлесләрендә фракция исеменнән кыю чыгыш ясаучылар С.Максуди, Г.Еникеев, Ш.Тукаев кына була. Аларның бу чыгышларын миссионерларның трибунасы булган «Казанский телеграф» газетасы рус халкына, патша хөкүмәтенә каршы чыгышлар дип бәяли.

Россия Дәүләт думасының һәм андагы хаким сыйныф вәкилләренең, мөселман халыклары тормышына нинди булса да борылыш ясарлык кануннар кабул итмәячәген яхшы аңлаган С.Максуди III Дәүләт думасы турында үзенең фикерләрен аңлатып «Русское слово» газетасына биргән интервьюсында: «Фракция сәяси

мәсьәләләрдән хөрриятләрне урнаштыру мәсьәләләрендә генә бәхәс итәргә тиешледер», дияргә мәҗбүр була.

III Дәүләт думасындагы эшчәнлеген беренче карашка бик кечкенә мәсьәләләрдән башлап җибәргән Мөселман фракциясе турында ул еллар татар вакытлы матбугатында шактый усал сүзләр языла. Заманында Г.Тукай, Ш.Әхмәдиев, Г.Исхакый, Ф.Туктаров һ.б. да Мөселман фракциясе һәм аның эшчәнлеген хурлау–сүгүдә үз өлешләрен кертәләр. Әмма III Дәүләт думасындагы 442 депутат арасында сигез кешедән торган Мөселман фракциясе, ягъни: Котлуг Мөхәммәд морза Тәвкилев, Шакир Тукаев, Галиасгар морза Сыртланов, Шәрәфетдин Мәхмүтов, Гали бәк Хасмөхәммәдов, Җиһангир Байбурин, Гайса мирза Еникеев, Садретдин Максудовлар тавышы Дума мәҗлесе барган залда биш ел буена яңгырый. Белемнәре, яшәү рәвешләре, тоткан сәясәтләре, кәсеп–хезмәтләре төрле булган бу кешеләрнең бер фикергә килеп, Думада сигез кешедән торган Мөселман фракциясенә оешуларының нигезендә »бергә эш йөртүнең лязем икәнне аңлаганнары аркасында» һәр мөмкинчелектән файдаланып, мөселман халыкларына аз булса да файда тиярдәй, я булмаса, зыяны булырдай законнарны үткәртү–үткәрмәү һәм Дума мөнбәреннән бөтен Россия халыкларына анда яшәүче мөселманнарның телләрен, диннәрен, мәктәп–мәдрәсәләрен саклап, үстереп яшәүгә хокуклар таләп итүен җиткерү теләге тора. «Бу кешеләрнең һәрбере милләтнең мәнфәгате өчен, фракциянең вөҗүде өчен үзләренең сәяси карашларын корбан итеп, Мөселман фракциясенә керде»[31], дип яза ул үзенең «Сөхбәтләрендә». Мөселман фракциясе, үз алдына куйган максатын азмы–күпме тормышка ашырырга омтылып, III Думаның биш елга сузылган эшчәнлегендә актив катнашачак, октябристларның да, шовинистларның да «нервларына тиячәк», мөселман халыкларына кирәкле кануннар үткәрү өчен фидакарьләрчә тырышачак.

III Думада эшләгән чорда С.Максуди абруйлы сәясәтчегә, оста дипломатка әверелә. Французча, русча сөйләшкән, рус, француз әдәбиятын, тарихын яхшы белгән, европача киенгән, үзен октябристлар, кадетлар һәм социалистлар белән дә иркен тоткан, алар арасында үз дәрәҗәсен белгән С.Максуди Думадагы депутатларның күбесе белән уртак тел тапкан. Думада авторитетлары зур бул-

ган Н.А.Хомяков, П.Н.Милюков кебек депутатлар да аңа дустанә караганнар.

«Мөселман вәкилләренең Думадагы вазыйфасы – төрле чаралар белән милләтемезгә хөрриятләрне алырга тырышмак вә һәрбер халык зарарына булачак эшләрнең, законнарның булмауларына тырышмактыр» – бу аз санлы Мөселман фракциясенең III Думада үз алдына куйган бурычы.

«Дума – һәр хаким милләт, уң партияләр үзенә файдалы бер эшне алырга тырышкан көрәш мәйданыдыр. Бу көрәш мәйданында без, мөселманнар, мәхкүмә (изелгән, буйсынган) милләт вәкилләре. Шуңа күрә Мөселман фракциясе дә милли фракцияләр, һәрвакыт аз булган милләт вәкилләре башка милләт арасында үзләрен ялгыз хис итәләр. Бу үксезлек, бу ялгызлык аларны бергә оештырадыр. Бер кавемне берләштергән нәрсәләр – аларның дине, теле, милләте, әдәбияты. Мәхкүмә милләтләр вәкилләренең карашлары сәяси, икътисади мәсьәләләрдә төрле булып, төрле партияләргә аерылулары мөмкин булса да, алар бу мәсьәләләрне читкә куеп, иң газиз булган дин, тел, кавемият, әдәбият мәсьәләләре тирәсендә берләшәләр. Хаким милләт партияләре арасында милләт мәхкүмәләрнең мөкатдәс диненә, газиз теленә һөҗүм итәргә теләүчеләр күп. Шул сәбәптән мәхкүмә милләт вәкилләре, сәяси аерымлыкларын онытып, иң мөһим булган милли эшләр тирәсендә оешырга мәҗбүр буладыр. Мөселман фракциясенең Думада бергә хәрәкәт итүенең, бергә оешуының төп сәбәбе вә әсәсе шулдыр»[32], – дип яза С.Максуди Думадагы Мөселман фракциясенең үз алдына куйган максат–бурычларын аңлатып.

Чыннан да, Мөселман фракциясенең бу позициясе, кайбер татар зыялыларының, сул партия вәкилләренең ачы тәнкыйтенә дә карамастан, милләтне милләт буларак саклап калу, сәясәттә, икътисадта, мәгарифтә алдынгы милләтләр белән бер рәттә булу өчен көрәш юлында дөрес булган бит. Мөселман фракциясе вәкилләре патша самодержавиесе кул астында милли, мәдәни яктан да изелеп яшәгән рус булмаган халыклар өчен Думада икътисади таләпләр һәм кануннарны тикшергәндә октябристлар, кадетлар белән берләшеп эш итәләр, ә инде мәгариф, мәдәният, вөҗдан

ирегенә кагылган мәсьәләләрдә – алар аерым, Думадагы үзләреннән кырык мәртәбә күбрәк булган башка партияләр вәкилләренә каршы позициягә басалар. Бу очракта сигез кешедән торган Мөселман фракциясе Думада Россиянең хаким сыйныфы тарафыннан буйсындырылган, һәртөрле хокуклардан мәхрүм ителгән егерме миллионлы мөселман халыклары хокукларын яклап, аларның телләрен–диннәрен саклауны таләп итәләр. Шуңа күрә, С.Максуди үзләренең Думада тоткан позицияләрен аңлатып: «Мәдәният бәшәриянең (кешелек) хәзерге дәверендә XX гасыр башында милләт хакимия хакында дөрес булган эш милләт мәхкүмә өчен дөрес түгелдер. Бу ике төрле милләт эчендәге әхвәл ике төрле үлчәү белән үлчәнергә тиешледер»[33], дип яза.

Мөселман фракциясенең эш режимы бик тыгыз була: алар Думада каралачак мәсьәләләр турында атнага бер–ике мәртәбә җыелышып сөйләшәләр, әгәр ул атнада мөселманнарга кагылышлы мәсьәлә каралса, кемгә дә булса, үзе яхшырак белгән мәсьәлә турында чыгып сөйләргә тәкъдим итело. Билгеле, өч–дүрт комиссиядә әгъза булып торган депутатлар барлык мәсьәләләрдән дә хәбардар булып, теге яки бу мәсьәләне хәзерләп тә, ныклап асылына да төшенеп җитә алмыйлар, шуңа күрә алар үзләренә ярдәмгә бер бюро төзиләр. Бу бюрога «үзенең куәт вә көче кадәре файда иткән» берничә кеше керә, болар арасында Муса Бигиев[34], Галимәрдән Топчибашев һәм Йосыф Акчура да була. Әгәр бу Дума, бөтен каршылыкларга карамыйча, озын гомерле булса, милләт илә фракция арасында мөнәсәбәтнең бик җылы булуы иң лязем эшләрдән булачактыр. Фракция, дини, мәдәни, икътисади хәбәр–мәгълүмаларга мохтаҗ. Чөнки адәм баласы Әбугалисина булса да, Идел буйларыннан Кытай чикләренә кадәр сузылган егерме миллионлы халыкның бөтен кирәкләрен, бөтен ихтыяҗларын күңелдән белә алмас»,[35] – дип яза ул Мөселман фракциясе исеменнән бөтен Россия мөселманнарына мөрәҗәгать итеп.

III Думада иң беренче эшләрдән итеп Россиядә ибтидаи (башлангыч) укуны гомумиләштерү хакында хөкүмәт тәкъдим иткән закон проектын карау була. Моның өчен махсус мәгариф комиссиясе дә төзелә. Комиссия Россиягә нинди ибтидаи мәктәпләр кирәклеге, аларның нинди мәгънәви нигезләрдә корылырга тиеш-

леге турында план проекты хәзерли. Мөселман фракциясе исеменнән бу комиссиягә Гайсә морза Еникеев керә[36]. Мөселман фракциясе, поляк вәкилләре фракциясе белән берләшеп, әлеге закон проектына бер пункт өсти: ибтидаи мәктәп мәмләкәт мәнфәгатенә муафыйк (ярашлы) булу өстенә, мәктәп булган җирдә яшәүче халыкның дине, мәгыйшәт аерымлыкларына да муафыйк булырга, ягъни ибтидаи мәктәпләрдә укыту, шундагы халыкның дини, мәгыйши вә рухи ихтыяҗларына муафыйк булып, аның белән бергә мәмләкәт мәнфәгатьләреннән дә аерылмаска тиеш.

Мөселман фракциясе үзенең беренче ел эшчәнлегендә Думага куелган бары бер закон проектына кыргызларның үз җирләренә хокукларын саклау хакында бер пункт кына кертә ала.

XX гасыр башында эчке Россиядән кыргыз–казах җирләренә (Акмулла, Амудәрья, Сырдәрья, Семиречинск, Урал, Семипалатинск валиятләренә) русларны күчереп утырту процессы бик актив бара, ә аларга күчмә тормыш белән яшәгән, ләкин шул җирләрнең төп хуҗасы булган җирле халыкларның иң яхшы җирләрен кисеп бирәләр. Киләчәктә бу хокуксыз халыкларның җирсез–сусыз да калу куркынычы килеп туа. Бу – Мөселман фракциясен борчыган төп мәсьәләләрнең беренчеләреннән. Әлеге мәсьәләне Дума мәҗлесенә кертеп тикшерү, кыргыз–казахларның җиргә булган хокукларын яклаган берәр закон кабул иттертү турындагы мәсьәләне күтәреп чыгучы Мөселман фракциясе, ә Думада шушы мәсьәлә каралганда чыгыш ясаучы С.Максуди була.

Мөселман фракциясе Думада үзенең кулыннан нәрсә килгәнен–килмәгәнен аңлап эш иткән. Фракция, алдан ныклап хәзерләнмичә, төпле дәлилләр җыймыйча торып, бер генә мәсьәләне дә тегe яки бу комиссиягә кертмәгән. Ул чордагы вакытлы матбугатта үзләре исеменә төрле ачы тәнкыйть сүзләре ишетүгә, эшсезлектә гаепләнүгә карамастан, алар беренче елны, өлгереп җитмәгән мәсьәләгә санап, башкорт җирләре хакындагы мәсьәләне, Духовное собрание турындагы проектны комиссияләргә кертмиләр. Алар фикеренчә, «ашыгып кертүдән, сабыр итү муафыйктыр», «безнең мөселманнар өчен иң өлгергән мәсьәлә икедер: берсе – Духовное собраниеләрне ислах вә аларның хокукын киңәйтү; икенчесе –

ибтидаи мәктәпләр хакында әүвәлге правилалар урынына үзебез теләгән закон чыгартырга тырышудыр. Думага закон ляихәсен кертүдән бигрәк, аны Дума алдында яклый белү, ул законның кирәклеген исбат итә белү читендер»[37].

III Думаның мөселман халыкларына карата тоткан сәясәтен, бу Думада төп роль уйнаган октябристларның үзләренә булган мөнәсәбәтләрен яхшы аңлаган Мөселман фракциясе җитәкчеләренең берсе булган С.Максуди: «Думаның бу мәсьәләгә ничек караячагын, андагы партияләрнең меселманнарга ничек карауларын, бу Думадан, андагы партияләрдән нәрсә көтәргә мөмкинлекне белмәгән хәлдә, алар турында ачык бер фикер хасыйл итеп җиткермәгән көенчә, эшкә ашмаячак закон фарызларын кертүдә ни файда?»[38], – дип яза. Әмма шуңа да карамастан, Мөселман фракциясе вәкилләре III Думаның беренче елында да Думада төрле закон проектлары каралганда унөч тапкыр чыгыш ясыйлар. Шулардан: С.Максуди – 4, Г.Сыртланов – 3, Г.Еникеев – 1. К.Тәвкилев – 1, Г.Хасмөхәммәдов – 4 мәртәбә Дума мөнбәренә күтәрелеп, Россиядәге мәхкүмә милләтләрнең хокукларын яклап, шул халыкларның аһ–зарын, үтенеч–таләпләрен Думага, аның аркылы хөкүмәткә һәм патша хәзрәтләренә җиткерергә тырышканнар.

III Думаның беренче ел эшчәнлегендә, ягъни сигез ай эчендә йөзләгән зур мәҗлес була, шул арада Думадан барлыгы 613 төрле закон үтә, аларның 350 се Думада карала һәм кабул ителә, ә 18е кире кайтарыла, 5 сен Дума кабул итми. Ләкин беренче елны Думада Россиянең барлык халыкларына файдасы тиярлек зур, әһәмиятле законнар кабул ителми. Дума вак, икенчел законнар карау белән мәшгуль була.

Беренче вакытларда Думага ышаныч белән караган Мөселман фракциясе, шул исәптән аның Европа парламенты эшчәнлеге белән таныш булган җитәкчесе С.Максуди да яңа җыелган, сайланган, Россия тарихында яңалык булган Дума патша хөкүмәтенең икътисади, сәяси карашларын рус булмаган халыклар файдасына үзгәртә һәм яңа законнар чыгара алыр, дип ышанган. Әмма тора–бара Думада эшләү, рус шовинистлары, милләтчеләре белән егерме миллионлы мөселман халыкларының хакларын хак-

лап, хокукларын яклап тикшерелә торган закон проектларына кечкенә генә өстәмә кертү өчен дә чын–чынлап «ут ягып» көрәшү, В.М.Пуришкевич[39], А.И.Гучков, М.Я.Капустиннардан бертуктаусыз төрле кимсетүле сүзләр ишетеп тору аңарда бу Думаның рус булмаган халыклар өчен нинди дә булса файдалы законнар кабул итәчәгенә булган ышанычны бетерә. Шулай да, һәр булган реаль мөмкинлектән файдаланып, төрле закон проектларына кечкенә генә булса да өстәмә кертү, бер генә булса да сүз өстәү – бу шартларда Мөселман фракциясенең үзләре булдыра алганны эшләргә тырышуның бер мисалы.

«Бирсәң, барысын да бир, бирмәсәң, бер нәрсә дә кирәк түгел», дип каты торыйкмы, яисә аякны юрганыңа карап сузып, бирелгән бер уңайлык вә хөрриятләрне әкренләп, азлап кына ала торыйкмы? Мин бу хакта бик озак, милләтнең өлгереп беткән ихтыяҗларын күз алдында тотып уйлаганнан соң, юрганыңа күрә аяк сузу фикеренә килдем»,[40] дип яза III Думадагы рус шовинистларының Мөселман фракциясенең һәрбер тәкъдименә каршы тавыш биреп баруыннан гаҗиз булган С.Максуди Думадагы Мөселман фракциясенең беренче елгы эшчәнлегенә бәя–хисап биргән «Хисапнамәсе»ндә.

Татар милли хәрәкәте идеологлары хәтта татар халкының милли аңы уянган, милли хәрәкәттә яңа күтәрелеш, чын–чынлап рухи инкыйлаб булган XX гасыр башында да «юрганыңа күрә аяк сузу» сәясәте алып барырга мәҗбүр булганнар.

Россиядәге егерме миллионлы мөселман халыкларына түбәнсетеп карарга өйрәнгән хаким милләт вәкилләре, бигрәк тә уңнар, рус шовинистлары, октябристлар Дәүләт думасына сайланган мөселман вәкилләрен «Мөселман дигәч тә, бары тик чалма киеп йөрергә яратылган, гакылга зәгыйфьрәк, бер зарарсыз, мәхлук адәмнәрдер»,[41] дигән караштa торалар. Болар: «Русия руслар өчен генәдер, рус булмаган кавемнәр руслар белән бер хокукта булырга тиеш түгел»,[42] диләр». Менә шушы шартларда мөселман халыклары өчен нинди булса да файдалы эш эшләргә тырышкан Мөселман фракциясенең III Думадагы бу «тешсез» эшчәнлеген ачы тәнкыйть утына алган «таңчы»лар, ягъни Г.Исхакый, Ф.Туктаров, шулай ук татар социал–демократлары «Все или ничего» дигән сәя-

сәтне алга сөреп, мөселман депутатларыннан радикаль үзгәрешләр көтәләр. Алар патша самодержавиесе хөкүмәтенә бәйсез булган «көчле вә куәтле Дума» чакыруны таләп итәләр. Дәүләт думасы яңа нигездә яңартылырга, изелгән хезмәт иясе халыкларын яклаучы орган булырга тиеш, дигән принципны алга сөрәләр. Ләкин, чынында, С.Максуди әйткәнчә, әлегә «юрганыңа карап аягыңны сузасың». Ә радикаллар теләгән юл, ул вакыттагы мөселман халыклары хәятенең андый гали хыял гына булган теорияләрдән бик түбәндә, бик гади бер юл белән агып яткан көне әле.

Мөселман фракциясенең октябристлар белән конфликтка кермичә генә эшләргә тырышуларын гаепләп чыгучыларның уй–теләкләрен аңлаган С.Максуди үзләренә алар хыялындагы «идеальный» Думада түгел, ә чынбарлыктагы Думада эшләргә туры килгәнлеген аңлатып: «Нәкъ менә шушы октябристлар, рус шовинистлары төп рольне уйнаган Думадан мөселман халыклары өчен мөмкин кадәр, зур яки кечкенә булуына карамыйча, закон ляихәсе карауны, кертүне сорарга кирәк «һәйбәт» Дума кайчан булачактыр, биш елдан, ун елдан, ә бәлки ул сез уйлаган Дума булмас, ул вакыт милләт нишләсен?! Һәрбер милләткә бөтен сораганнарын бирә торган Дума, бәлки, һичбер булмас. Мин хәл кадәренчә эш кылырга лязем, дим»[43] (Бу сүзләр буген дә әһәмиятле, чөнки сиксән елдан артык вакыт узганнан соң властька килгән «демократлар» да, алар күпчелек булган Россия Дәүләт думасы да, әлеге дәүләтнең зур өлешен тәшкил иткән рус булмаган халыкларга алар таләп иткән бәйсезлекне, иркенлекләрне, алар теләгән законнарны бирергә уйламыйлар әле. С.Максуди моны алдан күрә.) Европа белемле, чынбарлыкка реалистларча караучы С.Максуди үзенең татар милләтенә генә түгел, ә барлык төрки халыклар өчен дә хезмәт итүен, барлык тугандаш халыклар өчен дә тигез хокуклар таләп итүен аңлатып: «Милләтләр эчендә, хәят эчендә хата кылмауның сере – дөньяны хыял күзләреннән карамый, хакыйкать хәлне күрә белмәктә вә икътисади хәлне күреп гамәл итә белүдәдер»[44], ди.

Мөселман фракциясен татар матбугаты битләрендә төрлечә сүгү–хурлауларны авыр кичергән С.Максуди: гәзитләрнең вазыйфасы фракцияне сүгү дә, мактау да түгел, ә бәлки фракция белән

халык арасында бер арадашчы булып, фракция хакында милләт әхалиясенә бер дөрес фикер бирүдер, ди. «Яхшымы–яманмы – фракция милләт фракцияседер»[45]. Аз санлы Мөселман фракциясе бер яктан Думадагы күп санлы партияләр тарафыннан Думага яки комиссияләргә кертелгән һәрбер тәкъдименә каршы тавыш алып торса, икенче яктан татар вакытлы матбугаты тарафыннан эшсезлектә, куркаклыкта гаепләнә. Милләт хәлен җиңеләйтү бурычын үз өсләренә алып, Думага депутат булып сайланган Мөселман фракциясе вәкилләрен бу тәнкыйтьләр бер яктан чыныктырса, икенче яктан аларга карата милләттә тискәре караш уята. Матбугатның фракциягә булган карашы С.Максудины үзләренең III Думада эшләгән эшләре турында җентекле хисапнамә язарга мәҗбүр итә һәм бу хисапнамә «Йолдыз» гәзитенең уннан артык санында басылып чыга. «Фракциянең мөкәммәл (камил) булмавына милләтнең мөкәммәл булмавы да сәбәп буладыр. Һәр милләтнең фракциясе милләт халкына ошыйдыр»[46] – С.Максудиның моннан биксән еллар элек язган бу сүзләрен без үзебезнең Дәүләт советындагы депутатларыбызга карата бүген дә шул килеш кабатлый алабыз.

Еллар узган саен Думада эшләү авырлаша бара, чөнки дөнья аренасында да, Россиядә дә, төрле партияләрдә дә сәяси хәлләр үзгәреп тора. Дума төзеп, бөтен Россиядә шул Думага сайлаулар үткәреп, Европа илләре алдында демократия уены уйнап алган патша хөкүмәтен, үзләре Думада чагыштырмача аз санлы булсалар да, тавышлары көчле чыга торган социал–демократлар, трудовиклар, поляк һәм мөселман депутатларының буйсындырылган, хокуклардан мәхрүм ителгән халыкларны яклап ясаган чыгышлары инде туйдыра башлый.

1910 елның июнендә «хөкүмәтнең Думага илтифаты аз, Думада таянырлык көчле партия юк, Думаны оештырып алып бару уңайсыз», дип Дума рәисе Н.А.Хомяков рәислектән китә, ә аның урынына рәис булып октябристлар партиясе җитәкчесе А.И.Гучков сайлана. «Гучков рәис булырга риза булгач, октябристлар партиясе башсыз калды. Гучков, матрослары тыңламый башлагач, көймәсен ташлаган бер капитан. Әмма ул кечкенә көймәдән зур көймәгә күчеп утырган капитан»[47]. А.И.Гучков рәислек итә башлагач, Дума бик нык уңга авыша. Бу уңга авышу Дума мәҗлеслә-

рендә моңарчы хөкем сөргән хөррият мәсьәләсендә, бигрәк тә рус булмаган милләтләргә кагылышлы төрле закон проектларын караганда ачык күренә.

Әгәр С.Максудиның III Дәүләт думасындагы Мөселман фракциясе җитәкчеләренең берсе буларак эшчәнлегенә бәя бирергә теләсәк, аның III Думада иң күп эшләгән депутат һәм иң укымышлы, иң эшчән милләт вәкиле булуын күребез.

Думада Мөселман фракциясендәге сигез депутатны берләштереп, үзләрен сайлаган татар халкының гына түгел, ә сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән Төркестан халыкларының да, Думага депутатлар уздыра алмаган казах, кыргызларның да мәнфәгатьләрен кайгыртып, алар өчен мөһим булган мәсьәләләрне Думада күтәреп чыгып, алар өчен кирәкле законнарны уздырырга тырышып Дума мәҗлесләрендә, һәртөрле комиссияләрдә кат–кат чыгышлар ясау, фракция әхваленнән дип, «Йолдыз»да озын–озын мәкаләләр биреп бару – болар барысы да аның биш ел буена III Дәүләт думасында армый–талмый үз милләтенә, мөселман халыкларына фидакарьләрчә хезмәт итүен раслый.

1912 елның июнендә III Дәүләт думасы үзенең эшен тәгәлли. Шуның белән Россия Дәүләт думасындагы Мөселман фракциясе җитәкчеләренең берсе булган С. Максуди өстеннән депутатлык вәкаләте төшә. Шушы уңай белән «Йолдыз» гәзите Мөселман фракциясенең Думадагы биш еллык хезмәтенә бәя биреп болай дип яза: «Без аларга биш ел Дума мәйданында армый–талмый хезмәт иткәннәре өчен тәшәккер итәргә тиешбез. Биш–ун кешедән торган депутатларыбызның өч–дүрт йөз кеше арасында зур эшләр эшли алмаячаклары алдан ук мәгълүм иде. Шулай булса да, алар үзләренең кулларыннан килгән хезмәтләрен җиренә җиткерүдә кимчелек кылмадылар. Бик күп тугрыларда үзләренең фикерләрен Думаның мәҗлесенә кабул иттерә алмасалар да, мөселманнарның максудларын тәкърар–тәкърар Дума мөнбәренә чыгып сөйләп, Дума әгъзаларына аңлаттылар, максудларын Думага кабул иттерергә кулларыннан килгән кадәр иҗтиһад иттеләр»[48].

С.Максуди үзе Мөселман фракциясенең Думадагы эшчәнлеген, фракция хәленнән килгәнчә яхшы хезмәт итте, дип бәяли[47].

IV Думага сайлауларда С.Максуди кандидатурасы, милке юк, (имущественный ценз) дип кандидатлар исемлегенә кертелми. С.Максуди кебек милләтпәрвәрнең рәсми сәясәттән читләштерелүе татар зыялылары тарафыннан милләт өчен зур хәсрәт итеп кабул ителә. Ә Мөселман фракциясенең Думадагы иң эшлекле депутатлары Г.Еникеев, С.Максудилар турында «Казанский телеграф»: «Үз Ватаны дип Россияне санаган рус мөселманнары өчен хурлык булган әлеге чүп—чар адәмнәрнең Думадан тизрәк китүләре һәм IV Думага сайланмаулары яхшы булачак»[50], дип язып чыга. Әлеге газета, шулай ук, IV Думага татарларга русларга карата яхшы мөнәсәбәттә булган аек акыллы кешеләрне сайларга тәкъдим итә[51], рус халкы белән кулга—кул тотынышып бу сайлауларда катнашырга һәм Думага Париждан кайткан адвокатларны түгел, ә татарның сәүдә һәм хезмәт кешеләрен сайларга чакыра[52].

«Садри әфәнденең III Думада депутат буларак кылган хезмәтләрен халык күреп, зур рәхмәтләр белән каршылады. Садри әфәндене алдагы Думаларда депутат вазыйфасында күргәнче, шул арада мәгърифәт вә мәдәнияттә үзенең мәсләгенә муафыйк һәм милләткә файдалы башка бер эшкә сарыф кылачагына өметләнеп, үзебезне тынычландырабыз. Садри әфәнде бик яшь кеше, аның моңарчы күрсәткән хезмәтләрен, без аның әле милләтенә итәчәк мөһим хезмәтләренең башы гына дип хисаплыйбыз», дип яза «Йолдыз» гәзите үзенең 1912 елның 7 октябрь санында.

Чыннан да, II—III Думаларда Президиум әгъзасы, Мөселман фракциясе секретаре булып эшләү С.Максудины сәясәтче буларак үстерә. Ул бу чорда алдагы — 1917—1918 нче еллардагы — эшчәнлеге өчен зур тәҗрибә, сәяси багаж туплый, Россия сәясәт аренасында күренекле эшлеклегә әверелә.

### § 3. Садри Максудиның III Дәүләт думасы делегациясе белән Англиягә баруы.

Петербургта яшәгән биш ел эчендә Садри Максудиның тормышында аның күңелендә онытылмас хатирәләр калдырган вакый-

галар да күп булгандыр[53]. Безгә билгеле булган шундый вакыйгаларның берсе – аның 1909 елда Англиянең «Россия әхвәлиятен өйрәнү» җәмгыятенең чакыруы буенча III Дәүләт думасы делегациясе составында Англиягә рәсми визит белән баруы.

XX гасыр башында Англиядә, Англия белән Россия арасындагы мөнәсәбәтләрне якынайту максатыннан чыгып, «Россия әхвалиятен өйрәнү» җәмгыяте төзелгән була. Ә инде Россиядә Дәүләт думалары чакырылып, Россия халкы сайлап җибәргән депутатлар дәүләт эшләрендә катнаша башлагач, патша хөкүмәте демократик идарә итүгә юл тота дип, бу җәмгыять III Дәүләт думасында төп рольне уйнаган партия вәкилләрен Англиягә рәсми визит ясарга чакыра. Чакыруны югары дәрәҗәдә оештыру өчен бу җәмгыятьтә бер комитет та оештырыла, аның составына Англиянең танылган сәясәтчеләре, министрлары, галимнәре, әдәбият–сәнгать әһелләре керә. Комитет җитәкчесе профессор Перс депутатларны Англиягә чакыру өчен Петербургка үзе махсус килә.

Англияга Думаның үзеннән 15, ә Дәүләт Советыннан 5 кеше чакырыла: болар арасында октябристлар, урта уңнар, кадет, поляк, октябристлардан 7, урта уңнардан 3, мөселман фракциясеннән 1 кеше була.

Сигез кешелек Мөселман фракциясеннән делегат итеп С.Максуди тәкъдим ителгәч, профессор Перс «һиндстан мөселманнарының бездә сайлау хокуклары юк, Россия мөселманнарыннан Дәүләт думасы депутатының Англиягә килүе аларда каршылык тудырмасмы?» дигәч, аңа каршы сул октябристлардан булган А.И.Звягинцев: «Садри Максудов аз санлы фракция әгъзасы булса да, ул егерме миллионлы Русия мөселманнарының хакыйкый вәкиледер. Думада башка бер генә депутат та үзен Русиянең егерме миллионлы халкы вәкиле дип игълан итә алмас. Без мөселманнарга үзебез белән тиң хокук вә хакка лаек булырга тиешле ватандашлар дип карыйбыз», ди. Аның фикерен Дума рәисе Н.А.-Хомяков, депутатлардан П.Н.Милюков, А.И.Гучков та хуплыйлар. Перс та:«Русия мөселманын күреп, бәлки, безнең хөкүмәт тә гыйбрәт алыр, бер нәтиҗә чыгарыр», дип риза була һәм, шулай итеп, С.Максуди Англиягә рәсми визит белән барачак III Дәүләт думасы делегациясе составына кертелә.

Англиягә баручылар арасында Дума рәисе Хомяков, депутатлардан Звягинцев, граф Бобрынский, Шидловский, граф Алсуфьев, Стахеевич, князь Волконский, Маклаков, «Новое время» газетасыннан Б.Суворин, «Биржевые ведомости» мөхбире Александровский да була.

С.Максуди, соңыннан, 1909 елда үзенең «Англиягә сәяхәт» исемле китабын яза һәм 1909, 1914 елларда «Өмид» типографиясендә бастырып чыгара. Ул әлеге китапны язуының сәбәбен: «Мин мәмләкәт вәкиле булып баргач, бу сәяхәт ышнасында кылган эшләремнән, сөйләгән сүзләремнән үз милләтемне хәбәрдар итәргә тиеш санадым», дип күрсәтеп тә китә[54].

«Галәм хәлләренә һәрвакыт үз даирәң офыгыннан гына карау мәгъкул түгел. Бераз башка офыклардан да карарга тырышырга кирәк», ди ул Англиягә барганда үзләре узган юллар, илләр, аларның халыклары, хәятләре турында ул илләр белән сокланып, ә Россия өчеп әрнеп, борчылып. Ул үзенең әлеге китабында юлда күргәннәре турында шундый нәтиҗә дә ясый. Бу илләрнең, андагы халыкларның, таза, матур яшәвенең ике сәбәбе бар: беренчесе – бу илләрнең халыкларның эшчәнлеге, тырышлыгы, икенчесе – хөррият, ди. Мәсәлән, кечкенә генә Бельгия аша узганда аны җиде миллионлы бу илнең («Безнең Русиянең бер зуррак өязе кадәр мәмләкәттер») төзек, таза яшәве сокландыра. «Бельгиялеләрнең фәлсәфәсе: дөньяда тормыш никадәр авырайган саен, шулкадәр эшчәнлекне арттырып, хурлыклы ачлык хәленә калмау. Бельгиядә ач кеше юк, простой рабочий көнгә ике мәртәбә итле аш ашыйдыр. Мәмләкәт шул кадәр бай, гади эшче аена кырык сумнан ким алмый. Ничек итеп болар бу хәлгә килә? Күп эшләп. Шул ук вакытта «Ә бит дөньяда тору көннән–көн читенләшә барадыр, истикбалда (киләчәктә) хәят дәһшәтле бер вакыйга халәтен алачактыр», дип киләчәкне дә никадәр алдан һәм дөрес итеп күрә алган С.Максуди.

Халык тормышын яхшы белгән, халыкның ихтыяҗларын бала вакытыннан күреп үскән, шул изелгән, кимсетелгән халыкның бер вәкиле булган С.Максуди үзенең юлда граф Алсуфьев белән булган бәхәсендә: «Менә безнең вазыйфабызда яңа бер тормыш ачыладыр. Вазыйфабыз – хәятнең һәр тарафы ислахка мохтаҗ, алдымызда

бик күп хезмәтләр күренәдер. Әйдәгез, әзрәк үзегезнең интересларыгызны онытып, халыкның күтәрелүенә, аякка басуына, ислахларының тәмам тормышка ашуына ярдәм итегез, халык сезне хөрмәт итәр», ди.

Дәүләт думасында Россиянең киң катлаулары вәкилләре белән бергә берничә ел бергә эшләү дәверендә, патша хөкүмәтенең, рус булмаган милләтләргә карата булган сәясәтен үз җилкәсендә татыган С.Максуди Россия халыкларына барлык хокукларны бары тик хөррият кенә китерә алачагына ныграк ышана бара. Соңыннан, еллар узгач, Англиядә күргәннәренә анализ ясап ул: «Англиядәге тәхсин бер эш күрсәгез, бу хәлне тормышка ашырган сәбәпләрнең иң тирәне хөррият шәхсияне ихтирам иткәненә мин көннән–көн ныграк ышанам», диячәк.

Англиядәге визиты вакытында аңа иң тәэсир иткән нәрсә – Дума делегациясен Англия короле кабул итү, чөнки бу Россия Дәүләт думасы депутатларын беренче мәртәбә башка зур дәүләт җитәкчесенең рәсми кабул итүе була. С. Максудига әлеге мәҗлестә сүз бирелә һәм ул: «Без Русиядә яңа бер хәятнең башындамыз. Кирәк партияләрдә, кирәк Русиядәге милләтләр арасында яңа мөнәсәбәтләр ясала торган замандыр. Русиянең, якты киләчәген теләүче вәкилләр тарихи хаталардан сакланган кебек, мөмкин кадәр киләчәктә милләтләр арасындагы суыклык ясаган эшләрдән качарга тиешмез», ди. Ул үзенең чыгышын француз телендә ясый, ә Англия короленә мөрәҗәгать иткән беренче җөмләсен исә инглиз телендә әйтә.

Англия парламенты эшчәнлегендә аны сокландырган нәрсә – парламенттагы эшче депутатларның, хөкүмәтне курыкмыйча тәнкыйтьләүләре, төрле запрослар ясаулары, һәм хөкүмәтнең шул запросларга җавап бирергә мәҗбүр булуы. С.Максуди III Дәүләт думасында, аның төрле комиссияләрендә төрле закон проектлары каралганда Россиянең, мөселман халыкларының хакларын хаклап күп мәртәбәләр ясаган чыгышларында, мөгаен, Англия парламентындагы әнә шул депутатларның эшчәнлеге тәҗрибәсенә дә таянгандыр. Дәүләт думасының Англиягә визиты ике атнага сузыла. Бу делегацияне рәсми оешмалар да, җәмәгать оешмалары да, төрле уку йортлары һәм Англиянең атаклы аксөякләре дә ка-

бул итә. С.Максуди үзе катнашкан һәрбер мәҗлестә диярлек чыгышлар ясый. Башкалар, авырыксынып, теге яки бу мәҗлестә катнашудан, чыгыш ясаудан баш тартканда да ул үзләре чакырылган һәр җирдә булырга, делегация исеменнән сүз әйтергә тырыша. Бу аның Англиянең югары даирәсенә, аның укымышлыларына, киң җәмәгатьчелегенә Россия дигән илдә татар халкы да барлыгын, аның да дөнья мәйданында үз урыны булырга тиешлеген исбат итәргә тырышуы, ягъни аның үзенчә әйткәндә: «Бу чыгышлар үзеңнең милләтеңне инглиз күзендә күтәрү, күтәрә алмасаң һич булмаса, төшермәү, үз милләтең турында дөньяның иң куәтле халкына тугры уй, фикер бирү» булгандыр.

Россия Дәүләт думасы составында килгәч, протокол буенча, С.Максуди Англиядә югары даирә белән генә аралаша алган. Ләкин шулай да Англиянең, иң бай аристократларының берсендә кунакта булганнан соң, ул үзе белән гел конфликтка керә торган Бобрынскийга: «Бу лордның аристократлыгы ни бәһага төшәдер икән? Бунның бәһасын түләүче бөтен Англиянең кара халкы, колонияләрнең хокуктан мәхрүм ителгән, хәерче хәленә төшкән бичаралары түгелме?» дигән сорау да бирә. Дума депутаты буларак, Россиянең иң мәртәбәле кешеләре белән «бер казанда кайнаган» С.Максуди үзенең кайсы халыктан чыкканын яхшы хәтерләгән һәм шул халыкның, авыр хәлен җиңеләйтү өчен бар көчен биреп тырышкан. Чөнки ул үзе әйткәнчә: «халыкны яхшы белгән, халыкның ихтыяҗларын, җәфаларын бала вакытыннан эченнән күргән».

С.Максудига Ливерпульда киң җәмәгатьчелек алдында чыгыш ясарга, «Бүре дә тук, сарыклар да исән калырга тиеш» дигән принциптан чыгып сүз әйтергә туры килә. Монда чыгыш ясаудан хәтта ул үзе бик сокланып: «Ул күп укый, күп йөри, күп белә. Милюков тикмәгә генә Милюков түгел!» дигән П.Н.Милюков та баш тарта, чөнки биредә һәртөрле каверзный сорауларга җавап бирергә туры киләчәк. Дума рәисе Н.А.Хомяков та, С.Максудига бик дустанә мөнәсәбәттә булган П.Н.Милюков та аның үз нотыгында Англиянең һиндстан мөселманнарына карата булган сәясәте турында, мондагы мөселманнарның сайлау хокуклары булмавы турында сүз әйтүеннән куркалар. Әмма шулай булуга карамас-

тан, «кунак итәләр дип», ул һиндстан мөселманнары турындагы хакыйкатьне әйтмичә кала алмый. «Миңа кадәр сөйләгән нотыклар бик дустанә булды. Бу дуслыкның һәр ике тарафның гражданнарыннан булган мөселманнарның хокукларына яхшылык илә тәэсир итүен өмид итәм», – ди. Ул үзенең чыгышында: һәр ике илдә дә мөселман халыклары тигез хокуклы гражданнар булачагына ышанам, ди.

Ливерпульның иң асыл затлы аристократлары белән Россиянең аксөяк депутатлары җыелган бу мәҗлестә С. Максудиның Россиядә егерме миллионлы мөселман халыклары барлыкны белдергәненә эче пошкан, ачуы килгән һәм мөселманнарны «честный дворник, лакей итеп кенә күрергә теләгән, «Татар баласы, синең бунларны сөйләргә ни хакың бар?» дип кычкырасы килгән бер Дәүләт советы әгъзасына карата: «Ләкин татар баласы буны аннан сорачак түгел иде инде», дип язачак ул соңыннан үзенең әлеге китабында.

Россия Дәүләт думасы делегациясенең Англиягә визиты дөнья җәмәгатьчелеге өчен дә зур вакыйга була. Чит илләрнең Англиядәге матбугатчылык җәмгыяте журналистларны җыеп, Дума вәкилләре белән очрашу оештыра. Бу мәҗлестә башка мәмләкәтләрнең йөзләгән мөхбирләре белән әллә никадәр Лондон гәзитчеләре дә катнаша. Дөньяның оста каләм ияләре җыелган бу мәҗлестә С.Максуди түбәндәгеләрне сөйли: «Матбугатчылык вазыйфасы бик авыр вазыйфадыр. Заманыбызда тарих ясалуында иң мөһим фагыйл вазыйфадыр, нәфис бер сәнгатьтер. Заманыбызда тарих ясалуында иң мөһим фагыйл газеталардыр. Бу заманда министрларны төшергән, мәмләкәтләрне сугыштырган һәм килештергән һәрберсе–газетадыр. Европа матбугаты тырыша–тырыша Европаны хөррият юлына төшереп бетерде. Бүгенге көндә ике Ислам мәмләкәте халкы үзләренә хөррият вә тәрәкъкый урнаштырырга тырышып яталар. Бу илләрдә идарәи мәшрүтә (конституция) тәмам урнашу өчен, һич шөбһәсез, үз халыкларының иҗтиһады, гайрәте лязем булган кебек, Европаның да мәхәббәте вә симпатиясе шарттыр. Бу – сезнең кулыгыздадыр. Хөрриятkә сусаган бу ике мәмләкәткә хөррият кертүгә ярдәм итә аласыз, һәм зарар да итә аласыз. Бинаи галия һәрберегез калебе-

гез илә галәм Исламның хөрриятләүенә тырышачагыгызга ышанганга, мин сезне галәм Исламда хөррият урнашуына, тәрәккыйның тәмам җәелүенә хезмәт итүчеләр дип уйлап, сезнең шул фикеремне раславыгызны көтәм», – дип, ул көчле кул чабулар астында сүзен тәмамлый.

Ф.Туктаров үзенең алда телгә алынган китабында иң усал характеристиканы С.Максудига биргән: «Садретдин әфәнде үзе бик әрсез адәм. Шул әрсезлеге өстенә чибәррәк тәрбиясе, төплерәк гыйлеме булса, халык өчен файдалы булыр иде». Сорбонна бетереп, юрист дипломын алып кайткан, аңарчы Казандагы учительская школаны тәмамлаган, 19 яшендә чын татарча милли роман – «Мәгыйшәт» – язып бастырган С.Максуди турында ул: «Бичараның мәгълүматы бик өстән генә, сөйләр өчен хәтта татарчага да куәте юк, русчаны простой татар сәүдәгәре кадәр дә сөйли алмыйдыр, шуның өстенә табигате һәм акылы да, татар әйткәнчә, килделе–киттеледер», ди. Менә шушы «килделе–киттеле» С.Максуди Англиядә Дума рәисе Хомяков, Милюков, Звягинцевларның соравы буенча Байронга багышланган кичәдә һәм Дарвинның 100 еллыгына багышланган конференциядә, Букенгем сараенда Англия короле белән очрашуда катнаша, Ливерпульның аристократлары алдында һәм Лондонның дөнья матбугаты үзәгендә чыгышлар ясый, үзенең һәр чыгышын көчле кул чабулар астында тәмамлый. С.Максудиның берничә елдан соң басылып чыгачак әлеге китабындагы Байронга багышланган бүлеге аның фикер йөртү киңлеген, белеменең тирәнлеген, Байронның иҗатын һәм ул яшәгән чорны, хәятын никадәр тирәнтен белүен ачык күрсәтә. Ул дөнья язучыларына бәя биреп, алар арасында иң яхшысы һәм үзенең яраткан язучысы Диккенс ди: «Укып әхлак яхшылатасы килгән кешегә минем бу язучының әсәрләрен димлисем киләдер. Руссо, Толстой, Гюго кебек адәмнәргә тирән мәхәббәт белән караган, алар кебек адәмнәрнең җәфаларын аңлаган, аларны чыннан кызганган кешене белмим. Бу язучының берсенең әсәрен укып бетергәндә инсан үзендә бер инкыйлаб рухани хис итәдер», дип яза. Моннан С.Максудиның сәясәтче генә түгел, ә чын мәгънәсендә зыялы кеше икәнен, дөнья әдәбиятын тирәнтен белүен, тоюын аңларга була.

С.Максудиның Россия Дәүләт думасы делегациясе составында Англиягә рәсми визиты аңа алга таба Думада үзенең эшчәнлеген киңрәк җәелдерергә, Россиянең егерме миллионлы хокуксыз мөселман халыкларының хакларын даулап чыгышлар ясаганда үзенең хаклыгын тирәнтен тоярга, кыюрак булырга мөмкинлек тә биргәндер. Чөнки мөселман дөньясының (Россиядә генә түгел) бер уяначагына, аның тәрәккъыят юлына басачагына нык ышанган С.Максуди соңарак: «Киләчәктә мөселман мәмләкәтләре кайсы дәүләткә якын булсалар, политикада шуның сүзе өстен булачактыр», диячәк. Англиягә булган визитыннан соң ул 1910 елның сентябрь аенда сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән, мәдәниятсыз кавем дип хисапланып Дәүләт думасына депутатлар сайлаудан мәхрүм булган Төркестан мөселманнары белән очрашу өчен Хоканд шәһәренә бара, Самаркандта була. Англиядә алган тәэсирләре, Россиягә килгән француз делегациясе белән очрашулары нәтиҗәсендә туган уй—фикерләре һәм Төркестан халыкларының тәрәккъыйпәрвәрләрен кузгатып җибәрү максаты, аларның проблемаларына Россия Дәүләт думасының игътибарын юнәлтергә тырышкан С.Максудины юлга чыгара. Ул Самаркандта «Англиягә сәяхәт» китабында язачак фикерләрен дә әйткәндер: «Иң мөһим хокук һәр мәмләкәттә да сайлау хокукыдыр. Бу – иң мөһим мәсьәләдер. Бу хокукны алган кешегә башка хокукларны алыр өчен ишек киң булып ачыладыр. Еламаган балага сөт бирмәгән кебек, сорамаган кешегә дә хокук бирмиләр. Сорагач та тиз генә бирмиләр, гайрәт вә үзенең хокукыңның мөкатдәслегенә, газизлегенә тирән бер ышану лязем. Үзенең теләгәненә үзе ышанмаган кеше инсан түгел кеби, үзенең максатларына кызу бер ышану белән ышанмаган милләтләр дә милләт түгелдер. Французлар, инсан үзенең язмышының тимерчесе булырга кирәк, диләр. Хәрәкәтсез, гамәлсез, ходайдан ялваручылардан, кулын бәгълап ялкау зарланучылардан да мескен кеше юк».

С.Максудиның Россия Дәүләт думасы делегациясе белән Англиягә булган визиты, анда ясаган чыгышлары, француз парламенты делегациясен Петербургтан Мәскәүгә озата баруы, 1910 елда Англия парламенты делегациясен кабул иткән мәҗлестә катнашуы һәм чыгыш ясавы, 1911 елның сентябрь аенда Германиягә

баруы Дәүләт думасының В.М.Пуришкевич, А.И.Гучков кебек шовинистларында ризасызлык тудырса, Казан миссионерларын, милләтчеләрен бөтенләй чыгырдан чыгара. Ә «Казанский телеграф» газетасы исә: «Без мөселманнарга ирек бирдек, әгәр аларга шуның кадәр ирек бирелмәгән булса, бу мөселман хәзер Дума мөнбәренә чыгып: «Без бар һәм булачакбыз!» — дип кычкыра алмас иде»[55], дип язып чыга. Моңа, беренчедән, татар халкының мөселман халыклары арасындагы мәдәниятын танырга теләмәү, икенчедән, татар милли хәрәкәте идеологларының иң күренеклесе булган С.Максудиның Россиянең мөселман халыклары арасындагы авторитетын күрмәмешкә тырышу дип карарга кирәк.

## ИСКӘРМӘЛӘР


* Мухамметдинов Р.Ф. Зарождение и эволюция тюркизма. - Казань, 1996. - с.73.

1. М.Мәһдиев. Тарихи кыңгыравык. //«Мирас» — 1992 ел. — 8 сан.
2. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. — Казан: Татар китап нәшр. 1976—1988. — 7 том. — Б.387.
3. Йолдыз. — 1907 ел. 71 нче сан.
4. Казанский телеграф. — 1912. — 13 мая.
5. Йолдыз. — 1907. — 71 сан.
6. Ибраһимов Г. Әсәрләр. — Т.7 - Б. 335.
7. Йолдыз. — 1907 ел. 71 нче сан.
8. Шунда ук.
9. Шунда ук.
10. Шунда ук.
12. Т.Камалов. Идеал һәм инкыйлаб. — Казан. — 1992.
13 Йолдыз. — 1907. — 15 июль.
14. Шунда ук. — 20 гыйнвар.
15. «Г.Топчибашев кебек мөселманнар бармак белән генә санап күрсәтерлек кадәр аздыр. I—III Дума вакытында Петербургта торып, Мөселман фракциясенең эшчәнлегенә бик ярдәм иттте» (С.Максуди.)
16. Усал М—Ф. I—II—III Дәүләт думаларында мөселман депутатлары һәм аларның кылган эшләре. — Казан. — 1908 ел.
17. Шунда ук.
18. Шунда ук.
19. Дума. — 1907. — 1 май.
20. Г.Ибраһимов. Әсәрләр. - 7 том, 421 бит.
21. Йолдыз. — 1907. — 23 май.
22. Шунда ук.
23. Шунда ук.

24. Урал. – 1907. – 21 сан.
25. Йолдыз. – 1907. – 20 июль.
26. Шунда ук. – 29 июль.
27. Шунда ук. – 20 июль.
28. Шунда ук. – 29 июль
29. «Социалистларга язылган Дагестаннан сайланган Хайдаров, Мөселман фракциясе мәҗлесләренә йөри алмаса да, мөселманнарга гаид зур эш булганда һәрвакыт килде, бер–бер закон ләихәсе кертәсе булганда кул куярга әзер иде» (С.Максуди).
30. Йолдыз. – 1910. – 6 июнь.
31. Йолдыз. – 1908. – 7 июль.
32. Шунда ук.
33. Шунда ук.
34. Муса Бигиев турында инде совет власте елларында Г.Ибраһимов «Мөселман фракциясенә җан өрүче, тырышып эшләүче иде» дип язачак. /Г.Ибраһимов. Әсәрләр. 8 томда. Казан. Татаркитапнәшр., 1986. – 6 том, 335 б/.
35. Йолдыз. – 1907. – 13 апрель.
36. «Гайсә Еникеев – Мөселман фракциясенең иң эшчән депутаты. Кышкы, язгы каникулларда Петербургта калып, китапханәләрдә йөреп, материаллар вә законнар тикшереп утырды. Казаннан кара чәч, кара мыек белән киткән Гәйсә әфәнде биш елдан ак сакаллы карт булып кайтачактыр» (Усал М.–Ф.I–II–III Думаларда мөселман депутатлары һәм аларның эшләгән эшләре. – Казан. 1908 ел. – 110 бит.)
37. Йолдыз. – 1908 ел. – 7 июль.
38. Шунда ук.
39. III Думада депутатлары арасында «иң тыңгысызы» В.М.Пуришкевич була. Ул башка кешеләр сөйләгәндә урыннан торып 119 мәртәбә кычкырган, 66 мәртәбә рәис тарафыннан кисәтелгән, 2 мәртәбә өчәр мәҗлестән, берәр мәртәбә 15 мәҗлестән, барлыгы 43 мәртәбә Дума мәҗлесеннән чыгарылган.
40. Йолдыз. – 1908. – 7 июль.
41. Шунда ук.
42. Шунда ук.
43. Шунда ук.
44. Йолдыз. – 1908. – 2 ноябрь.
45. Шунда ук.
46. Шунда ук. – 1911. – 2 ноябрь.
47. Шунда ук. – 1911. – 2 ноябрь.
48. Шунда ук. – 1912. – 14 июнь.
49. Икътисад. – 1912. – 12 сан.
50. Казанский телеграф. – 1912. – 29 июля.
51. Казанский телеграф. – 1912. – 5 июня.
52. Казанский телеграф. – 1912. – 18 марта.
53. Шулай ук, С.Максудиның 1911 елның сентябрендә Германиягә баруы да

билгеле. Әмма бу турыда шул чорның вакытлы матбугатында мәгълүматлар юк. Соңгы вакытта Рәмзи Вәлиевнең «Мирас» журналында (1906. 1–2 сан) «Гыйбрәтле язмыш» дигән тарихи очеркы бу вакыйгага бераз ачыклык өсти: «Мин анда хәзерге заманда дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә ислам дәүләтләрен, Исламны файдалану, бөтендөнья «бердәм килешү төзү» һәм «гомуми хәлне ныгытуга» христиан диненең өлеше дә кертелергә тиеш кебек уйларымны сөйләргә теләгән идем», ди С.Максуди үзенең бу сәяхәтенең максатын аңлатып. Әмма П.Н.Милюков: «Сез үзегезнең Русиядән килгәнлегегезне онытмагыз, монда интернационализм мәсьәләсен куярга кирәкми», дип аңа чыгыш ясарга рөхсәт итми. Берлиннан бик күңелсезләнеп кайткан С.Максуди бу сәясәте турында вакытлы матбугатта бернәрсә дә язмаган.

54. С.Максуди. Англиягә сәяхәт. – Казан. – «Өмидъ» типографиясе. – 1914 ел. (Алга таба китерелгән барлык өзекләр шушы китаптан).

55. Йолдыз. – 1912. – 14 июнь.

# II БҮЛЕК
# САДРИ МАКСУДИНЫҢ II – III ДӘҮЛӘТ ДУМАЛАРЫНДАГЫ ЧЫГЫШЛАРЫ

Садри Максуди, Россиянең II һәм III Дәүләт думалары депутаты буларак, Дума мөнбәреннән, егерме миллионлы мөселман халыкларының хокукларын яклап барлыгы унбиштән артык нотык сөйли. Думада эшләгән биш ел эчендә ул төрле комиссияләрдә барлыгы йөздән артык чыгыш ясый. Ул Думаның иң күп чыгыш ясаучы, иң эшчән депутаты буларак танылa[1]. Аның һәрбер чыгышы диярлек Россия җәмәгатьчелегендә киң яңгыраш алган, газитләрнең игътибар үзәгендә була. С.Максудиның Думалардагы эшчәнлегенә төрлечә карыйлар, төрле мәсләктәге газитләрдә төрле фикерләргә урын бирә. Шундый тискәре фикер, мәсәлән, «Дума» газитендә дә бар. «Русча бик начар сөйли, һәм сүзләрен дә уйлап–уйлап кына торып сөйли, шуның өчен дә хөтбәсен Дума бер дә тыңламыйдыр»[2]. Шулай да аның һәрбер нотыгы «Россия», «Новая жизнь» кебек газитләрдә, татар газитләрендә, бигрәк тә «Йолдыз» газитендә басылып барыла. С.Максудиның әлеге хезмәттә каралачак чыгышларында шул чорның татар милләтен, мөселман халыкларын борчыган проблемалар, Мөселман фракциясе хәл итәргә тырышкан мәсьәләләр ачык чагыла. Шулай ук аның чыгышларында Думалардагы хаким милләт вәкилләренең мөселман халыкларына булган мөнәсәбәте, алар өчен мөһим булган мәсьәләләргә нинди караштa булулары, гомумән, патша хөкүмәтенең милли сәясәте нинди булуы күренә. Ул бу нотыкларын патша хөкүмәте, рус чиновниклары, рус милләтчеләре һәм миссионерлары тарафыннан җәберләнгән татар милләтенең, мөселман халыкларының мәнфәгатьләрен яклап, Россия дәүләтендәге хаким милләтнең зур урыннар биләгән иң укымышлы аксөякләре, интеллигенциясе алдында чиста рус телендә сөйләгән, шовинистларның һәм октябристларның «җен»

ачуларын чыгарган бу усал чыгышларында С.Максуди французча цитаталар китергән, латинча, гарәпчә мәкальләр, әйтемнәр кыстырып җибәргән, Дума әгъзалары Пуришкевич, Марков, Гучковлар белән французча бәхәсләшкән. Гомумән, ул үз йөзендә, Россия Дәүләт думасы, патша хөкүмәте чиновниклары һәм чит ил журналистлары алдында татар милләтенең дә, ирек бирелгәндә, үсәргә мөмкинлекләр булганда, хаким милләтләр кебек үк, сәяси һәм икътисади яктан көчле, укымышлы бер милләт булачагын исбатларга тырышкан.

С.Максудиның замандашы, татар милли хәрәкәтендә тирән эз калдырган, Октябрь инкыйлабыннан соң Төркиягә китәргә мәҗбүр ителгән галим, язучы Г.Баттал–Таймас үзенең «Ике Максудилар» (Анкара, 1959 ел) китабында аның II–III Дәүләт думаларында сөйләгән нотыкларыннан иң әһәмиятлеләреннән дип алты чыгышын күрсәтә:

1. Рус күчмәннәрен казах–кыргыз җирләренә күчереп утырту сәясәтенә протест нотыгы.

2. Төрекстан авылларында аракы сатуга каршы сөйләгән нотыгы.

3. Россиянең богазлар сәясәтенә каршы сөйләгән нотыгы.

4. Татар халкын панисламизмда гаепләүгә каршы сөйләгән нотыгы.

5. Мәгариф эшендә татар мәктәпләре өчен һичбер ярдәм (бюджет) каралмауны тәнкыйть итеп сөйләгән нотыгы.

6. Россия мөселманнарының иң югары салым түләүләренә дә карамастан, мөселман мәктәпләрен тоту өчен чыгымнарның мәгариф министрлыгы бюджетына кертелмәве турындагы нотыгы.

Әмма, безнеңчә, С.Максудиның Россия Дәүләт думаларында ясаган һәрбер чыгышы шул вакыттагы татар һәм мөселман халыкларының гасырлар буе хәл ителми килгән милли, мәдәни, сәяси, икътисади проблемаларын ни дәрәҗәдә булса да хәл итәргә тырышу, һич югында, бөтен Россия халыкларына егерме миллионлы мөселман халыкларының да барлыгын белдерү чыгышлары да ул. Аның теге яки бу нотыгын әһәмиятле яки әһәмиятсезгә бүлеп карау дөрес булмас, чөнки мөселман депутатының

Россия Дәүләт думасындагы һәрбер чыгышы ул үзе инде бер вакыйга булган.

С.Максудиның нотыкларының һәрберсе диярлек рус газеталарында да басылып барган, һәм алар киң җәмәгатьчелелектә зур кызыксыну уяткан, ә рус шовинистларының ачуларын китергән.

Гомере буе С.Максуди белән уртак тел таба алмаган Зәки Вәлиди дә үзенең «Бүгенге төрек иле (Төркестан) вә аның тарихы» исемле хезмәтендә аның Думада ясаган чыгышларын «гүзәл» дип бәяли, бары тик берничәсен генә ихтирази (тәнкыйди) яктан карап китә[3].

XX гасыр башында инде Оренбург Духовное собраниесенә буйсынган өлкәләрдә генә дә татар халкының алты меңләп мәктәп–мәдрәсәсе булган. Аларның һәрберсен мәхәллә халкы үз исәбенә тота, карый, чөнки Россия мәгариф министрлыгы үз бюджетыннан бу укуханәләр өчен бер тиен дә акча бүлеп бирми. Шуңа да карамастан, аларда рус теле укытылмауны сылтау итеп, мәгариф министрлыгы яңа мәктәпләр ачарга рөхсәт итми. С.Максуди үзенең әлеге нотыгында Россия мәмләкәтендә яшәүче һәр милләтнең үз ана телендә белем алырга, үз милләте балаларын үз ана телендә укытырга хокукы булырга тиеш, ди. Россия дәүләте фәкать руслардан гына гыйбарәт булмыйча, аның бик күп башка кавемнәрдән торуын искәртеп: «Әфәнделәр, тәгълим гомуми мәҗбүри булу низамына карар бирелгәндә һәр кавем үз телендә тәгълим алмак мәҗбүри булсын, дип карар итәргә кирәк»[4], ди.

Думаның беренче елларында, әле үзе дә кадетлар белән фикердәш булган С.Максуди, алар белән конфликтка кермәскә тырыша. Тик тора–бара аның кадетларга булган ышанычы кими. «Без, мөселманнар, һәрвакыт мәктәп–мәдрәсәләребездә тәгълим үз телебездә булуны рөхсәт итүне дәгъва кылабыз. Без моннан соң да бу дәгъвада торачакбыз»[5]. Ул сорыйбыз дими, дәгъвада торабыз, ди. С.Максудиның Россиянең егерме миллионлы мөселман халыклары исеменнән Дума мөнбәреннән ишетелгән тавышы инде мескен татар тавышы булмый. Бу инде үз халкының олылыгын, дәрәҗәсен белеп, аның Россиядә хаким милләт белән бертигез хокукларга ия булып яшәргә, үсәргә тиешлеген тирәнтен аңлап, өлгергән сәясәтче, дәүләт кешесе буларак әйтелгән сүзләр!

II Дәүләт думасының (1907 ел 15 май) «О введении всеобщего начального обучения в Российской империи» турындагы закон проекты каралган мәҗлесендә, С.Максуди депутат буларак, беренче чыгышын ясый: ул төрле мәсләктәге рус депутатларыннан гына диярлек торган Дәүләт думасына мөселман мәктәпләренең аяныч хәлен аңлатмакчы була.

«Без, мөселманнар, рус кавемен һич дошман күрмибез. Рус бюрократиясе илә рус кавеме арасында аерма барлыгын бик аңлыйбыз. Рус телен укытмаска, белмәскә димибез. Рус теле безгә мәмәләкәт тел булганы өчен генә түгел, бәлки гыйлем вә мәгарифкә бер юл булуы өчен дә ляземдер. Хәзер тәгълим гомуми хакында закон хәзерләгәндә мин һәркайсыгыздан Русия дәүләте фәкать руслардан гына гыйбарәт булмыйча, бәлки бик күп төрле кавемнәрдән торуын хәтерегездән чыгармасагыз иде дим»[5].

II Дәүләт думасында тәгълим гомуми турындагы закон кабул ителмичә кала, III Дәүләт думасында әлеге закон ике тапкыр: 1908 һәм 1910 елларда карала. Бу законнарның шулай кат–кат тикшерелүендә, зур бәхәсләр кузгалтуында Мөселман фракциясенең дә роле булгандыр, дип уйларга кирәк. С.Максуди, Г.Еникеев, Ш.Тукаев II–III Дәүләт думаларында бу мәсьәлә каралганда дүрт мәртәбә чыгыш ясыйлар, ә уку–укыту эшләре комиссиясенә кергән Г.Еникеев белән Ш.Мәхмүтов «бу мәсьәләдә бик нык тырышалар».

Мөселман фракциясе бу Комиссиягә әлеге закон проектына үзенең шундый өстәмәләрен бирә:

«1. Мөселманнарга махсусый ибтидаи (башлангыч) школларда рус теленнән башка нәрсәләрнең укытылуы үз телебездә булсын.

2. Яңа канун булачак ибтидаи школаларда мөселман балалары аз булган җирләрдә аларның үзләренең дин вә телләре тәгълиме кануни тәэмин ителсен.

3. Рус теленең безем өчен кирәк булганын вә әһәмиятен бик аңлыйбыз вә бу сәбәптән школаларда рус теленә лаек урын бирелеп тиешле рәвештә укылуын телибез.

4. Мөселманнарга махсусый школаларда укытучылар мөселманнардан булсын»[6].

Шушы закон проектын хәзерләү өчен төзелгән Комиссия, үзенең Думага хәзерләнгән әлеге проектын рус булмаган халыклар депутатларыннан кабул иттерә алмагач, Махсус Совещание төзәргә мәҗбүр була. Совещание поляк, грузин, румын, немец, латыш, татар телләрен әдәбияты булган телләр дип раслый, ләкин Россиядәге мөселманнарның һәрберен дә милләт буларак танымый. Ә бу карар буенча әдәбиятсыз халыкларга милли мәктәпләр ачарга хокук бирелми. Әлеге кагыйдә, кабул ителгән очракта (ә аның кабул ителәчәге бәхәссез) рус булмаган халыкларга тел өлкәсендә хөррият бирелми. «Безнең һәркайсыбызның асылы зур төрек нәселедер. Руслар булган мөселманнарның һәрбере төрекләр тамырының ботакларыдыр. Хөкүмәт тә, депутатлар да, Россиядә төрки халык дигән милләт юк дип, һәрберебезнең бабалары төркиләр икәнне белмәгәнгә салыналар»[7]. Ул үзенең бу чыгышы белән барлык мөселман халыкларының уку–укыту эшләренә булган хокукларын якларга, аларга да үз телләрендә белем алу хокукын законга керттерергә тырыша.

III Думаның 1908 елның 1 май мәҗлесендә бюджет мәсьәләсе карала. С.Максуди әлеге мәҗлестә Россия мөселманнарының ихтыяҗлары һәм хәлләре турында, аларның иң югары налог түләүләренә дә карамастан, мөселман мәктәпләрен тоту чыгымнарының мәгариф министрлыгы бюджетына кертелмәве турында озын нотык сөйли. Аның бу чыгышы «Россия» гәзитендә дә басылып чыга. Россиядәге бар халыкның җидедән берен тәшкил иткән мөселманнарга, ягъни егерме миллионлы халыкка Россиянең ике, ике ярым миллиардлы бюджетыннан уку–укыту эшләре өчен утыз биш мең сум акча бүленгән була. Бу – патша хөкүмәтенең мөселман халыкларына булган мөнәсәбәтенең һәм милли сәясәтенең ниндилеген бик ачык күрсәтә торган сан. Дәүләт думасы 1910 елның октябрендә әлеге закон проектына кабат әйләнеп кайта, шул мәҗлестә Мөселман фракциясе исеменнән Г.Еникеев белән С.Максуди сүз ала: «Инородецлар өчен булган мәктәпләрдә, училищеларда, школаларда учительләр мөселман булырга, укучыларга Ислам дине укытылырга тиеш. Без хөкүмәтнең мөселманнарга мөнәсәбәте ни рәвешле булырга тиешле икәнлеген тәгаен итеп куярга тиешбез. Бу асыл мәсьәлә:

Русиядә мөселманнарга булыргамы, булмаскамы? Бездә шундый бер тәкать тота алмаслык иҗтиһад бар, ул һәрбер кысуларга, изүләргә каршы торачактыр»[8].

Мөселман фракциясенең гомум тәгълим турындагы закон проекты каралганда керткән бу ляихәсен (тәкъдимен) законга кертү–кертмәү мәсьәләсе Думада берничә ел дәвамында кызу бәхәсләр кузгата торган мәсьәләгә әверелә. Мөселман фракциясе керткән бу ляихәне үткәрмәү өчен рус миссионерлары гына түгел, Думадагы күп санлы октябристлар, аларның сул канатыннан булган һәм III Думага Казан шәһәреннән бердәнбер депутат булып сайланган профессор М.Я.Капустин да «ут ягып» көрәшә. Депутат булып сайланганда Казан мөселманнарының да «максудларын химая кылырга вәгъдә итеп» аларның тавышларын алган М.Я.Капустин III Думада мөселманнарның теле һәм мәктәпләренә каршы чыгып сөйләүчеләрнең беренчесе була. Ул: «Милюков җәнаблары безгә: әгәр дә бер төрле милләткә аларның теләгәннәрен бирсәң, алар Русияне сөярләр, безгә алар теләгән нәрсәләрне бирергә кирәк, диде. – Ләкин алай эшләгәндә бу – Русияне сөю булмаячак», ди М.Я.Капустин. Профессор М.Я.Капустин фикеренчә, инородецлар бернинди хокуклары булмаган килеш тә Россияне сөяргә тиеш булып чыга.

Инде XIX гасыр азагында ук ысул җәдид белән укытуга күчкән күп кенә мәктәп–мәдрәсәләрдә тел буларак рус теле укытыла башлый. 1905 елгы инкыйлабтан соң, заманалар үзгәреп, инде татарлар арасында татар халкының икътисади, мәдәни яктан үсешен теләгән кешеләр рус телен белүнең, аның балаларга укытуның кирәклеген торган саен күбрәк аңлый башлыйлар. Рус теле аша дөнья икътисады, мәдәнияты, әдәбияты белән танышып һәм шуның нәтиҗәсендә тигез хокуклар яуларга омтылган татар зыялылары һәм алар исеменнән сөйләгән С.Максуди Думада тәгълим гомуми мәсьәләсе каралганда да, бюджет мәсьәләсе тикшерелгәндә дә, патша хөкүмәтенә, Дәүләт думасына аның зыялы, укымышлы, әмма шовинист депутатларына үзләренең максатларын, теләкләрен аңлатмакчы булып, рус милләтчеләре белән конфликтка керә–керә берничә мәртәбә чыгыш ясый.

Патша хөкүмәте тарафыннан татар халкына яңа мәктәп–мәдрәсәләр ачарга рөхсәт ителмәсә дә, Россиядә инородецлар өчен школалар ачып миссионерлык белән шөгыльләнү хөкүмәт тарафыннан нык яклана.

Ислам дине кабул ителгәннән бирле мөселман балаларына Ислам диненең ни икәнен өйрәткән, уку–язу күнекмәләре бирә торган урын – мәктәпләр, христиан динен тотучы халыклардан аермалы буларак, татар халкында киң таралган була. Россиядә руслар арасында башлангыч мәктәпләрдә уку аз таралган, шунлыктан хөкүмәт һәм III Думаның мәгариф комиссиясе уку–укыту турындагы закон проектын тикшергәндә рус телендә уку–язу, белем таратуны, ягъни башлангыч мәктәпләр ачуны күздә тоткан. Патша хөкүмәте милли сәясәтенең максаты – уку–язуны русча итү. Менә шушы мәсьәлә бөтен Россиядә, мөселман халыкларында, бигрәк тә татар халкы һәм аның зыялылары арасында шау–шу һәм бәхәс куптарган мәсьәләгә әйләнә: бер яктан бу мәсьәләдә патша хөкүмәте алып барган милли сәясәт ачык чагылса, икенче яктан рус булмаган милләтләрдә үз милләтләрен, телләрен саклау хәрәкәте күтәрелеп чыга. Думада бу закон проекты каралганда мөселман халыкларының дини мәктәпләрендә рус телен укыту әле мәҗбүри булмый, бу мәктәпләрдә рус теле үзләре теләсә генә укытыла. Ләкин С.Максуди моннан соң дини уку йортларында уку процессы элеккечә дәвам итәчәгенә ышанмый, чөнки аларда, алга таба, рус теле укытылмаса, хөкүмәт тарафыннан бюджеттан акча бирү каралмаячак, ә бу хәл исә мәхәллә саен бер мәктәп, мәдрәсә тоткан халык өстенә авыр йөк булып төшәчәк. Шуны яхшы аңлаган С.Максуди, мәктәпләрдә рус телен кертмәс өчеп тырышканчы, хөкүмәт ачачак ибтидаи укуханәләрдә һәм инородецлар өчен булган школа һәм училищеларда һәр халкының үз ана телен һәм динен укыту тиешлеге турындагы бер пунктны законга кертүне таләп итәргә кирәк, дип чыга. Мөселман фракциясе мәктәпләр мәсьәләсенә бик зур әһәмият бирә һәм мәктәпләрне уку–укыту турындагы законнан төшереп калдыру өчен бөтен көчен сарыф итә, дип яза С.Максуди үзенең «Тәгълим гомуми мәсьәләсе»нә багышланган «Сөбхәтләр»ендә. Әгәр, бу закон кабул ителеп, мәктәпләр гомуми уку законы астына кертелсә, рус мәгариф министрлыгы

биргән укыту программасы буенча укырга риза булмаган мәктәпләр ябылырга тиеш була.

Татар халкының Россия кул астына кертелгәненә дүрт йөз елга якынлашып килгәндә халык үзенең ана телен, динен, гореф–гадәтләрен шушы көнгә кадәр саклап кала алган. Россиянең нәкъ уртасында булган килеш, рус миссионерларының аның диненә, теленә каршы туктаусыз алып барган көрәшенә карамастан, татар милләтен милләт буларак саклап кала алган нәрсә – аның мәхәллә мәктәпләре булган.

Рус миссионерлары белән берлектә эш иткән патша хөкүмәте һәм аның мәгариф министрлыгы татар мәктәп–мәдрәсәләренә уку–укыту эшләрендә ирек бирүне рус дәүләте өчен куркыныч эш дип санаганнар. Татар мәктәп–мәдрәсәләре, башка дәүләт мәктәпләре шикелле үк, дәүләт кулына күчәргә һәм аларда уку–укыту эшләре дәүләт интересларында алып барылырга, патриотик рухта булырга, Россиягә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләргә, рус дәүләтенең бурыч–максатларына якынлаштырып белем бирелергә, татар теле тел буларак кына укытылырга тиеш дигән фикерне алга сөргәннәр.

Әгәр дә татар халкының мәктәп–мәдрәсәләрдәге уку–укыту шушы юлга кертелсә, моның татар халкы өчен зур фаҗига буласын аңлаган зыялылар, милләтпәрвәрләр исеменнән Думада чыгыш ясаган С. Максуди болай ди: «Безнең мәктәпләребез милләт фикере, теләге аркасында вөҗүдкә чыккан нәрсә. Аның бирәчәк тәрбиясе белән милләтнең рухи җаны арасында зур бер мөнәсәбәт бар. Земство тарафыннан ачылачак мәктәпләр никадәр мөкаммәл булмасын, аларның рухи тәрбиясе белән безнең милләт балаларының кечкенә мәктәпләрдә алган тәрбиясе арасында аерма булачак»[9].

Татар халкының үз милләтен сөюче халык, аның диниясе һәм миллиясе тәрәкъкый иткән, үскән халык булуының нигезе менә шул мәктәпләрнең искедән калган милли рухта булуларыннан килгәнне күрсәтеп С.Максуди: «Милләтләрне агарткан нәрсә – уку. Мәктәпләрдә рус телен аерым тел итеп укыту лязем (кирәк), ә хөкүмәт укуханәләрендә динебез һәм телебез укытылу лязем, әгәр мәктәпләребез киләчәктә уз ихтыярлары белән русча укыту-

ны кертмәсәләр, милләт балаларының, күбесе укуханәләргә китәчәк»[10], ди. Ә карала торган закон проектында исә «Укуханәләрдә азрак булган халыкның дине дә укытылырга мөмкин. Әгәр бу расходка акча табылса, әгәр дә укуханә советы рөхсәт бирсә» дигән пунктның Россия укуханәләрендә хаким милләт диненә, ягъни православный халыкның динен югары куеп, хөррият Диниягә зыян китерү, башка динне кысу, дип билгеләп, ул хаким милләт чиновникларының, бу расходларга акча тапмаячагын, укуханәләрдә мәхкүмә милләтләрнең динен, телен укытуга рөхсәт бирелмәячәген үзенең «Сөбхәтләр»ендә кат–кат яза. Беренче карашка Мөселман фракциясе бу закон проектын кирәгеннән артык җентекләп тикшерә кебек. Әмма С.Максудиның бу мәсьәләгә булган карашы аның «Сөбхәтләр»еннән ачык күренә: ничә гасырлар буе рус хөкүмәте изүе астында яшәгән татар халкының милли аңы уянып килә, әгәр форсаттан файдаланып, кечкенә генә булса да җиңеллекләр, иркенлекләр алып калырга тырышмасак, тарих гафу итмәс.

«Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телемебезне саклый алуымызга бәйледер. Иң мөһиме – ул телнең ибтидаи мәктәпләрдә өйрәнелүедер. Милләтнең нигезе – телдер. Мин телемезне укытмау–укыту безнең милләтемезнең исән калу–калмавы мәсьәләсе белән бер дип уйлыйм. Укуханәләрдә телемез укытылса, без калырбыз, укытылмаса, акрынлап бетәрбез, безне моннан милли мәктәпләребез дә алып кала алмас»[11].

С.Максуди үзенең Дәүләт думасында ясаган әлеге чыгышында сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән Төркестан халыкларының аяныч хәле, аларның мәдәни, икътисади яктан, мәгарифтән бик нык артта калулары турында да ачынып сөйли. Россиягә буйсындырылган вакытта бу халыкларның мәгарифе, мәдәнияты, икътисады ни хәлдә булса, хәзер дә шул хәлдә булуын ул бик күп дәлилләр белән исбатлап, рус милләте, Россия бөтен рус булмаган халыкларга мәдәният алып килә, дип «лаф» орган октябристларга, рус шовинистларына патша хөкүмәте милли сәясәтенең чын йөзен күрсәтә.

XIX гасыр ахырында Төркестанның беренче генерал–губернаторы фон Кауфман мәшһүр миссионер Ильминскийга Төркестан-

да миссионерлык эшен ничек башлап җибәрү турында киңәш сорап мөрәҗәгать иткән була. Ильминскийның бу тарафлардагы миссионерларны Төркестанны православныйлыкка әйләндерү өчен нинди юллар белән, ничек эш алып барырга кирәклекне өйрәтеп язган хатлары, еллар узгач, басылып та чыккан. Ул китап Төркестанда эшләүче миссионерлар өчен кулланма булып торган. Алар бу эшкә кыргызларның үз араларыннан Алтынсарин дигән кешене табалар һәм аны, хәтта Казанга җибәреп, русча укытып, рус миссионерларының эше белән таныштырып та кайтаралар. Төркестан мөселманнарын рус алфавиты белән укытып, бөтен Төркестанны руслаштыру максатыннан миссионерлык әсасена нигезләнеп салынган 92 русско–туземская школа ачыла. Ләкин бу школалар ачылып аларда берничә ел укыту эшләре алып барылганнан соң, Фирганә өлкәсендәге народное училищеләр инспекторы бу өлкәдә ревизия ясый һәм Фирганә валиятендәге русско–туземская школалардагы уку–укыту эшләрен канәгатьләнерлек тапмый: 1906—1908 елларда биредәге унбер мәктәптән бер генә мәктәп тәмамлап чыккан кеше дә булмый. Үзләренең гореф–гадәтләренә чит–ят булган укытучыларның алар белмәгән телдә укытулары, укытучылар тарафыннан Ислам диненә карата ихтирам булмау, ана телләре һәм үз диннәре укытылмау – укучыларда да, җирле халыкта да мәгарифкә, мәдәнияткә омтылыш тудырмый.

Россия хакимлеге астына кергән һәм мәгариф, мәдәният керер дип көткән Төркестан халкына, Төркестанга Россия алар теләгән мәдәниятны бирми, ди С.Максуди үзенең чыгышында. Чөнки бу халыкларга мәдәният кертү, мәгарифләрен үстерү өлкәсендә Россия хөкүмәтенең берничнди планы да булмый, шуңа күрә дә бу эш иң баштан ук рус миссионерлары кулына тапшырыла. «Руслар, шулкадәр зур бер өлкәгә хуҗа булып та, үзләренең фәгыйлиятьсезлегендә (эшлексезлегендә), хәтта үз гражданнары булган мөселманнарны исәпкә дә алмауларында һәмишә дәвам итәчәкме? Бүген Дума да, Русия дә үзенең мөселманнарга булган мөнәсәбәтен билгеләп куярга тиеш. Безгә иттифакый (очраклы) очрашкан ике юлчы шикелле барырга кирәкме, я булмаса, безнең арабызда бер дуслык вә карендәшлек мөнәсәбәтләре булырга тиешме?

Без бу мәсьәләне тәмам хәл кылмаганда мәдәният вә тәрәккый эшләре, бигрәк тә Төркестан тарафында, һичбер алга китәчәк түгел.

Бу асыл мәсьәлә: Русиядә мөселманнарга булыргамы, булмаскамы? Хөкүмәтнең әле бу мәсьәләне хәл итеп куйганы юк. Әмма миссионерлар җәмгыятьләре: «Русиядә мөселманнар булмаска тиеш», диләр[12]»

Россиянең киң җәмәгатьчелегендә, матбугатта шактый зур резонанс тудырган, рус миссионерларын чыгырдан чыгарган бу чыгышның ахырында С. Максуди III Дәүләт думасы депутатларына: «Әфәнделәр, мин сезгә, уңнарга, сулларга бүлеп түгел, ә Дәүләт думасының мәркәзендәге кешеләргә мөрәҗәгать итәм: миссионерлар Русияда мөселманнар булмасын, ди. Хөкүмәтнең ныклы фикере юк. Әфәнделәр, безнең хакта сезнең фикерегез ничек? Сез безгә үз телебездә укырга мәктәпләр бирәсезме? Сез безгә мәгарифне мәгариф көенчә бирәсезме, я сез мәгарифне руслаштыру булсын дисезме?» дип мөрәҗәгать итә. «Әмма кем генә дә «мөселманнар булмасын» дип карар бирсә дә, аларның карарлары вөҗүдкә чыкмас (тормышка ашмас). Безнең мәүҗүдемезгә ярдәмче куәтләр бар, бездә шундый бер тәкать тота алмаслык иҗтиһад бар, ул иҗтиһад һәрбер кысуларга, һәрбер изүләргә каршы торачактыр. Изү куәтенең дәрәҗәсенә карап бу куәт тә артачагына шөбхә юктыр. Без бар идек, бүген дә бар һәм моннан соңара да булачакбыз!»[13] дип, III Думаның шовинист депутатларын өнсез иткән, Россиянең прогрессив җәмәгатьчелеген шаккатырган сүзләрен әйтә. Аның бу чыгышы рус шовинистларына бик авыр тәэсир итә, һәм «Казанский телеграф» газетасы: «Бу мәктәп–мәдрәсәләр мәгариф министрлыгы кул астына кертелгән дип хисап ителсәләр дә, аларда ниләр укытылганы ныклап тикшерелми, тикшерелсә, аларда Максудов, Еникеев шикелле, ачыктан–ачык Русия патшалыгыннан аерылырга теләүчеләр чыкмас иде. Менә безнең Русиянең яхшы җанлылыгы нинди нәтиҗәләр тудыра: Максудов, ибтидаи мәктәпләр хакындагы пунктның, мөселманнар теләгәнчә кабул ителү–ителмәве, Русиядә мөселманнарның булуы яки булмаулары мәсьәләсен хәл кылачак, диде. «Әфәнделәр, без бу көнгә кадәр булдык, бүген дә бар, моннан соңа-

ра да булачакбыз!» диде.Бу ни дигән сүз? Бу — боларның бунтка дәгъват итүләреме?»[14] дип яза.

1905 елгы инкыйлабтан сон татар халкы ирешкән азмы–күпме иркенлекләрне дә кабул итә алмаган, татар халкы тәрәкъкыятенә каршы төшкән һәм үзе белән бергә яшәгән халыкның милли аңы үсүен, аның Россиянең мөселман халыклары милли хәрәкәтенең идеологы булуын танырга теләмәгән рус шовинистлары рупоры булган «Казанский телеграф» газетасы, билгеле, тыныч кала алмый. Газета С. Максудиның 1909 елда Россия Дәүләт думасы депутатлары делегациясе составында Англиягә ясаган визиты һәм депутат буларак, 1908, 1910 елларда Төркестанга ясаган сәяхәте, андагы мөселман халыклары белән очрашулары турында, болар — барысы да мөселманнарга ирек бирүнең начар нәтиҗәсе, дип язып чыга.

III Дәүләт думасында уку–укыту турындагы закон проектының кабат–кабат каралуыннан, уңнарның да, сулларның да, Мөселман фракциясенең дә бу закон пунктлары турында кызып–кызып бәхәсләшүләреннән, әлеге проблеманың Россия мөселманнары өчен никадәр мөһим булганлыгы ачык күренә.

Рус миссионерлары яңа тип мәктәп–мәдрәсәләрнең яшәве, беренчедән, дәүләт интересларына каршы килсә, икенчедән, башка вак халыкларны татарлаштыру белән шөгыльләнәчәкләр дигән сылтау белән татар мәгарифенә үсәргә комачаулык итеп килгәннәр.

С.Максуди һәм аның фикердәшләренең мәктәпләр һәм уку–укыту мәсьәләсе буенча җае чыккан саен Дума мәҗлесләрендә, аның комиссияләрендә ясаган чыгышлары, үзенә күрә, патша хөкүмәте алып барган милли сәясәткә каршы көрәшнең бер ысулы да булган.

Ләкин Думадагы аз санлы Мөселман фракциясе никадәр генә тырышмасын, III Дәүләт думасы бу законны рус хөкүмәте ничек теләсә, шулай кабул итә: мөселман мәктәп–мәдрәсәләре рус мәгариф министрлыгы карамагына тапшырыла, ә инородецлар укый торган училище, школаларда ана теле һәм дин белеме укытылмый, шул вакыттан башлап мөселман мәктәп–мәдрәсәләрдәге уку–укыту эшләренең программасын, алардагы укыту эшләренең торышын рус чиновниклары тикшерә, бәяли башлый.

«Ошбу соңгы ун ел эчендә хөкүмәтнең мөселманнар хакында сәясәте мәшһүр Ильминскийның киңәше илә йөртелде. 17нче Октябрь манифесты игълан ителгәннән соң да хөкүмәт, хәзерге халык вәкилләренең бар икәнлегенә карамыйча, православный чиновниклар тарафыннан тәкъдим ителгән фикерләргә иярә, алар хакындагы мәгълүматларны миссионерлар матбугатыннан ала»[15].

Татар халкының үз мәгарифенә, мәдәниятына игътибар бирүенә, ягъни Исламны әүвәлге хәленә кайтарырга теләүләренә рус милләтчеләренең (шовинистларының), башында Казан духовная семинариясенең ректоры Алексей торган рус миссионерларының татар халкының милли–мәдәни үсешенә бар көчләре белән каршы торуларына ачынып, нәфрәтләнеп, С.Максуди: «Хәриҗия (тышкы эшләр) департаменты безне милләт вә дин җәһәтеннән аерып, милләтемез белән көрәшергә, диниябез өчен бертөрле хөррият бирергә уйлыйлар. Әмма Русия мөселманнары һичбер вакыт милләт илә динне аермады. Миңа моңарчы, без мөселманнарның Ислам динендәге русиялеләр генә түгел, бәлки Ислам динендә торучы вә үз гореф–гадәтләре илә яшәүче бер милләт икәнлеген игълан итәргә туры килмәгән иде. Хәзер моны әйтәм һәм беркем авызымны томаламыйча торып, моны әйтүдән туктамаячакмын. Сезнең каршыгызда Ислам динендә яшәүче бер милләт бар. Без, аерым бер милләт булганга күрә, һәрвакытта үзебезнең лисаныбызны, үзебезнең әдәбиятыбызны нәшер итәргә иҗтиһад итәчәкбез һәм үзебезнең рус гражданы булып торырга никадәр хакыбыз булса, шулкадәр шул хакыбыздан файдаланып, башка милләтләр яшәгән шикелле яшәчәкбез. Шул исәптән мин сезгә игълан итәм һәм хөкүмәткә тәнбиһ (кисәтү) кылам: безнең милләтебезгә, әгәр дә мәүҗүд исә, безнең милли хәрәкәтләребезгә каршы көрәшергә маташу, безнең динебез илә көрәшергә маташу булып күренәчәктер. Хәриҗия департаментының динебезне милләтебездән аертырга тырышуы барып чыкмаячактыр.

Без, бердән, мөселман, икенчедән, хосусан бер милләт булып яши алачак һәм яшәячәкбез. Мин моңа ышанам.

Без Иван Грозный заманындагы кылыч вә ут илә куркытып православныйга көчләп кертүгә иҗтиһад кылынган заманнарда

чыдап кала алган, бүгенге бу департаментның хәйлә вә мәкерләренә чыдап кала алачакбыз. Мин әйтәм: без үзебез бер милләт булып Русиядә яшәячәбез!» ди[16].

Патша хөкүмәте мәктәп–мәдрәсәләрнең татар халкының милли аңын үстерүдә әһәмиятле роль уйнаганын тиз төшенгән, чөнки татарларда мәчетсез, мәктәпсез авыл булмаган, ә инде мәдрәсә тоту һәр авыл өчен мәртәбә саналган.

XX гасыр башында җәдидчелек хәрәкәте күтәрелеш алган чорда, Казанда «Госмания», «Мәрҗәния», «Мөхәммәдия», «Касымия», Оренбургта «Хөсәения», Уфада «Галия», Бакчасарайда «Зынҗырлы», Троицкийда «Мөхәммәдия», Уральскида «Мотыгия», Казан губернасындагы авыллардагы Курса, Каргалы, Кышкар, Ташкичү, Эстәрлебаш, Мәчкәрә, Буби һәм башка мәдрәсәләр татар халкының мәгърифәт учакларыннан саналганнар.

Үзенең фаҗигале язмышы белән тарихка кереп калган Буби мәдрәсәсе Иж–Буби авылында (хәзерге Әгерҗе районына керә) 1781 елда оештырылган һәм шул чорның иң мәшһүр мәдрәсәләреннән булган. XX гасыр башы – Буби мәдрәсәсенең татар мәгарифе һәм тәрәккыяте күгендә якты йолдыз булып балкыган чор. Бирелгән яңача уку–укыту, яшәү тәртипләре, хөр фикер ул вакытның консерватив муллаларына да, патша хөкүмәте чиновникларына да тынгылык бирмәгән. Патша хөкүмәте бу яңача фикерле мәдрәсәләрнең татар халкының тәрәккыятенә, милли аңы үсешенә юл ачканын яхшы аңлаган, чөнки Россия Дәүләт думасы мөнбәреннән төрки халыкларның хокукларын яклап чиста рус телендә ялкынлы, үткен чыгышлар ясаган С.Максуди да шушы мәктәп–мәдрәсәләрдә укыган ич.

Кара реакция елларында патша самодержавиясе һәм рус миссионерларының татар милли мәгарифенә котырынып ташлануы нәкъ менә шундый мәдрәсәләрнең берсе булган Буби мәдрәсәсеннән башлана. Рус хөкүмәтенең татар мәктәп–мәдрәсәләренә каршы башлаган погром–тентүләрнең татар милләтенең мәгарифенә, мәдәниятенә каршы күтәрелгән хәлиткеч көрәшнең башы гына икәнен яхшы аңлаган С.Максуди Дәүләт думасының 1911 елның 26 февралендәге мәҗлесендә тарихка кереп калган нотыгын сөйли.

«Хәзер һәр җирдә мөселманнар арасында тентү вә кулга алулар дәвам итә. Бер ай эчендә бер Вятка вәлиятендә генә ун мулла төрмәгә алынды, биш мәдрәсә, биш мәктәп ябылды. Себердә берничә мулла белән өч мөгаллим кулга алынды. Казанда мулла Галиев белән Апанаевларда, Уфада Җантурин белән Килдебәковларда тентүләр булды, барлыгы йөз илле җирдә тентү вә кулга алулар булды.

Мин сорыйм: ник Буби муллаларын гаепләре расланганчы ук төрмәгә яптылар? Арестовать итүчеләр городовойлар, исправниклар бит, ә алар татарча да, гарәпчә дә белмиләр. Тентү вә кулга алуларның болай ешлануы, шөбхәсез, мәзкүр (искә алынган) даирләрдә инородецларга дошманлык хөкем сөрүедер. Хөкүмәтнең безнең хактагы сәясәте үзгәрүнең сәбәбе бездә түгел, бәлки хөкүмәтнең сәясәте алышынып, рус милли фанатизмы юлын тотудадыр. Чөнки үз милләтен генә сөюче милләт сәясәте (хаким милләт) нинди дә булса бер инородец мәсьәләсен куертып кына яши аладыр. Үзен «бөек» милләт санаган милләт әле яһүд, әле поляк мәсьәләсен кузгату белән генә шөһрәт ала, шуңа күрә, хәзер алар бөтен көчләре белән Русиядә мөселман проблемасы тудырырга тырышалар. Бу – Меньшиковлар, Бобрынскийлар, Гучковлар сәясәтедер. Әйе, әфәнделәр, сез максудыгызга ирешерсез, фәкать бу Ватан өчен файдалы булырмы?»[17].

Рус самодержавиясе пантюркизм дигән яңа хәрәкәтләр уйлап чыгарып, милли күтәрелеш чоры кичергән татар халкына, аның зыялыларына каршы үзенең астыртын әзерләнгән ныклы көрәшен башлап җибәрә. С.Максуди, моңа үз бәясен биреп, Думаның 1912 елның 3 март көнге мәҗлесендә болай ди: «Мөселманнарда пантюркизм, панислмазим юк, ә бары тик дин, мәгариф, мәдәният юлында берләшергә теләгән тәрәккыйпәрвәр мөселманнарны, юк хәрәкәтне бар дип, гаепләү генә бар. Без бөтен Русия халкы күрә торган кысынкылыклардан башка, фәкать мөселманнар булган өчен генә махсус кысынкылыклар күрәбез. Хөкүмәт Русия мөселманнарының тәрәккый итүен, алга баруын теләми»[18].

Ул бу сәясәтнең төп асылын, сәбәбен «алар турыдан–туры безнең мәгариф вә тәрәккый хәрәкәтебезне туктата алмыйлар, шул

сәбәпле, алар безгә яла ягып (панисламизмда гаепләп – Ф.Г.), безне хөкүмәткә хилаф хәрәкәт итүчеләр дип күрсәтеп, безнең хәрәкәтебезне туктатмакчы булалар», дип, татар халкы арасында көчәйгән тентү һәм кулга алуларның тора–бара халыкта рус дәүләтенә каршы фикерләр, эшләр туачагына китерәчәген дә кисәтеп: «әгәр эшләр уңнар фикере буенча йөреп, хәзерге рухта дәвам итсә, Ватанга муафыйк түгел карашлар мәйданга килер. Мин сезгә моны башта ук белдереп куям», ди. «Әфәнделәр, нинди генә эшләр кылынса да, арабыздагы тәрәкъкый вә мәдәният хәрәкәтен туктата алмаслар. Бездә милли мәгариф хәрәкәте башланды да, нык тамыр да җәйде, инде безнең уннарча матбагаларыбыз, гәзитләребез, журналларыбыз вөҗүдкә килде. Бу кадәр мәдәният коралларына ия булган бер милләттәге хәрәкәтне басу мөмкин түгелдер. Граф Бобрынский миңа: «Арагызда чуалулар һәм хәрәкәт бар. Без моны туктатырбыз» дигән иде. Ләкин бездәге милли хәрәкәтне һичберәү туктата алмас, рус милләтенең мәдәни кисеменең ярдәме белән тәрәкъкый хәрәкәтебез алга баруында дәвам итәр!»[19].

1908 елга кадәр миссионерлар әдәбиятында панисламизм дигән сүз булмый. 1910 елда Казан миссионерларының съезды уздырыла, менә шул съезда, татарларга каршы чаралар оештыру йөзенннән, унике пункттан торган резолюция кабул ителә. Шулар арасында: исламияткә каршы тору өчен татарлар арасында чиркәү мәктәпләрен күбәйтүне сорарга; инородецлар булган епархияләрдә һәм өязгә окружной миссионерлар тәгаен итәргә; Русиядәге һәм читтәге мөселман матбугатында нинди фикерләр барлыгын белдерү өчен даими бер газета нәшер итәргә; хәзер дә вөҗүдтә булган мөселман мәктәпләрен хөкүмәт министрлыгына тапшырырга кебек пунктлар да бар[20].

1911 елда гына да татарлар яши торган урыннарда йөз илле җирдә тентү ясалган, җитмештән артык зур мәктәпләр ябылган, иң зур гәзит һәм журналлар туктатылган. Шулай итеп, хөкүмәт, мөселманнар арасында панисламизм дип аталган куркынычлы хәрәкәтне туктатабыз, дигән сылтау белән татар халкына һәм аның тәрәкъкыятенә каршы көрәш ача. Бөтен Русия һәм бөтендөнья мөселманнарының Ислам дине нигезендә берләшергә, ә

Идел–Кама буе татарлары Русиядән аерылырга тырышалар дигән уйдырмаларны бары тик хөкүмәтнең рус булмаган милләтләргә каршы сәясәтен алып баручы даирәләре һәм рус шовинистлары уйлап чыгаруларын фаш итеп, С.Максуди: «Мөселман зыялылары эшкә ашмавы күзгә күренеп торган мондый фикер илә бер дә мәшгуль була алмыйлар», ди.

«Мәдәният җәһәтеннән артта, администрация ягыннан кысылган, икътисади яктан ярлы булган өч–биш миллионлы Волга–Кама буендагы татарларның бөтен җир йөзендәге мөселман халкын берләштерергә тырышуы мөмкинме? Бу бит Филлиппин мөселманнарын, Һиндстан мөселманнарын, Азия, Африка һ.б. җирләрдәге мөселманнарны берләштерү дигән сүз. Әгәр дә панисламизмның вөҗүде хакындагы ялгыш фикерләр шул кысуларга сәбәп булмаса, мин һичбер вөҗүде булмаган хыялый панисламизм хакында сөйләп тә тормас идем»,[21] ди.

Миссионерлар, бигрәк тә Казан миссионерлары, Россиядә сәяси роль уйнарга һәм рус хөкүмәтен мөселман халыкларына каршы агрессив сәясәт юлына кертергә тырышалар. Казанда уздырылган миссионерлар съездының резолюциясе белән хөкүмәтнең Дахилия (эчке эшләр) нәзарәтенең 1910 елны П.А.Столыпин тарафыннан «Идел буе төбәгендә татар–мөселман йогынтысына каршы чаралар үткәрү» буенча оештырылган Махсус Киңәшмәнең карарлары аваздаш булуыннан хөкүмәтнең милли сәясәте белән миссионерларның тоткан юлы бер икәне күренә[22].

С.Максуди Думаның 1912 елның 3 март мәҗлесендә сөйләгән әлеге нотыгында Казанда булган миссионерлар съезды белән хөкүмәт тарафыннан чыгарылган карарларның бердәй булулары ук, ягъни мөселман мәктәпләрендә җәгърафия, тарих, рус теле һәм башка фәннәрне укытудан тыю, мәктәп–мәдрәсәләрдә бары тик дин дәресләрен генә укытуны калдыру һәм яңа мәктәпләр ачарга рөхсәт бирмәү – панисламизмга каршы көрәш лозунгасы астында татар халкының тәрәккыятенә каршы көрәш булып чыкканны раслый торган фактлар икәнен дә аңлатып уза.

«Әфәнделәр, Русия мөселманнары арасында Русия дәүләтенә зыян китерерлек һәм аның мәнфәгатенә каршы һичбер хәрәкәт вә теләк юк. Ләкин дөньяда шундый нәрсәләр бар ки, алар ха-

лыкның иң садыйк өлешен дә чуалта, иң тыныч гакылларны да дөрес юлдан чыгара ала һәм иң тыныч халык арасында да ышанычсызлык пәйда иттерә аладыр. Ә хөкүмәтнең бу сәясәте шуңа китерәчәгенә сезне кисәтәм»[23]. С.Максудиның әлеге чыгышы турында «Казанский телеграф» гәзите: «Казан татары һәм Париж адвокаты» хөкүмәт булмаган панисламизмны татарларны эзәрлекләү өчен уйлап чыгарды ди», дип язып чыга[24].

«Панисламизм – сәясиләнгән рус миссионерлары уйлап чыгарган бер нәрсә ул. Сез шул панисламизм сәясәте аркасында яңа гына уянып килә торган мөселманнарның алга баруларына, тәрәкъкыятләренә каршы киртә булып төшәсез. Русия мөселманнары арасында Русия дәүләтенә зарар китерерлек һәм аның мәнфәгатенә зыян итәрлек һичбер хәрәкәт вә теләк юк. Бездә бер теләк бар, ул әүвәлдә Русия империясенең камил хокуклы гражданины булуны теләүдән гыйбарәттер. Бу максудларыбызга ирешәчәкбез. Чөнки, теләсә нинди каршы тәдбирләр (чаралар) кылынса да, егерме миллионлы бер халык гомергә кысылган хәлдә кала алмаячактыр. Кайчан булса да халык өскә чыгар. Мин уйлыйм: без һәрвакыт Русия дәүләтенең алга баруы, зураюы өчен, Русия гражданы буларак, җәмәгать эшләрендә бергә йөриячәкбез. Безгә үзебез теләгәнчә бабаларыбыздан урнашып калган милли рухларыбыз илә үз халкыбыз һәм үз гаиләбез арасында тыныч яшәргә ирек кенә бирегез!»[25].

Соңгы елларга кадәр татар либераль–буржуазиясен, аның милли хәрәкәте идеологларын, җитәкчеләрен пантюркизм, панисламизмда гаепләү үзебезнең галимнәр арасында да зур «уңыш» белән алып барылды. Алар XX йөз башы татар милли хәрәкәте идеологлары тоткан бу юлны төрки халыкларны эксплуатацияләү өчен булган милли бердәмлек дип, милләтчелек агуы белән агулап, аларны гомуми демократик хәрәкәттән, рус пролетариатының сыйнфый көрәшеннән аеру максатында файдалануда гаепләделәр[26].

Бөтен төрки дөньяны һәм төрки халыкларны, шулай ук ислам дөньясын берләштерү мөмкин түгеллеген аңлаган милли хәрәкәт җитәкчеләре һәм идеологлары моңа көч тә сарыф итмәгәннәр, үз алларына моны максат итеп тә куймаганнннар.

Алар өчен рухи бердәмлеккә, рухи берләшүгә ирешү әһәмиятле булган. Чөнки алар Россиядә мәхкүмә милләт булып яшәгән мөселман халыкларының бары тик шул рухи берлеккә ирешеп, бер—берсенә ярдәм итешеп кенә милли, икътисади һәм сәяси яктан тәрәккъый итәчәкләренә ышанганнар.

Курку белмәс милләтче, оста сәясәтче С. Максудиның Дәүләт думасы мөнбәреннән сөйләгән бу ике нотыгы Россиянең киң җәмәгатьчелеген таң калдырган, чөнки аның әлеге чыгышлары патша хөкүмәтен, аның мөселман халыкларына каршы алып барган милли сәясәтен гаепләү акты булып яңгыраган, панисламизм дигән нәрсәне уйлап чыгарып, мөселман халыкларының, татар халкының тәрәккъыятен туктатып торырга теләгән, шул рухи күтәрелешкә йөз тоткан халыкка каршы көрәш чаралары тапкан рус миссионерларының, патша самодержавиесе дәүләт сәясәтенең чын асылын ачкан һәм мөселман дөньясын уяулыкка өндәгән. Аның бу ике чыгышы – инде Россиянең күренекле сәясәтчеләре, дәүләт эшлеклеләре, патша хөкүмәте, шулай ук чит ил журналистлары алдында Дума депутаты буларак кына түгел, ә татар халкының милли хәрәкәте идеологларының берсе буларак та ясаган чыгышлары ул.

Ул Дума депутаты буларак та, Мөселман фракциясе җитәкчесе буларак та, үзенең эшчәнлегендә бер нәрсәне үз алдына бурыч итеп куя: Думада теге яки бу мәсьәлә буенча чыгыш ясар алдыннан, «Йолдыз» гәзите аша, алдагы көннәрдә Думада нинди мәсьәлә каралачагын, бу мәсьәләнең мөселман халыклары өчен ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген аңлата, кирәк тапса, алардан үз чыгышында күтәреләчәк проблемаларны яклау, үзе китерәчәк фактларны раслау өчен дәлилләр җибәрүне сорап та мөрәҗәгать итә.

С.Максуди Дума мәҗлесләрендә Дума мөнбәренә менеп чыгыш ясый башласа, октябристлар партиясе вәкилләре, рус милләтчеләре шау—шу чыгаралар, аны үз фикерен бөтен Россия мөселманнары фикере дип белдерүдә гаеплиләр: моңарчы мөселманнарның каршы сүз әйткәннәре юк иде, мөселман депутатлары гына халык теләмәгәнне тели, дип күрсәтәләр, тыныч кына яшәгән мөселман халыкларын рус хөкүмәтенә каршы котырталар, диләр.

«Хосусан, минем нотыкларымнан соң Пуришкевич әллә ничә чыгып, «Максудов Парижда укыганга күрә, ул башка мөселманнар фикерендә түгел, башка мөселманнар бик юаш, алар һичбер нәрсә теләмиләр, бары Максудов кына үзенең Парижда алган фикерләре белән халыкның фикерен чуалта», дия иде»[27] дип яза С.Максуди соңыннан үзенең «Сөхбәтләр»ендә.

Мөселман фракциясенә һәм үз өстенә ташланган бу гаепне юкка чыгару өчен С.Максуди ял, бәйрәм көннәре турындагы закон проекты каралганда, бөтен Россия мөселманнарына «Йолдыз» гәзите аркылы мөрәҗәгать итеп, үзенең фикерләрен һәм Мөселман фракциясе тарафыннан сөйләнгән һәр нотык, һәрбер сүзнең, алар законга кертергә тырышкан һәрбер ляихәнең милләт фикере, милләт йөрәгенннән чыккан җан авазы икәнне раслауны сорый. Бөтен Россия мөселманнары аның бу мөрәҗәгатенә меңнәрчә хат–телеграммалар белән җавап бирәләр, һәм Думаның 1910 ел 1 май мәҗлесе мөнбәренә бер кочак хат күтәреп чыккан С.Максуди болай ди: «Без, мөселманнар, үзебезнең динебезнең, милләтебезнең бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә телибез. Бәйрәм – милләтнең, динен–рухын тәрбия итә. Бәйрәм – бер милләтне җыеп, оештырып тора торган зур мәгънәви бер җилемдер. Якшәмбе көнен, христиан бәйрәмнәрен ял көн итү турындагы законны кабул итү – ул мөселманнарның дини хисләрен изү, вөҗданнарына көчлек ясау, безнең, хөррият диниябезгә, безнең вөҗдан вә калебебезгә бер җәбер, хурлау. Дума, реакциянең узганчы кодрәтенә алданып, дин бабында мондый тәҗрибәләр ясап каравының ни дәрәҗәдә хәтәр икәнен беләме икән?

Комиссия (дин эшләрен ислах итү турындагы законны эшләү өчеп төзелгән комиссия, ә С.Максуди бу комиссиядә әгъза – Ф.Г.) безне, Ислам динендәге кешеләрне, христиан бәйрәмнәрен дә бәйрәм итәргә кыстамакчы була. Без болай мәҗбүри булуны диндә хөрриятне бозу була, дибез. Бер кавемнең дини бәйрәмнәрен бетерү, диннең тамырларыннан бер тамырын өзү буладыр, дибез»[28].

С.Максуди, Думада чыгыш ясаганнан соң, аның белән генә тынычланып калмыйча, берничә мәртәбә Җомга көнне ял итү мәсьәләсенең, мөселманнар өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен аңлатып «Йолдыз» гәзитенә мәкаләләр дә яза.

«Бер милләтнең дәвамы өчен иң мөһим булган нәрсәләре – дин вә телдән соң – ул милләтнең гореф–гадәт миллияседер. Бәйрәмнәр – адәм баласын тәрбия итә торган нәрсәдер. Әгәр бу закон тормышка ашса, ягъни христиан бәйрәмнәре Ислам динендәге мөселманнар өчен дә, бөтен Русиядә ял көне дип игълан ителсә, бу – без, мөселманнар өчен мыскыл хәл. Бу – безнең хиссият диниямезгә уңайсыз. Мөселман булган кешегә христиан бәйрәмнәрен ял итү тәрбия җәһәтеннән авыр киләдер. Дингә хөррият булган бер мәмләкәттә хөррият камил булырга тиеш. Дума һичбер вакытта халыкның хиссият диниясенә, дингә мәхәббәтенә тия торган канун чыгармаска тиеш. Бу – мәсьәләнең дини җәһәте. Әнә шуларга өстәп мөселманнарның үз бәйрәмнәре бар бит. Рус бәйрәмнәрен бәйрәм итү мәҗбүр булганлыкка карап мөселманнар үзләренең бәйрәмнәрен бәйрәм итүдән туктамаячак»[29], ди. Беренчедән, бу закон шул рәвешчә кабул ителсә, мөселманнарның дини хисләрен хурлау булачак, икенчедән, үз бәйрәмнәребездә һәм күп низамлы рус бәйрәмнәрендә сату эшеннән тукталу, сәүдәгәр халкына күп зарар китерәчәктер, дип тә аңлата ул.

Мөселман фракциясенең рус бәйрәмнәрен бәйрәм итмәү турындагы фикерләре, һәм С.Максудиның бу турында Думада ясаган чыгышлары гәзитләрдә басылып чыкканнан соң, ул татар приказчикларыннан үпкәле хатлар да ала: алар аны байлар мәнфәгатен кайгыртуда гаеплиләр. Моңа каршы ул болай ди: «Мөселман фракциясе мөселман байларының файдасын якламый, гомумә милләтемезнең файдасын күз алдында тота, гомуми халкымызның милли файдасына тырыша. Фракция халыкның бер кисеменә булмаенча, милләтнең гомуми мәнфәгатенә хезмәттәдер»[30].

Мөселманнар өчен Җомга көнен ял көн итеп һәм христиан бәйрәмнәрен эш көне дип законлаштырырга тырышуның асылында Россиядәге ике диннең дә бертигез хокуклы булуын, ягъни Ислам динен православный дине белән һәм Ислам динен тотучы мөселманнарны рус халкы белән бер дәрәҗәгә куюны, рус хөкүмәте тарафыннан моны закон нигезендә тануны теләү ята. Менә шуңа күрә, Мөселман фракциясе бу канунның шул килеш кабул ителүен мөселман халыкларының иң мөкаддәс хисләрен хурлау дип карый да инде.

Думаның 1 май мәҗлесендә ясаган чыгышында С.Максуди хәзергә мөселманнар мәдәният җәһәтеннән артта булсалар да, тиз заманда аларның әһәмиятле кавем булачаклары, мәмләкәт тарихында алдынгы бер роль уйнаячаклары шөбһәсез икәнлеген дә әйтә. Алар хәзер дә Думада булган эшләрне бик яхшы аңлап торалар: башта бер халыкның теленә һөҗүм ителсә, аннан соң аның дини бәйрәмнәренә – бу хәлләргә мөселманнар озак риза булып тора алмаслар, дип кисәтә.

Мөселман фракциясе, башка чарасы калмагач, Дәүләт думасының егерме миллионлы Россия мөселманнарының дини, милли теләкләренә бу кадәр игътибарсыз карауларына протест йөзеннән Думаның әлеге мәҗлесен ташлап чыгып китә. Сигез кешедән торган фракциянең Думага протест белдереп, Дума хәтле Думаның мәҗлесен ташлап чыгарга батырчылык итүенә гаҗәпләнгән дә, сокланган да «Новая жизнь» газетасы үзенең баш мәкаләсендә: «Думаның мөселманнарның дини һәм милли теләкләренә каршы килүен Мөселман фракциясе шикелле, егерме миллионлы мөселман халкы да үзен бик җәберсетелгән дип хис итәчәк. Бу мәсьәлә иттифакый хасыйл булган законнарны башка диндә һәм башка милләттә булган кешеләргә ничек начар булганлыгын күп мәртәбә күрсәтте. Әгәр дә Думаның бу законнарына мөселман халыклары, мөселманнарны руслаштыру, динле кешеләрнең диннәрен оныттыру, дип караса, бик уңайсыз булачак»,[31] дип язып чыга.

Җомга көнен эш көне, ә якшәмбе көнен һәм барлык христиан бәйрәмнәрен бөтен мөселман халыклары өчен ял итү турындагы закон проекты Мөселман фракциясе төзәтмәсеннән башка, ягъни мөселманнар бөтен Россия мәмләкәтендә Җомга көнне ял көне итеп, ә христиан бәйрәмнәрен һәм якшәмбе көнен эш көне итү турындагы поправкасын кире кагуны мөселман дөньясы, бигрәк тә, татар халкы үзенең милли хисләрен, динен мыскыл итү дип кабул итә. 1910 елның 28 маенда Казанның Купеческое собрание бинасында җыелган мөселманнар үзләренең җыелышлары исеменнән III Дәүләт думасы рәисе исеменә телеграмма, ә копияләрен «Россия», «Новое время», «Речь» газеталарына җибәрәләр.

«Без, Казан мөселманнарына, сәүдә мәхәлләләрендә хезмәт итүчеләргә ял көне хакындагы булган канун ляихәсенең 9 нчы матдәсенең өченче мәртәбә каралып та Мөселман фракциясенең поправкасын рәд итү (кире кагу) бик каты көчле тәэсир итте.

Без, безнең хакымыздагы мондый гадәләтсез карарны бирергә Дәүләт думасы вәкилләрен ни хәл мәҗбүр иткәнен бер төрле дә аңлый алмыйбыз. Безнең Дәүләт думасы өстеннән кемгә булса да шикаять итәсебез килә, ләкин сез мәмләкәтнең бөек хөкемдарлары вә закон чыгаручылары булганга, сезгә мөрәҗәгать итәмез, чөнки безнең гасырлардан бирле рус халкын яхшылык илә таныпкилүебезне беләсез.

Сез, безне христиан праздникларын бәйрәм итүгә этәреп, безгә бик зур гадәләтсезлек кылган булачаксыз, бу рус падишаһының, үзенең ватандашлары мөселманнарга мөнасиб (яраклы) тарихларының беренче караңгы сәхифәсе булачактыр. Бу эш безнең, рус халкы һәм халык вәкилләре хакындагы тәэсирләремезне үзгәртәчәк, безнең бабаларымыз вөҗүдкә китергән ике сорт арасындагы (ягъни ике халык арасындагы – Ф.Г.) тынычлык вә игътибарларны бетерәчәктер. Ачу вә явызлык орлыклары чәчмәгез: бу орлыклар махсус җирлекләр таләп кылмыйлар, анлар үзләренең начар җимешләрен мөселманнарның тыныч вә солыхта булган җирләрендә дә шытып чыгадыр. Сездән шуны таләп итәбез: иске идарә дә кыла алмаган игелексез адымны атламагыз»[32].

Россия составында яшәгән хокуксыз мөселман халыклары һәм аларның милли хәрәкәтләре башында торган бер төркем татар зыялылары өчен, социал–революционерлардан һәм социал–демократлардан аермалы буларак, хаким милләт белән бертигез хокуклар алып, Россиядә бәйсез, тигез хокуклы хөр милләт булып яшәү теләге, шуңа ирешү беренче урында иң мөһим бурыч булып торган. Алар бары тик милли проблемалар хәл ителгәннән соң гына, патша Россиясендә яшәгән башка халыклар белән берлектә һәммәсе өчен дә кирәк булган социаль проблемаларны хәл итәргә мөмкин булачак дип исәплиләр. Алар уенча, милли проблемалар хәл ителмичә торып, социаль проблемаларны хәл итү мөмкин түгел, чөнки милли хокуклар, милли тигезлек аркылы гына ха-

лыкны милләт буларак саклап калып булачак. Шуны яхшы аңлаган татар милли хәрәкәте җитәкчеләре исеменнән III Думада чыгыш ясаган С.Максуди үз нотыгында Мөселман фракциясенең үзләрен «кызыл» санаган «таңчы»лар, социал–демократлардан аермалы буларак, милли–азатлык хәрәкәтендәге үзләренең кыйблаларын ачык күрсәтә: алар халыкны ике капма–каршы лагерьга аермыйча, милли хөрлекне, бәйсезлекне беренче урынга куеп, бербөтен милләтнең гомуми мәнфәгатенә хезмәттә булуларына басым ясый.

XX гасыр башындагы татар милли хәрәкәте идеологларының берсе булган С.Максудиның Россия Дәүләт думасында сөйләгән һәрбер нотыгында диярлек күтәрелгән проблемаларның, ул хәл итүне сораган, таләп иткән мәсьәләләрнең хәзерге «суверен» Татарстанда яшәүче татар милләте өчен бүген дә актуаль яңгыравы бик аяныч, әлбәттә. Бүгенге милли бәйсезлек көрәшендә нәкъ менә Садри Максудилар җитми! Бүгенге милли хәрәкәтнең таркаулыгы, аның лидерларының төрле амбицияләргә бирелеп, милли хәрәкәтне көчсезләндерүләре, ә моннан татар халкына, аның мәгарифенә, милли үсешенә, суверенитет өчен көрәшенә зыян китерүләрен күргән вакытта Садри Максудиның гасыр башында ук: «Без татар милләтен ярлыга–байга аермыйча, бербөтен халык итеп карап, бердәм милләтнең мәнфәгатьләре өчен көрәшәбез. Мәхкүмә милләтләр бердәм булганда гына үзләренең телләрен, диннәрен саклап кала алырлар, алар бергәләшеп үз хакларын таләп иткәндә генә милләт буларак яши алырлар», дигән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр.

Г.Баттал–Таймас үзенең «Ике Максудилар» дигән китабында С.Максудиның III Дәүләт думасында сөйләген нотыкларының иң әһәмиятлеләре дип, аның Россиянең Төркиягә булган сәясәтенә каршы сөйләгән нотыгын да күрсәткән.

1910 елның февралендә «Новое время» газетасында Тышкы эшләр министрының Торкиягә каршы нигезсез белдерүеннән соң бер мәкалә чыга һәм әлеге күңелсез инцидент Думада тикшерелә. Думада бу турыда П.Н.Милюков кискен чыгыш ясый, ул әлеге газетадагы мәкаләнең һәм Россия тышкы эшләр министры Паприковның дәлилсез игъланы Россия белән Төркия арасындагы

мөнәсәбәтләрнең кискенләшүенә китерергә бер сәбәп икәнлегенә басым ясап әйтеп китә.

Думаның ул көнге мәҗлесендә П.Н.Милюковтан соң чыгыш ясаган С.Максуди исә үзенең нотыгында: «Без, 1909 елда Думада хәрби министрлыкның сметасын караганда Босния белән Герцеговинаның Австриягә кушылу вакыйгасы тәэсирендә булганга күрә, Төркия мәсьәләсенә артык игътибар итмәдек»[33], ди. 1910 елда исә тышкы эшләр министрлыгының Россиянең шәрыкька игътибарын юнәлтү һәм Балкан халыкларының үзенә мәхәббәтен җәлеп итү өчен кайбер эшләр дә эшләнгәнен әйтеп, ул: «Әфәнделәр, мин Төркия гәзитләренең асыл нөсхәләрен укучы ялгыз бер депутат булганга, Төркиянең безгә нинди карашта булганлыгын сөйләми китә алмыйм»[34], ди. Ул Төркия белән Болгария арасында тимер юллар хакында чыккан низагларны бетерүдә Русия дипломатларының эшчәнлеген уңай бәяләп, шушы вакыйгадан соң Төркиянең Русиягә дустанә карый башлавын искәртеп, хөкүмәтне Төркия белән дипломатик мөнәсәбәтләрне тизрәк җайга салырга чакыра.

«Мин үзем Русия белән Төркиянең дуслыгын чын—чын теләүчеләрдән. Ләкин теләүчеләрдән булсам да, Марков кычкырганча, үземнең мөселманлыгымнан һәм ислам мәмләкәтләренең тәрәккъыйлыгын теләүчеләрдән булганга гына түгел. Бәлки мин Русия кешесе булганга әйтәм. Мин үзем хакыйкый файдаларымыз һәм хакыйкый максатларымызның Төркия илә дус күрше булып торуымызга ышанам, һичкемгә яшерен түгел: шәрыкьта һәм гарәптә безгә дус мәмләкәтләр юк. Без үзебезнең дус патшалыкларымыздан ничәшәр мәмләкәтләр белән аерылганбыз. Безнең, хәзерге көндә мәмләкәтләремезнең гаскәрилек тарафыннан да әһәмиятле һәм һичкем белән сәяси иттифакларга кермәгән бер генә күршемез бар, ул исә – Төркиядер. Төркиянең, хәзерге вакытта Русиягә булган эчкерсез мәхәббәтен илтифатсыз калдыру һич тиеш түгел. Безнең дипломатларымыз Төркиядәге бу карашка сәяси бер рәвеш бирергә тиешләр. Әмма Төркиянең Русиягә карата мәхәббәтен сүндерә торган бер нәрсә булса, ул – болгар сәясәтен тотудыр. Шуның өчен мин үземезнең сәясәт ияләренә мондый сәясәт илә мәшгуль булмаска киңәш итәмен. Андый сәясәтләрне

тотып, Төркияне Германия кочагына атмаска кирәк. Чөнки Төркияне үземездән еракка җибәрү илә без үземебезнең өчен һичбер төрле файда хасыйл итә алмыйбыз»[35], ди.

Аның Думадагы бу чыгышы, беренчедән, аның сәясәтче генә түгел, ә бәлки оста дипломат икәнен дә күрсәтсә, икенчедән, Россия хөкүмәтенең ул елларда тоткан тышкы сәясәтен гаепләү акты да булып яңгырый әле. Чыннан да, С.Максудиның кисәтүе хак була: берничә елдан соң Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Төркия Германия ягыннан торып, сугышка керәчәк, Россия гаскәрләрендәге миллионлаган мөселман гаскәриләре үзләренең дин һәм кан кардәшләренә каршы сугышачак. Моны инде 1910 елда ук сиземли алган С.Максуди үзенең чыгышында: «Крит һәм Македония мәсьәләләрен хәл итәбез дип, безгә Төркияне Германия белән Австрия кочагына ташларга ярамый, бер төркем политиканнар сүзенә карап бөек милләтләрнең тынычлыклары бозылмаска тиеш»[36], дип Россиянең бу тышкы сәясәтенең Россия халыклары өчен дә файдалы түгеллеген кисәтеп үтә.

Шулай ук аның рус һем татар гәзитләрендә басылып чыккан, Русия җәмәгатьчелегендә киң яңгыраш тапкан Дәүләт думасының 1910 елның 7 апрелендә сөйләнгән нотыгына да туктап китәргә кирәк: чөнки Мөселман фракциясе зур тырышлык белән Дума мәҗлесенә чыгара алган әлеге мәсьәлә турында бик әзерлекле нотык белән С.Максуди чыга. Әлеге мәсьәлә — Эчке Россиядән казах—кыргыз далаларына рус крестьяннарын күчереп утырту һәм аларга әлеге күчмә халыкларның җирләрен бүлеп бирү турындагы мәсьәлә. Бу турыда «Йолдыз» гәзите: «1910 елның 7 апрелендә Думада Төркестан җирләре хакында закон проекты каралган заманда Садри әфәнде тарафыннан әтрафлы мөһим бер нотык ирад ителмеш иде», дип яза һәм «Россия» газетасында басылып чыккан бу чыгышның тулы текстын, тәрҗемә итеп, үзенең 20 май санында бирә.

«Бу проект җир мәсьәләсендә бөек инкыйлаб кебектер», ди ул әлеге проблеманы Думада тикшерүнең, ягъни әлеге мәсьәләнең асылын ачып. «Бу проектны карауны тудырган сәбәп: Төркестан җирләрен Русия мәмләкәте милке итеп хисап итүдер. Нинди дә булса бер патша, нинди дә булса бер хаким, мәмләкәт яки вали-

ятне сугыш яки солых белән үз тәхете астына кертсә, ул патша бу мәмләкәткә сәяси хуҗа була. Әмма җиренә, булган милкенә хуҗа була алмый, боларга шул халык, шул җир хуҗалары хуҗа булып кала. Бу – һәркем тарафыннан кабул ителгән кагыйдәдер.

Моннан кырык еллар элек, Русия бәгъзесе белән сугышып, бәгъзесе белән солых төзеп Төркестанны үз тәхете астына кертте. Хокукый мәмләкәт һәм хокук кагыйдәсе буенча Русия хөкүмәте һичкем тарафыннан милекләнмәгән буш җирләрне генә мәмләкәт милке итәргә хаклы иде. Әмма ул закон чыгарып, бүген каралган матдә нигезендә Төркестан халкы милкендә булган җирләрнең һәммәсен дә үз милке дип игълан итте.

Кыргыз җирләрен патшаның халык җирләре (Русия халкы) дип игълан итүне мин хакимиятсезлек һәм гаделсезлек дип хисап итәм. Болар – кыргыз халкының үз милкедер»[37].

С.Максуди моңарчы Төркестан халыклары рус мөһаҗирләренең үз җирләренә күчеп утыруларына каршы килмәгәнлекләрен бары тик бу халыкларның Русия хөкүмәтенең үзләренә карата алып барган җир политикасын белмәүдә икәнлеген күрсәтеп, әгәр дә җир комиссиясе Дума мәҗлесенә бу закон проектын кабул иттерсә, кыргызларны җирсез калдырачак, ди.

«Бу эшләрне уйлап эш итәргә кирәк. Дуслардан дошман ясаудан ни мәгънә? Бу эшнең нәтиҗәсе нигә барып чыгуы мөмкин икәнлеген беләсезме?

Сез төркестанлыларның сайлау хокукларын бетергәннән соң да алар бер эш тә кыла алмадылар, чөнки үзләренең хокуксызлыкларыннан аларның бик азы гына хәбәрдар. Шулай булса да, сез аларның хокукларын алып бетергәннән соң җирләрен дә үзләштерергә керештегез. Төркестанның бу көнгә кадәр нарасый булган халкы хәрәкәткә килергә мөмкин. Һиҗрәт идарәсендә миңа: «Без аннан курыкмыйбыз, хәрәкәтләр булса, без аны бастырырбыз», диделәр. Шул ук сүзне без уңнардан да ишетәбез. Ләкин мин сездән үтенеп сорыйм: бу эшкә кул куймагыз. Безнең фракция бу канун проектын рәд итә»[38].

Әмма Төркестан җирләре хакында Мөселман фракциясе керткән бу пункт та кабул ителми, җир комиссиясе керткән закон проектын да Дума үзенең алдагы мәҗлесләренә калдыра.

Шушы уңай белән С.Максуди үзенең «Сәяси сөхбәтләр»ендә бу мәсьәләләрнең асылын аңлатып болай дип яза: «Җирсез крестьяннарга жир табу мөнәсәбәтеннән караганда бу мөһим һәм бик файдалы, әмма Азиядәге төрки халыкны тар–мар итү җәһәтеннән караганда зарарлы, күңелсез, хафалы бер мәсьәлә. Русиядәге асыл кешеләрнең акрынлап Азиягә, Сибириягә вә Төркестанга күчеп китүләренең ике сәбәбе: икътисади вә сәяси сәбәпләре бар. Икътисади сәбәбе – Русиянең, Европа кисемендәге вилаятьләрдәге җирнең тарлыгы булса, сәяси сәбәбе – хөкүмәтнең бу җирләрдә рус милләтен күбәйтүдер.

Күчеп китүчеләрне хөкүмәт бик кадерли: бурыч та бирәләр, юлда барганда докторларга кадәр бирәләр. Ә бит күчеп килүчеләргә шунда яшәүче халыкларның җирләрен кисеп бирәләр. Думага кергән һиҗрәт хакындагы ляихәләр бары тик мөһаҗир руслар хакында гына, ә андагы җирләре бүленеп ярлыланган халыкның аянычлы хәлен яхшырту турындагы ляихәнең бер дә кергәне юк»[39], ди.

Дәүләт думасында «Россиядә гомуми башлангыч белем бирү» турындагы закон проекты (1907, 15 май) һәм III Дәүләт думасының бюджет мәсьәләсе каралган 1908 елның 1 май мәҗлесендә мөселман халыкларының иң югары налог түләүләренә карамастан, аларның мәктәпләрен тоту чыгымнарының мәгариф министрлыгы бюджетына кертелмәве турында ачынып та, нәфрәтләнеп тә чыгыш ясаган С.Максуди эчкечелеккә каршы закон проекты каралган мәҗлестә дә озын нотык белән чыга. 1911 ел, 25 ноябрь көнге мәҗлестә төп докладны Н.Черeванский ясый һәм үз докладында ул: «Мөселманнар юкка гына мәктәпләр ачуны сорамыйлар, ләкин аларның моңа хаклары юк, чөнки алар эчмиләр», ди. Россия империясендәге иң зур доход (керем) чыганагы булып дәүләтнең аракы сатуга монополиясе тора. Шуңа күрә дә дәүләт аракы сатудан кергән доходны арттыру максаты белән империядәге мөселман халыкларының дини, милли интересларын һәм мөселман руханиларының күп санлы протестларын санга сукмыйча мөселман, татар авылларында аракы кибетләре һәм кабаклар ача. Моны мөселман халыкларының динен, гореф–гадәтләрен хурлау дип кабул иткән С.Максуди үз чыгышында Россия-

нең үзе тарафыннан буйсындырылган, үз кулы астына кертелгән, мәдәни яктан артта калган халыкларга рус культурасының бердәнбер чагылышы булып аларны эчәргә өйрәтү, ягъни аракы кибетләре, кабаклар ачуы, эчкечелектән башка бернәрсә дә бирмәве турында әйтә. Хөкүмәтнең мөселман авылларында аракы кибетләре һәм кабаклар ачуын туктаттыру, булганнарын яптыру өчен кискен чаралар күрүен таләп итә.

Ләкин Россия Дәүләт думасының шовинист депутатлары Мөселман фракциясе исеменнән чыгыш ясаучы С.Максудиның Думада дүрт ел дәвамында хокуксыз һәм буйсындырылган егерме миллионлы мөселман халыкларының язмышы, аларның киләчәге турындагы кайнар нотыклары борчымый. III Дәүләт думасы Мөселман фракциясе таләп иткән һәм Дума мәҗлесләрендә берничә кат тикшерүне күтәреп чыккан бер генә мәсьәләне хәл итә. Бу – руханиларны гаскәрилеккә алу турындагы закон проекты каралганда муллаларның да, башка диннәрнең руханилары кебек үк, закон нигезендә, гаскәрилектән азат ителү турындагы ляихә. «Без поправка кертәбез: мөселман руханилары да рус руханилары шикелле үк бертигез закон буенча гаскәр хезмәтеннән азат ителсеннәр, дибез»[40]. Нәтиҗәдә, гаскәрилек уставының 35 нче статьясына мөселман руханилары да башка диннәрнең руханилары кебек үк, закон нигезендә, гаскәрилек хезмәтеннән азат ителү турындагы пункт законга кертелә һәм Дума тарафыннан кабул ителә.

«Садретдин әфәнденең Думада сөйләгән бу нотыгы Русия мөселманнарының йөрәк түрләреннән чыккан тавыш булып яңгырады һәм депутатларга бик гүзәл тәэсир итмеш, – дип яза «Йолдыз» гәзите, – бу Мөселман фракциясенең карарын, С.Максудиның нотыгын Дума комиссиясе кабул иткән»[41]. Һәм 1912 елдан башлап, шушы закон нигезендә, мөселман халыкларының да дин әһелләре хәрби хезмәттән азат ителә. Бу – Россиянең III Дәүләт думасында Мөселман фракциясе тәкъдим иткән күп санлы төзәтмәләрнең кабул ителгән беренчесе һәм соңгысы була.

1912 елның 9 июнендә III Дәүләт думасы ябыла. Шуның алдыннан гына Дума мәҗлесләре бара торган залның түшәме җимерелеп төшә. Бу Думага, IV Дума мәҗлесләре башланганчы, шуны

ремонтлау өчен финанс министрлыгы төзегән сметаны расларга кирәк була. С.Максуди, шул мәсьәлә тикшерелгән соңгы җыелышта кыргыз–казах һәм Төркестандагы мөселманнарның хәле турындагы закон проектына төзәтмәләр кертү турында үз фракциясенең соңгы сүзен әйтмәкче булып сүз сорый, ләкин аңа сүз бирелми.

Шулай да, Дума залының түшәмен төзәтү мәсьәләсе кузгалгач, ул, сүз сорап, мөнбәргә чыга һәм ул депутатлардан ярдәмгә мохтаҗ Төркестан һәм Казахстан мөселманнарының сайлау хокукларын кайтаруларын сорый, берничә миллионлы мөселман халкының язмышын уңай хәл итмичә Думадан китүне, депутат буларак, вазыйфаларын үтәп бетермичә китү булачагын әйтә. Ләкин зур тавыш чыгарып, октябристлар һәм рус шовинистлары С.Максудига сүзен дәвам иттерергә ирек бирмиләр. Шуннан соң ул үзенең сүзен нәкъ менә җимерек түшәмнән башлап китә. «Думаның бинасында гына түгел, үзендә дә зур мөһим «ярыклар» бар. Ул «ярыкларның» берсенә без мөселманнар да төшеп кысылган. Китешли мин сезгә шуны күрсәтеп китәргә телим, чөнки моны үземнең бурычым дип саныйм. Безнең монда биш ел эчендә сәхра халыклары белән Төркестанга караган бик күп канун пунктлары каралып үтелде. Әмма бу пунктларның берсен генә караганда да әлеге халыкларның бер генә вәкиле дә булмады, чөнки алар бу хокуклардан мәхрүм ителгәннәр»[42], ди ул үзенең соңгы нотыгында. Аның ул чыгышы турында «Казанский телеграф»: «Сәяси шарлатанлык яки үзен күрсәтү өчен оста сәяси маневр», дип язып чыга[43]. Октябристлар да, мәҗлесне алып баручы да аңа сүзен дәвам итәргә мөмкинлек бирмиләр. Пуришкевич исә, аның янына килеп, аңа төрле сүзләр кычкырып, мөнбәрдән тартып төшермәкче була, уңнар рәистән С. Максудины Дума мәҗлесеннән чыгарып җибәрүне таләп итәләр. Бераздан, тавыш–гауга тынгач, С. Максуди, сүз сорап, тагын Дума мөнбәренә чыга һәм болай ди: «Думадан киткәндә без үзебезнең бәхетсез, ташланган, сәяси хокукларыннан мәхрүм ителгән диндәшләребез хакында вөҗданыбыз кушуы буенча чын күңелдән берничә сүз әйтергә теләгән идек. Без һәрвакыт намус вә вөҗданыбыз әмер иткән рәвештә тугрылык белән

үзебезнең диндәшләребез һәм ватаныбыз Русиянең файдасына тырыштык»[44].

Бу – С.Максудиның, Россия Дәүләт думасы депутаты буларак, Дума мәҗлесендә әйткән соңгы сүзләре. Алдагы Дума мәҗлесләрендә инде аның мөселман халыкларының хакларын яклап сөйләгән көчле тавышы яңгырамаячак, чөнки ул алдагы Думага сайланмаячак: аның Россия күләмендәге рәсми сәяси эшчәнлеге шуның белән тәмамлана. Россия Дәүләт думаларында биш ел дәвамында төрле партия вәкилләре белән бәхәскә керә–керә эшләү, бер яктан, аны сәяси яктан чыныктырса, икенчедән, аны алдынгы фикерле депутатлар белән дуслаштыра. Гомумән, II–III Дәүләт думаларында эшләгәндә ул профессиональ сәясәтчегә әверелә, оста дипломат булып үсә, ә бу сыйфатлары исә аның алдагы эшчәнлегенә зур йогынты ясаячак.

Берничә елдан соң С.Максуди дигән милли каһарман татар милли хәрәкәтенең тагын алгы сафына басачак. Бу инде Садри Максудиның татар милли хәрәкәте күгендә якты йолдыз булып янган (кызганычка каршы, бик кыска арада) эшчәнлегенең икенче этабы булачак.

## ИСКӘРМӘЛӘР

1. Adile Ayda. Sadri Maksudi Arsal. – Ankara. – 1991. – S.69.
2. Дума. – Санкт–Петербург. – 1907. – 4 сан.
3. Әхмәдзәки Вәлиди–Туган. Бүгенге төрек иле (Төркестан) вә аның тарихы. – Истанбул. – 1942. 531 бит.
4. Йолдыз. – 1907. – 23 май
5. Шунда ук.
6. Йолдыз. – 1908 ел. – 5 гыйнвар.
7. Шунда ук
8. Йолдыз. – 1910 ел. – 9 ноябрь.
9. Йолдыз. – 1910 ел. – 2 сентябрь.
10. Шунда ук.
11. Йолдыз. – 1910 ел. – 21 октябрь.
12. Йолдыз. – 1910 ел. – 3 ноябрь.
13. Шунда ук.
14. Шунда ук.
15. Шунда ук.
16. Йолдыз. – 1910 ел. – 12 март.
17. Йолдыз. – 1911 ел. – 10 март.

18. Йолдыз. – 1912 ел. – 22 март.
19. Шунда ук.
20. Шунда ук
21. Шунда ук.
22. Идел буе төбәгендәге татар–мөселман йогынтысына каршы чаралар үткәрү буенча Махсус Киңәшмә беркетмәсе //Татарстан. – 1992 ел. – № 5/6.
23. Йолдыз. – 1912 ел. – 22 март
24. Казанский телеграф. – 1912 год. – 18 марта.
25. Йолдыз. – 1912 ел. – 22 март.
26. Х.Хасанов. Формирование татарской буржуазной нации. – Казань: Татарское кн.изд–во. – 1977. – с.240.
27. Йолдыз. – 1910 ел. – 29 июнь.
28. Йолдыз. – 1910 ел. – 9 май.
29. Йолдыз. – 1910 ел. – 27 апрель.
30. Шунда ук.
31. Йолдыз. – 1910 ел. – 10 май.
32. Йолдыз. – 1910 ел. – 1 июнь.
33. Йолдыз. – 1910 ел. – 21 март.
34. Шунда ук.
35. Шунда ук.
36. Йолдыз. – 1910 ел. – 21 март.
37. Йолдыз. – 1910 ел. – 20 май.
38. Йолдыз. – 1910 ел. – 25 июль.
39. Шунда ук.
40. Йолдыз. – 1912 ел. – 12 гыйнвар.
41. Шунда ук.
42. Йолдыз. – 1912 ел. – 20 июнь.
43. Казанский телеграф. – 1912 год. – 29 июля.
44. Йолдыз. – 1912 ел. – 20 июнь.

# III БҮЛЕК
# САДРИ МАКСУДИНЫҢ ТАТАР МИЛЛИ–АЗАТЛЫК ХӘРӘКӘТЕ ИДЕОЛОГИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУДАГЫ РОЛЕ.

## § 1. Садри Максуди милләтчелек һәм миллият турында

«Милләтче булмаган милләтләр – үз инкыйразыена үзләре әүвәлдән разый булган кызганыч милләтләр»[1].

Милли аң, милли хис, гомумән милләт мәсьәләсе XIX гасыр ахырларыннан башлап дөньядагы мәхкүмә (буйсындырылган) милләтләр өчен иң зур әһәмият бирелгән проблемага әйләнә. Зур, хаким милләтләр кул астында яшәгән мәхкүмә милләтләрнең үзләренең аяныч хәлләрен аңлаулары әлеге милләтләрдә милли хәрәкәт туугa китерә. Нәтиҗәдә, XIX гасыр ахырында таркау итальян халкы зур, көчле Италия дәүләтен төзи, милләт буларак юкка чыгып барган чехлар да кабат терелә, Төркия кул астында бетеп барган серблар да кабат дөнья мәйданына чыга. XIX гасырда Болгария халкы да милләт буларак үзенең барлыгын дөньяга белгертә. Әлеге милләтләр, милли аңнары үсү аркасында, милләт буларак, яңа үсеш чорына керәләр. Шулай ук XIX гасыр башы татар милли хәрәкәте идеологлары да Россиядәге күп милләтле мөселман халыкларында милли аңны үстерү, милли хис тәрбияләү, миллият тойгысын ныгыту юлында эшчәнлек алып баралар.

Бу чордагы татар вакытлы матбугатында милләт темасына багышланган күп санлы мәкаләләр дөнья күрә. Й.Акчура, Г.Баттал, Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов, Ф.Кәрими, Г.Гобәйдуллин кебек татар зыялыларының күбесе бу турыда үз фикерен әйтә.

С.Максуди да татар халкында милли хисне уятуга зур игътибар бирә. Ул үзенең эшчәнлегендә милли мәсләкне «Аурупа югарылыгындагы иҗтимагый фәннәр казанышларын һәм Русия дәүләт

күләмендәге профессиональ сәясәт белән тоташтырып, татар милли хәрәкәтенең заман дәрәҗәсенә күтәрелүенә (Йосыф Акчура, Җамал Вәлиди, Фатих Кәримиләр белән беррәттән) мөһим өлеш кертте»[2]. 1907–1913 елларда «Йолдыз» гәзитендә С.Максудиның татар халкының милләт буларак яшәве өчен икътисадта ярыш булырга тиешлеген аңлаткан «Милли сөхбәтләр»[3], милли хис, миллият тойгысының халыкны милләт иткән көч икәнен күрсәткән «Әфкяр миллиямез»[4], «Ике төрле милләтчелек»[5] кебек теоретик мәкаләләре басыла.

1905–1907 еллардагы революциядән соң килеп туган сәяси иркенлекләр милли хәрәкәтнең күтәрелүенә этәргеч була. Ләкин революцион идеяләрнең татар дөньясына да үтеп керүе, татарның үз эчендә, төрле революцион группалар барлыкка килү моңарчы бердәм булган милли хәрәкәтне икегә бүлә: «Милли омтылышны бер артта калганлык дип караучылар күбәя»[6]. С.Максуди үзе милли яңарыш, милли үсеш иң беренче урында торырга тиеш, алар тормышка ашырылганнан соң гына, барлык милләтләр (шул исәптәп хаким милләт булган рус милләте дә) ирешергә тырышкан социаль тигезлеккә ирешү өчен көрәш юлына да борылырга була дип саный. Шунлыктан, «таңчы»лар Г.Исхакый, Ф.Туктаров һ.б. кебек милли хәрәкәт җитәкчеләренә ул: «Хәрәкәт миллиямезне онытып, бу мәсләккә кереп китсәк, без бетәбез. Безгә куәт милли эшләремездә, хәрәкәт миллиямезгә хезмәт өчен ляземдер», ди. Милли бәйсезлеген, милли дәүләтчелеген югалткан милләт буларак, ахыр чиктә, бетүгә юл тоткан татар милләте бары тик бөтенлеген саклаганда гына мөстәкыйль яши алачак. Менә шушы фикер, С.Максудиның XX йөзнең беренче чирегендә татар милли хәрәкәте идеологларының берсе буларак тоткан юлында, эшчәнлегендә төп фикер булып тора. Милли бердәмлек, милләт бөтенлеге – бу аның милли көрәш эшчәнлегенең кредосы. Һәм милли көрәшнең бердәмлеген саклау, ягъни татар милләтен ярлыга–байга – ике капма–каршы сыйныфка бүлмичә, бербөтен көчле милләт булып милли көрәшкә күтәрү – бу С.Максудиның милли хәрәкәттәге максаты. Һәм ул үзе шуны аңлатып: «Бу миллиятсезлек мәсләк дулкыннарына кар-

шы көрәшүче көчләр табылды», дип, үзен дә шушы көчләргә кертеп: «Мин бик каты милләтче булдым,»ди[7].

Милләтчелекне хаким, мөстәкыйль милләтләр үз милләтенең телен, мәдәниятын һәм хәяте ысулларын башка, мәхкүмә милләтләргә кабул иттерергә тырышу дип карыйлар, ди ул. Шуңа күрә, «мөстәкыйль милләтләрдә милләтчелек һәрвакыт агрессивный була»[8].

Биредә С.Максуди дусты Й.Акчураның хаким милләттә империалистик милләтчелек, ягъни агрессив милләтчелек була, ул башка милләтләрнең законлы хокукларын боза, ә демократик милләтчелек үзенең законлы хокукларын кайтарырга тырыша, дигән фикерен яклый[9].

Милләте хакимия (хаким милләт) партияләре арасында милләт мәхкүмәләрнең мөкатдәс диненә, газиз теленә һөҗүм итергә теләүчеләр бар. Шул сәбәптән мәхкүмә милләтләр өчен бу газиз мәсьәләләр низаглы мәсьәләгә әйләнәдер. Мәхкүмә милләтләрнең дине, теле вә кавемияте бәгъзе фикерләр тарафыннан һөҗүмгә күчкәнгә, мәхкүмә милләт вәкилләре өчен бу газиз нәрсәләрне иң әүвәл сакларга тырышу иң мөһим вазыйфа булып китәдер. Шул сәбәптән, мәхкүмә милләт вәкилләре, сәяси аерымлыкларын онытып, иң мөһим булган дини, лисани (тел) вә кавеми (милли) эшләр тирәсендә оешырга мәҗбүр булалар, дип яза ул үзенең «Сәяси сөхбәтлә»ендә[10] III Думадагы төрле партияләр арасында милли фиркаларның ни өчен оешуын аңлатып. Бу аның ике сыйныфка бүленгән мөселман халыклары бер партиягә керә алмый, дигән фикерне алга сөреп, татар халкы арасында большевистик идеяләр таратырга тырышучыларга җавабы да булып тора.

Октябрь инкыйлабына кадәр дә, аннан соң да, гомумән, бүгенге көнгә кадәр, Россиядә «милләтчелек» мөһере сугылган милли хәрәкәт криминаль бер эш булып саналып, һәм антигуманистик характердагы идеология дип бәяләнеп киленә. Әмма «Мәхкүмә миллият фикере ата–бабаларыннан калган газиз тел, мөкатдәс, кадерле гореф–гадәтләр, өйрәнелгән тормыш ысулларын сакларга тырышудан гыйбарәт, бабаларыннан мирас булган, үзләре өчен газиз бер тормыш рәвешләрен, яшәешләрен саклауны фидакаренә теләүдән гыйбарәт»[11], ди ул.

Миллият хисе – милләтне башка хаким милләтләр арасында аны милләт буларак юкка чыгудан, бетүдән, аның милләт буларак яшәешен, бөтенлеген саклау өчен барган көрәштә чагыла. Ә инде милли хис, С.Максуди фикеренчә, милли мохиттан, милли гореф–гадәтләр, милли холык, милли мәдәнияттан башка барлыкка килә, үсә алмый.

Миллият тойгысының уянуы, үсүе шул милләтнең киләчәккә булган теләк–максатларын тормышка ашырырга омтылышы аркасында бара. Бәйсезлекләрен югалткан милләтләрдә исә бу хис үз бәйсезлекләрен кабат торгызу көрәшендә чагылыш таба. Мәхкүмә милләтләрнең үз бәйсезлекләре, хаким милләтләр белән бертигез хокукларга ирешү көрәше милли идеологиядән башка бара алмый. Ә милли идеология этник аңнан, милли рухтан, миллият тойгысыннан башка барлыкка килә алмый. Милли идеологияне формалаштыручы төп шарт – милли аңны үстерү һәм милли әдәбиятны торгызу, барлыкка китерү. Менә шуңа күрә дә, татар милли хәрәкәте лидерлары иң беренче чиратта мәктәп–мәдрәсәләргә яңача, заманча уку–укыту тәртипләре кертүгә, яңа типтагы дәреслекләр язуга, дөньяви белем бирүне куәтләүгә, вакытлы матбугат һәм театр сәнгатен барлыкка китерүгә, татар әдәбиятын торгызуга зур әһәмият биргәннәр. Чөнки: «милләтләрне чын милләт ясаучы, кавемият дәрәҗәсеннән күтәрүче – милли мәдәнияттер»[12]. Менә шуңа да татар халкында милли хисне, милли аңны үстерү юлында милли мәдәният зур роль уйнаган. «Безне берләштергән, алга барырга мәҗбүр иткән иң мөкатдәс нәрсә динебез исламиядер, телебездер»[13]. Ислам дине – ана теле – мәктәп–мәдрәсәләр – милли әдәбият – шуларны үстерү, саклау, ныгытуга XX йөз башында татар милли–азатлык хәрәкәте лидерлары, идеологлары, татар зыялылары зур игътибар һәм әһәмият биргәннәр. Аларның һәрберсе татар милли хәрәкәте идеологиясен формалаштыруга үз өлешен керткән. Ә С.Максуди исә алар арасында үзенең белем дәрәҗәсе, сәяси аңы, Русия сәясәтендә тоткан урыны, эшләгән эшләре белән шактый аерылып торган.

Аңа – Русия Думасы депутатына – патша хөкүмәтенең 1907 ел 3 июль указы белән Урта Азия һәм Төркестан халыкларын мәдәниятсыз халыклар, дип сайлау хокукларыннан мәхрүм итүнең әле-

ге халыклар язмышында нинди роль уйнаганы ачык күренә. Шуңа да С.Максуди, үзен «аерым бер милләт булуыбыз җәһәтеннән» әнә шул мәдәниятсыз дип табылып, милләт буларак танылмаган, сайлау хокуклары алынган «мәхкүмә халыкларга кагылышлы мәсьәләләрнең иң мөһиме — милләтләргә каршы булган кысынкылыкларны бетерү мәсьәләсе»н[14] хәл итү өчен көрәшергә тиеш дип саный. Думадагы эшчәнлеге вакытында туплаган тәҗрибәсе, сәяси багажы аның татар милли–азатлык хәрәкәте идеологиясен формалаштырудагы эшчәнлегендә дә чагыла. Россия Дәүләт думасындагы хаким милләт вәкилләре генә хакимлек итү, буйсындырылган милләтләргә, мөселман халыкларына түбәнсетеп карау, аларны санга сукмау, панисламизмда гаепләү — болар барысы да С.Максудины милләтчелекнең асылын аңлатып «Ике төрле милләтчелек» дигән мәкаләсен язарга этәрә.

Милләтчелекнең нигезендә милли изелүгә каршы протест ята, чөнки үз тарихында озын һәм авыр чорлар кичергән милләттә генә миллият хисе ныграк саклана һәм шуңа күрә дә аңарда милли изелүгә каршы көрәш тизрәк, көчлерәк күтәрелеп тә китә.

«Моңарчы бу ике төрле милләтчелек көрәше Русиядә сизелми иде, әмма, хөрриятләр чыгып, Дума чакырылгач, бу көрәшнең асылы мәйданга чыкты, алар (рус националистлары — Ф.Г.) үзләренең максатларын, барачак юлларын яшермичә, «Русия руслар өчен», диделәр[15].

Россиядәге мәхкүмә милләтләр бу сәясәтнең үз милләтләре өчен никадәр дәһшәтле көч икәнлеген бик тиз аңлап алалар һәм III Дума мөнбәрен шушы көрәш мәйданына әйләндерәләр. Рус милләтчеләре «идеаль киләчәктә бөтен Русия бер телдә сөйләшә торган, бер рәвештә яши торган халыктан гыйбарәт булачактыр»[15], диләр. Думадагы шушы көрәшнең эчендә кайнаган поляк, яһуд, әрмән депутатларының таләпләрен һәрчак яклап килгән Мөселман фракциясе исеменнән чыгышлар ясаган С.Максуди милли фракциясенең теләк–максатларын, аларның милләтчелегенең асылын аңлатып болай ди: «Мәхкүмә милләтләрнең һәрберсе үзенә генә хас булган гореф–гадәтләрен, мәдәниятләрен, телен, яшәеш рәвешен саклап калырга тырыша. Алар боларның бетүен үзләренең рухларының, яшәешләренең җимерелүе, дип карыйлар. Ә алар-

ның бетүенә разый булу – мәгънәви үлүгә разый булу ул. Бу – милли бетү»[17].

Россиядә милли мәсьәлә хәл ителмәсә, ягъни патша хөкүмәте үзенең мәхкүмә милләтләргә булган сәясәтен тамырыннан үзгәртмәсә, күп милләтле Россиядә әлеге ике төрле милләтчелек көрәше туктаусыз үсәчәген һәм капма–каршы ике куркыныч көчкә әйләнәчәген күпме еллар элек алдан кисәтеп, С.Максуди үзенең әлеге мәкаләсендә болай дип яза: «Сездә бетерү, югалту сәясәте куәтләнгән саен, бездә яшәү куәте, милләт булып яшәү теләге, үз–үзебезне саклау фикере куәтләнәчәктер»[18].

Россиянең күп милләтле халыклары арасында әлеге милли хәрәкәт, милли көрәш торган саен көчәя, кискенләшә бара: поляк, яһүд, фин кебек милләтләрнең үзләренең милли яшәешләре өчен көрәшләрен җиңеп чыкканчы дәвам итәчәкләренә ышанган С.Максуди, татар милләте өчен борчылып: «Минем хафаланган ноктам – безнең халкыбыз: без бу милләтләр шикелле, националист фиркаларның безгә булган һөҗүменә яхшы каршы тора алырбызмы?», ди[19].

С.Максуди үзенең әлеге мәкаләләре белән татар халкында милли хисне, милли аңны үстерүгә, милли горурлыкны уятырга, милли хиснең халыкны милләт итеп саклый торган иң көчле фактор икәнен аңлатырга тырышкан. Бүгенге көнгә кадәр «милләтче» исемен күтәрүдән курыккан татар халкына ул үз чорында ук мәхкүмә милләтләрдә милләтчелекнең һәр милләтнең үзен–үзе саклау өчен алып барган көрәше икәнен аңлатырга омтылган.

С.Максуди озын гомер юлы үтеп, бай тәҗрибә туплагач, 1950 елларның уртасында, гомеренең соңгы елларында, үзенең гыйльми эзләнүләренең һәм фикерләренең үзәк проблемаларының берсе булган милләт һәм миллият тойгысы хакындагы «Миллият тойгысының социологик әсаслары» исемле фундаменталь хезмәтен язачак. Әлеге хезмәт – аның бу өлкәдәге күп еллык уйланууларының, эшчәнлегенең нәтиҗәсе һәм милләтләрне милләт итеп яшәткән милли хис – миллият тойгысының асылын, нигезен аңлаткан һәм С.Максудиның милли хәрәкәттәге эшчәнлегенә йомгак ясаучы төп хезмәте.

## ИСКӘРМӘЛӘР

1. Гобәйдуллин Г. Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары //Мирас. – 1996. – № 3. Б.24.

2. Әмирханов Р.М. Садри Максуди һәм милләтчелек мәсьәләсе //Садри Максуди. – Казан. – 1996. – Б.91.

3. Йолдыз. – 1910. – 2 февраль.

4. Йолдыз. – 1908. – 18 февраль.

5. Йолдыз. – 1913. – 1 ноябрь.

6. Йолдыз. – 1908. – 17 февраль.

7. Шунда ук.

8. Йолдыз. – 1913. – 1 ноябрь.

9. Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман. – Казан. 1999. – Б.133.

10. Йолдыз. – 1908. – 3 июль.

11. Йолдыз. – 1913. – 1 ноябрь.

12. Г.Гобәйдуллин. Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары //Мирас. – № 3. – Б.24.

13. Йолдыз. – 1907. – № 74. «Милләтнең вөжданы».

14. Йолдыз. – 1915. – 29 октябрь.

15. Йолдыз. – 1913. – 1 ноябрь.

16. Шунда ук.

17. Шунда ук.

18. Шунда ук.

19. Шунда ук.

### § 2. Садри Максудиның Диния руханиягә булган карашлары һәм аның шул юлдагы эшчәнлеге

Садри Максудиның IV Дәүләт думасына сайлана алмавын татар милләтенең бер өлеше «олы хәсрәт» итеп кабул итә. «Садри әфәнденең III Думада депутат буларак кылган хезмәтләрен халык күреп, зур рәхмәт белән каршылады. Садри әфәндене алдагы думаларда депутат вазыйфасында күргәнче, шул арада мәгърифәт вә мәдәнияттә үзенең мәсләгенә муфыйк һәм милләткә файдалы бер эшкә үзенең көчен сарыф кылачагына өметләнен, үзебезне тынычландырабыз»[1]. Икенче өлеше исә «Миллионер Шакир Рәмиевнең байлыгы да Садри Максудига Дәүләт думасына үтәргә ярдәм итә алмады», дип шатлана. Бу вакыйга ул елгы һәр татар гәзитендә үзенчә яктыртылган. С.Максуди үзе IY Думага депутат булып уза алмавын ничек кабул иткәндер, билгесез, тик бу елларда ул рәсми

сәясәттән бераз читләшсә дә, барыбер, татар милли хәрәкәте идеологларының берсе булып калган.

Рәсми сәясәттән китеп торган елларда, ягъни 1912—1917 елларда татар дөньясында нинди генә мәсьәлә килеп чыкса да, С.Максуди теге яки бу мәсьәләне татар халкы өчен үзенчә уңай хәл итү юлларын тәкъдим иткән. Ул бу елларда татар милләте өчен мөһим булган проблемаларның халык мәнфәгатьләреннән чыгып чишелергә тиешлеген аңлаткан күп санлы җитди мәкалә—программалар язган. Татар зыялылары арасында да, җәмәгатьчелек алдында да С.Максудиның авторитеты зур булган. Моның ачык мисалы итеп 1912 елның июль—август айларында «Йолдыз» гәзитендә басылган анкеталарны күрсәтергә була, чөнки ул елны Диния нәзарәтенә мөфти сайлау татар халкы өчен чын мәгънәсендә милләтнең зыялы, укымышлы кешеләрен барлау чоры булып чыккан.

Мөселман Диния нәзарәтенең башына укымышлы, зыялы, берничә тел белгән, югары мәдәниятле мөфти сайланырга тиеш, дигән бердәм фикердән чыгып, анкетага җавап биргән кешеләр бер үк кандидатураларны күрсәткәннәр. Болар: Муса Бигиев, Зыя Камали, Һади Максуди, Риза Фәхретдинов һәм Садри Максуди. «Бу затларның кайсы мөфти булса да, Ватаныбыз өчен дә, әһле Ислам өчен дә хәерле булачактыр. Безнең Русия мөселманнары арасында безнең кайгыларыбызны кайгыртып, диниябезне вә дөньявиебезне җиңеләйтү юлында иҗтиһад итеп йөргән Садретдин Максудов бөтен мөселманнар тарафыннан ихтирам ителә торган мөхтәрәм бер әфәндебездер. Ул үзенең биш—алты тел белүе белән дә, сәясәттә, мәдәнияттә иң алдынгы фикерле кешебез булганлыктан, мөфтилеккә иң лаеклы зыялыбыздыр. Ләкин С.Максудиның хәзерге урыны, хезмәте бик әһәмиятле булганга, ул затның әүвәлге «мөнбәренә» менүенә әһәмият бирелсә, бигрәк тә гүзәл булыр иде, без аның IY Думага сайлануын үтенер идек»[2].

1906 елны Париждан кайту белән үк сәясәткә кереп китүе аркасында адвокатлык эшен читкә куеп торган С.Максуди 1913 елны, кыш буе әзерләнеп, Мәскәү университетында дәүләт имтиханнарын (25 фәннән) уңышлы тапшырып I дәрәҗә диплом ала һәм, Казанга кайтып, шул ук елның көзендә присяжный поверенныйлар советына присяга бирә. Почетный мировой судья В.Д.Бо-

ронинның Казан судебная палатасының присяжный поверенныйлар советына язган гаризасында С.Максудига түбәндәге бәя бирелә: «Его трудоспособность и нравственные качества безупречны. Несмотря на свои молодые годы, он успел уже заслужить общественное доверие и почтен избиранием в гласные Казанской городской думы. Высокое знамя присяжного поверенного г.Максудов будет нести с большим достоинством»[3]. Әмма мөселман динендәге С.Максудины Россия юстиция министры рөхсәтеннән башка присяжный повереный ярдәмчесе итеп билгели алмыйлар. Шулай да присяжныйлар Советы үзенең 1913 елның 9 ноябрендәге утырышында «кандидата прав Садрутдина Низамутдиновича Максудова зачислять в состав помощников поверенного И.И.Степанова, представив настоящее постановление на благовоззрение г.Министра юстиции» дигән карар чыгара. Бераздан Казан судебная палатасының өлкән рәисе присяжный поверенныйлар советына: «Ходатайство Совета о принятии в число помощников присяжных поверенных С.Максудова в настоящее время господином Министром Юстиции удовлетворено» дигән хәбәр җибәрә[4]. Шулай итеп, бу С.Максудиның тагын бер җиңүе була. «Безнең милләт укыган кешеләргә, хосуса, юристларга бик мохтаҗдыр. Садри әфәнде кебек милләтемезнең рух вә ихтыяҗларын яхшы таныган юрист һәрвакыт халыкка файдалы булачактыр»[5], дип язып чыга «Йолдыз» гәзите аның яңа сыйфатта татар халкына хезмәт итәчәген хуплап. С.Максуди үзе дә: «Хөкүмәт хезмәтенә кермичә, хөр юристлык юлын, ягъни адвокатлыкны хуплый», бу эше белән ул үзенең татар халкына файдалырак булачагына ышана.

Ул 1913 елдан Казан шәһәре думасында гласный була. Һәм тиз арада шәһәр думасындагы мөселман гласныйлары арасында лидерлык ролен ала, мөселман фракциясенең җитәкчесенә әверелә. Думада татар гласныйлары күп булмый, әмма аларның барысын да бер идея берләштергән. Ул – татар тормышына Европа яшәеше үрнәге кертергә тырышу, яңа мәктәпләр ачу һәм аларны шәһәр бюджетыннан финанслауга ирешү. Фракция бу өлкәдә җитди генә уңышларга да ирешә. Мәсәлән: 1912 елда рус–татар мәктәпләренең алты гомуми белем бирү классы һәм мәдрәсәләр каршындагы җиде класс шәһәр бюджетыннан финанслана. Ә

1913 елда исә бер рус–татар ирләр һәм биш кызлар училищесы өчен шәһәр бюджетыннан аерым бина саттырып алуга да ирешәләр[6]. С.Максуди монда да татар халкына кагылышлы мәсьәләләр каралган вакытта тыныч кына кала алмый. Мәсәлән, 1914 елның 20 маенда шәһәр думасы мәҗлесендә бәйрәм көннәре турында мәсьәлә каралганда, бу закон Дәүләт думасында кабат каралмыйча торып, бирседә тикшерелгә тиеш түгел, дип каршы чыга. Ләкин Казан шәһәр думасы якшәмбе һәм христиан бәйрәмнәре көннәрендә сәүдәгәрләргә кибет–контораларын ачмаска, ял итәргә дигән карар чыгара. Шәһәр думасының бу эшен мөселманнарның дини руханиясен хурлау дип санап, протест йөзеннән, С.Максуди, Һ.Максуди һәм Апанаевларның өчесе мәҗлесне ташлап чыгып китәләр. «Безнең бәйрәмнәребез сезнең бәйрәм түгел, сезнең бәйрәмнәрегез безнең бәйрәм түгел!», ди ул үзенең шул көнне думада ясаган чыгышында.

С.Максуди адвокатлык эшен алып бару белән бергә, татар дөньясының сәяси тормышында да кайнап яшәгән, дип әйтергә кирәк. Ул мөселман халыкларына, татар халкына кагылышлы һәр мәсьәләгә үзенең карашын белдергән, аларны татар милләтенә аз гына булса да файдалы хәл итү юлларын эзләгән.

Татарның беренче профессиональ сәясәтчеләреннән булган С.Максуди рәсми сәясәттән читләштерелсә дә, эшчәнлеген туктатмый. Бу чорда аның артыннан яшерен күзәтү оештырылу да аның милли хәрәкәттәге эшчәнлегенең сүрелмәгәнен раслаучы факт булып тора[7].

1913–14 елларда татар вакытлы матбугатында шактый кызу бәхәсләр чыгарган мәсьәлә – мөселманнарның рухания диниясен (дини оешмаларын) үзгәртү һәм дини мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыру мәсьәләсе була.

III Дәүләт думасында депутат чагында ук диндә хөррият комиссиясен мөселман халыклары өчен иң мөһим комиссиягә санаган С.Максуди бу эштән читтә кала алмый, әлбәттә. Аның әлеге мәсьәләне хәл итүгә зур әһәмият биргәнлеге «Йолдыз» гәзитендә басылган күләмле җитди мәкаләләреннән дә ачык күренә. 1914 елның 13 гыйнварендә ул «Шәрык» клубында «Русиядә мөселман идарәи руханияләрнең тәшкиләте» (төзелеше) турында лекция

дә укый. С.Максуди үзенең лекциясендә Россиядәге мөселман идарәи руханияләрне һәм дини мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыруның кичектерелсезлеге инде көн үзәгендә чыккан мәсьәлә, дип белдерә.

Моннан дүрт йөз еллар элек үзенең милли дәүләтчелеген, бәйсезлеген югалткан, төрле сәбәпләр аркасында бөтен Россия буйлап сибелгән татар халкын милләт буларак Ислам дине саклап калган. 1913 елда Россиядә 18 миллион (Бохара белән Хиваны да санасаң – 31 – миллион) мөселман яшәгән. Барысы 24321 мәхәллә булып, 26276 мәчет эшләгән, аларда 45359 дин әһеле хезмәт күрсәткән[8]. Менә шуңа күрә, XX йөз башы татар милли хәрәкәте идеологлары татар милләтенең мәдәни, икътисади һәм сәяси үсешен Диния руханияне һәм дини мәктәпләрне реформалаштыру белән бәйләп карыйлар. С.Максудиның әле 1910 елның 15 гыйнварендә Петербургка килгән Англия хөкүмәте делегациясе алдында ясаган чыгышында әйткән сүзләре үк: «Без, мөселманнар, үз динемезне тотып һәм саклап, христиан мәмләкәтендә камил хокуклы гражданнар булып тору мөмкин дип ышанабыз. Сәясәт бабында тәрәкъкыят дин вә милләтләрне аеруда түгел, бәлки төрле милләт вә диннәрне дуслаштыру вә якынайтудадыр»[9] – бу аның милләткә хезмәт юлындагы эшчәнлегендә үзенә принцип итеп алган мәсьәләләрнең иң беренчеләреннән.

Бу мәсьәләдә аның фикердәшләреннән булган танылган дин галиме Муса Бигиев тә, татар милли хәрәкәтенә юнәлеш бирүчеләрдән Гаяз Исхакый, Фуад Туктаровлар да, С.Максуди үзе дә дини мәктәп–мәдрәсәләрдә белем алганнар. Шуңа күрә, алар Ислам диненең мөселман халыклары, татар милләте язмышында никадәр зур роль уйнаганын, татар халкының икътисади яктан көчле һәм мәдәни яктан дөньядагы алдынгы милләтләр рәтенә чыгару бары тик дини оешмаларны яңача, заманча үзгәртеп кору, дини мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыру аша гына мөмкин булачагын яхшы аңлаганнар һәм моны халыкка да аңлатырга тырышканнар. Татар халкының башка белем алу йортлары булмаганлыктан, аның бөтен дини, дөньяви белемнәрне бирү урыны булып шул мәктәп–мәдрәсәләре саналган. Әмма инде XX гасыр башында алар башка милләтләрнең уку йортлары янында бик көчсез

булып калганнар. Муса Бигиев әйткәнчә, татар милләтенең рухиятен яңартканда гына, ягъни мәктәп–мәдрәсәләрдә дөньяви белем алган, дөнья фәне, мәдәнияты белән яхшы таныш булган, берничә тел белгән укымышлы милләт кенә икътисади, сәяси яктан үсә алачак.

Шулай итеп, милли мәктәп–мәдрәсәләргә дөньяви фәннәр кертү, аларда чит телләрне, рус телен өйрәнү кирәклеге мәсьәләсе көн үзәгенә килеп баса. Ә моның өчен мәктәп–мәдрәсәләрдә дини фанатизм белән агуланган мөгаллим–мөдәррисләрне дөньяви белемле, укымышлы укытучылар белән алмаштыру, бу уку йортларының яшәешен үзгәртү зарур була.

Чыннан да, рухи яктан таза, саф булмаган, динен сакламаган, гореф–гадәтләрен оныткан, яңарышка омтылмаган халык икътисади һәм мәдәни яктан үсә алмый, әзме–күпме үскән очракта да, үзенең узган тарихын, рухиятен белмәгән халык рухи яктан гарип булып калачак.

XX гасыр башында ук татар зыялыларын куркыткан бу мәсьәләне совет власте елларындагы милли сәясәт бөтен чынбарлыгы, тулылыгы белән тормышка ашырды. СССРдагы милләтләр милләт буларак бетүгә юл тотты, чөнки «милләт» сүзе үзе үк тыелган сүзгә әйләнде. Бу елларда үз халкына хезмәт итәргә теләгән татар зыялылары «милләтче» исемен алудан котлары чыгып яшәде. Динне дәүләттән аерып куйган совет дәүләте Диния нәзарәтенә тын алырга да ирек бирмәде. Татарстанда бер генә дини мәктәп тә, мәдрәсә дә калмады, Ислам дине кануннарын аңлатып–өйрәтеп яшәргә тиешле булган укымышлы имамнар бөтенләй бетте. СССРдагы башка халыклар шикелле үк татар халкы да динсезлек юлына кереп китте.

Ул елларда татар вакытлы матбугатында күтәрелгән проблемаларның иң әһәмиятлеләреннән берсе – Диния нәзарәтен һәм дини мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыру мәсьәләсе булган. Шуңа күрә, бу эшләрне тормышка ашыру өчен Диния нәзарәтенә укымышлы, берничә тел белгән, дөньяви фикердән, сәясәттән хәбәрдар булган, милләт җанлы мөфти сайлау мәсьәләсе 1912–14 елларда татар дөньясының көн үзәгендә торган. Бу турыда «Йол-

дыз» гәзите битләрендә М.Бигиев, Һ.Атласов, З.Камали, С.Максудилар үзләренең уй—фикерләре белән уртаклашканнар.

Әмма патша хөкүмәте татар халкының фикере белән санлашмыйча, Оренбург Диния нәзарәтенә Петроград имамы С.Баязитовны мөфти итеп куя. Моңа җавап итеп Казаннан Дума рәисе М.В.Родзянко һәм П.Н.Милюков исеменә күп санлы протест телеграммалары китә, алар арасында 1915 елның 9 августында З.Вәлиди, Г.Баттал, С.Максудилар кул куйган телеграмма да була[10].

Ниһаять, күп санлы мөрәҗәгатьләрдән соң, Эчке эшләр министрлыгы IY Думаның Мөселман фракциясенә июнь аенда Петербургта Киңәш мәҗлесе уздырырга рөхсәт бирә.

1914 елның 15—25 июнендә Петербургта Диния нәзарәте һәм дини мәктәпләрне реформалаштыруга багышланган зур Киңәш мәҗлесе була. Монда Мөселман фракциясеннән алты депутат (депутат булмаса да С.Максуди да делегатлар составында була), утыз өч дин әһеле катнаша. Бу дин әһелләре арасында заманының иң укымышлы, «иң мәгълумәтле, иң иттикатлы (ышанычлы) голамәләрдән, гарәпчәне чын гарәп, исламны ислам галиме кебек белгән, пайтәхет университетында хосусый дәресләр алган, чук укымышлы йөртелгән адәмнәрдән»[11] саналган Муса Бигиев тә була. Киңәш мәҗлесендә ясаган чыгышында ул: «Без күбрәк рухи мәсьәләләргә игътибар бирергә тиешбез... без аларны тәртипкә салсак, башка эшләребез дә төзекләнер»[12], ди.

Бу мәҗлескә бөтен Русиядән «мәгълуматлы мөселманнардан» делегатлар сайлана, әмма аларның күпчелеге шул ук кадимчелек юлында калган, яңарышны кирәксенмәгән өлкән яшьтәге имамнар булып чыга. Менә шуңа борчылган С.Максуди бу Киңәш мәҗлесе башланганчы ук «Йолдыз» гәзитендә «Киңәш мәҗлесенә кадәр киңәшләр» (1914 ел, 1179 сан) «Мәркәзияте диния» (1189 сан), «Рухани эшләремезне ислах хакында»(1193 сан) кебек мәкаләләрендә Диния нәзарәтен һәм дини мәктәпләрне реформалаштыру ничек алып барылырга тиешлеге һәм кирәклеге турында үзенең уй—фикерләре белән уртаклаша. Аның фикеренчә, Мәҗлескә барасы кешеләр үзләре яшәгән урыннардагы халыкның рухани эшләре турындагы уй—фикерләрен белергә тиешләр. С.Максуди

ул делегатларга рухани эшләрдә нинди үзгәрешләрнең кирәклеген, мөһимлеген, нәрсәләрне сакларга, нәрсәләрне үзгәртергә кирәк – менә шул мәсьәләләрдә Киңәш мәҗлесенә кадәр үк бер карарга килеп куярга кирәк, дип саный. «Хәлбүки, һәрвакыт иҗтимагый мәсьәләләрдә дөрес фикер – халык эчендә таралган фикер буладыр. Һәр җирдәге вөҗданлы, фикерле мөселманнарга хәзер бу мәсьәләне күрсәтеп Киңәш мәҗлесләре оештырырга хезмәт итү милли бер вазыйфа буладыр», ди. «Безнең Русия мөселманнарының рухани эшләренең тәшкиләтендә, һичшөбхәсез, бик күп җитмәгән җирләр бар, рухани учреждениеләрнең хәлен нигезеннән үзгәртәсе, төзәтәсе бар»[13]. Бу турыда соңгы елларда мөселманнар тарафыннан хөкүмәткә күп санлы хатлар, гаризалар языла, шулай ук С.Максуди үзе дә, депутат вакытында, рухани эшләрнең торышыннан риза булмаган Россиянең төрле җирләрендә яшәүче мөселманнардан күп кенә хатлар ала. Аларда төрле имамнардан, дин әһелләреннән, мәктәп–мәдрәсәләрдәге укыту системасыннан зарлану була, чөнки халык дин әһелләренең үзләрен төрлечә кысуларын сизә, ачык аңлый.

Патша тарафыннан куела торган мөфти хөкүмәт алдында мөселманнарның интересларын яклый алмый. «Урал» гәзите инде 1907 елны ук бу турыда «халыкка хәзерге мөфти дә, яңасы да кирәкми», дип халыкны үзенең дини эшләре белән идарә итүне үз кулына алырга өндәгән «Безгә мөфти кирәкме?» дигән мәкаләсен биргән була.

Бу уңай белән, соңарак, Фатих Әмирхан да «Кояш» гәзитендә (1915 ел, 738 сан, 28 июнь) «Мөфтилек мәсьәләсе вә аңа кандидатлар» дигән усал мәкаләсен бастырган.

Татар зыялыларының һәм татар милли хәрәкәте идеологларының дини эшләр оешмаларын һәм мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыруга әһәмият бирүләренең сәбәбе –татар халкының яшәү үзенчәлеге, ягъни Ислам дине, идеология буларак кына түгел, ә халыкның тормышындагы үзенчәлекле, төп фактор буларак та аңлатыла. Шуңа күрә дә: «Без, Русия мөселманнарының үзебезнең яшәешебезгә хас булган, динемезнең чын асылын ачкан рухани тәшкиләте булырга тиеш». «Шуның өчен, – ди С.Максуди, – Диния руханияне ислах итү мәсьәләсе руханиларга гына гаид бер

мәсьәлә дип карамый, һәрберебез катышырга, фикер йөртергә тиеш булган гомуми мөһим бер милли мәсьәлә дип карау тиеш дип уйлыйм»[14].

«Мәхкүмә милләтләр, һичбер вакыт каршылыкларны бер җиргә җыя торган, яхшы тәшкил ителгән һәм рухани учреждениеләре тәсдыйк ителгән, мөхтәрәм рухани затлардан башка үзенең малиясен (финанс хәлләрен) хәл итә алмый; дини учреждениесез бер милләт булып оешып тора алмый. Шуңа күрә, мәхкүмә милләтләрнең һәркайсы дини учреждениеләр түбәсе астына кереп үзләренә читтән килгән җил–яңгырлардан сакланырга тырышалар»[15]. (Мисал итеп күп еллар буенча һәртөрле изү–кимсетүләргә каршы тора алган полякларны алырга була. Аларны бербөтен милләт итеп саклап калган, бүгенге көнгә кадәр милләт итеп китереп җиткергән көч – аларның диннәре).

Дини оешмалар татар халкының сәясәт миллиясендәге мөһим нәрсә. Ләкин XX гасыр башында, бигрәк тә 1905 елгы революциядән соң, мәдәни–милли яктан яңарыш чорына кергән татар халкын, аның зыялыларын озак еллар буена яңарыш кичермәгән дини оешмалар, Диния нәзарәтенең торышы инде канәгатьләндерми. Татар зыялылары, үзенең динен, гореф–гадәтләрен саклап, мулла–имамнарына таянып кына рус хөкүмәтенең дүрт йөз елга якын сузылган, татар халкын халык буларак юк итү сәясәтеннән исән–сау алып кала алган, халыкны мәдәниятле, мәгарифле итү, икътисади, сәяси яктан үстерүне үзе нык тотынган дини эшләр институтын яңартмыйча, дини мәктәпләрне реформалаштырмыйча мөмкин түгеллеген яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә, бу елларда мөселман халыкларының рухани эшләрен яңарту, үзгәртү мәсьәләсе көн үзәгендә торган мәсьәләләрнең иң беренчесе була да инде.

С.Максуди да, башка татар зыялылары кебек үк, бу мәсьәләгә зур игътибар бирә: «Рухани эшләребезне ислах итү һич соңга калдырырга ярамаган бер милли вазыйфабыздыр»[16], ди. Ул үзенә Россиянең төрле якларыннан язылган хатларга игътибар итеп, башка милләтләрнең тәшкилят руханиясен дә күз алдында, шулай ук милли тәрәккъыят, милли истикбалны (киләчәкне) дә исендә тотып, рухани эшләрне ислах итү мәсьәләсе турында күп

уйлана. Нәтиҗәдә, бу өлкәдәге татар халкы алдындагы бурыч һәм максатларны күздә тоткан программа да төзи һәм үзенең әлеге программасына ул түбәндәге пунктларны кертә:

«1. Милли әмәл (өмет) саналырга тиешле Мәркәзият төзү;

2. Мәркәзият диниялләрдә уку–укыту, мәктәп–мәдрәсә эшләрен идарә итү өчен бер гыйльми шөгъбә (бүлек) ачу. Бөтен дини–милли мәктәп–мәдрәсәләрне бу шөгъбәләрнең идарәсенә бирү (ягъни, Русия мәгариф министрлыгыннан алу;)

3. Бөтен рухани мөнәсәбәттәге кешеләрне, ягъни мөәзин, имамнардан башлап, мөфти вә шәйхелисламга кадәр сайлап кую;

4. Бөтен рухани тәшкиләтебезнең вә руханиларыбызның Русиядәге башка диннәрнең рухани учреждениеләре һәм руханилары хуҗа булган хокукларга хуҗа булуы;

5. Мәмләкәт хәзинәсеннән рухания диниялләргә һәм руханиларыбызга акча бүленергә тиешлеге;

6. Милли рухани фонд булдыру;

7. Шәргый вакыфларны «вакыф» буларак канун тарафыннан тәсдыйк ителергә тиешлеге;

8. Мәхәлләдән башлап югары руханиятларга кадәр коллегия булырга, аларга рухани булмаган әгъзалар да кертелергә тиешлеге;

9. Вилаятьләрдә, өязләрдә махсусый руханиларның вәкилләре съездларын ясарга хокук бирелергә тиешлеге (хокук иҗтимагыя);

10. Рухани идарәләрнең язган язулары милли телдә лязем булуы, шулай ук русча тәрҗемәсе дә булырга тиешлеге;

11. Мәчет–мәктәп–мәдрәсә салуда хәзерге уңайсызлыклар бетерелергә, бу эш идарә руханиларның кулына бирелү турында ачыктан–ачык әйтелергә тиешлеге;

12. Рухани мәдрәсәләрнең хокуклары законда ачык булып, аларның закон тышында булулары бетерелергә тиешлеге;

13. Идарәи руханиятләрнең хәзер законда салынган актлары киметелмәү, бәлки заман икътисадынча арттырылырга тиешлеге;

14. Мөгаллим–мөдәррисләрнең хәзерге хокуксыз хәлләре бетерелеп, хөкүмәт тарафыннан тәсдыйк ителгән кешеләр булырга тиешлеге»[17].

Татар халкына әлеге Мәркәзият диния нигә кирәк булган соң?

Россиядә мөселманнар христиан дине хаким дин булган мәмләкәттә яшиләр. Заман үзгәрә, хәят алга бара, мәктәпләргә дин белән бергә фәннәр дә керә башлый. Фәннәрне дини мәктәпкә тормыш үзе китереп кертә, чөнки XX гасыр башында кешелек җәмгыяте кискен үзгәрешләр чорына кердә. Шуның белән бергә, Россиядәге иҗтимагый һәм икътисади үзгәрешләргә ияреп, татар халкының да икътисади, мәдәни таләпләре үзгәрә башлый. Һәм боларны тормышка ашыру өчен дин галимнәре генә түгел, фәнни мәгълүматка ия кешеләр дә кирәк булып чыга. Шулай итеп, татар халкына да дөньяви, милли югары уку йортлары кирәклеге мәсьәләсе туа. Нәтиҗәдә, дини һәм милли эшләрне бер Мәркәзияткә җыю кирәклеге мәсьәләсе дә килеп чыга, һәм мәгарифне дә үз эченә алган бу Мәркәзият саф дини генә булмыйча, милли дә, дөньяви да булырга тиеш.

Әмма С.Максуди бу мәсьәләнең әле өлгермәгән бер мәсьәлә, ягъниерактагы матур хыял икәнлеген, патша хөкүмәтенең бу эшкә рөхсәт бирмәячәген, бу турыда мөселманнарның үз араларындагы аңлашылмаучылыкларның да Мәркәзият диния төзүгә киртә булачагын яхшы аңлый. Ләкин шуңа да карамастан, Мәркәзият диния – барлык Диния нәзарәтләренең өстендәге бер гомуми Идарәи рухания булачак, дип аңлата ул үзенең әлеге мәкаләсендә. Ул Уфадагы Диния нәзарәтен бөтен Россия һәм Себер өчен, Кырымдагы Идарәи руханияне Кырым, Польша мөселманнарының дини эшләрен карау өчен булачак, дип күрсәтә. Ә боларның һәммәсен берләштерүче бер оешма – Мәркәзият диния төзелергә, ә гомуми Мәркәзият диниянең торган урыны – Петербург булырга, Идарәи мәҗлесе исә Коллегия кулына бирелергә тиеш, дигән фикерне дә әйтә.

Ләкин татар матбугатында Мәркәзият диния төзелү турында сүз чыккан саен рус матбугатында моңа каршы материаллар басылып килә. Моның төп сәбәбе – рус миссионерларының мөселман халыклары омтылган бу дини берләшүнең аларның милли тәрәккыятендәге әһәмиятен аңлауда була. Чөнки алар Россиядә яшәгән унсигез миллион мөселман халыкларының дини яктан

берләшү ихтималының үзләре өчен зур куркыныч көч булачак, дип уйлыйлар.

Шулай да, 1914 елның 15 июнендә Петербургта бөтен Россия мөселманнарының Киңәш мәҗлесе ачыла һәм С.Максуди әлеге мәҗлестә доклад ясый.

«Мөселман идарәи руханияләрен тизрәк ислах итү кирәклеген мөселманнар үзләре генә түгел, хөкүмәт тә тиеш таба». («Йолдыз». – 1914. – 18 май). Садри Максуди үзенең докладында иң мөһим булган эшләнәсе эшләрнең барлыгы унҗиде пунктын саный, һәм бу пунктларда күрсәтелгән эшләрнең ни өчен эшләнергә тиешлеген һәм кирәклеген җентекләп аңлата.

«Без, Русия мөселманнарының, әхлакый, мәдәни вә икътисади тәрәккыяте өчен бу мәсьәләләрнең тиз заманда яхшы рәвештә хәл ителүе лязем. Бу санаган теләкләребезне вөҗүдкә чыгару безнең милли идеалларыбыздандыр. Яшим дигән милләтнең милли идеаллары мәгълүм булырга тиешле, алар милләтнең калебендә генә түгел, телендә дә булырга тиешле. «Бар» буласы килгән милләт «юк»ларын да күрә белергә тиеш»[18].

С.Максуди тарафыннан Киңәш мәҗлесенә тәкъдим ителгән доклад Мәҗлес тарафыннан хуплана һәм кабул ителә. Киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим иткән шушы программасының һәм әлеге Киңәш мәҗлесендә ясаган чыгышының бертавыштан хуплануы аның ислам нигезләрен дә ныклы белүен, юрист буларак та авторитеты зур булуын раслый торган факт булып тора. Ул үзенең әлеге мәсьәләгә булган карашларын алга таба да үзгәртмәячәк, матбугатта әледән–әле шул турыда үз фикерләрен әйтеп торачак.

С.Максуди, татар милли хәрәкәте идеологиясен формалаштыруда зур роль уйнаган милләтче буларак, сыйнфый көрәшне, кан коюны кабул итми. Шуңа да, ул үзенең сәяси эшчәнлегендә татар милләтен бербөтен итеп саклап, милли иркенлекләрне бары тик законнар ярдәме белән генә алу, халыкның хәлен халыклар өчен файдалы законнар чыгарып кына төзәтеп булу мөмкинлегенә, кирәклегенә кат–кат басым ясый.

Беренче Бөтендөнья сугышы елларында С.Максуди Западный фронт өчен азык–төлек әзерләү бүлеге (Казан губернасыннан) белән

җитәкчелек иткән. Аңа еш кына Казаннан китеп торырга да туры килгән.

С.Максуди бу чорда адвокатлык эшен алып бару белән бергә, татар дөньясының сәяси тормышында кайнап яшәгән. Ул Россия мөселманнарына, татар халкына кагылышлы һәр мәсьәләгә үзенең карашын белдергән, аларны татар милләтенә аз гына булса да файдалы итеп хәл итү юлларын эзләгәнлеге аның шул турыда борчылып язган мәкаләләрендә ачык күренә.

Беренче Бөтендөнья сугышы барган елларда Россиянең IV Дәүләт думасы кыска–кыска гына вакытка җыелып ала. Ләкин шулай булуга да карамастан, Россия Дәүләт думасына әзме–күпме өмет багълаган С.Максуди милли кысынкылыкларны бетерү, мөселман халыклары өчен аз гына булса да иркенлекләр алу юлында булган барлык мөмкинлекләрне дә файдаланырга кирәк дип саный. Беренче Бөтендөнья сугышына 800 000 нән артык солдат биргән мөселман халыклары «күңеллеләр» (иреклеләр) полклары оештырган, яралы мөселман солдатларына ярдәм итүче хәйрия фондлары төзегән, лазаретлар ачкан татар халкы алдында «яңа бер дәвер ачыла. Европада кайсы милләтләр хуҗа, бөек булып калачак, кайсы милләтләр иске, биек урыннарыннан төшәчәк. Безгә исә ватанымыз өчен бу сугыштан соң әфкар, матур өмидләр, зур рольләр ачылачактыр»[19], дип ышана. Һәм ул шушы мөмкинлекләрдән файдаланып калырга чакырып Россиянең IV Дәүләт думасы депутатларына: «Сезнең вазыйфагыз исә, безнең хәлебезне, фикерләребезне, өметләребезне, зур сугышка рухи мөнәсәбәтләребезне ачык, милләтебезнең зурлыгына муафыйк, вәкарьле самими сүзләр белән Русиянең зур мөнбәреннән бөтен Русиягә белдерүдер»[20], дип мөрәҗәгать итә.

IV Дәүләт думасындагы һәм Дәүләт Советындагы партияләрнең һәрберсе диярлек бер блокка керәләр. Бу блокка иң суллар белән иң уңнар һәм мөселманнар фракциясе генә керми кала. С. Максуди моны Мөселман фракциясе тарафыннан эшләнгән иң зур сәяси хата дип бәяли. Чөнки бу Блокның программасындагы иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе: «милләтләргә каршы булган кысынкылыкларны бетерү мәсьәләсе була». Ул Мөселман фракциясенең бу Блокка кермәве, татар халкы, мөселман халыклары исе-

меннән, алар хокукларын яклап Думада сүз әйтүдән мәхрүм калу, дип саный. Чөнки аныңча: «мәсьәләнең иң нечкә җире шунда: безнең сәяси кешеләребез хиссият миллиягә зарар китермәскә, һәм артык зур позиция алып милләтнең гавам күзендә барлыгын оныттыра торган хәрәкәттә булмаска тиеш. Хокуклары җәһәтеннән разый булмаган милләт һәрвакыт, һәр мәйданда үзенең җитмәгән хокуклары хакында сөйләргә тиеш»[21]. Ул биредә Киңәш мәҗлесендә дини оешмаларны үзгәртеп кору һәм мәктәп–мәдрәсәләрне реформалаштыру буенча кабул ителгән программаның кайбер пунктларын гына булса да тормышка ашыра башлау мөмкинлекләрен дә күз алдында тота. Шулай ук, татар милли хәрәкәтенең киләчәктә яңа күтәрелеш алачагына ышанган С.Максуди әлеге мәкаләләрендә Россия Дәүләт думасы депутатларының патша хөкүмәтенә Россиядә һәртөрле сәяси, милли хокуклары кысылган халыкларның барлыгын һәрдаим искәртеп торуларын таләп итә. Шул ук вакытта ул мөселман халыклары арасында иң мәдәниятлесе булган татар халкының, аның Думадагы вәкилләренең Россиянең барлык мөселман халыкларына да хезмәт итәргә тиешлеге хакында да искәртә. Татар халкының башка төрки халыклардан башка гына сәяси, милли, икътисади яктан зур биеклекләргә ирешә алмаячагын, бары тик төрки халыкларның рухи бердәмлеге генә хокукый иркенлекләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәген җентекләп аңлата. IY Дәүләт думасындагы мөселман фракциясенә, Блокка кергән очракта, хәл итәргә, эшләнергә тиешле эшләрнең иң мөһимнәре итеп ул шуларны күрсәтә:

«1. Ял итү мәсьәләсен мөселманнар теләгәнчә хәл итү.

2. Дини эшләрне ислах итү.

3. Кыргыз–казакъларны җиргә беркетү мәсьәләсен хәл итү.

4. Төркестан мөселманнарына сайлау хокуклары бирү.

5. Бөтен мөселманнарга хас кануни кысынкыларны бетерү»[22].

С.Максуди патша хөкүмәте алып барган милли сәясәтнең мөселман халыкларына карата иң зур кысынкылыкларының беренчесе итеп Төркестан вә кыргыз валиятләрендәге мөселманнарның сайлау хокукларыннан мәхрүм ителүен саный, һәм алар турында: «Чын мәгариф керсә, алар кеше булачак халык. Бу, без,

Русияле укыган зыялыларның вөҗдани, тарихи, сәяси бер вазыйфасыдыр. Төркестан – бөтен төрек балаларының бишеге»[23], – ди.

1907 елдан, ягъни II Думадан бирле «мәдәниятсез халык» дип сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән, Россия мөселманнарының яртысын тәшкил иткән Төркестан халыкларының милли, мәдәни, икътисади хокукларын IV Думадагы Мөселман фракциясе якларга тиешлеген аңлатып, С.Максуди болай ди: «Безнең Мөселман фракциясе күбрәге җәһәтеннән Волга тарафыннан сайланган депутатлардан булса да, фракциянең әхлакый–сәяси вә тарихи вазыйфасы җәһәтеннән бүген Русия мөселманнарына хезмәт итәргә тиеш»[24].

С.Максудиның әлеге мәкаләсенә каршы «Кояш» гәзитендә /1915, 3 декабрь/ IV Дәүләт думасы депутаты М.–Ю.Джафаров җавап мәкаләсе белән чыга. «Блок мөселман фракциясе өчен ябык. Безгә анда керергә тәкъдим иткән кеше юк. Аның программасында бары тик поляк һәм еврейларга карата гына пунктлар бар. Максудов әфәнде үзе биш ел буе Дума трибунасыннан мөселманнар теләгән, аларга мөһим булган проблемалар турында кычкырды, әмма аның тавышы Россия тормышы киңлекләрендә югалып барды», ди.

Шул ук вакытта С.Максуди биш–алты кешедән генә торган фракциянең кыска гына срокка җыелган Дума мәҗлесләрендә зур эшләр эшли алмаячагын да яхшы аңлый. Чөнки Беренче Бөтендөнья сугышы китереп чыгарган авырлыклар, халыкның кайгысы башка тарафта булу татар милләтен милли эшләрдән читләштерә. Әмма, шуңа да карамастан, Думадагы Мөселман фракциясе кечкенә булган шикелле, фракциянең артындагы милләт тә «яңа гына сәясәт әлифбасын укып яткан бер милләт» булганга күрә, аларның мөселман халыклары өчен Думада нинди дә булса файдалы эшләр эшли, кирәкле законнарны үткәрә алуы икеле икәнлекне белгән С.Максуди «хәрәкәттә – бәрәкәт» принцибыннан чыгып фикер йөртә. Чөнки ул Россия халыкларының хәле, эшләре бары тик законнар ярдәме белән генә төзәлергә мөмкин, дип саный. С.Максуди, татар зыялысы буларак та, дин белгече һәм юрист, шулай ук иң демократик дәүләтләрдән саналган Франция парламентының эшчәнлеге белән

дә таныш кеше буларак та, көч кулланып, ягъни кан коеп, сугышып мөселман халыклары өчен милли–мәдәни, сәяси, икътисади иркенлекләр алу мөмкинлеген кабул итә алмый. Шуңа күрә ул мөселманнарның дини эшләрен һәм дини мәктәпләрен реформалаштыруга зур игътибар бирә дә инде. Ул Диния руханиясе яңартылган, дини мәктәп–мәдрәсәләргә яңача фикерле, зыялы мөдәррисләр килеп, Диния идарәсе башында да укымышлы, милләт язмышы өчен борчылучы, мөселманнар өчен кирәкле эшләрне эшләргә хәзер булган мөфти торганда гына дини берләшү кичергән мөселман халыклары, дини сафлану кичергән татар милләтенең яңа милли үсеш чорына керәчәк дип уйлый. Ә инде алга киткән халыкның үз максатына бары тик тыныч һәм прогрессив юл белән – илдәге законнарны үзгәртү, яңарту юлы белән ирешергә тиешлегенә ышана һәм шуңа омтыла. С.Максуди сугыш бер бетәр, якты көннәр килер, татар халкы кабат үзенә милли, мәдәни, икътисади, сәяси яктан үсүне, яңартуны максат итеп куяр һәм татар милли хәрәкәте яңадан күтәрелеп китәр дигән өмет һәм шуңа ышаныч белән яши.

## ИСКӘРМӘЛӘР


1. Йолдыз – 1912 ел. – 7 октябрь.
2. Йолдыз – 1912 ел. – 22 июль.
3. Садри Максуди (1879–1957). – Казан. – 1996. – Б.149.
4. Шунда ук. – Б.151.
5. Йолдыз. – 1913. – 4 июнь.
6. Ислам в татарском мире: история и современность. – Казань. – 1997. – С. 109.
7. Садри Максуди (1879–1957). – Б.153.
8. Д.Әмиров. Татарлар Санкт–Петербургга. – //Мирас. – 1994. – 2 сан. – Б.59.
9. Йолдыз. – 1912. – 12 гыйнвар.
10. Адила Айда. Садри Максуди Арсал. – М. – 1996. – 303 с.
11. Йолдыз. – 1907. – 18 гыйнвар.
12. И.Таһиров. Бәйсезлек баскычлары. – Б.90.
13. Йолдыз. – 1914. – 2 май.
14. Йолдыз. – 1914. – 23 май.
15. Шунда ук. – 18 май.
16. Шунда ук. – 19 ноябрь.
17. Шунда ук. – 4 май.

18. Йолдыз. – 1914. – 22 ноябрь.
19. Йолдыз. – 1915. – 18 гыйнвар.
20. Шунда ук.
21. Йолдыз. – 1915. – 19 октябрь.
22. Шунда ук.
23. Йолдыз. – 1910. – 23 октябрь.
24. Йолдыз. – 1915. – 19 октябрь.

# IV БҮЛЕК
# САДРИ МАКСУДИ ҺӘМ МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ

## § 1. Садри Максуди – Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты Идарәсе рәисе

«Татар милләтенең оешу тарихында 1905–1907 еллардагы рус революциясенең әһәмияте искиткеч зур була. «Аң» журналының 1912 ел санында бу инкыйлаб татарларга башка халыкка караганда күбрәк файда китерде, диелә»[1]. Шушы революция китергән иркенлекләрне файдаланып, татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдә мәктәп–мәдрәсәләргә уку–укыту системасына яңа агым килеп керә, дистәләгән исемдә газета–журналлар чыга, йөзләгән исемдә ун меңнәрчә тираж белән дөньяви, әдәби китаплар басыла башлый, беренче татар театры труппалары барлыкка килә. 1905 елгы рус революциясе татар халкының мәдәни үсешенә генә түгел, аның милли аңын үстерүгә дә зур этәргеч була. Бу елларда татар милләтенең аз санлы укымышлы–зыялылары арасында Россиянең I–II–III Дәүләт думаларына сайланып, Дума мөнбәреннән Россиядәге мөселман халыклары өчен файдалы эшләр эшләргә, татар халкына дини, сәяси, милли иркенлекләр алырга тырышучылар да була. Татар халкында, татар зыялыларының фидакарьларча тырышлыгы нәтиҗәсе буларак, гасырлар буе әле кабынып, әле сүнеп килгән милли хис, милли аң уяна башлый. Милли–азатлык хәрәкәте барлыкка килә. Әмма Россия патша хөкүмәтенең үз кул астындагы милләтләргә каршы алып барган милли сәясәте татар милләтенә, мөселман халыкларына милли яктан да, сәяси яктан да үсәргә ирек бирми. Ә инде 1914 елда башланган Беренче бөтендөнья сугышы исә бу милли күтәрелешкә бөтенләй киртә куя, халыкның башына яңа кайгы килә:

мөселман халыкларыннан бу сугышка бер миллионга якын гаскәр алына.

Бары тик 1917 елгы Февраль революциясеннән соң гына татар халкында милли хәрәкәт яңа күтәрелеш ала. Татар зыялылары, шул исәптән, татар милли хәрәкәте идеологларының берсе булган С. Максуди да Февраль революциясен мәхкүмә милләтләргә азатлык алып килде дип шатланып каршы ала. Татар зыялылары Россиянең мөселман халыкларына милли һәм сәяси шартларны файдаланып калырга, илдә стихияле үсеп килгән вакыйгаларга, күтәрелеп килгән яңа көчләргә бу мөмкинлекне юкка чыгырырга ирек бирмәскә кирәклеген, илдәге килеп туган ситуациянең шушы юлда кискен чаралар күрергә этәргәнен дә аңлыйлар.

Ләкин татар халкының милләт җанлы зыялылары Февраль революциясеннән соң барлыкка килгән уңайлы вакыттан бердәм көч булып, ягъни «социалистлар», «милләтчеләр», «таң»чылар (алар бу чорда милләтчеләргә кушылган булсалар да) барысы бергә берләшеп, милләт язмышын хәл итә торган бер концепция эшләп чыгара алмыйлар. Бу агымнарның һәрберсе үзе тоткан кыйбласын дөрес дип санап, үз идеясен алга сөрә, татар халкы өчен шушы хәлиткеч вакытта да татар милли хәрәкәте җитәкчеләре таркау булып калалар.

1917 елда татар милли хәрәкәтендәге күпләр, шул исәптән татар эсерларыннан Ф.Туктаров та, Россия федератив дәүләткә әйләнсә, татарлар бик сибелеп яшәгәнгә күрә, алар өчен җирле мохтарият төзү мөмкин түгел, ди. Г.Ибраһимов исә, аерым җирле мохтарият оештыруны алга сөрә.

С.Максуди да Россия шартларында аерым милли дәүләт төзү мөмкин дип уйламый. Ул Россиянең үзәгендә яшәгән татар халкының, аерым бер милли дәүләт төзи аласына ышанмый, шунлыктан ул, татар халкы аеруча күп яшәгән территориядә Эчке Россия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтариятын төзү һәм барлык милли эшләрне милләтнең үз кулына алу мөмкинлеген күз алдында тоткан хәлдә, барлык төрки халыкларны бердәмлеккә чакыра.

Г.Ибраһимов та Февраль революциясен зур өметләр белән каршылый, әмма ул: «Ирек вә тигезлек булыр, ләкин анда да һичбер милләткә, һичбер сыйныфка, әгәр ул үз ноктасыннан тырышмаса, һичбер нәрсәне китереп бирмәсләр», – дип алдан ук кисәтеп, татар милләте үзенең бәйсезлеге, үзенең дәүләтчелеге мәсьәләләрен үзе генә хәл итә алачагын әйтә[2]. Ул Бөтенроссия мөселманнарының 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә уздырылган I съездында чыгыш ясаганда: «Безнең халыкларны берләштергән нәрсә — ул милли хис, бу сыйнфый хистән көчлерәк, шуңа күрә без милли хис нигезендә берләшергә тиешбез», – ди.

II–III Дәүләт думаларында эшләгән вакытта алдынгы фикерле рус сәясәтчеләре белән тыгыз элемтәдә булган, кадетларга бик якын торган С.Максуди, Петроградта март ахырларында уздырылган кадетлар партиясенең YII съезды эшендә катнаша. Бу съездда ясаган чыгышында ул: «Россиянең сәяси тормышында да, Думада да алдынгы карашлы партияләр белән бергә бардык, бигрәк тә кадетлар белән. Миңа калса, бу алга таба да шулай булачак. Шуңа күрә, әлеге партияләр мөселманнарның фикерләренә, таләпләренә колак салырга тиешләр, чөнки бу партияләр, шул исәптән, кадетлар партиясе дә мөселманнарның ярдәменә мохтаҗ булды, киләчәктә дә мохтаҗ булачаклардыр»[3], – ди.

Әлеге съездда катнашкан Вакытлы Үзәк мөселман Бюросы аның бу белдерүенә протест белән чыга. Аларның протестлары рус газеталарында да /»Русская воля», «Дело народа»/ басыла. Протест белдерүенә А.Цаликов, З.Вәлиди, С.Алкин, С.Шамил, С.Джантурин, Г.Исхаки, М.Бигиев кул куйган. З.Вәлиди үзенең «Истәлекләр»ендә: «Аның /С.Максудиның — Ф.Г./ 30 миллионлы мөселман халкы исеменнән кадет партиясенә турылыклы булу турында әйтергә хакы да, хокукы да юк иде»[4], дип яза.

С.Максудиның әлеге белдерүе, җәмәгатьчелек тарафыннан, озак еллар рәсми сәясәттә, милли хәрәкәттә кайнаган профессиональ сәясәтченең җитди ялгышы дип кабул ителә. Әмма С.Максудины бу фикеренә китергән сәбәпләрнең берсе — ул чорда кадетлар Россиядә төп көчләрдән булу һәм алар властька килгән очракта, алар белән бергә эшләү мөмкинлегенә ышану, шулай ук, татар халкы өчен дә файдалы эшләр эшли алуга өметләнү булган, дияргә

кирәк. Икенчедән, С.Максудиның ул вакытта властька килердәй башка реаль көчнең булмаган дип тә уйлавыдыр. Әмма, ничек кенә булмасын, ул чорда сәясәтче буларак С.Максуди Россия күләмендә дә, мөселман халыклары арасында да күренекле, танылган шәхес була. Моны раслау өчен аның башка татар милли хәрәкәте җитәкчеләреннән аерып тора торган эшчәнлеге – Вакытлы хөкүмәт тарафыннан Төркестан белән идарә итү өчен төзелгән Комитет составындагы эшчәнлеге турында әйтергә кирәк. Вакытлы хөкүмәт Төркестан белән идарә итү өчен тугыз кешедән торган Комитет төзи һәм бу Комитетка биш рус, дүрт төрки вәкиле, шул исәптән, С.Максуди да кертелә. Ул Вакытлы хөкүмәтнең әлеге тәкъдимен кабул итүне үзенең милли бурычы дип саный. Әмма, соңрак, Төркестанга җибәрелүен үзен Петроградтан – сәясәт мәйданыннан читкә җибәреп тору дип кабул итәчәк. Комитетта ул үзенә мәгариф эшен сайлый, ягъни мәгариф министры вазыйфасында була. Тик әлеге Комитет Төркестанда әллә ни эшли алмый: көннән–көн көчәя барган эшче–солдат депутатлары Советы Комитетның эшенә кысыла башлый, аңа үзбашка эшләргә ирек бирми. Шулай да әлеге Комитетның әгъзалары булган С.Максуди, З.Вәлиди, А.Дәүләтшиннар «Ислам шурасы» оешмасы тарафыннан оештарылган 1917 елның 16 апрелендә ачылган I Бөтентөркестан мөселманнары съезды эшендә катнашалар. Съездда Россиядә нинди идарә, нинди формада булырга тиешлеге һәм Төркестан мөселманнарының бердәмлеге, берлеге мәсьәләсе карала. З.Вәлиди монда Федерация идеясен күтәрә, ә С.Максуди бу идеягә каршы чыга. 1917 елның май ахырларында Комитет рәисе Н.Н.Щепкин, аннан соң, үзенең Комитетка кертелүен сәясәттән читләштерелү дип караган С.Максуди да Мәскәүгә кайтып китә. Мәскәүгә кайтып төшү белән С.Максуди Бөтенроссия мөселманнары Советының 21 июнь көнге утырышында катнаша һәм мөселман халыкларының Учредительное Собраниегә сайлау тактикасын эшләү өчен төзелгән комиссия составына кертелә. Ул, шулай ук, Бөтенроссия мөселманнарының II съездын чакыру–оештыру буенча төзелгән комиссиягә дә сайлана. С.Максуди 23 июньдәге утырышта үзенең һәм Төркестанга җибәрелгән Комитетның андагы эшчәнлеге турында җентекле доклад ясый. Шулай ук 28 июньдә Учредительное Собрани-

егә сайлау тактикасын эшләү буенча төзелгән комиссиядә дә чыгыш ясый һәм анда ул : «Мөселманнарның әлеге сайлауда тоткан тактикасы – ул сыйныфлар күзлегеннән чыгып түгел, ә милли–мәдәни яктан чыгып корылырга тиеш. Халыкларның азат тормышында экономика түгел, ә самостоятельная единица булуга омтылыш төп рольне уйный»[5], ди. 29 июньдә ул мөселман халыкларының хәле турында бик җентекле чыгыш ясый. Утырышта Казанда уздырылачак Бөтенроссия мөселманнарының II съездының көн тәртибенә икенче пункт итеп С.Максудиның әлеге чыгышын кертү турында карар да чыгарыла.

Шулай итеп, «Татар милләтчеләренең атаманы – юлбашчысы»[6] С.Максуди Бөтенроссия мөселманнарының июльдә Казанда узачак II съездына һәм ноябрьдә Уфада ачылачак Милләт мәҗлесенә татар милли–азатлык хәрәкәте җитәкчеләренең, лидерларының иң көчлесе һәм иң күренеклесе булып килә.

Бу көннәрдә татар халкының яшәеш рәвешен үзгәртү, милли бәйсезлеккә ирешү юлларын ачыклау буенча төрле мәсләктәге, төрле дәрәҗәдәге вәкилләре: хәрбиләре, руханилары Казанда үзләренең съездларын чакыралар. 1917 елның 20 июлендә Казанда Дворянское собрание бинасында Бөтенроссия һәм Себер мөселманнарының II съезды ачыла. Корылтайга сайланган вәкилләрнең саны Мәскәүдә уздырылган I Корылтайдан азрак була. Кавказдан, Әзербайҗаннан берничә генә кеше килә, ә казах, кыргызларның шул көннәрдә үзләренең җыелышлары булганга, аларның вәкилләре дә кичегеп килә. Кырымнан да бер–ике генә кеше була. Нәтиҗәдә, II Корылтайда күпчелекне Идел–Урал төрек–татар вәкилләре тәшкил итә. Әмма Казан Корылтаенда каралачак мәсьәлә конкрет булганга күрә, ул үзенең эшчәнлеге ягыннан Мәскәү Корылтаеннан югары була. Шушы ук вакытта Казанда Бөтенроссия мөселманнарның Хәрбиләр Шурасы һәм руханиларның да съездлары эшли. 22 июль көнне шушы өч съезд берләшә. Бу берләштерелгән утырышта инде 21 июль көнне булган ямьсезлекләр[7] кабатланмасын өчен дә чаралар күрелә, мөселман социалистлары исеменнән съездда катнашучы Г.Ибраһимов та үз иптәшләрен кисәтеп куя. Мәҗлеснең тынычлыгын саклау исә Гаскәри Шура әгъзаларына тапшырыла. Шушы өч съездның берләште-

релгән утырышында С.Максуди доклад ясый, Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Милли–мәдәни мохтарияты турында Декларация игълан итә. Милли–мәдәни мохтариятның башкаласы итеп Уфа шәһәре билгеләнә. Диния нәзарәтенең Уфада булуы да моңа сәбәп була, чөнки бу чорда милли–мәдәни тәрәккыятне, дин белән бергә алып бару кирәк дип санала. Милли–мәдәни мохтариятны вөҗүдкә чыгару комиссиясе (С.Максуди, И.Әхтәмов, Г.Шәрәф, Ә.Мөхетдиния, Ф.Кәрими, Г.Кәрими, Н.Хәлфин, Һ.Атласи) һәм ноябрь аенда шунда узачак Милләт мәҗлесен хәзерләү өчен Вакытлы Идарә төзелә, ә аның рәисе итеп С.Максуди сайлана. (Ул бу җаваплы эшне бик саклык белән, җитди уйлаганнан соң гына үз өстенә ала). «Бу съездда Садри Максуди татарның беренче кешесенә әверелә, газеталар аңа дан җырлый. Мулланур Вахитов һәм татар большевиклары да, большевиклар партиясенең моны кискен рәвештә кире кагуына карамастан, Милли–мәдәни мохтарият игълан итүне яклап чыгалар»[8].

«22 июль көнне кичке тантаналы мәҗлестә Милли–мәдәни мохтарият турындагы Декларация Садри әфәнде Максуди тарафыннан игълан ителде. Бердәм бөтен театрны кул чабу тавышы тутырды, алдан хәзерләнгән Милли Байрак күтәрелде. Меңнәрчә халык театр әтрафына тупланган иде. Йөзләр, күзләр туйдагы кеби көлә, әтрафка шатлык чәчә иде. Өмид, милли өмид бу бинадан чыгып бөтен шәһәргә тарала, бөтен Казанны тарихи замандагы урыска каршы җиңеп кайткан көннәрен яшәтә иде»[9].

Татар зыялылары Милли–мәдәни мохтарият төзелүне татар халкының дүрт йөз елга якын сузылган милли коллыктан чыгуы, милли гаделлекнең торгызылуы дип карыйлар. Шуларның берсе булган Ш.Әхмәдиев: «Татарга Милли–мәдәни мохтарият бирелү – аңар алла–табигать тарафыннан бирелгән, ләкин вакытлы гына залимнар тарафыннан алынган хокукның кире кайтарылуы гына»[10], – дип яза.

Г. Ибраһимов кебек социал–революционерлар II съездда ук Милли–мәдәни мохтарият идеясына каршы төшәләр. Ләкин Эчке Русия һәм Себер төрки–татарларның Милли–мәдәни мохтариятны игълан ителгәннән һәм зур күпчелек тавыш белән хуплангannан соң Г.Ибраһимов 1917 елның 30 июлендә «Аваз» гәзитендә: «Күз

алдында эшләнгән бу иҗтимагый җинаять хакында протестымны игълан кыйлырга үземне бурычлы саныйм», дип язып чыга. Шулай итеп, төрле мәсләктәге татар зыялылары шушы тарихи мизгелләрдә дә Крыловның Чуртан, Аккош, Кысласы сыйфатында эш итәләр. Берләштерелгән өч съезд мәҗлесе «Учредительное Собрание җыелганны көтмәстән, «Эчке Русия мөселманнары өчен Милли–мәдәни мохтариятны тормышка ашырырга керешү һәм мохтариятның структурасын төзү хакында җентекле проект төзүне шушы съездга тапшырырга»[11] дигән карар чыгара. Ә 31 июль көнне исә С.Максудиның Милли–мәдәни мохтарият турындагы проекты нигез итеп кабул ителә һәм мохтариятны гамәлгә кую чараларын күрү өчен төзелгән комиссиягә шушы ляихә нигезендә эшли башларга хокук бирелә. Әлеге документта бик әһәмиятле һәм тарихчылар игътибарыннан бераз читтәрәк калган бер җөмлә бар. Ул – 23 июль көнге мәҗлестә Эчке Русия мөселманнары Милли–мәдәни мохтариятен гамәлгә кую юллары турында фикер алышканнан соң «тупраклы мохтарият таләп итү хакын Эчке Русия мөселманнарының үзләренә калдыру», ягъни Уфада узачак Милләт Мәҗлесе карамагына калдыру турындагы карар. Бу инде Казандагы съездда ук Милли–мәдәни мохтарият идеясе белән бергә территориаль автономия идеясе дә кире кагылмаганын раслаучы факт. Шулай ук мохтариятны гамәлгә кую өчен төзелгән комиссиягә Г.Шәрәфнең сайлануы да аңа «Идел–Урал штаты» проектын төзү, Уфадагы Милләт мәҗлесендә игълан итү һәм мәҗлескә әлеге проектны да кабул иттерү мөмкинлеге биргән.

Съезд Милли–мәдәни мохтариятнең төп нигезләрен кабул итә. Болар Татарстан республикасы һәм татар халкы өчен бүген дә актуаль булган мәсьәләләр: 1) Русия хөкүмәтенең татар халкының дин һәм телгә, тәгълим–тәрбия, милли мәдәнияткә бәйле эшләргә катнашмавы һәм аларны хәл итү татар халкының үз эше булу; 2) Русия хөкүмәте тарафыннан мөселманнарның милли эшләре рус халкының милли эшләре кебек үк бер дәрәҗәдә хокуклы, рәсми хокуклы булуны мохтариятның төп әсаслары итеп билгеләнү. Шулай ук төп әсасларга лисан (тел) хокукы, мәхкәмәләрдә хөкем теле татар теле булу, мәмләкәтнең идарә органнары эшендә катнашу һ.б. да кертелә.

1917 елның 20 ноябрендә Уфада ачылачак Милли мәҗлескә әзерлек йөзеннән С.Максуди 27 сентябрьдә «Йолдыз» гәзите аша «Эчке Русия мөселманнарның Милли идарәсе тарафыннан халыкка хитап» белән чыга. «Русиянең иске идарәсе вакытында иң изелгән, һәрбер хокуклары чикләнгән бер милләт булса, шөбхәсез, ул безнең мөселманнар иде». Үзенең бу мөрәҗәгатендә С.Максуди һәр милләткә, һәр дингә хөррият бирә торган гадел хөкүмәт, ягъни Вакытлы хөкүмәтнең властька килүен, мөселманнар өчен «ябылмый торган бер «өмид капусы» ачты, шуңа күрә, милләтләрнең һәр теләге тормышка ашып торганга күрә, яңа хөкүмәтне хуплап каршы алдылар», ди. Вакытлы хөкүмәткә каршы көрәшүче көчләр (большевиклар – Ф.Г.) тараткан коткыларга колак салмыйча, мөселман демократиясе рус демократиясе белән кулга–кул тотышып, туганлык, тигезлек, тугрылык нигезләренә корылган Вакытлы хөкүмәтне ныгытырга иҗтиһад итү тиешлеген аңлатып, золым һәм җәбер нигезе өстенә корылган иске хөкүмәтне кайтару юлында корал булмаска чакыра һәм бөтен имамнарның бу мөрәҗәгатьне халыкка укып аңлатуларын үтенә.

Милләт мәҗлесенә әзерлек чорында З.Кадыйри да дөньядагы илләрнең яшәеш рәвешләрен (Австрия–Венгрия берләшкән патшалыклар; Германия федерациясе; Америка штатлары берлеге; Швецария җөмһүриятләре берлеге турында) һәм Русиядә нинди идарә булырга тиешлеген һәм кирәклеген аңлаткан «Мәмләкәт идарәсе рәвешләре» дигән хезмәтен бастырып чыгара»[12].

Ниһаять, зур әзерлек эшләреннән соң Уфада 20 ноябрьдә Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Милли–мәдәни мохтариятының Милләт мәҗлесе ачыла. Бу мәҗлестә татар халкының бар зыялылары диярлек җыелган дисәк, ялгыш булмас. А.Г.Тугры имзасы белән чыккан «Вәкилләр көзгесе» дигән китапта аларның тулы исемлеге бирелә, аларның һәркайсы автор тарафыннан усал–усал характеристикага лаек булса да, Милләт мәҗлесенә татар милләте язмышы өчен янып–көеп йөрүче милләтпәрвәрләр җыелган була (И.Әхтәмов, И.Алкин, Ф.Мөхәммәтьяров, Г.Акчурин, Г.Исхакый, Һ.Максуди, Ш.Алкин, З.Кадыйри, Г.Ибраһимов, Н.Корбангалиев, Ш.Әхмәдиев, Мөхлисә Буби, Абруй Сәйфи, Фатих Сәйфи, Ф.Туктаров, Г.Баттал, Һ.Атла-

си, З.Камали, С.Җантурин, Г.Буби, С.Максуди һәм башкалар). Әлеге автор үзенең китабында алар турында кызыклы гына мәгълүматләр биргән.

22 июльдә Казанда булган съездда мохтарият игълан ителгәннән соң 16 кешедән торган Вакытлы Милли Идарә төзелеп, бу Идарәгә өч вазыйфа йөкләнгән була. Болар: 1) «Мохтариятны вөҗүдкә чыгару, 2) Мохтарият фикерен бөтен төбәкләрдә гамәлләштерү, 3) Милли–мәдәни кануннар чыгарачак Милләт мәҗлесен җыю».

Милләт мәҗлесен ачканда Идарә рәисе Садри Максуди: «Шушы өч ай эчендә һәр өч нәзарәт: Диния нәзарәте, Мәгариф нәзарәте, Малия нәзарәте һәрберсе үзләренә тиешле эшләр белән шөгыльләнде. Малия нәзарәте милләт фондына бер миллионнан артык сумма туплады, ә Мәгариф һәм Диния нәзарәтләре, мохтарият фикерен гамәлгә ашыру юлында эшләп, барлыгы 6300 мәхәлләдә мохтариятны яклаучылар булдырды», дип хисап бирә һәм «Бүген шимал төрекләре өчен бөек бер көн. Хакыйкатьтә Казан, Әстерхан ханлыкларыннан соң безнең халык бит бер милләт булып яшәүдән тәмам чыккан иде. Ул – бик олуг бер милләтнең калдыгы, соңы гына иде. Безне изгән кара куәт үз җәзасын күрде. Ул куәт хәзер кайтмаска тиешле. Без, төрек–татарлар бар куәтебез белән шул хакта тырышачакбыз», ди. Ләкин ул: «Без оешабыз, ләкин бу оешуларыбыз яшәрме?» дигән соравына үзе үк, әгәр халык бердәм булса, безне читтән, тыштан булган дошманнар җимерә, бетерә алмас, дип җавап бирә. «Без хәзер бу гасырда хәятка яңа нигез салабыз, безнең киләчәгебез якты!»[13] дип татар милләтенең утыз–кырык елдан соңгы якты киләчәге турында матур хыялларга бирелгән С.Максуди, көчле кул чабулар астында, Милләт мәҗлесен ачып җибәрә.

А.Г.Тугры, җирле мохтарият тарафдары буларак, ачы ирония белән: «Русиядәге бөтен милләт үз тәкъдирен үзе хәл кыйлган бер вакытта менә шундый курка–курка гына игълан кылынган съездлар моның җавабын үзләре бирерләр. Шушы сәясәт диңгезенең көчле фортунасы вакытында моның белән маташу түбәнлек иде. Ә аны Керенский хөкүмәтеннән тәсдыйк кылырга (танытырга)

йөрү аннан да коләчрәк иде»[14], дип язып чыкса да, Милләт мәҗлесе үз эшен күтәренкелек белән башлап җибәрә һәм дәвам итә.

Сул эсер Ш.Әхмәдиев, Совет хөкүмәтенә тәбрикләү җибәрү турында тәкъдим белән чыга, ләкин Милләт мәҗлесе аның тәкъдимен кире кага: ул Совет хөкүмәтен танымый.

«Әгәр зур Корылтайлар «тупраклы мохтарият» дигән лозунг тотса, безнең тарихта бик күңелле сәхифәләр язылган булыр иде», ди «Вәкилләр көзгесе»нең авторы ачынып, «Төрек–татарның эше кайчан вә нинди генә урында булмасын, һаман хәерчелек вә сәдакага багълы була. Билләһи газим, бу чит мәмләкәтләр хозурында бик оят булган бу хурлыктан милли Идарә дә котыла алмады, ул да сәдака җыюдан башлады!» дип яза. Шулай да, әлеге китапның авторы Милләт мәҗлесенең бер файдалы эшен дә күрә алган. Бу – мәҗлестә бик мөһим мәсьәлә – «тупраклы мохтарият» мәсьәләсе каралу. «Ләкин инде без соңа калган идек. Ул вакытта Русияне үзгәртеп бетергәннәр дә идарә итәргә керешкәннәр иде инде. Хәтта гыйлем вә мәгарифтә иң түбән дәрәҗәле башкорт агайлары да «тупраклы башкорт мохтарияты» игълан итеп, бөтен эшне бозып куйганнар иде»[15], ди.

Милләт мәҗлесе 1918 елның 11 гыйнваренә кадәр эшли. (Милләт мәҗлесе кабат 1918 елның 1 маена билгеләнә). Бу вакытта мохтариятның төп законнары эшләнә һәм раслана, Милли Идарәсе һәм аның рәисе итеп «бу эшне сыек вакыттан ботка хәленә китерелгәнче даими болгатучы кеше Садри Максудов»[16], Диния нәзарәтенә мөфти итеп Г.Баруди, казыйлар итеп Р.Фәхретдинов, К.Тәрҗемани, Мөхлисә Буби; Малия нәзарәтенә Ш.Алкин; мәгариф нәзарәтенә Н.Корбангалиев сайлана. Мәҗлес шулай ук Версаль конференциясенә делегатлар итеп Г.Исхакый, Ф.Кәрими, З.Шнасины күрсәтә.

Милләт Мәҗлесе эшли башлагач та «тупракчылар» фракциясе барлыкка килә, ул Г.Ибраһимов, И.Алкиннарның зур тырышлыгы белән төзелә, аңа утыздан артык делегат керә. Милләт Мәҗлесе Милли–мәдәни мохтариятне тормышка ашыру мәсьәләләрен хәл итү өчен җыелган булса да, озак һәм кызу бәхәсләрдән соң, Идел–Урал штаты, ягъни татар милли дәүләтен игълан итә. Әлеге штатның дәүләт төзелеше турындагы концепцияне – докладны Галим-

җан Шәрәф ясый. Мәҗлестә Идел—Урал штатын төзү өчен аерым бер комиссия да сайлана һәм сигез кешедән торган бу комиссиягә Г.Ибраһимов, Г.Шәрәф, И.Алкин, Г.Акчурин, С.Атнагулов, Ф.Сәйфи, С.Енгаличев, И.Хәлфин керә (Болар һәммәсе дә «туфракчылык» идеясен яклаучылар, «төркичеләр»дән бу комиссиягә берәү дә керми).

Әмма «Вәкилләр көзгесе»нең авторы А.Г.Тугры С. Максудины Милләт мәҗлесе ябылганнан соң узган бер—бер ярым ай вакыт эчендә милләт вәкилләре, Милли Идарәгә чикләнмәгән хокуклар биреп калдырган хәлдә дә, шул хокуклардан файдаланмауда, ягъни эшсезлектә гаепли: «Әгәр бу урынга Ваисов яки З.Вәлидине калдырсаң, алар бөтен бер мәмләкәт төзеп бетергән булырлар иде»[17].

Әгәр Россиядәге хәлләр шул көенчә генә барса, берзаман җирле мохтарият, ягъни Идел—Урал штаты да төзелер, Россия эчендә федератив дәүләт булып яшәү мөмкинлеге дә чыгар иде. Чөнки Милли—мәдәни мохтарият җирле властька бәйләнмәсә, озын гомерле булмаячагы шушы Милләт мәҗлесендә үк инде ачык күренә. Мәҗлестә барлыкка килгән бу ике фракция, ниһаять, берләшеп, бергә эшләү мөмкинлекләрен эзли башлыйлар, ә аларны берләштергән идея—федерация идеясе була. «Туфракчылар» Идел—Урал штаты җирле мохтариятын төзү фикерен күтәреп чыгып, бу штатның чикләрен дә билгелиләр, ягъни ул үз эченә Уфа, Казан губерналарын, Оренбург губернасының көнбатыш, Пермь губернасының көньяк өлешен, Алабуга, Сарапул, Малмыж, Самара, Бөгелмә, Богырслан уездларының зур өлешләрен — татар—мөселман халкы яшәгән (3.690.000) территорияне үз эченә алырга тиеш була.

Милләт мәҗлесендә «туфракчылар» тарафыннан С.Максуди, үзен Әхәт бәк Цаликов, Г.Терегуловлар белән бергә федерация дошманы дип игълан ителүенә карамастан, ул татар халкы өчен Милли—мәдәни мохтариятны яклаган хәлдә, Россия читендә яшәүче мөселман халыклары өчен җирле мохтарият кирәк дип саный, аның, бу фикеренә Ф.Туктаров та кушыла.

Әмма бердәмлек булмау аркасында безнең узган тарихыбызда күпме фаҗигалар булганлыгы һәркемгә дә мәгълүм. 1917 елның 1

маенда Мәскәүдә уздырылган Бөтенроссия мөселманнарының Беренче съездында ук инде З.Вәлиди кискен рәвештә бербөтен мөселман милләте дигән милләт юк, мөселман халыкларын берләштерү аларның һәркайсының телен, культурасын бетерүгә китерәчәк, дип чыгыш ясаган була. «Ихтилял көннәрендә җыелган башкорт җыеннарында иң зур әһәмият бирелгән мәсьәлә җир мәсьәләсе булганга, З.Вәлиди тарихтан илһамланып уртага чыгарган мохтариятлы Башкорт иле хакындагы проблема җирле халыкның җир мәсьәләсендәге теләкләре белән туры килә иде»[18].

Милли–мәдәни мохтарият идеясын яклаучылар да, Идел–Урал штатын төзү идеясын күтәреп чыгучылар да башкорт халкы өчен архиважный булган мәсьәләгә – җир мәсьәләсенә игътибар итмиләр. Инде XX йөз башында ук татар халкы бөтен Русиядә сибелеп яши: Украина шахталарында күмер чаба, Уралда алтын прискаларында алтын чыгара, Уралда, Оренбургта, Казах, Кыргыз далаларында мөгаллимлек, сәүдәгәрлек итә. Шунлыктан аның интереслары да бөтен Русиядә. Милли–мәдәни мохтарият идеясын яклаучылар, аны тормышка ашырырга омтылучылар үз фикерләрен татар халкының әнә шул милли үзенчәлегеннән чыгып эш итәләр дә инде. Ә бертирәдә компактлы булып яшәгән аз санлы башкорт халкы өчен җирле автономия кирәгрәк дип табыла. Шушы мәсьәләдә татар милли хәрәкәте җитәкчеләре белән каршылыкка кергән З.Вәлиди, шуңа күрә, җир мәсьәләсен, җирле мохтарият мәсьәләсен башкортлар өчен иң мөһим мәсьәлә һәм иң кулай чишелеш дип карый. Бер–берсеннән ерак араларда яшәгән, мәгариф, мәдәният, сәяси һәм милли аңның үсеше ягыннан төрле дәрәҗәдә булган мөселман халыкларын бу вакыттагы илдәге сәяси хәл болай да бүлгәләгән иде инде. Һәм З.Вәлиди җитәкчелегендәге бер төркем зыялыларның аерым башкорт дәүләте төзәргә йөрүләренә, гомер–гомергә бербөтен булып диярлек яшәгән татар– башкорт халкының милли азатлыкка булган омтылышларына зур зыян китерде дип караган татар милли хәрәкәте җитәкчеләре, бу күренешне башкорт халкының да милли аңы уянуы дип таный да, Г.Исхакый, Ф.Туктаровлар З.Вәлидинең бу эшчәнлеген гомерләренең ахырына кадәр гафу да итә алмыйлар.

«Зәки Вәлиди дигән атасы башкорт арасында мулла булган бер татар егете дә татар—башкорт аерылыгы мәсьәләсен мәйданга аткан, аерым башкорт тәшкиләтен мәйданга китерергә тотынган иде. Милли эшләремезгә зур зыян китереп, Казанда бөтен Русия мөселманнары Корылтае игълан ителгәч, Оренбургта башкорт Корылтае чакырганнар иде»[19].

«Ул заманнар иске охранка агенты большевик Манатов белән берничә иярчене, большевиклар пропагандасына алданып, берничә йөз меңнән артмаган башкортларның аерым милләт кебек, аерым бер дәүләт төзү уенын алга сөрде»[20], дип яза соңыннан Г.Исхакый Милли—мәдәни мохтариятның төзелү тарихы, эшчәнлеге, милли хәрәкәтнең уңышлары һәм ялгышлары турында анализ ясаганда. Г.Баттал да милли хәрәкәтнең сул канатында булган Г.Ибраһимов, Ш.Манатов, М.Вахитовларны милли хәрәкәтнең тамырына балта чабалар, дип гаепләп чыга**.

Милли—мәдәни мохтариятның җитәкчеләре бу вакытта большевиклар режимын вакытлыга санап, төрек—татарларның үз билгеләнү хокукларын теге яки бу формада тормышка ашуына өметләнә әле. Алар большевиклар хөкүмәтенең милләтләр эше наркомы И.Сталинның Наркомнац каршында мөселман комиссариаты төзелү һәм аның комиссары итеп Ә.Цаликовны чакыруны да кискен рәвештә кире кагалар.

Милләт мәҗлесе ике ай дәвамында үзенең эшен алып бара, бу мәҗлестә кызу бәхәсләр белән мохтариятның төп законнары кабул ителә, «төркичелек», «туфракчылык» идеяләре тарафдарлары тыңланыла. Идел—Урал штаты идеясен тормышка ашыру юлында кыю адымнар ясала. Урта Иделдә һәм Көньяк Уралда яшәгән төркиләрнең күпчелеге Идел—Урал штаты эченә керергә, ягъни әлеге штатның мәйданы 221.000 кв.км, ә халкы 6,5 миллион булачак дип исәпләнелә. Шул ук вакытта Милләт Мәҗлесендә расланган нәзарәтләрнең һәрбере үз эшен эшли. Хәрби Шура гаскәр туплау белән шөгыльләнә, рус полкларыннан аерып алып, мохтариятның 10.000 кешедән торган милли полкы төзелә. Бу полк бөтен Идел—Урал шәһәрләрен большевиклардан әле 1918 елның 12 апреленә кадәр саклый.

Милләт Мәҗлесендә Идел–Урал штатының төп нигезләрен төзү өчен аерым бер комиссия төзелә һәм уналты кешедән торган әлеге комиссиягә Г.Ибраһимов, Г.Шәрәф, И.Алкин, Г.Акчурин, С.Атнагулов, Ф.Сәйфи, С.Енгаличев, Н.Хәлфин, «төркичеләрдән» Г.Баттал керә. /С.Максуди, Милли–мәдәни мохтарият Идарәсе рәисе итеп сайлангач, нейтраль позициягә күчә, «төркичеләр» фракциясеннән чыга/. Мәҗлес бу мәсьәләдә ун пункттан торган резолюция кабул итә. Аның алты пункты төрек–татарларының территориаль автономиясен аерым штат рәвешендәге федератив дәүләт төзү турында, 7–8–9 пунктлары Милләт мәҗлесенең татар–башкорт мөнәсәбәтләрен җайга салу юлларын эзләү турында, ә бер пункт исә С.Максуди таләбе буенча кертелә. Бу пункт – Милли–мәдәни мохтарият турында Милләт мәҗлесендә кабул ителгән карарларның үз көчендә калуларын, аларның законлы булуларын раслаучы пункт.

29 ноябрь көнне Милләт мәҗлесендә Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының /Идел–Урал штаты рәвешендә/ җирле мохтариятен төзү турында тарихи карар кабул ителә, ә 1918 елның 6–7 нче январь мәҗлесендә Идел–Урал штаты төзелү игълан ителә. Бу турыда төп документлар кабул ителгәннән соң, 11 январь көнне кичен Милләт мәҗлесе ябыла. Шулай итеп, Г.Шәрәф эшләгән проект нигез итеп алынып әлеге Мәҗлестә татар милли дәүләтчелеген төзү идеясе хәл ителә. С.Максуди, Мәҗлес ябылгач, Казанга кайта һәм инде ул анда Идел–Урал штатын төзүдә катнашмый.

Кызганычка каршы, С.Максудины үз чорында да, хәзер дә татар халкы өчен Милли–мәдәни мохтарият идеясен сайлавын аның сәяси хатасы дип санаучылар бар. «Милли дәүләтчелек булдыру перспективасын бары тик Милли–мәдәни мохтарият проекты белән генә бәйләп, аны тормышка ашыру өчен күп көч сарыф итүләрен, тупраклы мохтариятка тиешле әһәмият бирмәүләрен берничек тә аклап булмый»[21]. Әмма, реалист буларак, ул үзенең эшчәнлегендә шул чор өчен иң реаль дип санаган позицияне сайлый: аның өчен иң мөһиме җирле берләшү түгел, ә бөтен Россия мөселманнарын рухи берләштерү, аларның рухи бердәмлекләре була. Башта Бөтенроссия мөселманнарының Милли–мәдәни мох-

марияте дип фараз кылынган мохтарият, илдәге вакыйгалар, мөселман халыклары арасында килеп чыккан каршылыклар аркасында, Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты рәвешендә игълан ителә. Бу – шул чорда Россия шартларында эшләргә мөмкин булганның иң бөек ноктасы дип карарга тиештер. Дөрес, С.Максуди «җирле» мохтарият идеясен күтәреп чыкмый. Ул, аерым дәүләт булып, Россиядән аерылып чыгуны да максат итеп куймый, чөнки ул чорда бу мөмкин дә булмый. Гомере буе сыйныфлар көрәшен кабул итмәгән С.Максуди Россиядә сибелеп яшәгән татар халкы өчен милли бердәмлек, ә мөселман халыклары өчен рухи бердәмлекне яклаган, шуңа күрә дә, Милли–мәдәни мохтарият Идарәсе рәисе буларак эшчәнлегендә дә ул шушы фикеренә турылыклы калган. Әмма, шулай да, ул ерак киләчәктә аерым дәүләт төзү фикереннән дә баш тартмаган. / «Мөмкин булса, үзебезгә аерым дәүләт тәшкил итү дәрәҗәсенә кадәр тырышачакбыз»/.

Бу чордагы эшчәнлеге өчен сыйнфый көрәшне кабул итмәгән, тарихи үсеш аркылы бары тик законлар нигезендә генә татар халкының яшәешен үзгәртергә, аны мәдәни, игътисади, сәяси яктан Европа халыклары дәрәҗәсенә күтәрү өчен бар көчен, белемен, акылын биргән либерал С.Максуди һәм аның фикердәшләрен «тупраклы мохтарият» яки милли–мәдәни мохтариятне «тупраклы мохтарият»кә бәйләп төзмәүдә гаепләү дөрес булмастыр. Чөнки тарихи вакыйгалар шулай килеп чыга. «Тупраклы мохтарият»игълан ителә, ләкин инде аны тормышка ашыру мөмкинлеге булмый. З.Вәлидиләр тарафыннан игълан ителгән башкорт җирле автономиясе дә советлар тарафыннан юкка чыгарыла бит.

Совет хөкүмәте 1917 елның 2 (15) ноябрендә «Россия халыклары хокуклары Декларациясен» кабул итә (декларациядә халыкларның үзбилгеләнү мәсьәләсен дә хәл итү хокуклары турында сүз бара). Милләт мәҗлесе туфраклы Идел–Урал штаты идеясын, бергә яшәү өчен кыенлыклар туганда, Россиядән аерылу мөмкинлеге белән дә бәйләп карый. Ләкин 1918 елның 12 (25) гыйнварендә матбугатта игълан ителгән «Хезмәт ияләре һәм изелгән халык хокуклары Декларациясе»ндә бары тик совет властен таныган ха-

лыклар өчен генә «үзбилгеләнү хокукы»на ия булуы әйтелә. Милләт мәҗлесе Совет властен танымый, шуңа күрә Совет хөкүмәте дә аның карарларын танудан баш тарта.

1918 елның 13 апрелендә большевиклар власте үзенең декреты белән Милли–мәдәни мохтариятны юкка чыгара: милли оешмалар бетерелә, милли полк таратыла, мохтариятның бар милке конфискацияләнә, җитәкчеләренең, качып китә алмаганнары кулга алына, Уфа совдепына килгән И.Сталин һәм татар–башкорт комиссариаты председателе М.Вахитов кул куйган телеграммада болай диелгән:

«Милли идарә», так называемое национальное управление внутренней России и Сибири, и все связанные с ним губернские, уездные и районные учреждения, а также «Милли фонд» упраздняются. Все имущество, деньги, документы их передаются в распоряжение Центрального мусульманского комиссариата при народном комиссариате по делам национальностей»[22].

«Бөтен илләремез русларның большевиклары тырнагы астында калып, Милли–мәдәни мохтариятемез җимерелде. Бүген шул вакыйгаларның егерме еллыгын искә алганда, илемебез безнең халыкларның шулкадәр өмид, ышаныч берлә тудырган милли дулкыннан фәкать Диния нәзарәтебез генә калды. Ул да хокуксызлыгыннан буылып, халкыбызның тырышлыгы, дини хезмәтчеләремезнең фидакарьлеге берлә генә күтәргән байрагын саклап килә. Милләтнең шул зур көннәрдә хөрмәтле урыннарда йөретелгән милләт хезмәтчеләренең зур күпчелеге большевиклар тарафыннан төрле елларда үтерелде, мөһаҗирлеккә киткәннәренең күбесе милли эштән китте, дөнья кайгысына бирелде, үзенең милләтенә биргән сүзләрен онытты. Бу эшләремезгә бәһа кую, бөтен эштән чигенгәннәрдән хисап сорау милләтнең үз эшедер, аларга тамга сугу тарихыбызның эшедер»[23], дип язачак Г.Исхакый 1937 елда «Яңа милли юл» журналында.

Ләкин 1918 елның июлендә Казанда ак чехлар идарә иткәндә төрек–татар халкы Милли Идарәсенең илдәге әгъзалары мохтариятның Милли үзәген һәм милли полкларын кабат торгызалар һәм сентябрь аенда Уфада узган дәүләт җыелышы вакытында Учредительное собрание хөкүмәте белән бергәләшеп эшләү турында ки-

лешү да төзиләр. Башта ук Милли–мәдәни мохтарият идеясенә каршы булган Г.Ибраһимов 1919 елда алар турында: «Безнең милли ахмакларымыз Колчак ярдәме белән шул чирле туган баланы яңадан тергезмәк булдылар»[24], – дип язып чыга.

Адмирал Колчак, аларның үзенә багъланган өметләрен юкка чыгара: ул милли оешмаларны танымый һәм милли гаскәр төзәргә дә рөхсәт бирми, ә милли полкны 16 нчы татар полкы дип үз гаскәре составына кертә. Шулай итеп, Милли–мәдәни мохтариятның калдыклары булган бу хәрәкәт ике ут арасында кала: бер якта большевиклар, икенче якта исә рус империячел идеяләре белән сугарылган адмирал Колчак хөкүмәте. Соңрак, Колчак гаскәрләре чигенгәндә, татар полкының югарырак дәрәҗәле чиннары һәм мохтариятның кайбер әгъзалары Ерак Көнчыгышка качарга мәҗбүр булалар: болар – «Колчак арбасына дегет лагуны булып китүчеләр»[25], ягъни Г.Исхакый, Ф,Туктаров, Г.Терегулов, Г.Еникеев, З.Кадыйри һәм башкалар. Әмма Г.Баттал, соңрак, үзенең Г.Ибраһимовка багышланган мәкаләсендә аның бу сүзләрен бик кискен кире кагып: «Казан төрки милли политикларының, сүздә халык власте яклы булып кыланган большевиклардан качып, патша режимын яңадан торгызу тарафлысы булган кара диктатор адмирал Колчакның кочагына сыенулары турындагы сүзе чып–чын бер уйдырмадан һәм ялганнан башка берни түгел иде»[26], дип яза.

1918 елда татар–башкорт республикасы төзү уе белән янып йөргән М.Вахитов, Г.Ибраһимов кебек күренекле шәхесләр дә, Г.Баттал язганча, большевиклар тозагына эләгәләр: алар бу идеянең чынга әйләнәсенә ышаналар. Шуңа күрә дә әлеге идеяне кабул итмәгән, аңа ышанмаган Г.Исхакый, Ф.Туктаров, С.Максуди һәм башкалар алар тарафыннан матбугат битләрендә дә, митинг–җыелышларда да аяусыз тәнкыйть ителәләр.

Шулай итеп Октябрь инкыйлабы татар милли хәрәкәтенең идеологларын, татар зыялыларын капма–каршы ике лагерьга бүлә. Берәүләр, социалистик революцияне кайнар яклап, Татарстан Совет социалистик республикасын төзеделәр һәм, бераз соңрак, шул социалистик революциянең канлы балтасы астында һәлак ителделәр. «Сәясәт базарының әрсез маклеры», «мескен һәм шакшы

язучы кисәкләре»[27] дип М.Вахитов ачы көлеп язган Ф.Туктаров, Г.Баттал, Г.Исхакыйлар эмиграциягә китәргә мәҗбүр булдылар.

1919 елның январенда Милли–мәдәни мохтариятның Петропавловск шәһәрендә җыелган әгъзалары үзләренең «Кече мәҗлес»ләрен уздыралар, хәтта «Маяк» исемле бер гәзит тә чыгара башлыйлар. (Аның барлыгы утызлап саны чыгып кала). Ләкин инде бу Милли–мәдәни мохтариятның Россиядәге эшчәнлегенә куелган соңгы нокта була.

Милләт мәҗлесе Версаль конференциясенә баручыларга (Г.Исхакый, Ф.Кәрими, А.Цаликов) 25 000 сум күләмендә акча биргән була, тик соңарак бу акча большевиклар тарафыннан талап алына. Г.Исхакый конференцияга бару өчен ярдәм сорап «Маяк» гәзите аша Кызылъяр шәһәренең хәлле кешеләренә мөрәҗәгать итә[28].

Шулай итеп, XX йөзнең беренче чирегендә татар халкының зур күтәрелеш алган милли–азатлык хәрәкәте Россиядә урнашкан большевиклар власте тарафыннан бастырыла, татар милләтенең гасырлардан бирле яшәп килгән үзенең бәйсезлеген торгызу хыялы сүндерелә.

С.Максуди, 1919–1921 елларда Милли–мәдәни мохтариятның Милли Идарәсе рәисе буларак, эмиграциядә Европа аренасында сәяси эшчәнлек алып бара. Тик 1925 елда Төркиягә бөтенләй күчеп килгәч, ул үзенең бу сәяси эшчәнлеген туктата. Шуннан соң эмиграциядәге татар милли хәрәкәтен озак еллар буенча икенче олуг милләтчебез – Гаяз Исхакый җитәкли.

### §2. Садри Максудиның эмиграциядә Милли Идарә рәисе буларак эшчәнлеге.

1918 елның 13 апреле декреты белән большевиклар хөкүмәте тарафыннан Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты куып таратылганнан соң, большевиклар хөкүмәте тарафаннан эзәрлекләнгән С.Максуди да, киемнәрен алыштырып, кыяфәтен үзгәртеп, айлар буе авылдан–авылга күчеп йөргәч, ниһаять, Финляндиягә качак булып килеп җитә. Йөз елга якын мех сәүдәсе белән шөгыльләнгән Финляндия татарлары большевиклар кулыннан исән–имин котылган С. Максудины сөенеп

каршы алалар, аңа кадер–хөрмәт күрсәтәләр. Әмма Россиядә гражданнар сугышы барганга күрә, Финляндия бу илдән беркемгә дә сыену урыны бирми. С.Максуди өчен яшәү өчен рөхсәт сорап йөргән кешеләр дә берни эшли алмый. Шуннан соң эчке эшләр министры янына С.Максуди үзе бара һәм министрга: «Без рус түгел, безнең каныбыз сезнең белән бер. Берзаман Думада без сезнең хакны да даулаган идек. Ә сез исә бүген безгә үзегездә калырга да ризалык бирмисез», ди.

Министр: «Әйе, хәтерлим. Думада Садри Максудов дигән берәү безне бик яклады. Сез ул кешене беләсезме?» дип сорагач, Садри Максуди үзенең, шул Садри Максуди икәнлеген әйтә[29]. Россиянең III Дәүләт думасында бик чуалчык, бик четерекле булган Финляндия мәсьәләсе каралганда Садри Максуди шушы мәсьәләне тикшерү өчен оештырылган комиссиядә берничә мәртәбә чыгыш ясый, ә 1910 елның, 6–8 июнь саннарында «Йолдыз» гәзитендә «Сәяси сөхбәтләр» исеме астында «Финляндия мәсьәләсе нидән гыйбарәт?» дигән озын мәкаләсен дә бастырып чыгара.

1809 елда Швеция белән Россия үзара килешүе нәтиҗәсендә Швециянең берничә губернасы Финляндия исеме астында Россиягә бирелә, әмма бу өлкәләр Россия кул астына кергәч тә, үз ирекләре белән яшәп ятуларын дәвам итәләр. Бары тик XIX нчы гасыр ахырында гына аларның барлык хокуклары да кысыла башлый, финнар үзләренең рус гаскәрләрендә хезмәт итәргә, ә үз гаскәрләренең бетерелергә тиешлеген милләтләрен бетерү дип кабул итәләр. 1908 елда Россия Дәүләт думасы Финляндиядәге төрле җәмгыятьләрнең хәрәкәтләре турында уңнар тарафыннан ясалган запрос каралганда Столыпин зур чыгыш ясый. Ул үзенең чыгышында Россия белән Финляндиянең гомуми мәнфәгатьләренә ярақлы кануннар кирәклеге турында әйтә. Менә шушы проблема тикшерелгәндә, мәхкүмә милләтләрнең патша хөкүмәтенең төрле кысуларына, аларның ирекләрен чикләүләренә, бу милләтләрнең хөррият таләп иткән тавышларына битараф кала алмаган С. Максуди, финнар үз хокукларын таләп итеп чыкканда аларның милли хәрәкәтләрен яклап чыгышлар ясый. Күрәсең, бу чыгышлар турында Финляндиядә дә ишеткәннәр.

Шушы очрашудан соң эчке эшләр министры аңа Финляндиядә яшәргә рөхсәт кәгазен үзе китерә, С.Максудины хөкүмәт кунагы дип белдерә.

1919 елның январенда Парижда Тынычлык конференциясе булачагы игълан ителә. С.Максуди бу конференциядә катнашырга уйлый, ләкин аның кулында аңа бу вәкаләтне биргән бер документ та булмый. Милли–мәдәни мохтариятнен Россиядә калган әгъзалары Уфадан Петропавловск шәһәренә килгәч, анда «Рече мәҗлес» уздыралар һәм аның Парижда икәнен газеталардан укып белгән Мәҗлес эмиграциядәге С.Максудины үзенең рәисе итеп таный, аңа 1919 елның 23 январенда 32 номер астында үзенең таныклыгын бирә. Бу таныклык нигезендә Садретдин Низаметдин улы Максудовның Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты Милли идарәсенең рәисе икәнлеге Милли управлениенең мөһере һәм култамгасы белән раслана. Таныклыкка Милли управлениенең рәисе өчен Гайсә Еникеев кул куйган. Мәҗлес Парижда үткәреләчәк Тынычлык конференциясенә Ф.Туктаров белән Г.Исхакыйны вәкилләр итеп сайлый. Алар бу Конференциядә катнашырга тиешле С.Максудига әлеге мандатны да тапшырырга тиеш булалар.

Ләкин Парижга бару өчен бу гына җитми, икенче бер катлаулы мәсьәлә – виза мәсьәләсе килеп чыга. Финляндия аңа берничек тә виза бирә алмый, шунлыктан, С.Максуди, анда виза алу мөмкинлеген ишетеп, Стокгольмга килә, аннан транзит виза белән Германия аша Парижга китә. Франция исә әле бу вакытта бары тик Керенский хөкүмәте илчелеген генә таный. С. Максудиның законнан тыш булган бу хәрәкәт–маҗаралары турында шул вакыттагы бер француз газетасы язып та чыга.

С.Максуди бу Тынычлык конференциясенә зур өметләр багълый: чөнки ул Россиядә большевиклар астында калган татар халкының проблемалары мәсьәләсен халыкара конференциянең көн тәртибенә куярга тырышачак. «Eclair» газетасының 30 май санында чыккан мәкаләдә С.Максуди Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларның Милли–мәдәни мохтарияты җитәкчесе һәм Россиядәге 30 миллионлы мөселманнарның лидеры буларак та таныла. «Садри Максудов – утыз миллионлы Россия мөселманнарының

җитәкчесе, аларның ышанычы һәм таянычы буларак большевизмга каршы көрәш алып бара. Революциядән соң төзелгән татар дәүләтенең җитәкчесе хәзер Парижда. Ул безнең хәятне, телебезне дә бик яхшы белә. Максудов, тәҗрибәле сәясәтче буларак, үзенең Париждагы эшчәнлеген бик оста йөртә, аның оста дипломатиясе большевиклар белән бәхәстә гел җиңеп чыгарга ярдәм итә»[30].

Бу тану С.Максудига бераз җиңеллек китерә, димәк, ул Тынычлык конференциясендә халыкларның язмышларын хәл итүне сорап чыгыш ясый алачак.

С.Максуди, Россиядәге ун миллионлы төрек–татар халкының вәкиле буларак, Тынычлык конференциясенә Меморандум әзерли. Америка, Англия, Франция делегацияләре җитәкчеләре белән очрашып аларга Казан татарларының хәлләрен аңлата. Һәрберсенә үзе язган Меморандум текстын тапшыра. Ләкин үзләрен Европа хакимнәре дип санаган һәм Ислам дөньясы вәкилләрен санламаган, бөекдержавачыл идеялардән арына алмаган бу делегацияләр тарафыннан алар күтәргән проблемалар игътибарга алынмый.

Бу вакытта Парижда яшәгән С.Максуди, З.Вәлиди, Мостафа Чокай, Г.Топчибашевлар бергә җыелышып киңәшәләр. Парижда С. Максуди азәрбайҗан халкының чит илдәге вәкиллеге җитәкчесе Г.Топчибашев белән очраша һәм алар мөселман халыкларына кагылышлы проблемаларны әлеге Конференциягә бергәләп әзерлиләр. М.Чокай белән С.Максуди үзләренең демократик Русия өчен көрәшчәкләрен, мөселманнарның хокукларын да шул шартларда якларга тырышачакларын аңлаталар. Г.Топчибашев, үзләренең бердәм көрәш юлына баса алмауларын «Рәсәй мөселманнарының бер бердәм комитет оештыру заманы килеп җитмәгән» әле дияргә мәҗбүр була. Ә С.Максуди исә үзенең демократик Русия өчен көрәшү юлына басуын «без артыбыздагы күперне яндыра алмыйбыз»[31], дип аңлата. Димәк, С.Максуди һәм аның көрәштәшләре илгә кайту өмете белән яшәгәннәр.

Ул, шулай ук 1920 елның 25 ноябрендә Женевага – Милләтләр Лигасына да Россиядәге татар халкының хәлен аңлаткан, большевиклар кул астында калган татар халкы язмышына Халыкара юл белән тәэсир итүне сорап Мөрәҗәгать һәм доклад җибәрә.

Моны С.Максудига Милләтләр Лигасының сәясәт комитеты директоры Поль Манионнан килгән хат раслый.*

С.Максуди Тынычлык конференциясендә үзен бик борчыган мәсьәлә – Төркиянең хәле турында да чыгыш ясарга уйлый һәм бу турыда, Милли–мәдәнн мохтарият җитәкчесе буларак, 1920 елның 10 январенда белдерү ясый.

Бу вакытта Антанта илләре Төркияне инде бүлешеп бетергән, ягъни Измирны греклар, көнбатыштагы җирләрен французлар, англичаннар, Анталияне итальяннар басып алган була. Төркия хәлифәсе исә инглизләр кулында әсирлектә, ә Төркияне сугышка китереп кертеп шушы хәлгә төшергән Әнвәр паша үзе Германиягә качкан була. «Османлы хәлифәсе бөтендөнья мөселманнары өчен Папа католиклар өчен булган кебек изге иде. Русия мөселманнары Төркиягә каршы сугышырга теләмәсәләр дә, Русия гражданнары буларак, Төркиягә каршы сугышкан Франция, Англия ягыннан сугышка катнашкан Русия гаскәрләренә 800.000 гаскәри биргән һәм алар бу илләр өчен дә сугышканнар. Бу дәүләтләр үзләренең, һәрьяктан Русия мөселманнарына бурычлы икәнлекләрен онытмаска, аларның теләкләренә колак салырга тиешләр. Истамбул хәлифә кулыннан алынмасын – бу Русия мөселманнары теләге генә булмыйча, бәлки бөтендөнья мөселманнары теләге дә. Инглиз императорына буйсынган җирләрдә миллионнарча, ә Франция хөкүмәтенә буйсынган өлкәләрдә унике миллион мөселман яши һәм бу мөселманнар да хәлифә өчен, аның кадере өчен куркалар. Әгәр Истанбул хәлифә кулыннан алынса, ихтилаф дәүләтләр җир йөзендәге миллионнарча мөселманнарның дошманлыкларын казаначаклар. Бу дошманлык бәлки Русиядә туып, көчәеп Көнбатыш идеологиясенә каршы идеология өчен нигез булачактыр. Төрекләрдән, хәлифәдән Истамбулны тартып алу фикерегездән кайтуыгызны сорап, Русиянең ун миллионлы татар–мөселман лидеры буларак Тынычлык конференциясенә шушы үтенеч белән мөрәҗәгать итәм»[32], ди.

Ләкин бөек империячел идеяләр белән сугарылган һәм башка дин вәкилләренең, аз санлы һәм качак рәвешендә бернинди хокукларсыз, вәкаләтсез яшәгән вәкилләренең бу теләк–үтенечләре

Тынычлык конференциясенең карарларына кертелми һәм аларның бу Конференциядән көткән өметләре дә акланмый.

Россиядәге ун миллионлы татар халкы исеменнән мандатлы вәкил булып йөрсә дә, Садри Максуди Парижда Милли–мәдәни мохтарият әгъзаларыннан берүзе генә була.

1919 елның июль аенда Гаяз Исхакый белән Гомәр Терегулов Парижга Тынычлык конференциясенә килү өчен виза сорап Токиодагы рус илчесенә гариза җибәрәләр. Ул Париждагы рус делегациясе әгъзасы Чайковскийга, ә анысы исә бу кешеләрнең Франциягә килүләренең мөһимлеге турында аның фикерен сорап С.Максудига мөрәҗәгать итә. С.Максуди 3 августта Г.Терегулов белән Г.Исхакыйга виза җибәрә, тик виза аларга барып җитми. Авыру сәбәпле Парижга килә алмаган Г.Терегуловны Ф.Туктаров алыштырган, алар исә чех әсирләренә ияреп, Прагага килгән булалар. Бу турыда газеталардан укып белгән С.Максуди, адрес табып, Г.Исхакыйга хат яза. Аның хатын алгач, Г.Исхакый үзенең көндәлек дәфтәренә түбәндәгеләрне яза: «12.01.1920. Бүген хәл үзгәрде, Садри Максудидан Париждан хат алдым. Безнең солых хәятына бик зур кыйммәт биргән милли хәрәкәтнең башындагы Милли–мәдәни Идарәнең рәисе һәм Европада танылган Садри Максуди көтелмәгәндә уртага чыкты. Бу хәбәр минем рухи хәлемә бик нык тәэсир итте. Садри Солых конференциясенә безнең теләкләремез турында Меморандум биргән»[33].

С.Максуди 1920 елның февралендә Г.Исхакый һәм Ф.Туктаровка кабат виза җибәрә һәм алар, ниһаять, март аенда Парижга килеп җитәләр[34]. Төрек әсирләрен Төркиягә кайтаруны оештырып йөргән Й.Акчура да 1920 елның 1 мартында Стокгольмда була, С.Максуди белән очраша. Шулай итеп, озак вакытлар аерылышып торган милли хәрәкәт җитәкчеләре кабат очрашалар. Милләтебезнең төрле мәсләктәге, әмма большевиклар властен бер үк төсле кабул итә алмаган бу милләтпәрвәрләребез берләшеп, төрек–татар халкының эмиграциядәге вәкиллеген оештыралар һәм бу турыда рәсми Белдерү белән чыгалар, ә 6 апрельдә аларның инде өчесен дә Франциянең тышкы эшләр министры шул вәкиллек җитәкчеләре буларак кабул итә. Бу очрашу вакытында алар министрга:

1. Руссиядәге төрек—татарларның милли хокукларын халыкара бер хәлгә китерелүенә ярдәм кирәклеген;

2. Төркия хәлифәте мәсьәләсенең төрекләр өчен уңай хәл ителүен, ягъни Антанта илләре тарафыннан басып алынган территорияләрнең азат ителүен, төрек әсирләренең Төркиягә кайтарылуларын теләүләрен җиткерәләр.

Миллеран аларга Франция—Россия арасындага солых килешүе вакытында сезнең таләпләрегез искә алыначак, ди («М—Г. Исхакый: хәйәте вә эшчәнлеге» дигән китаптан. Төрек телендә. Анкара. 1979.).

1920 елның ахырларында Россиянең элеккеге Учредительное Собрание әгъзалары Киңәшмәсен оештыручы инциатива группасы эмиграциядәге барлык Учредительное Собрание вәкилләренә мөрәҗәгать белән чыккач, Эчке Русия төрек—татарларның чит илдәге вәкиллеге рәисе С.Максуди һәм бу вәкиллекнең әгъзалары булган Г.Исхакый белән Ф.Туктаров Парижда П.Н.Милюков (элеккеге Дума депутаты) җитәкчелегендә чыккан «Последние новости» газетасының 16 декабрь санында Белдерү белән чыгалар.

Белдерүдә алар үзләренең бу тәкъдимне яклаулары һәм эмиграциядә булган барлык элеккеге Учредительное Собраниенең мөселман вәкилләрен бу Киңәшмәдә катнашырга чакыралар. «Россиядәге законлы тәртипләрне һәм дәүләтчелекне торгызу Россиядә яшәгән барлык халыкларның катнашыннан, шулай ук демократик көнбатышның теләкләшлегеннән башка һич мөмкин түгел, нинди исемдә булуына карамастан, Россия демократиясе, чит илләрнең демократиясе дә иске режимының дәүләт системасын яңартырга теләмиләр, шунлыктан, Февраль революциясе һәм Учредительное Собрание сайлау Россия халыкларының яшәешенең асылы һәм дөньяви әһәмияткә ия тарихи Рубикон.

Без, Эчке Русия татарлары, иске режим вакытында үзебезнең милли яшәешебездә милли изү һәм эзәрлекләүләрнең төрле формаларын татыган, һәм хәзер дә кешелек тарихында күрелмәгән большевиклар эзәрлекләүләренә тарыган халык буларак, бу турыда бернинди сәяси икеләнүләргә кушыла алмыйбыз.

Рус сәяси маятнигы хәзергә кадәр ике нокта арасында уйнады: уңнан да, сулдан да хокуксызлык һәм ул хәзер, ниһаять, чын демократизм ноктасында тукталырга тиеш.

Без Учредительное Собрание әгъзаларыннан торган Киңәшмәне Россиянең барлык демократик хәрәкәтләренең һәм барлык халыкларның эмиграциядәге вәкилләрен берләштерергә тиешле бер Оешма оештырырга хаклы дип саныйбыз»[32].

1917 елның сентябрендә Эчке Россия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтариятенең Милләт мәҗлесенә хәзерлек чорында «Йолдыз» гәзитендә басылган «Эчке Русия мөселманнарының Милли идарә тарафыннан халыкка хитап»ында әйтелгәнчә, һәр милләткә, һәр дингә хөррият бирә торган гадел хөкүмәт, ягъни Вакытлы хөкүмәтнең властька килүен «мөселманнар өчен» ябылмый торган бер өмид капусы» ачты, шуңа күрә милләтләрнең һәр теләге тормышка ашып торганга күрә мөселман дөньясы яңа хөкүмәтне хуплап каршы алды»[35], дигән С. Максуди әле бу вакытта Вакытлы хөкүмәткә ышанычын бөтенләй югалтмаган була. Россиядәге большевистик режимны анда яшәүче барлык халыкларның бердәм көрәше генә юк итә алачагына инанган С.Максуди эмиграциядәге барлык милли оешмаларны берләшергә, бергә эш итәргә, килеп чыккан һәр мөмкинлектән файдаланырга чакыра.

1921 елның 8 январенда Парижда Бөтенроссия Учредительное Собраниесе членнары Киңәшмәсе ачыла. Элеккеге Учредительное Собрание вәкиле булмаса да, С.Максудига 18 нче номерлы таныклык тапшырыла, ул бу Киңәшмәнең эшендә катнаша һәм аның икенче утырышында ук татар халкы исеменнән Декларация игълан итә. «Общее дело» газетасы аның әлеге утырыштагы чыгышы турында болай дип яза: «Садри Максудов бик озаклап татар милләте, аның язмышы турында, яңа дәүләтчелеге турында, шулай ук башкорт, чуваш республикалары турында сөйләде. Россиядәге татар халкының тарихы турында озын, җитди лекция укыды»[36]. Шулай ук бу газета үзенең 12 январь санында Бөтенроссия казаклары вәкиле Харламовның һәм С.Максудовның Киңәшмәдә игълан иткән Декларация текстларын тулысынча бастырып та чыгара. (Кызганычка каршы, С.Максуди архивында

газета тулысынча сакланмаган): «Без моңарчы чын демократизм ноктасында тордык һәм хәзер дә шушы караштa торуыбызны дәвам итәбез.

Без ышанабыз ки, Россия эчендәге барлык изелгән, газапланган халыклар да шул караштa торалар, ягъни большевизмны каһәрләсәләр дә искегә кайтырга теләмиләр. Россия халыклары инстинктив рәвештә иске режим белән хәзерге тирания арасында өченче төрле дәүләт строе торырга тиешлеген сизәләр һәм бу азатлык, тәртип, кешегә карата хөрмәт белән карый торган режим булырга тиешлеген аңлыйлар.

...Без, Эчке Россия татарлары, аерым, үзенчәлекле халык булганга, большевиклар белән дә, реакция белән дә бара алмадык, чөнки боларның берсе дә чын халыкчан хәрәкәтләр түгел иде. Икенчедән, аларның берсе дә безнең милли таләпләребезне канәгатьләндерми, ягъни безгә азат милли тормыш итү мөмкинлеген бирми иде.

Үзебезнең гасырларга сузылган газапларыбызга да һәм Россиядәге безнең хәзерге аянычлы хәлебезгә да карамыйча, без рус халкы белән ирекле булып бергә яшәү мөмкинлегенә нык ышанабыз: чөнки без беркайчан да рус халкын халыктан чыкмаган хөкүмәт белән тигезләмәдек.

Без, Белдерүебезне тәмамлап, сезгә, халык вәкилләренә мөрәҗәгать итәбез: Россиянең элеккеге һәм хәзерге изүчеләреннән ачык һәм нык итеп баш тартыгыз, барлык классларга, Россиянең барлык халыкларына нәрсә бирергә теләгәнегезне, бирәчәгегезне ап–ачык итеп әйтегез...»[37] – диелә белдерүдә.

Күпчелеге рус милләтеннән булган вәкилләрдән торган бу Киңәшмә дә рус булмаган халыкларның вәкилләре теләгән нәрсәләрне, ягъни милли азатлык, милли дәүләтчелек проблемаларын яклап чыкмый: большевизмга каршы көрәштә ярдәм күтәрелергә өметләнгән милли хәрәкәтләр оешмаларын алар шуның белән үзләреннән читләштерәләр дә. Нәтиҗәдә, Россия халыкларының эмиграциядәге милли хәрәкәтләре һәркайсы аерым хәрәкәт итә башлый, шулай итеп, алдан ук җиңелүгә дучар була.

Милли–мәдәни мохтариятның эмиграциядәге вәкиллеге алып барган бу тигезсез көрәш турында Советлар Россиясендә калган һәм

революцион идеяләр белән янып яшәгән Г.Ибраһимов 1922 елда ук инде: «Тик берничә гаҗиз бәндә генә әле һаман да Финляндия, Голҗә, Харбин татар буржуаларының нәҗес кулларыннан тамган бер тиеннәргә чукынып, Париж банкирларының бусагалары төбендә рус монархларына койрык булып, имеш, революциягә каршы көрәшкән булып адәм көлдереп йөриләр. Болар – Садри–Фуад, Закир–Гомәр, Баттал–Гаяз»[38], дип үзенең «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» дигән хезмәтендә язып чыга.

1921 елда Россиядә башланган ачлык, бигрәк тә, Идел буенда көчле була. 1921 елның 21 июлендә ВЦИК декреты белән Бөтенроссия ачларга ярдәм комитеты төзелә. Бу ачлык шулкадәр көчле һәм зур территорияне үз эченә ала: совет дәүләте бөтендөнья җәмәгатьчелегенең ярдәме кирәклеген танырга мәҗбүр була. «Для спасения голодающих нам нужно по меньшей мере 4 миллиона тонн зерна, иными словами 8000 поездов по 50 вагонов каждый. Надо поднять народы Европы». – Бу – тышкы эшләр министры Чичеринның беренчеләрдән булып әлеге ярдәмне оештырып җибәргән Ф.Нансенга әйткән сүзләре (В.И.Белокопытов. Лихолетье. Казань. 1976).

Шулай ук Й.Акчура да Төркиядәге Америка банкы аша Россиядәге ачларга ярдәм оештыру белән шөгыльләнә. С.Максуди, илдәге милләттәшләренең хәле белән чын күңеленнән борчылып, ашыгыч рәвештә Эчке Русия мөселманнарының эмиграциядәге вәкиллеге исеменнән дөньяның барлык мөселман дәүләтләренә мөрәҗәгать белән чыга. Ул үзенең Мөрәҗәгатендә Идел буендагы ачлыкның коточкыч авырлыгы нәкъ менә татар халкына төшкәнлеген, алар арасында ачлыктан кырылыш башланганы турында әйтә һәм акчалата яки матди ярдәм күрсәтә алган дәүләтләрнең, җәмгыятьләрнең, ярдәмнәрен Американың «Ачларга ярдәм» комитеты аша татарлар яши торган төбәкләргә: Казан, Әстерхан, Уфа шәһәрләренә атап җибәрүләрен сорый. «Мөселман дөньясы гасырлар буе рус хөкүмәте астында изелгән, хәзер исә большевиклар астында ач үлемгә дучар ителгән диндәшләрен ташламаслар, дип ышанабыз», диелә Мөрәҗәгатьтә. Мөрәҗәгатькә Г.Исхакый белән Ф.Туктаров та кул куйган.

«Диндәшләребез, Росиядәге ачлыкка дучар ителгән 30 миллион халыкның 9 миллионы мөселманнар. Әмма, шулай да, без сездән ачлыктан интегүче Россия халкына, кайсы диндә булуларынна карамыйча, ярдәм итүегезне сорыйбыз»[39], диелә әлеге Мөрәҗәгатьтә.

Милли–мәдәни мохтариятның Милли Идарәсе исеменнән Троицк реаль училищесының элеккеге директоры Нияз Максудов Американың ачларга ярдәм комитеты рәисе Гувер белән бергә эшләү һәм ачлыкка дучар ителгән татар халкы арасында ярдәм оештыруга караган барлык мәсьәләләрне хәл итү, әлеге ярдәмне Идел буе татарларына алып барып җиткерүнең иң дөрес юлларын эзләү һәм һәрьяклап ярдәм итү өчен Төньяк Америкага җибәрелә[40].

Бәлки, чыннан да, бу Мөрәҗәгатьнең тәэсире булгандыр: ул елларны Американың «Ачларга ярдәм» комитетының матди ярдәме Идел буе халыкларының күбесен ачлыктан саклап калышты, тик бу ярдәм барлык татар авылларына гына килеп җитә алмады...

С.Максудины бер яктан Идел буендагы каты ачлык бик борчыса, икенче яктан илдә калган гаиләсенең хәле турында берни дә белмәве бик газаплый. Ул Американың «Ачларга ярдәм» комитетыннан, Финляндиядәге дусларыннан үзенә гаиләсен табуда ярдәм итүләрен сорап күп тапкыр хатлар яза. Ниһаять, Төркиянең Росиядәге илчесе Әли Фуат паша аркылы аның хатлары хатынына барып җитә, һәм ул, зур кыенлыклар кичеп, С.Максудины «кардәше кебек яраткан» Муса Бигиевнең ярдәме белән 1922 елның апрелендә Финляндиягә килә. С.Максудиның гаиләсе белән кавышуына шатланган Финляндия татарлары аларга Хельсинкидан ике сәгатьлек юлда – урман эчендә бер вилла алып бирәләр, һәм биредә узган ике атна вакыт дүрт елга якын гаиләсе белән аерылып яшәргә мәҗбүр булган С.Максуди өчен иң бәхетле көннәр була.

Төркиягә китеп яши башлагач та, гомеренең соңгы көннәренә кадәр, С.Максуди Финляндиядә яшәүче татарлар белән якын бәйләнештә кала, аларга дини, милли оешмаларын саклауда, үстерүдә үзенең киңәшләрен биреп, бу җәмәгать оештырган төрле

кичәләрдә катнашып, гомумән, үзенең аларга булган рәхмәт хисләрен гомере буена саклап яши.

1922 елның июль ахырларында С.Максуди гаиләсе белән Германиягә, Берлинга күченеп килә. Ул монда үзеннән алда Берлинга килгән һәм татар милли хәрәкәте оешмасын төзәргә омтылып йөргән Г.Исхакый һәм Ф.Туктаров белән очраша.

1923 елның декабрь ахырларында әллә ничә илләр аша, дөнья гизеп, Парижга Зәки Вәлиди килеп җитә. Чыннан да, Җир шары бик кечкенә икән: үз туган җирләрендә бер—берсе белән бер уртак фикергә килә алмаган, төрле мәсләктәге бу татар зыялылары — Фуад Туктаров, Гаяз Исхакый, Садри Максуди һәм Зәки Вәлидиләрнең юллары Парижда кабат кисешә. Үзләрен төрки халыкларга хезмәткә багышлаган бу затларны язмышлары Төркиядә дә бергә очраштырачак әле. Зәки Вәлиди белән Садри Максуди хәтта берничә ел Мәгариф баканлыгында бергә эшләячәкләр, Стамбул университетында укытачаклар. Кызганычка каршы Русиядә вакытта да мөселман халыкларына, татар милләтенә хезмәт итүләренә дә карамастан, төрлесе—төрле идеяләр яклы булган татар милли хәрәкәте идеологлары, җитәкчеләре эмиграциядә дә бердәмлеккә ирешә алмаганнар. С.Максуди белән М.Чокай кадетларга, Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Ә.Цаликов Керенский хөкүмәтенә, З.Вәлиди исә сул эсерлар (Виктор Чернов төркеменә) тугъры калалар[41].

Эмиграциядәге төрле рус оешмалары, җәмгыятьләренең, аз санлы милли оешмаларның эшчәнлекләренә бертуктаусыз аяк чалып торулары, төрле мөселман халыкларының милли оешмалары белән уртак тел таба алмау, бүлгәләнү һәм Россиядә большевизмның көннән—көн көчәя, ныгый баруы, шуның аркасында илдәге милләттәшләре белән элемтәгә керә алмау, үзләренең милләттән, аның шатлык—кайгысыннан аерылып, уй—фикерләрен, теләкләрен белмичә эшләү — болар барысы да С. Максудины актив милли көрәштән читләшүгә китерәләр, һәм ул Берлинда фәнни эшкә чума: бик кызыксынып һәм бирелеп Дәүләт китапханәсендә эшли. Биредә ул төрки халыкларның үткәнен ныклап, һәрьяклап өйрәнергә керешә, чөнки ул Европа халыкларының, шул исәптән, галимнәренең һәм зыялыларының да төрки халык-

лар турында берни белмәгәннәрен күрә, аңлый. Шунлыктан, форсаттан файдаланып, китапханәдәге төрки халыкларның тарихына караган китапларны, кулъязмаларны барлый, бик тырышып үзенә кирәк материалларны күчерә һәм ул Төркиягә дүрт чемодан кулъязма күтәреп килә. Нәтиҗәдә, аның Төркиядә язылачак төрки халыкларның тарихына, теленә караган фундаменталь хезмәтләренең нигезе шушында салына.

Салкын, кырыс табигатьле Германия хәятын кабул итә алмаган С.Максуди, китапханәдә эшен бетергәч, 1923 елда Франциягә, үзенең күңеленә якын Парижга килә. Биредә ул Сорбоннага бәйле Институтта төрки халыклар тарихы буенча лекцияләр курсы укый башлый, аңа профессор дәрәҗәсе бирелә. Бу – мөселман галименең, татар улының зур җиңүе була. Әлеге вакыйга турында үзенең шатлыгын уртаклашып, Г.Топчибашев Төркиядә чыга торган «Вакыт» гәзитендә: «Хөрмәтле диндәшебез Садри Максуди, конкурста җиңеп, затлы Париж университетында французларга француз телендә төрки халыклар тарихы буенча лекцияләр курсын башлап җибәрде», дип яза[42]. Шулай итеп, акрынлап булса да, ул үзенең шәхси тормышын җайга сала, элеккеге Дума депутатлары арасында булган дуслары ярдәмендә уңайлы фатирга урнаша, кызларын француз мәктәбенә укырга бирә, үзенә дуслар–фикердәшләр таба, бөтен барлыгы белән фән дөньясына чума.

1923 елның июнь аенда С.Максуди Париж университеты каршындагы Славян институтында депутатлар палатасының тышкы эшләр комиссиясенең элеккеге председателе Ж.Лейгь рәислегендәге утырышта киң француз җәмәгатьчелеге, ягъни Парижның төрле университетларыннан җыелган галимнәр һәм югары рангллы сәясәтчеләр алдында «Россиядә төрки халыкларының килеп чыгуы турында» доклад ясый. «Последние новости» газетасында В.Ф.М. псевдонимы астында әлеге авторның комментарийлары белән С.Максудиның бу доклады турында «Турко–татары и Россия» дигән мәкалә чыга. С.Максуди үзенең әлеге докладында Россиянең 130 миллионлы халкының 27 миллионы төрек–татар (төрки халыклар) икәнлеген, төрки халыкларның һәм монголларның Чингизидлар династиясендә бер коалиция төзүләрен, ләкин тел ягыннан төрле халыклар булуын, шулай ук монгол–та-

тар хәрәкәтенең беренче тапкыр төрле мәдәнияткә ия булган халыклы Көнбатыш һәм Көнчыгышны якынлаштыруда зур роль уйнаганын әйтеп китә. «Татар иго»сы турында сөйләгәндә бу әһәмиятле якларын да әйтергә онытмаска кирәк, ди.

Докладның икенче өлешендә ул Бөек Петр реформаларын Россиянең киләчәге күзлегеннән караганда прогрессив булганлыгын әйтә, ләкин анынча, Көнчыгыш автократиясе белән Көнбатыш демократиясе XIX гасырның буеннан–буена бер–берсе белән көрәшергә мәҗбүр булалар һәм бу көрәш Россия империясенең җимерелүе, Романовлар нәселенең бетүе белән тәмамлана. Әмма бу хәл демократиянең җиңүенә дә китермәде, ди. Докладчының бу фикере белән килешмәскә дә була, әмма бу фикер рус тарихының башыннан диярлек аның белән бергә яшәгән халыкның вәкиле фикере буларак бик кызыклы, дип билгеләп китә мәкалә авторы.

Рус басып алулары төрки халыкларның яшәешендә төп нигезләрен сизерлек үзгәртте, шулай да төрле изелү–кимсетүләргә дучар булган халыкта тора–бара милли аң уянды, татарлар, ниһаять, милли азатлыкка омтыла башладылар, үзләренең дәүләтчелекләрен торгызу өчен көрәшкә күтәрелделәр. Хәзер инде Россиянең киләчәген Россиягә демократик принципларның керү–кермәвенә карап кына күзалларга мөмкин булачак. Россия үзенең тынычлыгын һәм көчен куркытылган халыкларның эндәшмәве белән түгел, ә үз гражданнарының азатлыгы, шул азат халыкларның ирекле рәвештә бер–берләренә якынлашулары белән алар яшәгән өлкәләрнең берләшүе мөмкин булганда гына кайтара алачак. Россиянең һәм анда яшәгән төрки халыкларның, шул исәптән, татар халкының да язмышы бары тик ирекле илдә генә хәл ителә алачагына аеруча басым ясап С.Максуди үзенең докладын тәмамлый. (Төрки халыклар тарихы, татар халкының тарихы турында С.Максуди Сорбоннада укыган студент елларында ук инде киң җәмәгатьчелек алдында докладлар белән чыккан була, алар турында «Йолдыз»да әйтелеп кителә).

1923 елның 4 декабрендә Сорбоннада С.Максудиның беренче дәресе уза. Лекциягә Хөсәен бәй Рәкыйп, Алимәрдән Топчибашев, Мостафа Чокай да килә. Биредә беренче мәртәбә төрки ха-

лыклар тарихы укытылачак кафедра ачыла. Сорбонна университеты тарихында төрки халыклар тарихы буенча лекцияләр укыла башлау да беренче мәртәбә була, шулай ук, С.Максуди да Сорбоннада француз телендә лекция укучы беренче татар профессоры була!

1923–24 елларда С.Максуди Сорбоннада лекцияләр укуын дәвам итә. Төркиядәге революцияне шатланып каршы алган С.Максуди, Ататөрекнең чакыруы буенча, 1925 елның башында инде бөтенләйгә Төркиягә күчеп китә. Һәм аның сәясәтче буларак эшчәнлегенең яңа этабы, галим буларак фәнни эшчәнлегенең яңа күтәрелеше башлана.

С.Максуди милли көрәштән читләшсә дә, үзен милли көрәшкә багышлаган, эмиграциядәге татар милли азатлык хәрәкәтен озак еллар сүндермичә саклап, шул хәрәкәтнең язма органы булган «Милли юл», «Яңа милли юл» журналларын чыгарып килә алган атаклы милләтче Гаяз Исхакый белән дуслык мөнәсәбәтләрендә кала, аның белән уй–фикерләр алышып яши.

«С.Максуди төрки халыкларның берлеген кайнар якладьы, милли мәсьәләдә австрияле социаль–демократ О.Бауэр һәм П.Шпрингерның милли–мәдәни автономияләр турындагы концепциясен яклый иде, һәм бу концепциягә гомере буе турылыклы калды», дип язды Т.Дәүләтшин үзенең «Совет Татарстаны» дигән китабында***. Ләкин Т.Дәүләтшинның бу фикере белән килешеп бетәсе килми. Чөнки инде гомеренең соңгы елларында язылган «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән хезмәтендә С. Максуди беренче планга җирле автономия концепциясен куя.

Үз туган илен ташлап китәргә мәҗбүр булган олуг милләтче Садри Максуди Төркиядә дә үз кыйбласына, тоткан мәсләгенә тугры кала: ул төрки халыкларга хезмәт итүен дәвам итә.

С.Максуди 1925 елда, үзе андагы хокук факультетын оештыручыларның берсе буларак, Анкараның яңа гына ачылган беренче уку йорты – Хокук мәктәбендә моңарчы әле беркем тарафыннан да укытылмаган яңа бер фән – «Төрек хокукы тарихы» курсын укыта башлый. Шулай ук бу фән буенча Төркиядә беренче дәреслекне дә ул яза. Биредә С.Максуди хокук бүлеге профессоры вазыйфасында унсигез ел эшли, ә 1943 елдан Истанбул университе-

тына күчә һәм озак еллар буе анда хокук тарихы укыта. Аның «Хокук тарихы» дәреслеге 1927, 1928, 1931 елларда берничә кат басылып чыга, ә «Гомуми хокук тарихы», «Төрек тарихы һәм хокук», «Хокук фәлсәфәсе», «Теократик дәүләт һәм лаик дәүләт» кебек хезмәт–дәреслекләре 1937–1947 елларда һәркайсы берничә мәртәбә басыла һәм хокук факультетында укучы студентларга озак еллар буенча дәреслек булып хезмәт итә. Дөньяның иң данлыклы университетларыннан булган Сорбоннаны тәмамлаган С.Максуди хокук фәне өлкәсендә үз заманының иң абруйлы белгечләреннән саналган, дисәк тә ялгыш булмас. Аның хокук фәненең теоретик нигезләрен ачкан, андагы проблемаларны яктырткан бу хезмәтләре дөньякүләм әһәмияткә ияләр.

Ә инде 1947 елда басылган «Төрек тарихы һәм хокук» исемле хезмәтенә үзен мөстәкыйль дәүләт дип игълан иткән Татарстанның хокукый һәм гамәли законнарын эшләүчеләр игътибар итсә, алар татар халкы өчен файдалы эшләр эшли алырлар иде. Чөнки С. Максудиның бу хезмәте төрек халкы белән тугандаш татар халкының гореф–гадәтләренә, әхлакый законнарына, этик нормаларына да нигезләнеп язылган.

С.Максуди, шулай ук, Төркия Тел Академиясен ачу өчен дә зур тырышлык куя, төрек теле белеме буенча күп санлы хезмәтләр яза. Ул төрек теленең үсеше, аны гадиләштерү, чит сүзләрдән чистарту, гамәлгә кую өчен гаять зур эш башкарган тел галиме дә. Галим ул елларда «Төрек йорты» журналында төрек теленә, төрек тарихына багышланган күп санлы мәкаләләр бастыра, һәм 1930 елда үзенең 1928–29 елларда «Миллият» гәзитендә чыккан «Телне яңарту мәсьәләләре» турындагы, ягъни төрек телен чит сүзләрдән чистартуга, телне төрекләштерүгә кагылган унбишләп мәкаләсен җыеп «Төрек теле өчен» дигән китап чыгара, ә бу китапка кереш сүзне Мостафа Кемал Ататөрек үзе яза. Ататөрек җитәкчелегендә башланган әлеге хәрәкәтнең җимеше булган бу китап «Телдәге революцияне» башкарып чыгуда зур әһәмиятле роль уйный. Ата–төрекнең әлеге китапка булган мөнәсәбәте С.Максудиның төрек мәдәниятында, фәнендә тоткан урынының зурлыгына, әһәмиятлегенә бирелгән бәя дә, аның авторитетының киң җәмәгатьчелек алдында тагын да күтәрелүенә бер сәбәп тә була.

С.Максуди, үзенең бар гомерен төрки халыкларның тарихын өйрәнүгә багышланган З.Вәлидидән кала, тарих фәнен үстерүгә дә иң зур өлеш керткән галимнәрнең берсе. Аның 1924 елда иртәдән–кичкә кадәр Берлинның Милли китапханәсендә басылып эшләвенең файдасы була: Төркиядә аның «Искетлар–сакалар» (1938 ел), «Урта Азиядә төрек дәүләтләре» (1934 ел), «Төрек тарихы вә хокук» (1947 ел) исемле китаплары дөнья күрә. Төрки халыкларның тарихын өйрәнү, бу шанлы тарихны Европа илләре халыкларына да таныту теләге аңарда Тарих Академиясе төзү кирәклеге турындагы фикерне уята һәм ул Милләт вәкиле булган елларында әледән–әле бу фикерен матбугат битләрендә, Милләт мәҗлесләрендә дә кузгаткалап тора: ул 1950 еллардан соң гына төзеләчәк әлеге Академиягә нигез салырга, аның төзелешенең, эшчәнлегенең төп принципларын билгеләргә тырышкан. (Әлеге «Тарих җәмгыятен» төзүдә Йосыф Акчура да зур көч куйган, ул әлеге җәмгыятьнең беренче рәисе булган һәм 1932 елда уздырылган I Төрек тарихы конгрессының эше белән җитәкчелек иткән). Хәзер эшли торган «Тарих җәмгыяте» исә аның шул тырышлыгы нәтиҗәсе булып тора.

Төркиядә Ататөрек вакытында С.Максуди сәясәт белән дә шөгыльләнә: өч мәртәбә Төркия парламентына депутат булып сайлана. Бер мәртәбә Й.Акчура белән бергә эшли. 1946 елда Төркиядә Демократлар партиясе төзелә һәм С.Максуди, дәүләтнең демократик киләчәгенә якты өметләр багълап кичке «Соң сәгатьтә» гәзите битләрендә һәр атна диярлек демократия, күппартиялелек, гражданлык хокуклары турында гади халыкка аңлаешлы телдә язылган күп санлы мәкаләләрен бастыра. Аның әлеге мәкаләләре төрек халкының төрле катлаулары арасында бу мәсьәләгә карата зур кызыксыну уята. Һәм алар С.Максудины гади халык арасында да киң танытуга һәм авторитеты күтәрелүгә китерә. Инде ул 1950–1955 елларда Бөек Милләт мәҗлесенә Милләт вәкиле булып демократлар партиясенең Анкара бүлегеннән сайлана. Милләт мәҗлесендә тел мәсьәләләре каралганда, хокук буенча кануннар проектларын тикшергәндә анда Россия Дәүләт думасы мәҗлесләрендәге озынча буйлы, кара мыеклы, соңгы мода белән киенгән чибәр яшь ир–егетнең кискен, кызу тавышы түгел, инде Төркиянең иң аб-

руйлы сәясәтчесе, олы галиме булган Садри Максуди Арсалның салмак, көчле, вәкарьле тавышы яңгырый. Бу утырышларның Милләт мәҗлесе китапханәсендә сакланган стенограммаларын укыганда күз алдына, ирексездән, олпат гәүдәле, инде чаларган мыеклы, күзлекле һәм үз дәрәҗәсен, һәр сүзенең бәһасын белеп кенә сөйләүче Садри Максуди килә. Ул 1950 елларның урталарына кадәр Төркия һәм Европа сәясәтендә күренекле урын били: Төркия делегациясе составында Милләтләр лигасы эшендә катнаша, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң төзелгән Европа советында да актив эшли.

С.Максуди, Төркия Милләт мәҗлесе депутаты буларак, Милләтләр Лигасында Европа федерациясе Конституциясен төзү өчен Европа илләренең танылган юристларыннан оештырылган Комитет әгъзасы була. Европа федерациясендәге суверен федераль дәүләтләр (штатлар) турындагы документка үзенең тәкъдимнәрен кертә, аларның күбесе кабул да ителә. «Европа федерациясе бүген Европадагы барлык мәдәниятле халыклар өчен идеал һәм сугышларны булдырмау өчен бердәнбер юл булып тора», ди ул Европа федерациясе төзелүгә зур өметләр багълап. Ул 1951 елның 2 февралендә Баледа Конституция проектын тикшергәндә «Европа федерациясе һәм федераль дәүләтләрнең суверенитеты принциплары» дигән зур доклад ясый. С.Максуди бу докладында Америка Кушма штатлары һәм Швейцария Конституциясен анализлый. Суверенитет концепциясенә ул юрист буларак хокукый принциптан гына түгел, ә хокукның фәлсәфи, этик принципларыннан чыгып та бәя бирә. Конституция проектына Европа федерациясен төзегәндә федераль штатларның суверенитеты турында статьяларны ап–ачык итеп эшләп бетерергә чакыра.

Г.Баттал–Таймас үзенең «Ике Максудилар» дигән китабында С.Максудиның эшчәнлегенә, аның сәяси, милли карашларына шундый характеристика бирә: «Ул тормышка аек карашлы төрекче–милләтче иде. Үзенең мәкаләләрендә, лекцияләрендә, чыгышларында милли гамәлләргә карата күп тукталды, сәяси, икътисади мәсьәләләрдә либераллар тарафдары булды. Социализмны кабул итмәде, сыйнфый көрәш мәсьәләсе дә аны җәлеп итмәде»[43].

С.Максуди 1955 елда гына сәясәттән китә һәм үзенең калган гомерен бары тик фәнгә генә багышлый. Аның соңгы гыйльми хезмәтләренең берсе «Милләт тойгысының социологик әсаслары» дип атала. Бу житди, фәлсәфи хезмәт бөек милләтченең үзеннән соңгы буыннарга, милли тәрәккъыят юлында үз халыкларына хезмәт итәчәк буыннарга васыяте сыйфатында карала ала. Анда милләт һәм милли мөнәсәбәтләр проблемасына тирән теоретик анализ ясала. Садри Максудиның бу китапта төпле дәлилләр белән нигезләнеп бәян ителгән фикерләре милли мәсьәләрне тикшергәндә, милли идеологиянең ориентирларын билгеләгәндә, методологик таяныч ролен үти алалар[44].

«Садри Максуди Төркия дәүләтен ныгыту буенча мәгърифәтче вазыйфасын үти, үзенең киңәшләре, фикерләре һәм фәнни эзләнүләре белән төрек халкына хезмәт итә, файдалы эшләр башкара»[45]. Әмма ул Төркиянең мәгарифен җайга салу өчен бар көчен биреп эшләүчеләрдән берүзе генә булмый, 1926 елдан башлап Истамбул университетында дөньякүләм танылган тарихчы–галим З.Вәлиди төрек тарихы укыта, бу олуг галим шул елларда тарих буенча барлыгы дүрт йөздән артык җитди хезмәт яза. Ул елларда И.Акчура, Г.Батталлар да фән белән актив шөгыльләнәләр, әмма алар арасында Төркия тарихы, тел белеме, хокук тарихы буенча төп хезмәтләрне язган, үзләренең әлеге дөньякүләм әһәмияткә ия булган хезмәтләре белән фән дөньясында киң танылу алган галимнәр – Зәки Вәлиди белән Садри Максуди була.

Шулай итеп, үзенең унике ел гомерен татар милли хәрәкәтенә, милли азатлык көрәшенә багышлаган, милли хәрәкәтнең лидерларыннан булган олы шәхеснең әлеге эшчәнлеге 1925 елда төгәлләнсә дә, аның төрек халкына, төрки халыкларга хезмәте гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә.

С.Максуди 1957 елда Истамбулда вафат була. Ул көннәрдә Төркиянең барлык газеталары кайгы сүзләре белән чыга, гаиләсенә Европаның төрле илләреннән, Төркия дәүләт җитәкчеләреннән килгән кайгы телеграммаларында, үлеме уңае белән мәкаләләре басылган газеталар Төркия үзенең зур галимен, дәүләт эшлеклесен һәм сөекле улын югалты, дип язалар. Дөньяның киң җәмәгатьче-

леге С.Максудины олы дәүләт эшлеклесе, төрек халкы исә аны үзенең улы дип таный.

С.Максуди 21 февральдә Истамбулда җирләнә, табуты куелган мәчет янына, мәрхум белән хушлашырга дип, дистәләрчә мең кеше җыела. Аның кабере бүген дә кадерләп саклана, зиярәт кылына. Истанбулда С.Максуди исемендәге урам да бар. Бүгенге көнгә кадәр С.Максуди үлгән көнне Төркиядәге җитди гәзитләрдә бу олуг шәкес турында мәкаләләр басыла, аның төрек халкына багышланган фидакарь һәм олы хезмәте хөрмәтләп искә алына.

## ИСКӘРМӘЛӘР

* Күчермәсе миндә саклана.

** Баттал-Таймас Г. Миражга алданган язучы //Татарстан. – 1995. – 7/8 сан. – Б.103.

*** Давлетшин Г. Советский Татарстан. Теория и практика ленинской национальной политики.– 1974.

1. И.Таһиров. Бәйсезлек баскычлары. Б.19.
2. Г.Ибраһимов. Әсәрләр. 6 том. Б.116.
3. Йолдыз. – 1917. – 25 март.
4. З.Валиди–Тоган. Воспоминания. – Уфа. «Китап». – 1994. – 171-172 с.
5. Адилә Айда. Садри Максуди Арсал. – М., – 1996. – 303 с.
6. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. – Казан: Татар китапнәшр. 1976–1988. – 5 Т. Б.381.
7. Хатын–кыз җәмгыяте турында хәзерләнгән кагыйдәләрне чыгаргач, алар бик зур тавыш–гауга куптара.
8. И.Таһиров. Бәйсезлек баскычлары. Б.79.
9. Г.Исхакый. Милли–мәдәни мохтариат игъланының егерме еллыгы // Яңа милли юл. – Берлин. – 1937. – 9/10 сан.
10. Ш.Әхмәдиев. Олуг татар бәйрәме //Аваз. – 1917. – 25 июль.
11. Милли мохтарият: Эчке Русия мөселманнары өчен Милли–мәдәни мохтарият әсаслары. //Мирас. – 1993. – Б.90.
12. З.Кадыйри. Мәмләкәт идарәсе рәвешләре. – Уфа. Элек–типография «Тормыш». – 1917.
13. Йолдыз. – 1917. – 1 декабрь.
14. А.Г.Тугры. Вәкилләр көзгесе. – Эстәрлетамак. – 1918. – Б.3.
15. Шунда ук.
16. А.Г.Тугры. Вәкилләр көзгесе, Б.9.
17. Шунда ук.
18. Г.Баттал. Казан төркиләре //Казан утлары. – 1995. – 5 сан. – Б.171.
19. Г.Исхакый. Милли–мәдәни мохтарият игъланының егерме еллыгы // Яңа милли юл. - 9/10 сан.

20. Г.Исхакый. Милли юлыбызның нигезләре //Милли байрак. – Мюнхен. – 1954. 2/4 сан.

21. Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман. – Казан. – 1999. – Б.9.

22. Мулланур Вахитов. Жизнь и деятельность пламенного революционера–ленинца. – Казань. – 1985. – с.30

23. Г.Исхакый. Эчке Русия вә Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты игъланының егерме еллыгы //Яңа милли юл. – Берлин. – 1937. – 9 /10 сан.

24. Г.Ибраһимов. Әсәрләр. 6 том, Б.203.

25. Шунда ук. Б.277.

26. Г.Баттал–Таймас. Миражга алданган язучы //Татарстан. – 1995. 7/8 сан. Б.103.

27. Мулланур Вахитов. Жизнь и деятельность..., – с.36.

28.MUHAMMED AYAZ ISHAKI. HAYATI VE FAALIYETI. – Ankara. – 1979.

29. Adili Auda. Sadri Maksudi Arsal. – Ankara. – 1991. – s27.

30. Eclair. –Париж. – 1919. – 30 мая. (Газета ялгыша: С.М. 10 миллионлы татар халкы исеменнән генә эш итә).

31. Вәлиди Әхмәтзәки Туган. Хатирәләр. Өфө. «Китап». – 1996. – Б.575.

32. Белдерүнең копиясе (француз телендә) С.Максуди архивында саклана.

33. MUHAMMED AYAZ ISHAKI. HAYATI VE FAALIYETI. – Ankara. – 1979.

34. 1906 елдан башлап Октябрь инкыйлабына кадәр татар вакытлы матбугаты битләрендә Ф.Туктаров, Г.Исхакыйлар тарафыннан сүгелеп–хурланып торган С.Максуди Парижда аларны бик җылы каршы ала. Чөнки ул «Милләт өлкәсендәге эшләрне үзенең шәхси мәнфәгатьләреннән өстен куя иде». (Г.Баттал–Таймас. Ике Максудилар. //Мирас. – 1995. – 11/12 сан; – 1996. – 1/ 2 сан).

35. Общее дело. – Париж. – 1920. – 16 декабря.

36. Общее дело. – Париж. – 1921. – 12 января.

37. Шунда ук.

38. Г.Ибраһимов. Әсәрләр. 7 том, Б.168.

39. Белдерүнең күчермәсе С.Максуди архивында саклана.

40. Документ С.Максуди архивында саклана.

41. З.Вәлиди Туган. – Хатирәләр. – Өфө. – «Китап». – 1996. – Б.604.

42. Гәзит С.Максуди архивында саклана.

43. Г.Баттал–Таймас. Ике Максудилар. //Мирас. – 1996. 1/2 сан.

44. Я.Г.Абдуллин. Милли идеология мәсьәләсе һәм С.Максуди мирасы // Шәһри Казан. – 1993. – 6–9 февраль саннары.

45. Садри Максуди (1879–1957). Г.Пултар мәкаләсе. Б.31.

## ЙОМГАКЛАУ

XX гасыр башында татар милли хәрәкәтенең идея юлбашчылары булган, үзләре сайлаган мәсләккә кыйбла тотып милләтенә хезмәт иткән татар зыялылары, большевиклар тарафыннан эзәрлекләнә башлагач, мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр булалар. Илдә большевиклар хакимлеге урнашканнан соң, татар халкының милли азатлык хәрәкәте тәмам сүндерелә. Ләкин халкыбызның мөһаҗирлектә – Кытайда, Германиядә, Төркиядә яшәгән бу каһарманнары милли–азатлык утын бүгенге көн милләтпәрвәрләребезгә җиткереп, аларга шул уттан зур учак тергезеп җибәрергә мөмкинлек бирә алдылар.

Татар халкының мөһаҗирлектәге милли азатлык хәрәкәте җитәкчесе Гаяз Исхакый, мәсәлән, озак еллар буена Берлинда «Яңа милли юл» журналы чыгарып килә. Бу журнал илдән читтә яшәгән мөселман халыкларын озак еллар дәвамында берләштереп, җыеп торган үзәк була.

Милләттәшләребезнең күбесе үзләренә сыену урынын Төркиядә тапканнар. Садри Максуди һәм аның фикердәшләре булган әлеге затлар ялгыз булмаган, алар тирәсенә күп милләтле мөселман халыклары вәкилләреннән көчле берлек тупланган һәм алар шул милләтләрнең танылган, күренекле шәхесләре белән аралашып яшәгәннәр.

Мәсәлән, 1954 елның 23 февралендә Гаяз Исхакыйның 76 яшьлек бәйрәме уңае белән уздырылган зур мәҗлескә төрки халыкларның мәшһүр ул–кызлары: генераллар, руханилар, мөгаллимнәр, язучылар, врачлар, сәүдәгәрләр җыела. Бу мәҗлестә Идел–Уралдылардан (татарлардан) башка кавказлыларның җитәкчесе легендар Шамилнең оныгы Сәгыйд, әзербайҗанлы профессор Җәгъфәр угълы Әхмәд бик, атаклы төркиче Рәхмәти Арат, И.Гаспринскийның улы доктор Хәйдәр бәк һәм башкалар була. Ә бит аларның һәркайсы үз милләтенең тарихында тирән эз калдырган шәхесләр.

Миргазиз Укмасый әйткәнчә, «тарихын оныткан халык – үле гәүдәдер». Әгәр гореф–гадәтләребезне, телебезне, динебезне саклап, көчле–куәтле бер олы милләт булып яшәргә теләсәк, үзебезнең үткәнебезне белү, чын тарихыбызны торгызу – безнең бүгенге көндәге иң беренчел бурычыбыз.

Әлеге хезмәттә XX йөзнең беренче чирегендә татар милли–азатлык хәрәкәте идеологларының берсе, Россиянең II–III Дәүләт думалары депутаты, җәмәгать эшлеклесе, Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтариятының Милли Идарәсе рәисе С.Максудиның 1906–1924 еллардагы сәяси эшчәнлеген, аның татар халкының иҗтимагый–сәяси тормышында тоткан урынын һәм уйнаган ролен ачарга, күрсәтергә тырыштык.

Бөтенроссия мөселманнарының «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелүне мөселман халыкларының сәяси аренага чыгулары дип карарга кирәк. С.Максуди үзенең II–III Дәүләт думаларындагы эшчәнлеген шушы партиянең программасы нигезендә алып бара. Шуңа күрә, хезмәттә «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелү тарихын, бу партиянең эшчәнлегендә зур роль уйнаган татар зыялыларының, милли хәрәкәт җитәкчеләренең эшчәнлеген аның «Милләтнең вөҗданы» исемле мәкаләсе аркылы күрсәтелде, бәяләнде. Шулай ук С.Максудиның II–III Дәүләт думаларындагы эшчәнлегенә игътибар бирергә һәм бу эшчәнлеге «Йолдыз» гәзитендә басылган «Сәяси сөхбәтләр»е аша күзалларга, Думаларда ясаган чыгышлары аша аның XX йөз башы татар милли хәрәкәтенә ясаган йогынтысын ачыкларга, ягъни аның сәяси эшчәнлеген анализларга омтылдык.

XX йөз башындагы татар милли хәрәкәте идеологларының берсе булган С.Максудиның Россия Дәүләт думасында сөйләгән һәрбер нотыгында диярлек күтәрелгән проблемаларның, ул хәл итүне сораган, таләп иткән мәсьәләләрнең хәзерге «суверен» Татарстанда һәм Рәсәй киңлекләрендә яшәүче татар милләте өчен бүген дә бик актуаль яңгыравы бик кызганыч, әлбәттә. Бүгенге милли хәрәкәтнең таркаулыгы, аның лидерларының төрле амбицияләргә бирелеп, милли хәрәкәтне көчсезләндерүләре, ә моннан татар халкына, аның азатлык өчен көрәшенә зыян китерүлә-

рен күргән вакытта С.Максудиның гасыр башында ук: «Мәхкүмә милләтләр бердәм булганда гына үзләренең телләрен, диннәрен саклап кала алырлар, алар бергәләшеп үз хакларын таләп иткәндә генә милләт буларак яши алырлар», дигән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр иде.

Аның ул чыгышларын җыеп китап итеп бастырып чыгарганда, бүгенге депутатларга да практик ярдәме тияр иде: чөнки аларда, беренчедән, бүгенге көндә дә татар халкы өчен хәл ителмәгән мәсьәләләрне хәл итү юллары күрсәтелсә, икенчедән, аларда, халык өчен, милләт өчен файдалы эш эшләргә теләгәннәргә өйрәнерлек нәрсәләр дә бар.

Тикшеренүләрдән шундый нәтиҗә ясарга кирәк: С.Максуди, II–III Дәүләт думалары депутаты буларак, Россиянең сәясәт аренасына чыгып, мөселман халыкларына, татар милләтенә сәяси, милли хокуклар таләп итеп, киң җәмәгатьчелектә көчле яңгыраш тудыручы чыгышлар ясаган бердәнбер депутат һәм татарның беренче профессиональ сәясәтчесе була. Аның башка татар милли хәрәкәте җитәкчеләренең карашларыннан аермалы булган әлеге эшчәнлеген хронологик тәртиптә, ягъни үсештә, үзгәрештә күрсәтергә омтылыш ясалды.

С.Максудиның 1906–1924 еллардагы сәяси, милли эшчәнлеге өйрәнү шундый нәтиҗәгә китерде.

Садри Максуди XX йөзнең беренче чирегендә татар милли хәрәкәтендә күренекле урын тота, бу хәрәкәткә идея юнәлеше бирүче идеологларның иң көчлесе һәм авторитетлысы була.

Садри Максуди үзенең, татар милли хәрәкәте идеологларының берсе буларак, Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Г.Ибраһимов һәм башка күренекле татар зыялыларынан эшчәнлегеннән үзгәрәк эшчәнлеген, татар халкын ике капма–каршы сыйныфка аермыйча, бербөтен татар милләтенә хезмәт итүгә багышлый. Ул милләт өчен иң мөһим булган сәяси, милли проблемаларны хәл иткәннән соң гына, Россиянең хаким милләте белән бергә социаль мәсьәләләрне хәл итүне дөрес дип саный. Сыйнфый көрәшне гомере буе кабул итмәгән С.Максуди, татар милли хәрәкәте идеологларының берсе буларак, үзенең тоткан кыйбласына тугъры кала: аның өчен милләт бердәмлеге идеясе милли көрәшнең төп идеологиясе бул-

ган. С.Максуди татар милләте, мөселман халыклары өчен иң беренче чиратта хәл ителергә тиешле проблемалар дип милләтләрнең теленә, диненә, мәгарифенә, мәдәниятенә кагылышлы проблемаларны саный, чөнки ул милләтне милләт итеп оештырып тотучы тел, дин, мәгарифне бары тик халыкны сыйныфларга бүлмичә, бүлгәләмичә генә үстерергә, саклап калырга мөмкин булачак, дигән фикердә тора һәм шул мәсләктә үзенең эшчәнлеген алып бара.

Ул депутатлык эшчәнлегендә дә, аннан соңгы елларда да татар милләтен бербөтен итеп саклап калганда гына аны икътисади, сәяси яктан үстерергә мөмкин булачак дип саный һәм гомере буена үзенең шушы фикеренә турылыклы булып кала. Хәзер инде танырга кирәк: С.Максуди хаклы булган. Чөнки Октябрь инкыйлабыннан соң ике капма–каршы сыйныфка бүленергә мәҗбүр ителгән татар милләте, башка милләтләр кебек үк, үзен үзе бетердe. Нәтиҗәдә, татар милләте телен, динен онытып, милли хисен, милли горурлыгын югалтып барган бер халыкка – «совет халкына» әйләнеп калды.

Илдәге соңгы еллардагы сәяси үзгәрешләр татар халкында милли хәрәкәтне кузгатып җибәрде. Бу милли күтәрелеш, иң беренче чиратта, халыкның узган тарихы белән кызыксынуын көчәйтеп, аңа игътибарын арттырды. Татар халкы тарихындагы «ак битләр» тарихчылар тарафыннан яңача языла, әкренләп булса да, матбугатта әлеге оныттырылган тарихыбызны ясаган, XX йөз башында патша хөкүмәтенең милли сәясәте астында изелеп яшәгән милләткә «җан өргән» милли хәрәкәт җитәкчеләренә багышланган хезмәтләр чыгып килә. Үзгәртеп кору чорына кадәр татар халкының коммунистик идеологиягә корылган тарихында бары тик шул идеяләрне яклаган һәм шул идеяләр өчен көрәшкән шәхесләрнең генә эшчәнлекләре берьяклы яктыртылып киленде, ә татар халкының милли хәрәкәте җитәкчеләре булган Габдрәшит Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Габделбари Баттал, Галимҗан Шәрәф, Һади Атласи, Ильяс Алкин, Садри Максуди һәм башкаларның милли эшчәнлекләренә бары тик дошман сыйныф идеологиясе вәкилләре буларак кына бәя бирелде һәм искә

алынды. Ниһаять, соңгы елларда татар халкы тарихында аларга үзләренә тиешле урын һәм бәя бирелә башланды.

Әлеге хезмәт шушы шәхесләр арасында заманының иң укымышлы, иң күренекле милләтчеләреннән булган, татар милли хәрәкәте тарихында тирән эз калдырган, аның сәяси, милли көрәшендә зур роль уйнаган шәхес булган Садри Максудиның Россиядәге унике еллык иҗтимагый–сәяси һәм, шулай ук, аның эмиграциядә 1919–1924 елларда Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли Идарәсе рәисе буларак, милли хәрәкәт лидеры вазыйфасындагы эшчәнлеген дә үсештә күрсәтү, бәяләү һәм аның исемен халкыбыз тарихына кире кайтаруны максат итеп язылды.

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


**I. Чыганаклар:**

*1. Газеталар:*

1. Дума. – СПб, 1907.
2. Ил. – Мәскәү, 1916.
3. Йолдыз. – Казан, 1906–1918.
4. Корылтай. – 1917.
5. Урал. – Оренбург, 1907.

*II. Рус телендә:*

1. Биржевые ведомости. – Казань, 1912, 1917.
2. Казанский телеграф. – Казань, 1910, 1912.
3. Общее дело. – Париж, 1921. – 11 января, 16 декабря.
4. Последние новости. – Париж, 1920. – 16 декабря.

*III. Француз телендә:*

1. Eclair. – Париж, 1919. – 30 мая.

*IV. Журналлар:*

1. Икътисад. – Казан, 1912. – № 12.
2. Исламский мир. – Лондон, 1920 – 5 февраля.
3. Сөембикә. – 1914.
4. Мәктәп. – 1913, 1914.

V. *Максуди С.* Англиягә сәяхәт. – Казан: «Өмидь» литотипографисе. – 1914.

*VI. Архив:*

1. Садри Максудиның Төркиядә яшәүче оныгы Гөнел Пултарда саклanучы барланмаган, эшкәртелмәгән архивы материаллары.

*VII. Государственная Дума. Стенографические отчеты. Созыв третий.*

Сессия 1. Часть первая. — СПб.: 1908.

а. Созыв третий. Сессия II. – СПб.: 1909.

б. Созыв третий. Сессия III. – СПб.: 1910.

в. Созыв третий. Сессия IV. – СПб.: 1911.

г. Созыв третий. Сессия V. – СПб.: 1912.

**II. Әдәбият.**

*Татар телендә:*

1. Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. – «Фән». – Казан. – 1999.

2. Абдуллин Я. Иҗат һәм көрәш баскычлары //Садри Максуди. /1879–1957/. – Казан. – 1996. – Б.18–28.

3. Абдуллин Я. Садри Максуди милләт һәм миллият хакында. //Садри Максуди /1879–1957/. – Казан. – 1996. – Б.72–88.

4. Абдуллин Я. Садри Максуди – олуг галим //Казан утлары. – 1996. – 1 сан. Б.141–150.

5. Абдуллин Я. Садри Максуди: иҗат һәм көрәш баскычлары /тууына 115 ел уңае белән/ //Ватаным Татарстан. – 1994. – 21 октябрь.

6. Абдуллин Я. Милли идеология мәсьәләсе һәм Садри Максуди мирасы //Шәһри Казан. –1993. – 6–9–10 февраль.

7. Абдуллин М., Батыев С. Татарстан АССР: чынбарлык һәм буржуаз уйдырмалар. – Казан. Тат.кит.нәшр. – 1980.

8. Акчура Й. Дамелла Галимҗан әл–Баруди. – Казан. – «Иман». – 1997.

9. Әмирханов Р.М. Садри Максуди һәм милләтчелек мәсьәләсе. //Садри Максуди /1879–1957/. – Казан. – 1996. – Б.89–97.

10. Әмирхан Р.У. Гали рухлы шәхес //Мирас. – 1992. – 8 сан. – Б.72–79.

11. Әмирхан Р.У. Исхакыйның уң кулы //Татарстан. – 1996. – 8 сан. – Б.60–68.

12. Әмирхан Р.У. Мөхәммәдия мәдрәсәсе //Мирас. – 1992. – 11 сан. – Б.73–83.

13. Әмирхан Р. Милли матбугатыбыз карлыгачы. //Татарстан. – 1996. – 9 сан. – Б.72–81.

14. Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан. Тат.кит.нәшр. – 1997. – 384 б.

15. Әмиров Д. Татарлар Санкт–Петербургта //Мирас. – 1993. – 3 сан. Б.98–104.

16. Әхмәдиев Ш. Бабамыз Исмәгыйль бәк //Сөембикә. – 1914. – 23 сан, 1 октябрь.

17. Баттал–Таймас Г. Милләт төшенчәсе турында //Татарстан. – 1994. – 7/8 сан. – Б.98–105.

18. Баттал–Таймас Г. Миражга алданган язучы //Татарстан. – 1995. – 7/8 сан. – Б.101–108.

19. Баттал–Таймас Г. Казан төркиләре //Казан утлары. – 1995. – 3 сан. – Б.151–184; 4 сан. – Б.140–167; 5 сан. – Б.162–179.

20. Баттал–Таймас Г. Ике Максудилар //Мирас. – 1995. – 11/12 сан. – Б.120–126; 1996. – 1/2 сан. – Б.217–226; 3 сан. – Б.119–124.

21. Баттал–Таймас Г. Милли тәрбия //Мәктәп. –1913. – 3 сан, 21 март.

22. Бәшири З. Дәрдмәнд–Закир Рәмиев //Мәдәни җомга. –1998. – 21 август.

23. Вәлиди Җ. Милләт вә миллият //Мирас. – 1994. – 3 сан. – Б.80–85; 4 сан. – Б.68–71; 5/6 сан. – Б.201–206.

24. Вәлиев Р. Фаҗига. – Казан. Тат.кит.нәшр. – 1996. 190 б.

25. Вәлиев Р. Садри Максуди һәм Борһан Шәрәф – ике очрашу //Садри Максуди /1879–157/. – Казан. – 1996. – Б.109–116.

26. Вәлиев Р. Кыяммәткә юл. //Мирас. – 1994. – 1 сан. – Б.66–71; 2 сан. – Б.66–75; 1993. – 12 сан. – Б.79–83.

27. Вәлиев Р. Талантлы шәхес фаҗигасы //Татарстан. – 1993. – 1 сан. – Б.44–49.

28. Вәлиев Р. Гыйбрәтле язмыш //Мирас. – 1996. – 1/2 сан. – Б.172–195.

29. Вәлиди Әхмәтзәки–Туган. Әсәрләр. – Өфө. – «Китап». – 1996. – 123 б.

30. Гайнетдинов М. Садри Максуди һәм матур әдәбият //Садри Максуди /1979–1957/. – Казан. – 1996. – Б.103–108.

31. Гайнетдин М. Садыйк хәзрәт кем ул? //Татарстан. – 1996. – 8 сан. – Б.77–80.

32. Гаффарова Ф. Мин милләтемнең баласымын. – Казан: «Иман» нәшр., – 1997. – 124 б.

33. Гаффарова Ф. Россия Дәүләт Думасындагы эшчәнлеге // Садри Максуди /1879–1657/. – Казан. – 1996. – Б.40–53.

34. Гаффарова Ф. Милләтнең асыл улы //Татарстан. – 1995. – 5/сан. – Б.38–44.

35. Гаффарова Ф. «Мин милләтемнең баласымын» //Татарстан. – 1996. – 3 сан. – Б.32–38.

36. Гаффарова Ф. Тараттың, әмма югалтмадың //Татарстан. – 1995. – 11/12 сан. – Б.101–107.

37. Гаффарова Ф. Садри Максуди – Милли–мәдәни мохтарият рәисе //Татарстан. – 1996. – 10 сан. Б.23–29.

38. Гаффарова Ф. Бертуган Максудилар. //Заказанье: Проблемы истории и культуры. – Казань. – 1995. – Б.75–78.

39. Гаффарова Ф. Без бар идек һәм булачакбыз //Ватаным Татарстан. – 1994. – 2 март.

40. Гаффарова Ф. Максуди һәм Гаспринский //Шәһри Казан. –1995. – 16 май.

41. Гаффарова Ф. Депутат Максудиның бер нотыгы //Шәһри Казан. –1994. – 26 март.

42. Гаффарова Ф. «Матур яшәдегез, кордашым!» Фатих Кәримов //Ватаным Татарстан. – 1995. – 18 март.

43. Гаффарова Ф. Садри Максудиның Англиягә сәяхәте //Әдәби җомга. –1995. – 24 ноябрь.

44. Гаффарова Ф. Дус һәм тату яшик дисәк //Ватаным Татарстан. – 1994. – 10 август.

45. Гаффарова Ф. Һади Максуди һәм «Йолдыз» гәзите //Шәһри Казан. – 1994. – 25 сентябрь.

46. Гаффарова Ф. Ул да сибелгән татарның газиз улы иде // Заман. – 1996. – 21 июнь.

47. Гаффарова Ф. Укымаган милләт байымый //Заман. – 1996. – 6 сентябрь.

48. Гаффарова Ф. «Бар» буласың килсә, «юк»ларын да күр // Ватаным Татарстан. – 1998. – 9 октябрь.

49. Гаффарова Ф. Татар җанлы Әхмәт ага Тимер. //Татар иле. – 1999. – 10 сан, 11 март.
50. Гаффарова Ф. Гасыр улы //Мәгърифәт. – 1998. – 17 октябрь.
51. Гаффарова Ф. Изге дисбенең бер төймәсе //Ватаным Татарстан. – 1998. – 25 сентябрь.
52. Гаффарова Ф. «Милли баба» Исмәгыйль бәк Гаспринский //Ватаным Татарстан. – 1999. – 26 март.
53. Гаффарова Ф. Милләтнең зирәк баласы //Татар иле. – 1999. – 6 сан, февраль.
54. Гаффарова Ф. Бертуган Максудилар //Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман. – Казан. – 1999. – 124–131 бб.
55. Гаффарова Ф. Габдулла Буби //Татар иле. – 1999. – 22 сан, август.
56. Гаффарова Ф. Олтан түгел, солтан булды //Заман. – 1999. – 6 сан, 12 ноябрь.
57. Гаффарова Ф. Яңа елдан ни көтәсез? //Шәһри Казан. – 1999. – 31 декабрь.
58. Гаффарова Ф. Милләткә хезмәткә багышланган гомер // Казан утлары. – 2000. – 1 сан.
59. Гаффарова Ф. Милләткә хезмәт юлында //Чирек гасыр фикери эзләнүләр юлында. – 2000. Школа. Казан. – Б.10–16.
60. Гаффарова Ф. Садри Максудиның тормыш юлы //Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан – Казань. – 1999. – Б.291–302.
61. Гаффарова Ф. Әхмәтһади Максуди (1868–1941). //Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. – Казань. – 1999. – Б.302-308.
62. Гобәйдуллин Г. Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары //Мирас. – 1996. – 3 сан. – Б.24–39.
63. Даишев С., Субаев Н. Йосыф Акчура //Татарстан. –1992. – 5/6 сан. – Б.30–35.
64. Зәкиев М. Садри Максуди һәм Адилә Айда төрки тарихы турында //Садри Максуди /1879–1957/. – Казан. – 1996. – Б.66–71.
65. Зәкиев М. Халыкны шәхесләр күтәрә: Садри Максуди һәм башка күренекле шәхесләр турында //Шәһри Казан. – 1995. – 24 февраль.

66. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. – Казан: Татар.китап нәшер. 1976–1988. – 5–6–7 томнар.

67. «Идел буе төбәгендә татар–мөселман йогынтысына каршы чаралар үткәрү буенча Махсус Киңәшмә беркетмәсе» //Татарстан. – 1992. – 5/сан. – Б.66–77.

68. Исхакый Г. Эчке Русия һәм Себер төрек татарларының милли–мәдәни мохтарияты игъланының егерме еллыгы //Яңа милли юл. – Берлин. 1937. – 9/114 сан. – Б.6–10.; 10/115 сан. – Б.1–8.

69. Исхакый Г. Милли юлыбызның нигезләре //Милли Байрак. – Мюнхен. – 1954. – 2/4 сан. – Б.3–9.

70. Исхакый Г. Элек сүз //Мирас. – 1992. – 2 сан.

71. Исхакый Г. Милли көй вә моңнарыбыз //Мәктәп. –1914. – 5 сан. 20 март.

72. Камал Т. Идеал һәм инкыйлаб. – Казан: Татаркитапнәшер., – 1992. – 93 б. – 11 сан. – Б.84–88.

73. Камалов Т. Инкыйлаб, хакимият һәм милли демократия //Мирас. – 1992. – 11 сан. – Б.84–88.

74. Кәримуллин Ә., Даутов Р. Сәяхәтнамәнең авторы турында берничә сүз. Садри Максуди иҗаты //Казан утлары. – 1994. – 7 сан.

75. Кәримуллин Ә. Садри Максуди Арсал //Идел. – 1991. 10/11 сан. – Б.78–84.

76. Максуди С. Миллият тойгысының социологик әсәслары // Мирас. – 1994. – 4 сан. – Б.72–77; 5 сан. – Б.205–209; 10 сан. – Б.135–140; 11/12 сан. – Б.166–171; 1995. – 1/2 сан. – Б.179–186; 3 сан. – Б.103–109; 4 сан. – Б.116–118; 5 /6 сан. – Б.131–139; 10 сан. – Б.115–117; 1996. – 1/2 сан. – Б.107–111.

77. Максуди С. Ял көненең мөселманнар өчен Җомга көн булуын таләп итеп сөйләгән нотыгы //Йолдыз. – 1910. – 1 май.

78. Максуди С. Дахилия нәзарәте сметасы каралганда сөйләгән нотыгы //Йолдыз. – 1912. – 22 март.

79. Максуди С. Милли–мәдәни мохтариятне вөҗүдкә чыгару хәйәтеннән //Йолдыз. – 1917. – 14 август.

80. Максуди С. Эчке Русия мөселманнарының Милли Идарәсе тарафыннан халыкка хитап //Йолдыз. – 1917. – 27 сентябрь.

81. Максуди С. Милли мәҗлес ачылганда сөйләгән нотыгы // Йолдыз. – 1917. – 1 декабрь.

82. Мөхәммәтшин Р. Татар зыялыларына бер караш //Садри Максуди /1879–1957/. – Казан. – 1996. – Б.98–102.

83. Мәһдиев М. Тарихи кыңгыравык //Мирас. – 1992. – 8 сан. – Б.80–83.

84. Мәхмүтфуад. Мәдрәсәләрдә чуалышлар //Мәктәп. – 1913. – 24 март.

85. Мәхмүтфуад. Исмәгыйль бәк-җәмәгать хадиме. //Мәктәп. – 1914. – 9 сан. – 12 октябрь.

86. Нигъмәтуллин Э. Садри Максуди яза //Шәһри Казан. – 1995. – 25 август.

87. Нуруллин И. Фатих Әмирхан. – Казан: Татар.китап нәшер., – 1988. – 278 б.

88. Нуруллина Р. Максудилар нәселе кайдан килә? //Ватаным Татарстан. – 1994. – 23 декабрь.

89. Садри Максуди /1879–1957/ //Казан. – 1996. – 160 б.

90. Садри Максуди. Дәүләт думасында сөйләгән нотык //Мирас. – 1994. – 2 сан. – Б.59–66.

91. Солтанбеков Б. Йөз елга бер табыла торган саф алтын // Татарстан. – 1993. – 6 сан. – Б.45–51.

92. Таһиров И. Бәйсезлек баскычлары. – Казан: Татаркитапнәшр., – 1994. – 278 б.

93. Таһиров И. Инкыйлаб һәм татарлар //Мирас. – 1996. – 3 сан. – Б.111–114.

94. Таһиров И. Татар милләтен ничек аңларга? //Мирас. – 1992. – 6 сан. – Б.89–96.

95. Таһиров И. Тарих сабак бирә // Мирас. – 1994. – 11/12 сан. – Б.161–165.

96. Таһиров И. Парижда укыган Садри //Социалистик Татарстан. – 1990. – 27 май.

97. Тирәшкәвия О. Милләт вә анын тамырлары //Сөембикә. – 1914. – 20 сан. – Б.10–11.

98. Тугры. Вәкилләр көзгесе. – Эстәрлетамак. – 1918.

99. Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. – Казан: Татаркитапнәшр., – 1975–1977.

100. Усал М.–Ф. I–II–III Думаларда мөселман депутатлары һәм аларның кылган эшләре. – Казан. – 1908. – 195 б.

101. Я.Хәлили. Милләт даһие //Сөембикә. – 1914. – 20 сан. 1 октябрь.

*Рус телендә:*

102. Абдуллин Я. Татарская просветительская мысль. – Казань: Татар.кн.изд–во, 1974. – 320 с.

103. Амирханов Р.У. Татарская демократическая печать /1905–1907/. М.: Наука, 1988. – 190 с.

104. Валиди Заки Тоган. – Вспоминания. – Москва. – 1997. – 383 с.

105. Гаффарова Ф. Амирханов Р. Многогранный талант //Научный Татарстан. – 1999, № 4. – С.60–64.

106. Гаффарова Ф. Ахмедхади Максуди //Исторические портреты. - Казань. Изд-во «Магариф». - 2000. - С.105-111.

107. Гаффарова Ф. Садри Максуди //Исторические портреты. - Казань. Изд-во «Магариф». - 2000. - С.147-154.

108. Давлетшин Г. Советский Татарстан. Теория и практика ленинской национальной политики. – 1974.–652 с.

109. Исхаки Г. Идель–Урал. – Наб.Челны: изд–во КамАЗ, 1993. – 63 с.

110. //Ислам в татарском мире: история и современность. – Казань. – 1997.

111. //Исламско–христианское пограничье: итоги и перспективы изучения. – Казань. – 1994.

112. Из истории формирования и развития свободомыслия в дореволюционной Татарии. – Казань: Татар.кн.изд–во, 1987. – 121 с.

113. Каримуллин А. Садри Максуди Арсал //Идель. – 1991. – № 11/12 – 88–95 с.

114. Кульшарипов М. Заки Валиди и образование башкирской автономной советской республики /1917–1920 гг./ – Уфа: Башкир. кн.изд–во, 1992.

115. Михайлова С. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья. Изд–во КГУ, 1972. – 227 с.

116. Михайлова С.М., Коршунова О.Н. Этические аспекты правоведения и деятельность Садри Максуди //Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман. – Казан. – 1999. – С.154–162.

117. Мулланур Вахитов. Жизнь и деятельность пламенного революционера–ленинца. – Казань. –1985.

118. Мусульманские депутаты Государственной Думы России. 1906–1917. – Уфа. – «Китап» – 1998. – 377 с.

119. Мухаметшин Р. Окрыленный борьбой. – Казань: Татар.кн-.изд–во, 1987. – 143 с.

120. Мухаметдинов Р. Зарождение и эволюция тюркизма. – Казан: изд–во «Заман». – 1996. – 270 с.

121. Султанбеков Б.Ф. – История в лицах. – Казань. – Татар.кн.изд–во. – 1997.

122. Султанбеков Б.Ф., Малышева С.Ю. Трагические судьбы. – Казань. – Тат.кн.изд–во – 1996. – 283 с.

123. Султанов Ф.М. Ислам и татарское национальное движение в Российском и мировом мусульманском контексте: история и современность. – Казань. «Школа». – 1999. – 236 с.

124. Общественная и философская мысль в Татарии в начале XX века. – М.: Наука, 1990. – 198 с.

125. Тагиров И. Национальное движение: его прошлое, настоящее и будущее //Татарстан. – 1995. – № 3–4. – 4–10 с.

126. Тагиров И. Дорогой свободы и братства. – Казань: Татар.кн.изд–во, 1987. – 431 с.

127. Хабутдинов А. Невостребованное наследие. //Казань. – 1998. – № 7–8. – 28–33 с.

128. Хайрутдинов Р. Трудное возрождение: /февраль 1917–1920 гг./. – Казань: Татар.кн.изд–во, 1992. – 184 с.

129. Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов. – Казань:Татар.кн-.изд–во, 1917. – 431 с.

130. Хасанов М.Х. Писатель. Ученый. Революционер. – М.: Наука. 1987.

131. Хасанов Х.Х. Формирование татарской буржуазной нации. – Казань: Татар.кн.изд–во, 1977. – 326 с.

*Төрек телендә:*

132. Adile Ayda. Sadri Maksudi Arsal. Türk Büyükleri. — Ankara, –1991. – 280 s.

133. Ali Akiş. Idil–Ural Dâvasi ve Sovyet Emperyalizmi. – Ankara, – 1963. – 46 s.

134. Ahmet Bican Ercilasun. Türk Dili Üzerine Incelemeler. – Ankara, – 1993. – s.224–236.

135. Ahmet Temir. Yusuf Akçura. – Ankara, – 1997.

136. Gönel Pultar. Sadri Maksudi Arsal'ın Türkiye'deki Politik Faaliyetleri //Садри Максуди (1879–1957). – Казан, 1996. – б.29–40.

137. Tanyeri Cansever. Sadri Maksudi Arsal'ın Türkiye'deki Siyası Hayatı. //Садри Максуди (1879–1957). – 1996. – б.54–65.

138. Necip Hablemitoğlu. Çarlik Rusya'sında Türk Kongreleri (1905–1917) – Ankara. – 1997.– s.317.

# КУШЫМТА

## I. Садри Максудиның кыскача тормыш юлы.

Үзенең гомерен татар халкына, мөселман халыкларына хезмәт итүгә багышлаган Садри Максуди (Садретдин Низаметдин улы Максудов) 1878 елның 23 июлендә (иске стиль белән) Казан өязе Ташсу авылында (хәзерге Биектау районы) Низаметдин мулла гаиләсендә дөньяга килә.

Бу гаиләдә белемгә омтылыш көчле була. Садри башта үз авыллары мәдрәсәсендә – әтисендә укый, аннан Казандагы абыйсы Әхмәдһади мөгаллимлек иткән Галләмия мәдрәсәсендә белем ала. Биредә ул сигез ел буена төрек, гарәп, фарсы телләрен, Ислам фәлсәфәсен, дин белемнәрен өйрәнә. Ләкин, тора–бара, абыйсы Һади өендәге төрекчә китап–журналлар, «Тәрҗеман» гәзите генә яңалыкка сусаган һәм кызыксынучан табигатле яшүсмер егетне инде канәгатьләндерми башлый: ул үзлегеннән русча өйрәнергә керешә.

Садриның аннан ун яшькә өлкәнрәк булган абыйсы Һади төрки дөньяда беренче гәзит – «Тәрҗеман» гәзитен чыгара башлап, үз гәзите битләрендә төрки халыкларда миллият хисләрен уятучы беренче орлыкларны чәчәргә керешкән атаклы Исмәгыйль бәк Гаспринский белән дустанә мөнәсәбәтләрдә була. 1893 елны Гаспринский аны Бакчасарайга Зынҗырлы мәдрәсәсенә укытучы итеп чакыргач, Һади Максуди бик шатланып ризалаша һәм үзенә ияртеп, энесе Садретдинны да Кырымга алып китә. Биредә ул төрек телен, тарих, җәгъръфия, табигать белемен өйрәнә. Садретдинның Кырымга килүе һәм анда Исмәгыйль бәк Гаспринский белән танышуы яшь егетнең киләчәгенә төп юлны билгеләгән һәм аның тормышында иң зур әһәмияткә ия вакыйгага әйләнә.

Яшүсмер Садри үзенең яшьтәшләренә караганда укымышлырак була, һәм нәкъ менә шушы ягы белән ул Исмәгыйль бәкнең

игътибарын җәлеп итә. Ә яшь Садрига анның бер фикере бик ошый, ул – төрки халыкларның берлеге, бердәмлеге турындагы фикер. Исмәгыйль бәк Гаспринский, һәр форсаттан файдаланып, бөтен төрки халыкларның бер гаилә, ягъни кырым һәм казан татарларының, башкорт, кыргызларның бертуган булуы, христиан динендәге чуваш, шаман булган якутларның да бер төрки гаилә әгъзалары икәнлекләрен Садрига җентекләп аңлата. Шул ук вакытта Исмәгыйль бәк Гаспринский Казан татарларының, иң мәдәниятле халык булулары аркасында үзләрен башкалардан югары тотулары, үзләрен өстен куюларын тәнкыйть итеп, ачынып сөйли һәм яшь Садрида моны бетерү өчен, аңа бөтен төрки халыкларның бертигез булуларын, бердәм булганда гына тәрәкъкыят юлында уңышларга ирешеп булачагын аңлатырга тырыша.

Бер елга якын бергә аралашып яшәүнең файдасы була: яшь Максуди төрки бердәмлек, халык язмышы турында уйлана башлый. Аңарда бөек төркиче Исмәгыйль бәк Гаспринскийга карата тирән ихтирам һәм аркадашлык хисе уяна. Һәм, еллар узгач, ул тормышының һәр хәлиткеч борылышында Исмәгыйль бәк Гаспринскийның милләт хисе һәм төрки бердәмлек турындагы сүзләрен исенә төшерә. Кызы Гадилә Айда әйтүенчә, ул «Минем рухи атам – Исмәгыйль бәк Гаспринский» дия торган була. Шунысы да хак: Исмәгыйль бәк Гаспринский С.Максудиның милләткә хезмәт итүдәге тоткан кыйбласына озак еллар юнәлеш биреп торучы да әле ул.

Ләкин Зынҗырлы мәдрәсәсендә белем эстәп яткан вакытта, 1894 елны Ташсудан күңелсез хәбәр килә: аталары Низаметдин мулла авырый башлаган. Агале–энеле Максудилар Казанга кайтып китәргә мәҗбүр булалар.

Казанга кайткач, Садри Галлямия мәдрәсәсен тәмамлый һәм Учительская школага укырга керергә карар итә. Бәхетенә күрә аның бу теләгенә гаиләсе дә каршы килми, абыйсы Һади да аны хуплый, ул С.Максудины әлеге мәктәпкә кабул итүләрен сорап, Казан татар укытучылар мәктәбе инспекторы исеменә гариза да яза. Биредә укыганда Садри тулысынча рус әдәбияты һәм рус теленә тәрҗемә ителгән фәнни әдәбият дөньясына чума. Үзе укыган рус романнары тәэсирендә татарча «Мәгыйшәт» исемле роман

яза. Роман 1898 елда басылып та чыга. Ә бит С.Максудига бу вакытта бары тик унтугыз яшь кенә була, әмма, шуңа да карамастан, «Мәгыйшәт» романына инде киләчәктә Максуди үзе шуларны хәл итүгә бар гомерен багышлаячак проблемаларның күбесе салынга. Муса Акъегет, Заһир Бигиев романнары югарылыгында язылган әлеге әсәр «алар иҗатында билгеләнгән казанышларның дәвамы, үстерелеше, яңа югарылыкларга омтылыш булып тора»[1].

«Мәгыйшәт» романының 1914 елда басылып чыккан икенче басмасына кереш сүзендә С.Максуди үзе болай дип яза: «Мәгыйшәт» реалист юлда язылса да, фикер тарату максаты белән, укучыда «әмәл» (өмет) тудыру фикере белән язылган бер әсәрдер». Ул үзенең әлеге романында күтәрелгән проблемалар аша татар милләтенең киләчәккә юлын күрсәтергә, татар укучысын үзенең бүгенгесе, киләчәге хакында уйланырга чакырган, дияргә кирәк.

Учительская школада укыган елларда Садрида француз телен өйрәнәсе килү теләге туа. Шунлыктан ул, сабакташлары йокларга яткач, русчага тәрҗемә ителгән Руссо кебек философларның әсәрләрен, Мольер пьесаларын, фәнни әдәбиятны да зур кызыксыну белән төннәр буе укып утыра. Ул вакытта Россиядә француз әдәбияты, француз мәдәнияты белән кызыксыну көчле була, шунлыктан ерак Франция, үзе әсәрләнеп, мавыгып укыган серле Париж С.Максудида Франциягә барып уку теләген уята. Әмма ул бу уй–хисләрен хәтта абыйсы Һадидан да яшерә, чөнки аңа үзенең бу теләге тормышка ашмас хыял гына булып тоела. С.Максуди 1901 елны Учительская школаны барлык предметлардан да «бик яхшы» билгесенә генә тәмамлап, «башлангыч мәктәп укытучысы» исемен алып чыга.

Учительская школаны тәмамлагач, С.Максуди Петербург университетына укырга кермәкче булып, Петербургка бара. Тик рус университетының ишекләре татар баласы өчен ябык була. Шуннан соң ул Ясная Полянага барып үзе һәр әсәрен яратып укыган һәм хөрмәт иткән Л.Н.Толстой белән очраша. С. Максуди үзенең Толстой белән очрашып–сөйләшеп уздырган вакытын гомеренең иң гүзәл мизгеленнән саный. Аннан ул Кырымга китә, анда Исмәгыйль бәк Гаспринский белән күрешә, аңа үзенең укуын дәвам

итәр өчен Төркиягә китәргә теләвен әйтә, әмма Исмәгыйль бәк Гаспринский аңа ул вакытта Европа мәдәниятенең мәркәзе булган Парижга китәргә, укуын шунда дәвам итәргә тәкъдим итә. Исмәгыйль бәк Гаспринскийның бу тәкъдименнән соң, күңеленең иң тирән җиренә яшерелгән Парижга барып уку теләге Садрида яңадан кабынып китә. «Ара–тирә «Тәрҗеман»га мәкаләләр язарсың, мин дә сиңа җибәргәләрмен, сине ач тотмабыз» дип, ул С. Максудиның бу сәфәренә үзенең хәер–фатыйхасын бирә. С. Максуди башта Төркиягә, ә анда берникадәр вакыт яшәп, бераз француз теленнән дәресләр алгач, тәвәккәлләп, Франциягә китә. Бөтенләй дә диярлек французча белмәгән, таныш–белешләре булмаган С.Максуди үзенең зирәклеге, тырышлыгы, чыдамлыгы аркасында бөтен авырлыкларны җиңеп, һәммәсенә түзеп, бер ел эчендә француз телен өйрәнеп, Парижның Сорбонна университетының хокук факультетына укырга керә һәм дүрт елда аны бетереп тә чыга. Ул хокук дәресләреннән башка фәлсәфә һәм социология дәресләренә дә йөри. Монда укыганда аңа даими матди ярдәм күрсәтүче булмый, шуңа күрә ул Россиядәге төрле газетларга, (шул исәптән, «Тәрҗеман»га да) хәбәр, мәкаләләр язарга, рус теленнән дәресләр бирергә мәҗбүр була. Ләкин авырлыкларга да карамастан, Франциядә узган ул еллар романтик рухлы С.Максуди күңелендә матур хатирәләр калдыра, чөнки ул анда үзенә гомерлек дуслар, фикердәшләр таба: Парижда Йосыф Акчура, Яхъя Кемал[2] һәм башкалар белән дуслаша, алар белән төрки халыкларның үткәне һәм киләчәге турында кайнар бәхәсләр алып бара.

Бөтен нәрсәне белергә теләгән С.Максуди, тырышып укудан тыш, Парижда яшәүче халыкның төрле катламнарының тормыш–көнкүреше, уй–фикерләре белән дә кызыксына: ул студентлар яшәгән чардакларда, эшчеләр яшәгән арзанлы фатирларда да еш була. Аны ул елларда аксөякләрнең әдәби салоннарында да күрергә мөмкин булган, ул хәтта моның өчен үзенә фрак та тектергән. Әдәбият–сәнгать яраткан С.Максуди театрларга еш йөри, музейларда була, ә каникул вакытларында Франция буйлап сәяхәткә дә чыгып китә.

Парижда укыган елларда даими матди ярдәм алып тормаган С. Максуди гәзитләргә мәкаләләр язып кына акча эшләп булмаганлыгын тиз аңлый һәм Америка язучысына ияреп «Йөз ел соңра» дигән роман яза, аның бу романы 1906 елда «Тәрҗеман» гәзитендә С.М. имзасы белән басылып чыга. Шулай ук аның ул чорда француз телендә бер пьеса да язып караганы билгеле[3].

1902 елны, инде Парижга барып, университетта укый башлагач, С.Максуди Исмәгыйль бәк Гаспринскийдан хат ала, ул аңа тиздән «Тәрҗеман» гәзитенең егерме еллыгы булачагы турында яза. Әлеге хаттан соң С.Максудины бу уңай белән төрки халыклар арасында бернинди дә хәзерлек эшләре алып барылмавы борчый. Ул: «Әгәр бу хәл башка алдынгы милләтләрдә булса, бер юбилей үткәрерләр иде, ул милләт үзенең милләтпәрвәрләренә олы хөрмәт, ихтирам күрсәтер иде», дип көенә. С.Максуди сабакташы Й.Акчура белән киңәшләшеп, бу юбилей мөнәсәбәте белән Төркиядә һәм Россиядә яшәүче танылган зыялыларның Исмәгыйль бәк Гаспринскийга хатлары рәвешендә бер китапчык чыгарырга уйлыйлар һәм үзләренең теләк–киңәшләрен әйтеп, барлыгы йөздән артык кешегә хат язалар. Бу китапчык Россия төркиләре арасында Исмәгыйль бәк Гаспринскийның «Тәрҗеман» гәзитенең егерме еллык юбилеен үткәрү өчен нигез, бер этәргеч була. 1903 елда Бакчасарайда милләтсөярләрнең җыелышуы «бер милли конгресс рәвешен ала, төрле өлкәләрдән килгән төркиләр һәм Россия төркиләре өчен милли мәдәниятәрен үстерүдә, диннәрен, телләрен саклауда русларга каршы тору өчен бер киңәш мәҗлесе булды», дип яза С.Максуди үзе бу турыда соңыннан. С.Максуди белән Йосыф Акчура, бу бәйрәмгә кайта алмасалар да, үзләренең әлеге юбилейны уздыруда этәргеч булулары белән бик горурланалар.

«Йокымсырап яткан татар халкының күңелсез хәятенә җан өрүче»[4] Исмәгыйль бәк Гаспринский төрки халыкларының бердәм һәм бер гаилә булып кына мәдәниятләрен, икътисадларын тәрәккъый итү өчен көрәшеп, телләрен–диннәрен саклап кала алачаклары турындагы фикеренә гомере буена турылыклы кала. Ә аның шәкерте, остазының бу фикеренә кушылып, 1906 елдан башлап, II–III Россия дәүләт думалары депутаты буларак, Дума

мөнбәреннән изелгән, хурланган мөселман халыкларының хокукларын бертигез яклап ялкынлы чыгышлар ясый, татар халкында миллият хисен уяту, тәрбияләүдә, милли хәрәкәткә юнәлеш бирүдә әһәмиятле роль уйнаган шәхесләрнең берсенә әверелә. Татар милли хәрәкәте идеологларының иң авторитетлысына әйләнгән С.Максуди, еллар узгач, бу юлда тәҗрибә туплагач, үзенең «рухи атасының» милләткә хезмәттә озак еллар буена үз иңнәрендә нинди авыр йөк күтәреп барганын яхшы аңлый. «Мөхтәрәм мөгаллим, Сезне милләт тарафыннан Русиянең бөтен нокталарында исламнар тарафыннан билгеләп үтелә торган мактаулы олуг бәйрәм белән белән котлыйм. Сезнең: яшәдем! дип әйтергә хакыгыз бар. Сез бүген һәр мөселманның фикерендә, милләтнең тарихысыздыр. Сезнең хәятегез мисалы, без, Русия мөселманнары өчен үрнәктер» дип язачак ул 1908 елның 13 маенда «Йолдыз» гәзитендә «Тәрҗеман»ның егерме биш еллык юбилее уңае белән.

1906 елны, биш ел иленнән аерылып яшәгән С.Максуди Сорбоннаны тәмамлап, юрист дипломы алып, милли хисләр белән ташып, үзен милләт тәрәкъкыятенә хезмәт итәргә әзерләп, Россиягә кайта, һәм шушы елдан аның татар милләтенә фидакарьләрчә хезмәткә багышланган эшчәнлеге башлана.

1996 елның 16–20 августында Н.Новгородта «Мөселман иттифакы» партиясенең III съезды уздырыла һәм съезд эшендә И.Гаспринский. И. Акчураларның чакыруы буенча С.Максуди да катнаша, сәясәт комиссиясендә эшли, әлеге партиянең Идарәсенә сайлана, шушы партия тарафыннан аның кандидатурасы II Дәүләт думасына депутатлыкка тәкъдим ителә.

С.Максудиның, шулай итеп, 1907 елдан 1912 елга кадәр булган II–III Дәүләт думаларындагы, депутат буларак эшчәнлеге, ягъни ил күләмендәге рәсми сәясәттәге эшчәнлеге башлана. II Думада ул Президиум әгъзасы итеп, III Думада исә Мөселман фракциясе секретаре итеп сайлана.

III Думада С.Максуди иң тынгысыз һәм иң эшчән депутатлардан була. Ул III Думада, төрле закон проектлары каралганда барлыгы унбиштән артык чыгыш ясый. Ул чыгышларның һәрберсе диярлек Россия газеталарында, татар вакытлы матбугатында басылып бара.

1907—1912 еллар — татар вакытлы матбугатында өзлексез кыйналуга, тәнкыйтьләнүгә дә карамастан, III Думадагы сигез кешедән торган Мөселман фракциясе, аның иң, эшчән депутатларыннан булган С.Максудинын сәяси эшчәнлегенең иң актив еллары.

1912 елны IV Думага сайлауларда С.Максудиның кандидатурасы узмый. Аның сәяси, иҗтимагый эшчәнлегенең икенче этабы башлана. Ул Диния Руханияне үзгәртеп кору, мәктәп-мәдрәсәләрне реформалаштыру буенча башланган хәрәкәттә дә актив эшчәнлек җәелдереп җибәрә.

Шулай ук ул елларда С.Максуди тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларның берсе турында кыскача гына булса да әйтеп үтәргә кирәктер.

1910 елда утыз яшенә кадәр буйдак булып яшәгән С.Максудиның шәхси тормышында зур үзгәреш була: ул миллионер Шакир Рәмиевнең кызы Камиләгә өйләнә.

Шушы елның башында Муса Бигиев С.Максудины Уралдагы алтын приискалары хуҗаларының берсе — Шакир Рәмиев белән таныштырмакчы була,

— Шакир Рәмиевнең бик гүзәл Камилә исемле кызы бар, кем белә, бәлки бер-берегезгә ошап та куярсыз. Сиңа өйләнергә дә вакыт, ди.

— Мина бирерләрме соң аны? — ди С.Максуди. — Димләүчесе мин булгач, бирерләр. Бары тик бер-берегезне ошатуыгыз гына кирәк, — ди М.Бигиев көлеп. Һәм ул, озакка сузмыйча, Ш.Рәмиевкә хат та язып сала. Ниһаять, 1910 елның җәй башында аңа Ш.Рәмиевтән аларныц икесен дә кунакка чакырган хат килеп төшә. М.Бигиев белән С.Максуди шунда ук югары Уралга Рәмиевләргә китеп баралар. М.Бигиев Ш.Рәмиевкә С.Максудиның аның кызы Камилә туташ белән танышырга теләве турында әйтә. С.Максудиның Россия Дәүләт Думасы мәҗлесләрендә ясаган чыгышлары, гәзитләрдәге мәкаләләрен укып барган Рәмиевләр гаиләсе, бигрәк тә кызлары Камилә, аның белән бик теләп һәм зур кызыксыну белән танышалар. С.Максуди уртача буйлы, озын кара чәчле, нечкә билле бу сөйкемле кызны беренче күрүдә үк ошата. Камиләгә дә С.Максуди бик ошый. Нәтиҗәдә, бәлки М.Бигиев-

нең дә үгетләүләре тәэсир иткәндер, Ш.Рәмиев аларга үзенең хәер-фатыйхасын бирә. Ноябрь аенда Оренбургта бу ике яшьнең туйлары була. Туйга татар дөньясынын, барлык танылган байлары, зыялылары чакырыла, бу вакыйга турында барлык татар гәзитләре дә диярлек язып чыга*.

С.Максуди, туйдан соң, хатыны белән Петербургка китә, анда үзенең депутат буларак эшен дәвам итә. 1912 елны аларнын беренче кызлары Гадилә туа, ә 1914 елны икенче кызлары Наилә дөньяга килә. С.Максуди өчен бу еллар бик бәхетле еллар була: беренчедән, ул гаилә тормышы белән бик бәхетле булса, икенчедән, бөтен көчен, сәләтен биреп милләтенә хезмәт итә алуы белән үзен бәхетле саный.

Татар милләтенең иң бай промышленникларыннан булган Ш.Рәмиевнең кызына өйләнү С.Максудиның матди хәленә генә уң ай тәэсир итеп калмый, аңа җәмгыятьтә берничә баскычка югарырак күтәрелергә дә ярдәм итә. Петербургта яшәгәндә алар шәһәрнең затлы нәселдән чыккан аксөякләре белән аралашып яшиләр, аларны үзләрендә дә кабул итәләр.

М.Бигиев таныштырган һәм аның димләве аркасында табышкан бу пар искиткеч бәхетле гаилә булып чыга. Камилә ханым, зыялы татар хатын-кызларына хас булганча, сабырлык, түземлелек белән бу тормышта С.Максуди өлешенә тигән барлык авырлыкларны, кимсетелүләрне дә, зарланмыйча, аның белән тигез күтәрешә. Соңрак, С.Максуди Төркиянен, беренче кешеләренең берсенә әйләнгәч тә, ул тыйнак, сабыр булып кала ала.

С.Максуди белән Камилә ханым кырык җиде ел буе тату, матур гомер итәләр, ике кыз үстерәләр. Ул кызларның берсе — Гадилә исемлесе — Төрциянең беренче хатын-кыз дипломаты. Гадилә Айда унтугыз ел буе Голландия, Италия. Испания һ.б. илләрдә Төрциянең тулы вәкаләтле илчесе була. Соңыннан фән белән шөгыльләнә, әтисенең язылып бетмичә калган хезмәтләрен төгәлли. С.Максудиның тормыш юлы турында «Садри Максуди Арсал» дигән китабын яза.

Татар милләтенең асыл улларыннан булган С.Максуди белән зыялы кызларыннан булган Камилә Рәмиеваның оныклары Гөнел Пултар белән Гөлнур Очак та Төркия җәмгыятендә үзләренә ла-

еклы урын табалар. Гөлнур ханым Төркия финанс министрлыгының тышкы сәүдә бүлеген җитәкли, ә Гөнел ханым исә Билкенд университетында инглиз әдәбияты укыта, язучы. Хәзерге вакытта ул Төркиядәге татар мөһаҗирләре турында роман яза.

Россиядән чит кеше исеме астында чыгып китәргә мәҗбүр ителгән Садри һәм Камилә Максудилар туган җирләреннән аерылгач та юкка чыкмыйлар. Татар халкының иң күркәм сыйфатларын үзләренә җыйган бу ике асыл зат мөһаҗирлектә дә үзләренең кыйблаларына, мәсләкләренә тугры калып, шул максатларына хезмәт итәләр. Ә бу инде, затлы агачны кая гына күчереп утыртсаң да, барыбер үзенең асыл җимешләрен бирәчәк дигән сүз.

С.Максудиның иң актив сәяси, милли эшчәнлеге 1917 елның Февраль революциясеннән соң, ягъни Эчке Русия һәм себер төрек–татарларынын Милли–мәдәни мохтәриятен төзү, анның Беренче Милләт мәҗлесе эшләгән чорга туры килә. 1917 елның 22 июлендә игълан ителгән Милли–мәдәни мохтәррият 1918 елның 13 апреленә кадәр генә яшәп калуына да карамастан, дүрт йөз елга якын үзенең дәүләтчелеген югалткан, әмма шул дәүләтчелеген, бәйсезлеген кабат торгызу теләген югалтмаган татар халкы өчен бу көннәр тарихка шанлы көннәр булып кереп кала. Милли–мәдәни мохтәрият совет хөкүмәте тарафыннан куып таратыла, ә анның җитәкчесе С.Максуди чит илгә качарга мәҗбүр була. 1918—1923 елларда ул шушы Милли–мәдәни мохтәриятның җитәкчесе буларак эмиграциядәге татар милли азатлык хәрәкәтен җитәкли. Парижда уздырылган Тынычлык конференцияләрендә катнаша. Ул 1923 елларга кадәр Россиядәге сәяси хәлләр үзгәрер да илгә кире кайту мөмкинлеге туар дигән өмет, ышаныч белән яши. Әмма инде бу ышаныч аңарда көннән–көн кими бара.

С.Максудиның 1925 елдан соңгы эшчәнлеге турында Төркиядә зур–зур хезмәтләр языла, кызы А.Айданың «Садри Максуди Арсал» исемле китабы чыга. Инде менә кырык елга якын һәр ел саен 20 февраль көнне Төркиянең җитди гәзитләрендә аны искә алу мәкаләләре чыгып килә, ә «Төрек йорты» журналы 1957 елдан башлап һәр ел саен үзенең февраль санында С.Максудига багышланган материаллар биреп бара.

С.Максудиның Төркиядәге тормышы һәм аның андагы киң кырлы эшчәнлеге турында үзенә аерым бер хезмәт язу сорала. Ә биредә исә аның Төркиядә чын иҗат, фән һәм сәясәт дөньясында кайнап узган утыз ике еллык гомере турында кыскача гына булса да әйтеп китәргә кирәк дип санадык.

Төркиядә Республика игълан ителгәч, С.Максуди зур шатлык хисләре кичерә, 1924 елның җәендә «андагы үзгәрешләрне үз күзләре белән күрер өчен» Франциядән Төркиягә китә. Анда ул Төркиянең хөкүмәт җитәкчесе Мостафа Кемал белән таныша, ә ул исә шул елның ахырларында аңа яшь Республикага хезмәт итәргә чакырып рәсми хат җибәрә. С.Максуди 1925 елның, башларында «Анда мине тарихи хезмәтләр көтә», дип, Парижда инде көйләнеп барган тормышын, яраткан эшен калдырып, бөтенләйгә Төркиягә күчеп китә һәм шул елдан башлап гомеренең соңгы көннәренә кадәр, утыз елдан артык Төркия бу талантлы галимнең, сәясәтченең икенче Ватанына әйләнә. Бик күп татар мөһаҗирләрен үзенә сыендырган, татар халкының И.Акчура, Г.Баттал, Ф.Туктаров, Г.Исхакый, М.Бигиев, З.Вәлиди кебек асыл улларын кабул иткән төрек халкы С.Максудины да үз улы итеп таный.

Безнең милләтнең мәдәнияты, әдәбияты күгендә якты йолдызлар булып янарга тиешле күпме ул-кызлары кайсы илләргә сибелмәгән дә, нинди гена халыкларга хезмәт итмәгән! Әгәр алар үз күгебездә янсалар, безнең хәятебез ямьлерәк, яктырак булыр иде бит. Тик 1917 елдан башлап, динебезне, телебезне оныттырып бетерә язган канлы тарихыбызга карап әрнергә генә кала...

## ИСКӘРМӘЛӘР

* Бу турыда тулырак мәгълүматны А.Айданың «Садри Максуди Арсал» китабыннан кара.

1. Гайнетдинов М. Галим һәм матур әдәбият //Шәһри Казан. -1994. - 29 сентябрь.

2. Төрек шагыйре.

3. С.Максудиның оныгы Г.Пултарда саклanучы архивта.

4. Йолдыз. - 1914. - 14 сентябрь.

## II. С.Максуди мәкаләләре.

*1. Әфкяр миллиямез (Интеккән, йончыган, гарипләнгән милли хисебез)*

Моннан ун–унбиш ел элек кадәр яшәгән Русия мөселманнарының хәятендә гаять газиз бер хәрәкәт бар иде. Бу хәрәкәт миллия тәрәкъкыйпәрвәр һәм гаять милләтпәрвәр иде. Бу хәрәкәт әүвәл заманның сәяси омтылышы булмаганга бер мәркәз тәшкил итми иде. Моның белән бер үзәктән идарә итүчеләр юк иде. Бу һәр җирдә, гүя бер заманда пәйда улмыш бер хәл иде. Бу хәрәкәт бер мәркәздә бөек бер куәт белән барлыкка килеп тә башка җирләргә таралмады, бәлки шул ук вакытта барча әтрафларда үзенең яшәүен исбат итте. Миллия вә тарихчылык ноктасыннан каралганда бу хәл мәгънәви бөек бер нур иде. Ләкин бер җирдә ялтырамага башланып та бөтен әтрафны яктырткан куәтле нур түгел иде.

Ләкин һәр кеше белә, бу нур бер көн куәт алачак, моңа сорау зур иде һәм бер вакыт бөтен мәйданны милли нур яктыртачак иде. Әмма һәркем бу нурның сүндерелүеннән курка иде, чөнки әүвәл заманда хәят сәясия башка иде. Шуның өчен бу нурларның кадерен белгән, аны таныган һәм тагын да көчәйтү, бөекләтү тарафдарлары бер янмага башлаган кәндиләрне сүндермәячәк, бер хәят сәясиянең мәйданга чыгуын бөтен рухлары белән телиләр, шуңа омтылалар иде.

Мәмләкәттә иркенлек вә хөрриятләрнең мәйданга чыгуын теләгән киләчәк тарафдарлары булганнар милләтнең бердәмлеген таләп итәләр.

Әүвәл замандагы хәрәкәт миллиямез, бигрәк тә, мәктәп вә мәдрәсә, тәгълим вә тәрбия юлында булса да, әдәбият, сәүдә бабында да бу хәрәкәтнең тәэсире юк түгел иде. Бу заман бик хуш бер заман иде. Ике ысул илә укыту яңа мәйданга чыккан иде, халык икегә бүленеп, кайсылары җәдид, кайсылары кадим аталып, шау килеп, ихлас илә кычкырышалар иде.

Җәдидләр кадимнәрне бик түбән күреп, аларга мөнәсәбәттә шаулашып хата ясыйлар иде. Кадимнәрнең дә кайсылары җәдидләрне кяфирга кадәр тиңләп ялгышалар иде. Низаг куәтле иде. Ләкин бу низаглар, бу ачулар һәрбере милли иде. Милләт эшләре

хакында иде. Кадиме булсын, җәдиде булсын — милләтпәрвәр иде. Низаглар динемез вә милләтемез даирәсендә йөриләр иде.

Яңа мәктәпләрнең хисабы бик күп булмаса да, ачылган җирләрдә көннән—көн тәрәкъкый итә, абруйга керә иде. Бу яңа мәктәпләр өчен яңа китаплар басылган иде. Бунларның, арада берничәсеннән башка эшкә яраклысы булмаса да, һәрберенең мәйданга килүе тәбрик ителә иде.

Хәрәкәт миллиямезнең бу башлангычы булганга бер галәмәт кеби, һәркем әлифбалар язу—басу белән маташа иде. Ысул җәдид, икенче төрле әйткәндә «яңа ысул» бары тик шул башлангыч укулар дәрәҗәсендә генә кирәк кебек аңлатыла иде.

Бу яңа ысул башлангычына имамнар гына катнашмый иде. Бөтен халык зур әһәмият бирә иде. Хөсәеновларның, Акчурин, Шәфигуллин, Дибердиевләрнең, Яушевларның, Рәмиевләрнең вә башка сәүдәгәрләрнең бу юлдагы иҗтиһадлары гаҗәпләнүгә, сокланугa лаек иде. Ә яңа гына чыга башлаган ул хикәяләр, романчыкларга килсәк, аларның һәрберендә никадәр өмет утлары чагыла иде. Язылган бер хикәячектә мотлака бер укыган егет вә бер укыган кыз, иске белән чагыштырып, үзенә нәтиҗә ясый иде.

Бу романчык, хикәяләр авторларының бу укыган яшьләр теленнән әйттерелгән сүзләренә килсәк, һәрбере кирәк, һәрбере киләчәккә гаять ышанган, ышанычы таза бер телдә сөйләшәләр. Бу хикәяләрне укыганда үз милләтеңнең унтугыз—егерме яшьләрендәге күзе ачык, саф шәкертләрнең дулкынлануларын күрсәк, һәрберен мөкатдәс милләт баласы дип маңгайдан үбәсе килә иде. Әле хәтеремдә: Казанда басылган «Сәлимә» китабының килеп чыгуыннан туган Казан яшьләре арасындагы дулкынлануны кабул итмиләр иде. Әүвәл вакыт школада яшьтәшләрем арасында халкыбызга мәхәббәт арттыру фикеренә хезмәт итәргә телидер идем. Шул фикер белән күп вакыт милли сөхбәтләр, милли әңгәмәләр була иде. Ул хакта әле халкыбыз арасында хәбәр бик аз иде. Гәҗите дисәк, бары бер «Тәрҗеман» иде. Алай булса да, халкыбыз арасында берәр сөенечле хәбәр булдымы, аны иптәшләр арасында бер—беребезгә сөйләүне гадәт иткән идек. Беркөн кич, кесәмнән чыгарып, иптәшләремә «Сәлимә» китабын күрсәттем, сөйләгәндә һәрберенең күзләрендәге горурлык хисен күрсәгез иде,

шөбһәсез, укучылар, «Сәлимә» хакында фикерегезне үзгәртер идегез. Әлбәттә, аларның һәрбере алай түгел иде, төркичә укымаган, язу танымаганнары да бар иде. Мондыйлар бу кеби хиссияттән бик ерак иде, алай булса да, миллият орлыгы һәрберендә бар иде. Ләкин ул орлык тәрбия ителмичә кала иде.

Бу гәҗитәгә мөнәсәбәтле кешеләрнең һәрбере яшьләр булганга, нәшер итүчеләр үзләренең бөтен гайрәтләрен шул эшкә сарыф итәләр иде. Аз заман эчендә бунларның фикерләре аз мәгълүмәтле, бөтенләй тәҗрибәсез, ләкин саф яшьләр арасында бик тиз таралды. Ул вакытта миллият бураннарына мин дә эләккән идем. Мин дә шул дулкыннар эчендә идем. Китап язмый чыдый алмаган идем. «Мәгыйшәт» исемле бер хикәя нәшер иткән идем. Китап чыкканнан соң бер ай ярым эчендә утыз дүрт тәбрикнамә алган идем. Бу тәбрикләрне язучыларның күбесе мәдрәсә шәкертләре иде.

Моннан бер унбер сәнә элек Троицкига сәяхәт иткән идек. Ул замандагы пароходта барган, Уфада, Чиләбедә күрелгән имам, мөдәррис вә шәкертләрнең һәрберендә гайрәт гаҗәеп иде, һәрберенең фикере бер җиргә төбәлгән иде, мәктәпләрне ислах итү, әдәбият тәшкил итү, халыкта мәгърифәт тарату эшләрендә голамә вә шәкертләрнең фикерләре икегә бүленгән иде. Беренче кисем — фикерсезләр, болар күп сөйләшми иде. Икенче кисем — фикерлеләр, бу соңгыларның һәрберенең фикере бар иде. Халыкта уку–укыту күтәрү, мәгълүмат нәшер итмәк, халыкның күзен ачмак вә буңа кирәк булган акчаны милләтнең байларыннан алмак иде. Ул вакытта милләтнең алга киткән кешеләренең һәрберсендә милләтемезнең тәрәкъкыят миллиясе өчен кирәкле акчаны байлардан алмак фикерендә кабул ителгән һәм киң таралган иде.

Ул вакытта һәркем, милләтемез голамәләренең мәгънәви һәм байларыбызны матди ярдәме белән тәрәкъкыя итәчәкбез дип ышана иде. Бу фикерләрне милләтнең байлары да кабул итә иде. Ихтыяҗны яхшылап аңлатканда һичбер вакыт булышудан баш тартмыйлар иде.

Никадәр мөкатдәс заман иде. Ул заманда никадәр газиз бер хәрәкәт миллиямез бар иде! Бу хәрәкәт миллиямез акрынлап үсеп барганда гына, кинәттән, мөселманнарның хәтеренә дә килмәгән

япон сугыш игълан итте. Соңра бер заман Октябрь манифесты чыкты. Хөрриятләрдән бәхәс чоры башланды: сөйләшүләр, сәяси җыеннар, митинглар хасыйл булды, әллә никадәр гәҗитәләр, журналлар чыкты, һәркем теләгенне яза, сөйли башлады. Табигый, мөселманнар да хөррият тарафдарлары булдылар, бу мөселманнардан һәммәсе дә: бай да, шәкерт тә, мужик та, хөррият фазыйләтләрен аңлый иде. Мөселманнарның фикере, хөррият тарафдарлары булудан максудлары, хәрәкәт миллияне хөррият сәясендә иркенләп үстерү иде. Әлбәттә, хөррият кирәк дигәндә мөселман, бары тик милли эшләре өчен кирәкле хөрриятне уйлыйдыр иде. Әле эшләр болай барганда ярый иде.

Төрле гәҗитәләр чыкты, алар төрле фиркаләргә ия булып, төрле–төрле мәсләккә хезмәт итә башлады, гәҗитләрдә язылган фикерләр бер–берсенә охшамый, бер–беренә каршы. Бер гәҗит мактаган нәрсәне, икенчесе яманлый иде. Бу гәҗитләрдә әллә кайчаннан бирле милләт арасында мөкатдәс күрелеп килгән нәрсәләрдән көлеп язулар күренгәли башлады. Әүвәлдән хезмәт итеп килгән кешеләрдән көлүләр башланды.

Хәзер милләткә әһәмият бирмәгән, аның турыда язмаган фикерләр юк иде. Бу гәҗитәләрдә халкымызның гомуми тенденцияләреннән, теләгән нәрсәләреннән көленә башланды. Милли омтылыш бер артта калганлык, дип караучылар күбәйде. Аз заман эчендә бунларның фикерләре аз мәгълүмәтле, бөтенләй тәҗрибәсез, ләкин саф яшьләр арасында бик тиз таралды. Яңа фикерләргә яңа кергән яшьләр гаять зур ышану һәм кыюлык белән һәр тарафта кычкыра башладылар. Шул әйткән мәсләкләрен аңлауларына караганда боларның кыюлыклары зуррак иде. Яшьләр бик каты сөйләшә–кычкырыша башлады. Бу саф яшьләрнең гайрәтләре, бәхәсләре яшь булмаган кешеләргә дә тәэсир итте.

Бу хәлне күреп, бер дә хөррият матбугатка өйрәнмәгән безнең халкыбыз бөтенләй шашты. Мөселманнар арасында фикерләр бөтенләй чуалды, бичара милләтемез нигә ышанырга белми башлады. Халыкның күпчелеге бу мәсьәләдә бер хата булганны томанлы гына сизсә дә, бердән, моның хатасы кайда икәнне әйтә алмый иде әле, икенчедән, бу кадәр яшьләргә каршы чыгып, аларга каршы барырлык көч юк иде. Алай булса да, берничә өлкәнрәк адәм-

нәребез бу эшкә, бу хаталы хәлгә чыдый алмадылар, халыкка чыгып кычкырдылар: җәмәгать, бу егетләр хата итәләр, хәрәкәт миллиямезне онытып, бу мәсләккә сугылсак, без бетәчәкбез. Куәтләремезне, дәрәҗәмезне тәрәкъкыебыз дәрәҗәсенә хас булмаган бер мәсләккә сарыф итмик. Безгә куәт милли эшләремездә, миллиямезгә хезмәт өчен лязем дер, диделәр. Ләкин ул заманда бу адәмнәргә сүзләрен ишеттерү бик читен иде, чөнки яңа мәсләк егетләре үз фикерендәге хаталарын күрсәткән кешеләр өстенә ябырылды. Шулай да курыкмаган берничә кешеләребез булды. Алар хәрәкәт миллиямезне өстерәп агызып китеп барган бу миллиясез мәсләк дулкыннарына каршы күкрәкләрен куйдылар.

Инде бүген бу мәсләк дулкыннары акрын–акрын ага башлады. Ташу тукталды, гөрләвек булып ага башлады. Бәрәкәт бирсен, инде бу ташулар хәрәкәт миллиямезне агызып китә алмады. Бары тик бу хәрәкәтнең табигый барышын туктатып тора гына алды. Бу милләтсезлек ташуы туктады. Биналарның агып китүе хәвефе бетте.

Миллият бинасын төзәргә уйлаучыларга эшкә тотынырга вакыт җитте. Милләтсезлек җиле туктады, буран тынды. Буран башлаганда миллият хәрәкәте каты булмаган, бөтен ватандаш милләтләр бу бураннан бик каты милләтче булып чыктылар – моннан ике сәнә элек милләтсезлек җиле никадәр каты булса, ватандаш милләтләрдә бүген милләтчелек җиле шул кадәр куәтләнде.

Мин дә бик каты милләтче булдым. И, ул борын заманда милли хәрәкәтне онытып торган гайрәтле башлар, килегез, зинһар, кайтыгыз, куәтегезне, гайрәтегезне милләтемезнең гыйлем вә мәгарифендә, сәүдә вә дәүләт тәрәкъкыятендә сарыф итегез. Эш күрсәтерлек яшьләребез күп юктыр, һәрберегез милләткә кадерлесез.

«Йолдыз». 1908 ел, 228 сан, 17 февраль.

*2. Ике төрле милләтчелек*

Милләт фикере. Аның истигбалы. Ике төрле милләтчелек: мәхкүмә (буйсындырылган) милләтләрдә милләтчелек, сәяси хөррият булган мәмләкәтләрдә милләтчелек көрәше. Русиядә националистлар ни телиләр, Русиядә вак милләтләр ни диләр.

– Садри әфәнде, бер яктан, рус милләтчеләре дип, безнең, гәҗитәләребез рус националистларына кырын күз белән карыйлар, дип сорадылар. Хәлбуки, шул ук гәҗитләр үзебездәге милләтче кешеләрне мактыйлар. Милләтне яраткан, милләтенә хезмәт итәргә тырышкан кешеләрне мактыйлар. Бу ике халыктан ике милләтче фиркагә ике төрле карау, сезнеңчә ничек була, бу тигезлек уламы? – дип сорадылар. Бу егет мин яраткан саф рухлы бер яшь кеше булганга, бер дә иренми бу хакта язып җавап бирергә туры килде. Бу язу файдасыз булмас, бәлки бу егет шикелле бу хакта аңлап җитмәгән башка кешеләр дә бардыр, дидем дә яздым.

Бу соңгы унтугызынчы гасыр тарихында иң мөһим роль уйнаган фикер, һич шөбһәсез, милләт фикере булды. Бу гасырның соңында социалистның фикере дә зур урын тота башлады исә дә, ул фикер гасыр башында юк иде. Аның хәзергә кадәр дә һәр җирдә бер дәрәҗә мөһим урын алганы юк. Хәлбуки, милләт фикере бөтен җир йөзендә бер дәрәҗә таралган бер куәтле фикердер, яхуд фикер – куәттер. Соңгы гасырдагы тышкы сәясәттә вә эчке сәясәттә хөкүмәтләрнең вә мәхкүмә милләтләрнең, иң күп куәт сарыф иткән, иң күп әһәмият биргән мәсьәләләре милләт мәсьәләләредер. Буны инкарь итеп булмаган бер хакыйкать дип беләм. Моннан илле еллар элек таркау италиялеләрнең зур Италия вөҗүдкә (барлыкка) китерүләре унтугызынчы гасырда булды, немецлашкан, бетеп барган чехларның терелүләре дә бу гасырда тәмам булды. Төркия кулында тәмам түбән хәлгә төшеп беткән серб кавеменең сәяси хәяткә чыгуы бу гасырда булды. Болгар исемле онытылган болгар милләтенең терелүе дә унтугызынчы гасыр нәтиҗәседер. Бу вакыйгаларның һәрберендә милләт фикере иң зур вакыйга булды.

Милләт фикере нинди зур вакыйгаларда гамәл булганын санап бетерү мөмкин түгел. Әле һаман да ул үзенең хөкемен йөртеп тора. Мин уйлыйм ки, истикбалда һәм бик озак заманнар, бик күп гасырлар эчендә милләт фикере кешелек тарихында хөкүм фикерләрдән бере булачактыр. Моның рухи, икътисади, иҗтимагый бик күп сәбәпләрен тикшерү минем мәкаләмнең эше түгел.

Милләт фикере һәр вакыт ике төрле кавемнәр тарафыннан ике төрле аңланып киленер. Бу көндә һәм шулай ике төрле аңлау дәвам итә. Милләтне (милләтчелекне) хаким, сәясәтче мөстәкыйль милләтләр, үз милләтенең телен, мәдәниятен, ысул хәятен башка, үзенә мәхкүмә милләтләргә кабул иттерергә тырышу дип аңлыйлар. Никадәр зур милләтләр ачык билгеле булган бу теләкләрен яшерергә тырышсалар да, сәяси мөстәкыйль милләтнең, үз милләте фикерен мәхкүмә милләтләргә кабул иттергә тырышудан гыйбарәт булмый калмыйдыр. Мөстәкыйль милләтләрдә милләтчелек һәрвакыт агрессивный була. Ул башканы үзенә охшату нияте белән яна.

Мәхкүмә милләтләрдә исә милләт фикере бөтенләй башка рәвештә аңлана: мәхкүмә милләтләрдә миллият фикере ата–бабаларыннан калган газиз тел, мөкатдәс, бер кадерле гореф–гадәтләр, өйрәнгән тормыш ысулларын сакларга тырышудан гыйбарәт – кыскасы, бабаларыннан мирас булган, үзләре өчен гарәби бер тормыш рәвешләрен, яшәешләрен саклауны фидакаренә теләүдән гыйбарәт була. Бу миләттә башкаларны үзенә охшату, тәмсил итүне теләү кайда! Ул үз милләтенең башкаларның эчендә эреп, югалып китүеннән саклый алса, шуңа куана, шатлана. Мөстәкыйль милләтләрдә миллият фикере һөҗүмдер, ә мәхкүмә милләтләрдә милләт фикере дә кыерсытылган, басырылган.

Бу ике милләтнең беренчесе, шөбһәсез, кешелек яшәеше ноктасыннан караганда файдасыздыр. Икенчесе исә, хәят иҗтимагыя (җәмгыять тормышын) законын өйрәнү җәһәтеннән зарарсыз, (башка милләтләргә) башкасы җәһәтеннән караганда гали, мөхтәрәм бер милләттер. Ләкин, бу ике төрле милләт фикеренең икесе дә гасрымызда ачык дәрәҗәдә зур роль уйныйлар, һәр икесе дә сәяси вакыйгаларда мөһим иҗтимагый фактлар, ерактан бул-

са да, үзләренең тәэсирен сиздереп торалар, һәр икесе дә ачык дәрәҗәдә гамәлдә. Әгәр дә Англия, Австрия мәҗлесенең хәятенә, аларда булган бәхәсләрне дикъкать белән карасаң, күреләчәк ки, бу диспут–бәхәсләрнең очы милләт мәсьәләсенә барып төртелми калмыйдыр. Мәсьәләне мәйданга йә хаким милләт, йә мәхкүмә милләт чыгара.

Сәяси хөррият камил булган мәмләкәтләрдә, мәҗлесләрдә, диспут–бәхәсләрдә югарыда сөйләнгән ике милләт бер–бере белән бик ачык сугышалар. Берсе дә үзләренең максудын яшерми.

Ләкин сәяси хөррият камил булмаган мәмләкәтләрдә бу ике милләтнең сугышулары ул кадәр заһир булмый (күренми, беленми). Хаким милләт үзенең милләтчелек фикерен, башка милләтләрне тәмсил сәясәтен, башка милләтләрне үз эчендә эретү теләген парламентка салмаенча гына хәл кылырга тырыша. Хөррият булмаган мәмләкәтләребездә мәхкүмә милләтләр исә бу хөкүм (хаким) милләт тарафыннан тәмсил сәясәте йөртелгәнен, үзенең милләтенә һөҗүм булганын, милләтенә бу сәясәттән киләчәк нәтиҗәләрне кирәк күрми, сизми, йә сизсә дә, хөррият булмагач, кулында моңа каршы бер чарасы да булмый.

Бу тарафтан хаким милләт милләтчелеген мәйданга кую өчен фәрманнар, әмерләр чыгара, ә икенче тарафтан (мәхкүмә милләтләрдән) моңа каршы торырга үтенечле гаризалар бара.

Ләкин, табигый, меңнәрчә гаризадан бер фәрман көчлерәктер. Мең гаризага караганда бер фәрманың булса, шул җитә. Бу хәлләр Англия, Австрия, Төркиядә нәкъ шушы рәвештә булып үтте.

Русиядә бер дәрәҗә хөрриятләр дөньяга чыгып, Дума булгач та, бу хәлнең асылы мәйданга чыкты. Ягъни ике төрле милләтчелекнең көрәшүе Русиядә дә күренә башлады. Дума булган күп вакытта ачыктан–ачык Думада «милләтче» дигән рус фиркасе мәйданга чыкты. Бу фирка мәйданга чыккач та, үзенең максатын, барачак юлын яшермәде, аларны бер җөмлә белән бөтен галәмгә фаш итте: «Русия руслар өчендер», диделәр. Үткән III Думада болар, куәтле партия булып, үзләренең шушы сәясәтләрен, ягъни рус булмаган Русия халкына Русиядә көн итү русларга гына мөмкин дигән политиканы йөртә башладылар. Мондый бер

сәясәт йөртеләчәкне күрер—күрмәс, Русиядәге мәхкүмә милләтләрдә бу сәясәтнең үзләренең милләтләренә никадәр дәһшәтле бер һөҗүм булачагын тиз аңладылар да көрәшкә башладылар. Шулай итеп, Русиядә вә әүвәл Думада да, вә аннан соң бөтен мәмләкәттә милләтчелек мәйданга чыкты да көрәшә башлады.

Бу яктан рус националистлары: «Мәхкүмә милләтләр безнең кебек торсыннар, мәктәпләрендә рус телендә укытылсын, үз телләрендә гәҗите булмасын, үзләренә махсус җәмгыятьләр ясамасыннар, әдәбиятлары тәрәкъкый ителмәсен, нинди генә аларда дөньяда аерым бер милләт яшәтә торган нәрсә бар, болар акрынлап бетерелсен, бу кавемнәр үзләре дә акрынлап руслашсыннар», диләр. Националистлар бары дингә генә тимиләр. Диннән кала барлык милли нәрсәләргә каршы килеп бәреләләр. Аларча, идеал киләчәктә, бер вакыт бөтен Русия бер телдә сөйләшә торган, бер рәвештә яши торган халыктан гыйбарәт булачактыр.

Моңа каршы мәхкүмә милләтләр болай диләр: «Безнең тарихыбыз тирән, караңгы заманнардан бирле бер халык, бер милләт булып килгәнбез, безнең аерым бер телебез бар, матур җырларыбыз, көйләребез бар, телебездә әдәби нәрсәләр бар. Дөньяга карауда халкыбызда, рухыбызда башкалардан бер аерымлыгыбыз бар, үзебезгә махсус гадәтләребез бар. Ләкин бу нәрсәләр безгә барысы да газиз, мөкатдәс, якын. Безнең моннан һичбер төрле аерыласыбыз килми, боларны сакларга без бөтен гайрәтебезне сарыф итәргә әзер. Боларның бетүе безнең рухыбызның, мәүҗүтебезнең, (яшәешебезнең) җимерелүе, боларның бетүенә разый булу — мәгънәви үлүгә разый булу ул. Бу безнең өчен милли бетү. Без моңа һичбер вакыт разый булмаячакбыз. Без хәятне миллиятебез белән бергә булганда гына кабул итә алабыз, без башка кавемнәргә, хосуса, бездән мәдәниятлерәк милләтләргә хөрмәт итәбез. Алардан яхшырак нәрсәләрне алабыз. Ләкин катгый рәвештә аларга охшап, алар арасында эреп бетәргә теләмибез.

Бу, безне үзләренә охшатып, безне югалту фикере, ассимиляция сәясәте безгә әҗәл юлы булган шикелле, безне үзенә охшатырга теләгән кавемнәргә дә файдалы түгел, юк урынга куәт сарыф итү генә, диләр. Үзе танымаска теләгән бер милләтне кайсы милләтнең җир йөзеннән югалтканы бар? Сездә бетерү, югалту сәясәте

куәтләнгән саен, бездә яшәү куәте, милләт булып яшәү арзусы (теләге), үз–үзебезне саклау фикере куәтләнәчәктер, диләр.

Шушы юлда ике төрле милләтчелек, һәр икесе хәзер дә үзләренең юлларын яшерми Европада сугышалар. Бер дәрәҗә хөррият мәйданга чыкканнан бирле, Русиядә дә ике төрле милләтчелек пәйда булды. Безнең Русиядә дә әүвәлгечә бу ике төрле милләтчелек яшерен пыскып ятмыйлар, үзләрен белдерәләр, безгә һәм вак милләтләргә:

– Син акрынлап бет, – дигән фирка чыкты. Икенче яктан:

– Юк, без бер дә бетәргә теләмибез, бездә–бар булырга, сездә безне бетерергә теләүдән кырык өлеш катырак булган бер теләк, бер хис бар, – диләр.

Менә бу ике төрле милләтчелек, шулай, безнең Русиядә дә бер-беренә каршы фикерен яшерми, кычкырыша башлады. Бу көрәш моннан соң һаман куәтләнә генә барачактыр.

Бу көрәштәге поляк, яһүди, әрмәннәр кебек милләтләр өчен мин хафаланмыйм. Алар көрәшә белер һәм беләләр.

Минем, иң хафаланган ноктам – безнең халкыбыз: бу көрәш мәйданга чыккач, безнең хәл ничек булып бетәр, дим. Без дә башка вак милләтләр шикелле националист фиркаларның безгә булган һөҗүменә яхшы каршы тора алырбызмы икән, дим.

Бу хакта башка сөхбәтләремдә, бәлки, бер вакыт озын җавап бирергә дә тырышырмын, хәзер шуны гына әйтәм: минем үземдә безнең бер милләт булып яшәячәгебезгә бик тирән бер ышану һәм моны бик каты бер теләү бар. Мин уйлыйм: бу ышану, бу теләү милләтнең һәркайсында да шул дәрәҗәдә үк каты урнашкандыр.

«Йолдыз». 1913 ел, 1053 сан, 1 ноябрь.

*Фатих әфәнде Кәримов*

Моннан берничә көн микъдар сәфәргә узышлый бик аз вакытта гына Петербургта туктаган идем, бер көн кич фикердәш, мәсләктәш кешеләрдән берничә аркадаш белән утырган мәҗлесебез, рухлы бер җәмгыятебез булды. Бу җәмгыятебез шундый күңелле, җылы рухи шатлык, фикерләргә өмет бирә торган сәнәләр үткәч

тә сагыныла торган бер сөхбәт иде. Шул газиз Русиянең парланып торган самавары әтрафында якын яки мәсләктәш кешеләрең белән ачык, самими, шад яки әдәби сөхбәтләргә ни җитә! Мондый мәҗлесләрдә, мәгълүм ки, сөйләшү өчен тема итеп милли мәсьәләләр, хәят милләттә мөһим соңгы вакыйгалар алынадыр. Сүз чыгып, милли кешеләребездән бере Фатих әфәнде Кәримовның хезмәт эшчәнлегенә унбиш ел була, диештек. Бу мөнәсәбәт илә милләтебезне аңлаганнары тарафыннан Фатих әфәнденең хезмәтенә унбиш ел уңае белән аңа лаек бер бәйрәм ясау лязем икәнне әйтәбез. Ләкин инде юбилейга вакыт бик аз калды, шунлыктан аңа милләт исеменнән рәхмәт әйтеп, эшчәнлегенә егерме еллыгын үткәрү уе белән калабыз. Ләкин унбиш еллык хезмәт миллия яныннан тавыш–тынсыз гына узып китү мөмкин түгел.

* * *

Мин хөрмәт иткән каһарманнарның беренчеләреннән бер кеше. Мин Фатих әфәндене шулай дип тәсдыйк итәм һәм, минем бу фикерем белән хакыйкатьпәрвәр, саф калебле кешеләрнең дә Фатих әфәндегә теләкләрен белдерәм. Фатих әфәнде кешегә фәкыйрь бер заманда бик кирәкле бер кеше булды. Бер милләт эчендә бер–бер кеше эш күрим, хезмәт итим, файда итим дисә, моның өчен мәгълүмәт сахибе булу һәм хезмәт итәргә теләү генә җитмидер. Моннан башка бер милләткә табыну да, бер җәмгыять бәшәриягә хезмәт итә алыр өчен берничә мөһим сыйфатларга ия булу лязем-дер. Бу сыйфатлар исә мәсләкле булу, җитди фагыйләт мәсләктә була. Бу кыйммәтле сыйфатлар барсы да бер кешедә, ә бит алар аерым–аерым да бик сирәк очрый торган нәрсәләрдер.

Әгәр дә бер кешедә боларның һәрбереннән бер өлеш булса, ул кешенең мөнәсүп булган милләтенә нинди генә булса да бер бабта зур хезмәтләр итәчәге, итә аласы шөбһәсездер.

Фатих әфәнде бу сыйфатлардан зур өлеш алган бәхетле бер кешедер: ул әкмал тәхсил итәр–итмәс үзенең тотачак мәсләкне тәгаен итте – ягъни үзенең рухиятенә ихтыяҗ фагыйләтен нинди юлда сарыф итәсе килә, нинди кыйблага карап хезмәт итүне күңеле тели.

Бу исә бик зур эш. Дөньяда нә кадәр кеше үзенең урынын таммый.

Мәсләк итеп Фатих әфәнде милләт вә милләтнең тәрәкъкыен алды. Унбиш сәнәләр кадәр элек бу хәрәкәт милләтемезнең бик башы айлары иде. Милләткә хезмәт итү, итәргә теләү, милләткә хезмәт итүне хәятта мәсләк итеп алу ул заманның безнең халыкка бүләк иткән берничә дистә егетләрнең һәрберендә фидакарьлек дәрәҗәсенә кадәр барачак бер әмәл, игътиразый кабул итмәс иҗтимагыя иде.

Фатих әфәнде шул унбиш–егерме каһарманнарыбызның берсдер һәм шулар арасында беренчеләреннәндер. Халкыбыз бер милли укытучылар хәзерли торган югары уку йортына ия була алмыйча зар елап йөридер.

Милләт яшьләрендә фикер уяту ноктасыннан «Шәкерт вә студент» тарихи бер әсәрдер. «Авыл мәктәбе», «Европага сәяхәт», «Кырымга сәяхәт» һ.б. Фатих әфәнде үзенең мәсләгендә моңарчы күрелмәгән гамәл белән хезмәт итте. Заман кичкән саен Фатих әфәнде мәсләгеннән язу, салулау түгел, ныграк ябыша бара. Мәсләкне аңлауда, мәсләгенә муафыйк юлларны карыйк.

Фатих әфәнде 1905 елның бураннарында да адашмады, ихтилал томаннары эчендә дә юлдан сапмады.

Ләкин бер мәсләк ясап та шул мәсләктә фагыйләт күрсәткән вә шул фагыйләтен бер елдан артык дәвам иттергән кешеләр санап чыгарлык аз.

Мин бу язмамны Берлинның «Виктория» кофеханәсендә яздым. Тәрәзәдән бай, матур төзек урамнар, мал белән тулы кибетләр, сау–таза кешеләр күренә, кая карасаң, анда байлык, дәүләт вә куәт. Күңелемә бу зур мәдәниятне, бу дәүләтне немецлар кайдан чыгардылар, дигән сөаль килә. Немецлар алдында тез чүгәсе килерлек бер мәдәният мәйданга чыгарганнар.

Милләт өчен иң зур, файдалы хезмәте – (Ф.Кәримовның – Ф.Г.) гәҗитчелек хезмәтедер. Әгәр кеше безнең телдә бер генә хәфтә гәҗитә чыгарып, файдалы фикерләр таратса, ул кешегә мин дан укылырга тиеш дип уйлыйм. Фатих әфәнде биш–алты сәнәдән бирле бер гәҗитәнең һәм дә милли гәҗитәләребезнең иң яхшыларыннан беренең башында тора.

«Вакыт» кебек бер гәҗитәнең милләткә иткән хезмәтен тәкъдир итүне укучының үзенә тапшырам.

Фатих әфәнденең сәясәттә тоткан юлы хакында төрле кешедә төрле фикер булырга мөмкин. Ләкин милләт, вә монафигы милләт ягыннан каралса. Һәркем Фатих әфәнденең гәҗитчелектә, сәясәттә тоткан мәсләгендә хезмәт иткәнен тәсдыйк итәр.

Фатих әфәнде фәкыйрь бер милләттә, кешегә фәкыйрь бер заманда кирәкле бер кеше булды.

Хезмәт итәм, диде һәм итә алды. Эшләре нәтиҗәле булды. Һәркайсыбыз бу кешегә унбиш сәнә узып барышлый бер самими рәхмәт, саф бер тәшәккер белгертергә бурычлымыздыр.

Фатих әфәнде! Сезнең бөтен күргән мәшәкатьләрегезне күз алдына китереп, кулыгызны кысып, гаять самими бер сурәттә сезне тәбрик итәм.

Сезнең хәятегезнең һәрбер сәхифәсе пакъ, ак, һәрберсе берәр хезмәт белән зиннәтләнгән. Матур яшәдегез, кордашым! Милләт файдасы өчен моннан соң да озын–озак яшәгез. Тәкрар итәм: яшәгез, брадәрем!

Берлин. «Виктория» кофеханәсе. 5 сентябрь, 1911 ел.

«Йолдыз». – 1911, 22 сентябрь.

*Әмәлләр* остазы*

Исмәгыйль бәкнең вафаты сәбәпле хис иткән авыр вә тирән кайгымны тышка чыгарасым килә, ләкин, калебемнән мәгънәви яшьләр акканда, газиз остазымны югалту сәбәпле рухымның югалтулары һичбер төрле сүз вә фикер рәвешен алмый. Хәзер дә хис иткәнем бары бала кебек, иң газиз, иң мөкатдәс бер нәрсәсен гаип иткән бер бала кебек егламак арзусдыр. Ләкин икенче тарафтан беләм, бу кафи түгел, остазның җылы җеназасы алдында бу хәл миндә тудырган хисләрне гади еглау белән түгел, бер самими фикер, ачык сүз белән тәгъбир итәргә тиешмен.

Ләкин ни әйтсәм дә, һәр сүз, һәр җөмлә Исмәгыйль бәкнең минем каршымдагы зурлыгына, аның тарихи эшләренең бөеклегенә, минем аңа булган чиксез ихтирамыма чагыштырмача бик

* өметләр

кечкенә, бик баналь, бик төссез күренәдер. Гаспринский кем? Ул дөньяда ниләр эшләде?

Менә әгәр сүз белән моны белдерү, тәкъбир итү мөмкин булса иде, мин шушы сөальләргә җавап бирергә тырышыр идем. Бу хакта хәзер шуны гына әйтә алам:

Гаспринский һәрберебезнең фикерендә, һәрберебезнең ихтирам пантеонында иң бөек урын алган бер кешедер. Һәрберебезнең офык миллиясендә нурани бер ноктадыр. Һәрберебезнең фикере тарихында иң мәгълүм бер кагыйдәдер.

Эшләгән эшләре?

Әнә шул, ихтыярсыз, һәрберебезнең самими ихтирамын үзенә җәлеп иткән, исеме зекер ителгәндә һәрберебезнең авызына «бөек» кәлимәсен китергән гамәлләредер.

Хакыйкатьтә, уйлап карагыз, Исмәгыйль бәктән бөек безнең күпсанлы татарның кеме бар?

Русия дәүләтенә кушылганнан бирле ничә гасырлар безнең төрки кавемнәр, мәдәнияттән ерак, мәгарифсез, зыясыз, караңгы, күңелсез бер хәят белән яшәделәр.

Урманнарда, степьләрдә таралган төрек татарлары, нурсыз, шадлыксыз, моңлы бер хәят эчендә гасырлар кичерделәр. Шаннар (даннар) онытылган, хәл шадлыксыз, истикъбал ямьсез иде. Алда бер шадландырган бер максат юк иде. Кыскасы, безнең Русия төрекләре ничә заманнар рухсыз, шадлыксыз, чөнки имласыз, идеалсыз бер хәят белән яшәделәр. Менә татар хәятенда шул дәвергә, ниһаять, яңа бер дәвер башлауына сәбәп булган кеше — Исмәгыйль бәк Гаспринский булды. Гаспринскийның мәйданга чыгуы, аның мөнбәр тәгълиме булган «Тәрҗеман»ның зоһуры Русия мөселманнарында яңа хәятнең башыдыр. Беренче буларак мәгънәсез хәятыбызга бер мәгънә биргән, максатсыз яшәешебезгә иҗади әмәлләр иткән, шадлыксыз тормышыбызда өмидләр тудырган кешебез Исмәгыйль бәк булды. Хәзерге көндә хәят миллиябездә күңелебезгә шатлык биргән кайсы гына хәлне, вакыйганы тикшереп карасагыз да, аның иң башында Гаспринский булганын күрересез. Вакыты килер, моны тарихчыларыбыз документлар белән исбат итәрләр.

Зур бер кавемнең хәятында бер кеше яңа бер дәвер ясасын да, кайгылы, моңлы яшәгән бер милләт эчендә өмидләр тудырсын да, гасырлардан бирле өметсезлеккә өйрәнгән бер милләткә идеаллар ясап бирсен дә, зур бер кавемгә хур Исрафилдан өреп җан керткән кеби, хәят кертсен дә, шул кешенең әһәмиятен, тарихи ролен тел белән аңлат, каләм белән яз, имеш. Бу мөмкин түгел. Гаспринский шикелле кешенең хезмәтләрен, уйнаган ролен хис итәргә мөмкин, ләкин тәүсиф, тәгъриф итәргә мөмкин түгел.

Мин шуңа моннан ваз кичәм. Минем бүген әйтеп каласым килгән шул гына: сөекле остаз Исмәгыйль бәк, син бу дөньяны ташлап китеп калебләребезне яраладын, ләкин син мәгънәви үлмәдең, синең исемең гомуми бер ихтирам, бер олылау илә югалмас хәлдә мәңге яшәячәктер. Нәшер иткән фикерләрең бервакытта да тәэсирләрен гаип итәчәк түгелдер, яшәячәктер. Син чәчкән фикерләр, дөньяда татарлар яшәгәндә аларга тәрәкъкыят юлында бер конституция булачактыр. Син йокы хәлендәге татар балаларына бер идеал бирдең. Үле хәлендәге бер милләткә милли вөҗдан бирдең. Син үлдең, газиз остазым, әмма яшәячәксең.

Заманында лаек илә тәкъдир ителмәгән 30 сәнәлек бөек хезмәтләрдән, фагыйләтләрдән арган рухыңа кабереңдә рәхәт булсын. Без исә сиңа дөньяны рәхәт итә алмадык. Кулыбыздан килгән бары–җәннәтнең сезгә рәхәт булуын теләүдер. Каберегезнең туфракларын, дини гадәтләребезчә бер ихтирам, тирән бер хөрмәт белән үбәм.

Сиңа (үзеңә) җәннәт, сиңа оҗмах булмаган бу лаексыз дөньяда, син остаз, без – татарларга бу дөньяны үзгәртергә, рәхәт итәргә теләдең.

«Йолдыз». – 1914, 14 сентябрь.

*Милләткә хитап*

Милли–мәдәни мохтариятне вөҗүдкә чыгару хәятеннән 22 нче июльдә Казанда дәхли Русия мөселманнары өчен зур бер вакыйга булып үткәне һәркемгә мәгълүм. Мөселманнарның берләшкән өч съезды бер авыздан дәхли Русия мөселманнарына хәзердән үк милли вә мәдәни мохтариятне гамәлгә куя башларга карар бирде.

Бу мохтариятне вөҗүдкә чыгару юлларын күрсәтүне шул көннәрдә Казанда җыелган Русия мөселманнарының икенче гомуми съездына тапшырды.

Гомуми съезд бу мәсьәләне карар өчен махсус бер секция ясады.

Шундый резолюция кабул ителде. Мохтариятне хәзердән гамәлгә кую хәстәрен күрү өчен 12 кешедән торган бер хәйәт сайланды.

1) Милләт мәҗлесен җыю.

2) Гомуми мохтариятне гамәлгә кую шартларын булдыру.

Хәйәт алдында зур эшләр, зур хезмәтләр тора. Бу эшләр безнең тарихыбызда мисалы күренмәгән эшләр. Хәйәт мохтариятне вөҗүдкә чыгару өчен бөтен көчен сарыф итәчәк. Ләкин хәйәтнең эшләре, хәрәкәтләре милләт тарафыннан яхшы каршы алынып, һәр җирдә хәйәт үзенең эшләренә милләт тарафыннан хупланып торса гына мохтарият мәсьәләсе муафикият белән мәйданга чыгачактыр. Милләтләрнең искедән теләгән бер мөкатдәс теләген вөҗүдкә чыгару бөтен милләтнең бергә хәрәкәте, бөтен милләтнең бу эшкә матди вә мәгънәви ярдәме белән генә мөмкин булачактыр. Шуның өчен, әгәр милләтебез безгә тарихның киң вә якты юллар ачылган бервакытта мохтариятне вөҗүдкә чыгаруны теләсә (тели, әлбәттә) бу эшләрне сайланган 12 кешегә генә ташлап куймаска тиешләр. Шунын өчен без бөтен милләтнең бу 12 кешегә ярдәм итүен үтенәбез. Ике төрле ярдәм кирәк. Берсе – мәгънәви, икенчесе – матди. Мәгънәви ярдәм һәр җирдәге милли тәшкиләтебезнең, шураларыбызның, комитет вә бюроларыбызның үзләренең эшләрен мохтарият бурычларына мәслихәт вә киңәшләренә муафыйк йөртүе белән булачактыр. Моннан башка халкыбызның һәрбере үзенең теле вә фигыле белән, сүзе вә каләме белән һәр җирдә мохтарият фикерен халыкка таратырга, урнаштырырга тырышуы белән булачактыр.

Мохтарияткә матди ярдәм исә аны вөҗүдкә чыгару өчен кирәк булган расходларга акча бирү белән буладыр. Киләчәктә безнең мохтарият нигезенә корылган оешмаларыбызны яшәтер өчен безгә ике төрле юлдан акча килеп торачак. Бер яктан мәмләкәт хәзинә-

сеннән һәм шәһәр вә земстволар кассасыннан һәр ел мәгълүм микъдарда акча милләт эшләре файдасына алынып торачак. Икенче тарафтан исә милләт өстенә салынган милли салым (налоглардан) килеп торачак. Хәзергесе вакытта мохтарият кулында бер тиен дә акча юк.

Зур милләтнең зур эшләрен акчасыз алып барып булмаячак. Милләтебез алдында зур мөмкинлекләр ачкан тарихның бундый якты көннәренә яңадан кайту ихтималы ерак, милләтебезгә үз хәйәтен, үз тормышын үзе теләгән юлга салырга, теләгән рәвештә оештырырга хәзер генә мөмкин. Бу көндә эшләнгән эшләр, вөҗүдкә чыгарылган хәлләребезгә хокук булып калачактыр. Хәзер тырышсак, моңар кадәр кысылып—изелеп килгән газиз милләтебез киләчәк гасырлар буенча ирекле, үз эшләрен үзе йөртү хокукын алып калган, дөньяда яшәргә хаклы каһарман бер милләт булачактыр. Әгәр буны эшли алмый калсак, бу нинди үкенеч вә нинди хәсрәт булачак.

Бүтәннәр белән барәбәр Русиядәге олуг төрек—татар балаларына беренче туган бу якты көннәрдә, зинһар, һәркайсыбыз бөтен башка нәрсәләрне онытыйк та бергәләшеп һәрберебез өчен гомумнең идеалы булган Милли мохтариятне вөҗүдкә чыгарыйк, киләчәктә озын гасырлар буенча халкыбыз ирекле, мөхтәрәм бер милләт булып яшәсен. Әгәр бу эшне эшләп калсак, һәрберебез тынычлап үләргә хаклыбыз. Гомеребезнең ахырында яшь буын бездән: «Сез, әти, сез, бабай, гомерегездә нинди зур эшләр эшләдегез?» дип сорасалар, сезнең һәркайсыгыз: «Без, улым, шушы шималдагы ислам динендәге төрек балаларына милли ирек, Милли мохтарият мәйданга чыгардык», диярбез. «Бу көндә сезне шатландырган, һәр җирдә ялтыраган милли мәктәпләр, милли китапханәләр, милли университетлар, милли голамәләр — болар һәрберсе 17 нче еллардагы безнең буынның иҗтиһадларының җимешләредер. Бу эшкә без, ул вакыт кешеләре, һәрберебез:баебыз, фәкыйребез, укыганыбыз, укымаганыбыз — барыбыз катыштык. Кайсыбыз матди, кайсыбыз мәгънәви хезмәт иттек, диярбез. Бу хис, бу фикер безнең вөҗданыбызны рәхәтләндергән шикелле, яшь буын балаларыбызнын калебләрен мөһим милли хисләр, горурлык белән шатландырырлык

эшлик, зинһар, милләттәшләр! Зур көннәр, зур теләкләр милләттән зур эшләр телидер! Яшәсен милләтебез! Яшәсен Мохтарият!

Мохтариятне вөҗүдкә чыгару комитетының рәисе: Садри Максуди. Сәркатип өчен: Габдулла Шнаси.

Уфа. Комиссия по созыву первого Мусульманского Национального совета. Председатель С.Максудов.

«Йолдыз». – 1917, 14 август.

*Эчке Русия мөселманнарының Милли идарәсе тарафыннан халыкка хитап.*

Русиянең иске идарәсе (самодержавиесе) вакытында иң изелгән, һәрбер хокуклары чикләнгән бер милләт булса, шөбһәсез, безнең мөселманнар иде. Рус законының күп матдәләрендә руслык, христианлык файдаларын гына күздә тотып, без төрек–татар, мөселманнарның файдалары күзгә алынмый, алар һаман кысыла, хокуклар юкка чыгарыла иде. Мөселманнарның мәчетләре, мәктәп–мәдрәсәләре тәмам хокуксыз нәрсәләр булып, аларның күпчелек матдәләре илә хокуклары чикләнгән, һәм дә Русиянең чын гражданы саналмаган мөселманнарның үз җилкәләренә йөкләтелгән иде. Золым, каһәр, наданлык нигезләренә корылган Русия самодержавиесе мөселман мәктәп–мәдрәсәләренә бер тиен ярдәм итмәсә дә, аларны үзенең золымы астында изеп тотса да, ләкин ул аның берлә генә канәгатьләнми, бар көче илә аларда руслык–христианлык рухы урнаштырырга иҗтиһад итәдер иде. Христиан руханиларына ярыйсы гына хокуклар бирелгән хәлдә, мөселман руханиларына хокук бирелми, аларның гади адәмнәрдән аермалары юк иде. Иске законнар буенча бөтен хакимият рус дине илә рус милләтенә бирелеп, башка диннәр вә аларның халыклары хокуксыз коллар иде. Рус законының II җилдәсе мөселман төрек–татарларның тәрәкъкыйсы өчен бөек бер койма, аларның хокукын чикләү юлына шомлы киртә иде.

«Золым күп яшәмәс». Бу сүз дөрес булып чыкты. Русиянең сәгадәтен, Русиядә яши торган һәрбер милләт вә халыкның ирекле булуны тели торган демократиянең иҗтиһади сәясендә әлеге золым патшалыгы үзенең золым патшасы илә барәбәр мәйданнан югалды. Аның урынына һәр милләткә, һәрбер дин әһеленә тулы

хөррият бирә торган гадел хөкүмәт урнашты. Бу гадел хөкүмәтнең эш башына менүе Русиядәге һәрбер милләт, вә хосусый, без мөселманнар өчен ябылмый торган бер «өмид капусы» ачты. Бу күпер безнең милләт өчен күк капусы кебек мөбарәк бер күпердер, ул күпер ачык булып торганда һәрбер теләк кабул була. Милләтләрнең һәр теләге булып тора. Мөселманнар, шуңа чын күңелдән ышанганга күрә, яңа хөкүмәтне хуплап каршы алдылар, демократиянең эшләгән эшләре Ватан вә милләтләрне хакыйка бәхетле итәчәк булганга күрә, тән вә җаннары илә демократия–хөрриятчеләр тарафыннан булындылар.

Төрек–татарларның Русиядә ирекле, бәхетле булып яшәүләре хөррият сәясендә генә булганлыктан аларның хөррият вә хөрриятчеләр тарафында булучылыклары табигый иде.

Яңа хөкүмәтнең эш башында калуы Русиянең үзе һәм дә анда яшәгән милләтләрнең мәсгүд булуы өчен лязем булса да, халыкның җилкәсендә гомер итеп килүне гадәт иткән, хокуксыз милләтләрнең газапларыннан ләззәт алып килгән хөкүмәт тарафдарлары яңа хөкүмәтне төшереп, Русияне яңадан золым, кан һәм яшь дәрьясына батырмакчы булалар. Болар хәзерендә бик зәгыйфь булып, ачык сурәттә эш итәргә батырчылык итә алмасалар да, астан искелек фикере таратылуында, халык арасына ихтилаф салып иске хөкүмәтне яңадан кайтарырга тырышуында шөбһә юктыр. Узган көннәрдә булып үткән Корнилов вакыйгасы моңа бик ачык шаһиттыр. Менә шуларны игътибарга алып, һәм дә мөселманнарның Русиядә ирекле, бәхетле мәсгүд булып яшәүләре Русиянең патшалык идарәсе демократия–хөрриятчеләр кулында булганда гына, һәм Русиядә хөррият тәмам урнашканда гына булачагына ышанып кына Эчке Русия мөселманнарының «Милли идарәсе» мөселманнарга мөрәҗәгать итәдер ки:

«Мөселманнар иске идарәне кайтару хосусында булган коткыларга колак салмаска, аларның сүзләре тышкы яктан никадәр тәмле булса да, аңа игътибар итмәскә, бар көчләре белән хөрриятне саклау юлында иҗтиһад итәргә, хөрриятчеләргә матди вә мәгънәви ярдәмдә булырга, мөселман демократиясе рус демократиясе илә кулга–кул тотышып, туганлык, тигезлек, тугрылык нигезләренә корылган Вакытлы хөкүмәтне ныгытырга иҗтиһад

итәргә тиешдер. Романов нәселеннән булган патшалар заманасында меңәрләп харап ителгән мәчет вә мәдрәсәләрнең, дин вә милләт юлында йөзәр–меңнәрчә асылган һәм киселгән шәһидләрнең ана телләре илән сездән: золым вә җәбер нигезе өстенә бинан ителгән теге иске хөкүмәтне кайтару юлында корал булмаска сорыйлар, гадәләт нигезләренә корылган яңа хөкүмәткә һәм анын арка таянчы булган хөрриятчеләргә матди вә мәгънәви ярдәмдә булуыгызны үтенәләр, Русиядә хөрриятнең чын мәгънәсе илә урнашуына гайрәт вә фидакарьлек итүегезне телиләр. «Бетсен золым вә җәберләр, яшәсен тигезлек, иркенлек вә гадәләт» дигән тавышларыгызга алар да чын күңелләре илә «Амин!» диләр.

Әгъзалар ошбу хитапнамәне бөтен имамнарның һәм дә комитетларның халыкка укып аңлатуларын үтенәләр.

Мохтарият рәисе: С.Максуди

Малия нәзарате әгъзасы: Ш.Алкин

Мәгариф нәзарате әгъзасы: Һ.Мансур.

Диния нәзарате идарәсе рәисе: Г.Баруди.

«Йолдыз». – 1917, 27 сентябрь.

## III. Садри Максудиның III Дума мәҗлесләрендә сөйләгән нотыклары.*

*1. Ял көненең мөселманнар өчен Җомга көн булуын таләп итеп сөйләгән нотыгы. (1910, 1 май).*

Атнада бер көн ял итү – без, мөселманнар өчен, бик мөһимдер. 9 нчы статьяны тавышка куйганчы, мин янәдән бер кат сезгә мөселманнарның бу хакта ни теләгәннәрен, бик озынга китмәенчә, сөйләп китәргә телим.

Без ни телибез? Хөкүмәт без хәзер караган закон белән сәүдә кешеләренә, хезмәткәрләргә атнада бер көн итүне лязем итәдер. Без, мөселманнар, шуны телибез: бу ял көн Җомга көнгә туры

* С.Максуди Россия Дәүләт думасындагы чыгышларын рус телендә ясаган. «Йолдыз» гәзите исә аларны тәрҗәмә итеп бастырган. Бу китапка кергән нотыкларның теле җиңеләйтелеп, хәзерге телгә якынайтып бирелде.

килсә иде, дип. Христиан динендә булган Русия кешеләре өчен бу лязем ял итү көне якшәмбегә туры килә. Бу – безнең теләгән максудның берсе.

Икенчесе шул: рус–христиан бәйрәмнәрендә безгә бәйрәм итү лязем булмаса иде. Христиан бәйрәмнәре урынында без үзебезнең мөселман бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә ихтыярлы булса идек.

Менә безнең теләгән нәрсәләр болардыр. Безнең бу сорауларыбыз бик төпле, бик урынлы.

Ни өчен мөселманнар ял итү көненең Җомгага туры килүен телиләр? Җавабы ап–ачык: анын өчен без, мөселманнар, үзебезнең динебезнең, милләтебезнең бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә телибез, сакларга телибез. Чөнки без беләбез: бәйрәмнәр – бер кавемнең хәятендә бик мөһим нәрсәләрдер. Бәйрәмнәр милләтнең динен–рухын тәрбия итәләр, милләтне диндарлыкка өйрәтәләр, бәйрәмнәрдә, төрле гореф–гадәтләрдә, исемнәрдә милләтнең үсә торган балалары үзләренең дини вә әхлакый фикерләренең нигезләрен салалар. Бәйрәмнәр – бер милләтне җыеп, оештырып тота торган зур мәгънәви бер җилемдер,

Бәйрәмнәр аркасында диннең сафлыгы саклanaдыр, диннең вә милләтнең төрле–төрле мөкатдәс гадәт–горефләре онытылмыйдыр.

Менә боларны белгәнгә күрә, мөселманнар һичбер вакыт үзләренең бәйрәмнәреннән язарга, мәхрүм булырга разый булачак түгелдер. Чөнки мөселманнар өчен бәйрәмнәрдән мәхрүм булу үз бәйрәмнәренә кул селтәү, гадәт диниядән мәхрүм булу илән бердер.

Бу һич була торган эш түгел, һәм булмас. Ял итү комиссиясенең мөселманнарны якшәмбене ял көне дип санарга мәҗбүр итү – мөселманнарга: сез үз бәйрәмнәрегездә ял итүдән котылдыгыз дигән сүзгә барып чыгадыр. Чөнки бу комиссия бик яхшы беләдер ки, безнең халык өчен һәм үз бәйрәмнәребезне һәм христиан бәйрәмнәрен бәйрәм итү өчен һич мөмкин булмаган бер эштер.

Бу закон нигезендә ял итү лязем булган көннәр – рус бәйрәмнәре, якшәмбе көннәр беләнбергә җитмеш көн кадәр булачактыр.

Безнең үзебезнең мөһим мөселман бәйрәмнәребез җомгалар белән бергә җитмешкә туладыр. Аннан башка без, мөселманнар, Рамазанда һәрвакыт кояш баерга ике сәгать калгач, иң сату итә торган вакытта, кибетләр вә башка тиҗәрәтханәләрне ябып эштән туктыйбыз. Шулай итеп, Рамазанда сату итә торган көн озынлыгының бары яртысында гына сату итәбез. Барлыгы унбиш көн һәм сиксән биш көн җыела. Моңа лязем булган җитмеш рус бәйрәмнәрен дә кушсаң, йөз илле биш көн буладыр. Әгәр, комиссия теләгәнчә, мөселманнарга рус бәйрәмнәре дә лязем булса, безгә елына йөз илле биш көн эшсез булырга кирәк. Мөселманнар рус бәйрәмнәрен ял иткәндә, акрынлап үз бәйрәмнәрен оныттырлар, дип уйлап эш иткәндә генә мөмкин буладыр бу законны үткәреп. Бу – 9 нчы статьяның чын хәйләседер, безнең вөҗданга хилаф сере, хөкүмәт шундый комиссия төзегәндә, рус бәйрәмнәрен онытырлар, дип. Әлбәттә, моны комиссия ачык итеп әйтә алмый, кыймый. Комиссия безне, ислам динендәге кешеләрне, христиан бәйрәмнәрен дә бәйрәм итәргә кыстамакчы була. Без болай мәҗбүр булуны, диндә хөрриятне бозу була, дибез.

Безнең дәүләтнең зур законында диндә хөррият булу язылган. Төп законнарда иркенчелек язылган бер мәмләкәттә ничек итеп христиан булмаган бер халыкны христиан бәйрәмнәрен дә бәйрәм итәргә җәберләмәк кирәк?

Әфәнделәр, әгәр дә Думада бер комиссия мөселманнарга якшәмбе көн чиркәүдә руслар гыйбадәт иткәнен карап торуны лязем итеп бер ляихә ясаса, бу законга мөселман депутатлар каршы торып сүз әйткәч, диндә хөррият булган бер мәмләкәттә бу каян чыккан җәбер дип ихтиразын иткәч, комиссия җавап итеп әйтә: бу законда диндә хөрриядкә хилаф эш юк. Без сезгә якшәмбе көнне чиркәүдә булган өстенә, теләсәгез, Җомга көн мәчеткә барырга ихтыяр бирәмез дисәк, сез, әфәнделәр, ни әйтер идегез? Һич шөбһәсез, монда бу закон ляихәсен, ягъни, сез җәбер, хөррият вә гадәләткә (тигезлеккә) хилаф бер ляихә дияр идегез. Комиссиянең җавабын хилаф вәкилләренә лаек булмаган халыкның вөҗданын кайната торган берсе җавап дияр идегез. Мондый ляихәне җәбер һәм гакылсызлык дияр идегез.

Инде мин сездән сорыйм, әфәнделәр: безгә якшәмбе көн ял итүе лязем булуы белән бу хәзер әйткән фарыз ляихә арасында аерма нидә? Бу ике ляихә һәр икесе җәбер, бары аермасы шунда гына: бу соң фарыз кыйлган җәбер өлгесеннән тагын да катырак, тагын да авыррак. Юкса, бу ике хәл һәр икесе дә бер төрле җәбер: мөселманнарның дини хисләрен изү, вөҗданнарына көчлек ясау.

Үз бәйрәмнәребезне бәйрәм итәргә ихтыярсыз булудан, без якшәмбе вә бүтән христиан бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә тиешлек, бу, һичшөбһәсез, безнең хөррият диниябезне хурлау, безнең вөҗдан вә калебебезгә бер җәбердер.

Комиссия әйтә: мөселманнарга якшәмбе бәйрәм итү лязем булмаса, безгә сәүдә җәһәтеннән конкуренция хәвефе бар, имеш. Бу – юк сүз. Беләсез, иң зур сәүдә кайнаган шәһәрләр – Мәскәү вә Петербург. Боларда бер–ике мөселман магазины бардыр. Статистикадан мәгълүмәтләргә караганда Русия мөселманнары арасында сәүдә белән шөгыльләнүчеләрнең хисабы руслар арасындагыга караганда бик күпкә ким. Безнең милләттәшләребезнең күбесе кыргызлар, башкортлар, төрекмәннәр. Болар күчмә тормыш белән торалар, хайван асрау белән көн итәләр, калганнары иген игү белән мәгыйшәт итәләр. Бу очракта мөселманнарның якшәмбене бәйрәм итмәүләреннән руслар–христианнар өчен нинди конкуренция булырга кирәк?

Бер кавемнең дини бәйрәмен бетерү – ул кавемнең диненә зарар китерү буладыр, диннең тамырларыннан бер тамырны өзү буладыр, дидек. Чөнки бәйрәмсез булмыйдыр, һәм динсез мөкатдәс бәйрәм дә булмыйдыр. Безгә кайсылары әйтә: гүя без мөселман вәкилләре байларның мәнфәгатен яклыйбыз, имеш. Килгән күп санлы телеграммаларның барысы да диярлек хезмәт ияләреннән, һәм алар ял көненең Җомга көнгә туры килүен телиләр. Ләкин без хуҗаларның гына да мәнфәгатен яклаучылар да, приказчиклар көен генә көйләүчеләр дә түгел, без – үзебезнең мөселман бәйрәмнәрен яклаучы, аларны сакларга тырышучы. Без, мөселманнарны бәйрәмнән мәхрүм булуны бик зур нигъмәттән мәхрүм булу икәнлекне бер дә аңламый, дип беләләр. Безнең бу тәкъдимне кабул итмәгән комиссия мөселманнарның тормыш шартларын вә тарихларын беләме икән? Мөселман әхвәл–рухиясенә вакыйфмы

икән? Мөселманнарның Дәүләт думасына никадәр өмет багълап торганны беләме икән?

Реакциянең узгынчы кодрәтенә алданып, дин бабында дингә тыгылганлыгы белән бу эштә мондый «тәҗрибәләр» ясап каравына ни кадәр урынсыз—ихтыярсыз, бигрәк тә ни дәрәҗә хәтәр икәнен беләме икән бу комиссия?

Әгәр бу кышта Думаның мөселманнарга каршы эшләгән эшләрне жыеп—сөйләп күрсәтсәм, сез үзегез дә гаҗәпләнерсез.

Уку комиссиясе, ике ай элек, безгә үз телебездә уку вә укыту хокукын бирмәскә ясап куйды.

Моның артыннан, күптән түгел, Азиягә күчү комиссиясе, аннан соң Дума, Төркестанда күчмә милләттәшләребезнең җирләрен алырга канун чыгарды. Бүген инде ял итү комиссиясе мөселманнарны милли, дини бәйрәмнәрдән мәхрүм итәргә сезгә закон проекты кертәдер.

Әзрәк чынлабрак уйлап карагыз, мөселманнарга каршы ясаган эшләрегез нидән гыйбарәт? Сезнең бу хәрәкәтегез, яхшылап, төпләп уйлаганнан соң булган эшме? Яки җүнләп бу хакта уйлап та карамыйча, рус булмаган кавемнәрне яратмавыгыздан килгән плансыз бер эшме? Әфәнделәр, уйлагыз, сез бик зур бер хата ясыйсыз. Сез сизәсезме, мөселманнарның башында нинди яхшы фикерләрне җимерәсез?

Хәзер дә мөселманнар, мәдәният җәһәтеннән никадәр артта булсалар да, тиз заманда аларның әһәмиятле бер кавем булачаклары хисапларына муафыйк вә мөкабәл бер роль уйнаячаклары шөбһәсездер. Бу халыкның сәясәт вә гражданлык мәйданына керә башлаган заманында ук сез бу халык өстенә берсе артыннан берсе кимсетүләр өясез. Болай итәсез дә, аннан гаҗәпләнгән буласыз, ник мөселманнар Думаның бер кисеменә (октябристларга) начар күз белән карыйлар, дип аптыраган буласыз.

Аптырарга урын юк. Мөселманнар мәдәнияттә артта булсалар да, ул кадәр сез уйлаганча ук хәбәрсез түгел.

Монда булган эшләрне бик яхшы аңлап торалар, әгәр бер халыкның теленә һөҗүм ителсә, тагып бераздан дине, бәйрәмнәренә зарар, кимчелек китерергә фараз кыйлынса, бу халыкның калебе җәрәхәтләнмәү, ачуы килмәү мөмкинме?

Октябристлар, мин сезгә сөйлим. Сез безнең Җомга көне хакындагы поправканы кабул итмәскә ихтыярлысыз. Теләсәгез ничек хәрәкәт итегез, ләкин бик зур хата эшлисез. Әлбәттә, сез әйтә аласыз, без сез мөселманнарның яхшы яки начар каравына бер дә игътибар бирмибез, дия аласыз.

Ләкин болай хәрәкәт итүнең икенче ягы бар. Әгәр сез мәмләкәтнең, һәртөрле сыйныф халкын белмәмешкә салынсагыз, бөтен мәмләкәт халкы сезне белмәмешкә салынып кына калмас, һич танымас булыр. Минем сезгә актык сүзем: без мөселманнарга ял итү көне Җомга көн булу гаять мөһим бер мәсьәлә. Бу – безнең халыкның теләгән нәрсәседер.

Теләсәгез, без әйткәнне кабул итәсез, теләсәгез, безнең халыкка каршы тавыш бирәсез. Ләкин янә әйтәм: без, мөселманнар, бу мәсьәләгә зур әһәмият биреп көтеп торабыз.

*2. III Думада тәгълим гомуми мәсьәләсе хакында сөйләгән нотыгы (1910 ел, 23 октябрь).*

«Әфәнделәр, законны матдә, матдә карарга керешкәнче, бу закон ләихәсе хакында мөселманнарның теләк вә максудлары нидән гыйбарәт икәнен сезгә сөйләп, аларның максудларыннан Дәүләт думасын хәбәрдар итүне үземнең бурычым санадым. Җөмләдән әүвәл ул мөселманнарның дини мәктәпләренең бу ләихәдә мәзкүр махсус мәктәпләр турысындагы кагыйдәләрдән алынуларын телиләр. Сания мөселман балалары укый торган школаларның һәр кайсында аларның үз телләре һәм үз диннәре тәгълим ителү лязем иде, диләр. Мөселман балалары өчен булган училищеларда укыла торган нәрсәләрнең, рус лисаныннан матдәсе һәр кайсы укучыларның үз лисаннарына укылсын иде, диләр, вә ана теле тәгълименә гаид мәсьәләләр мөселманнарның идарәи руханияләрен ризалыклары илә хәл кыйлынсыннар иде, диләр. Менә, әфәнделәр, безнең бер закон ляихәсенә кертелүен таләп кыйла торган максудларыбыз ошбулардан гыйбарәт. Ләкин без бер «тәрбияче» тарафыннан безнең максудларыбызга каршы ихтиразыйларны ишеттек. Мин һәм минем иптәшләрем – һәркайсыбыз – ана теле тәгълим ителә торган мәктәпләр хилафына уңнар

тарафыннан сүзләр сөйләнәчәгенә алдан ук ышанып куйган идек. Шулай да, мин алар тарафыннан бундый ана теле хилафына игътираз булыр дип фараз кыйлмаган идем. Хосуса, мин октябристларның сул канатында эшчәнлек күрсәткән Капустин ана теле хилафына сүз сөйләр дип бер дә уйламаган идем, чөнки II Думага сайлау заманнары минем бик яхшы хәтеремдә калган. Шул сайлауда ул Казан шәһәреннән ялгыз депутат булып үтте, шунда ул сайлаучылар мәҗлесендә, Казан мөселманнарының даими химаячылары булырга вәгъдә итте.

Хәзер инде мин сорыйм, шул заманнан хәзергә кадәр нинди үзгәреш булды? Капустин, мөселманнарның, максудларын химая кылырга вәгъдә биргән заманда, мөселманнарның максудлары нидән гыйбарәт икәнлеген белгән булырга тиеш иде, чөнки һичбер белмәгән нәрсәне химая кылырга вәгъдә кылуның асыл мәгънәсе юк. Мөселманнарның иң беренче күз тотып торган максудлары – үзләренең ана телләрен саклау һәм үзләренең диннәрен саклаудыр. Казан шәһәре мөселманнары Капустин җанәбләрснә мөрәҗәгать кылган заманнарда, әлбәттә, ошбу ике нәрсәне, ягъни ана телләре илә мәктәпләрен күз алларында тоталар.

Инде хәзер Капустин мөселманнарның бу максудларын химая кыйлу урынына теле һәм мәктәбе хилафына чыгып сөйләүчеләрдән беренче депутат булып чыкты. Капустин ошбу сүзләрне сөйләде:

«Милюков җәнабләре безгә: әгәр дә бер төрле милләтләрнең вәкилләренә аларның телләрен бирсәң, алар Русияне сөячәкләр, безгә алар теләгән нәрсәләрне бирергә кирәк, диде. Әгәр дә инородецлар артыннан кистем–бәрдем барсак, ул вакытта алар безне сөячәкләр, ләкин бу Русияне сөю булмаячак».

Капустинның фикеренчә, инородецлар бер нәрсә биргәнлек өчен генә Русияне сөяргә тиеш түгел.

Бәлки аның фикеренчә, алар Русияне тиктомалга сөяргә тиешләрдер?

Безгә һичбер нәрсә бирелми торып, безнең Русиягә мәхәббәт итүебезне теләү илә Капустин мәктәпләр рус мәктәпләре булырга һәм андагы учительләр руслардан булырга тиеш, ди.

Минем беләсем килә: аның «рус» дигән сүзенең морады нәрсә икән? Әгәр дә ул сүздән рус таифәсе булу морад исә, мин дә аның илә бер фикердәмен. Әгәр аның максуды «православный рус» дигән сүз булса, һәм татар авылларында, мөселман карьяларында мөселман балаларына учительлек кылучы кеше православный мәзхәбендәге кеше булса, мин аның бу сүзенә игътираз (кире кагу) итәм. Мин генә түгел, чөнки мөгаллимлекнең, балаларга мәгариф тәгълим кыйлудан башка, тәрбия җәһәтеннән дә әһәмияте бар. Бу җәһәттән караганда мөселманнарның һичбересе үзләренең дини тәрбиячеләре православный рус булырга риза булачаклар түгел. М.Я. та, комиссия да, мөселманнар булганчыга кадәр сабыр итәргә киңәш бирәләр. Мөселманнарның ул киңәшкә һичбер разый булу ихтималлары юк. Мөселман балалары укый торган ибтидаи училищеларда учительләр, әлбәттә, мөселман булырга тиеш. «Инородецлар өчен булган училище һәрвакытта миссионерлык рухында булалар» дим.

Мин, Русиядәге мөселман инородецлар хакындагы вакыйгаларны калдырып торып, икенче бер мәсьәләне сезгә аңлатмакчы булам, ягъни сезгә бу Думада аларның барлыклары тәмам онытылган әтрафлар хакында, хаклары бетерелеп, берьякка ташланган Төркестан хакында сезгә сөйләмәкче булам. Сез уйлыйсыздыр, мәзкүр зур һәм киң җирләрдә рус мәдәнияты һәм мәгарифе алга бара, ул тарафларда акрынлап рус мәгарифенең алмашуы бара, анда рус фикерләре тарала, дип. Юк, сез ялгышасыз: мәзкүр тарафлар, Русиягә табиг (буйсынган) калдырылган заманнарда ни рәвештә булган булса, хәзерге көндә дә шул рәвешледер.

Ник болай бу? Рус хөкүмәтенең бу көнгә кадәр мәдәният кертүне, бу тарафларга мәгариф нәшер итүне теләмәгәненнән генәдер. Бу сүзнең дөреслеген исбат итү өчен бик күп дәлилләр бар. Мин сезгә хәзер бер документ күрсәтәм. Бу документ Русия хөкүмәтенең мәзкүр тарафларны алган көннән башлап хәзерге заманга кадәр ул тарафларда мәгариф итәргә теләмәгәнлеген, бәлки аның максуды аларны православныйлыкка әйләндерү булганлыгын сезгә исбат итә алыр. Мин сезгә документны укып күрсәтәм. Бу тарафлар табиг кылынганнан соң беренче генерал–губернатор фон Кауфман, мәшһүр миссионер Ильминскийга мөрәҗәгать кылып, Төркестан-

ны православныйлыкка әйләндерү өчен нинди юллар илә барырга кирәклекне өйрәтергә куша. «Төркестан тарафында инородецлар образованиесенең ничек бина кылынганлыгы хакында кыскача тарихи хәтирәләр» дигән рисаләнең берничә сәхифәсен укып күрсәтәм. (Укый.)

«Төркестандагы инородецларның образование эшләрен мөмкин кадәр нык нигезгә бина кылуны теләгәннән, генерал фон Кауфман Ильминскийга мөрәҗәгать итеп, аның бу эшкә якыннан иштирәк (булышу) итүен үтенде, хәтта аны Төркестан тарафына күчертү өчен иҗтиһадлар сарыф кыйлды. Аны ошбу тарафның, әхвәле һәм мондагы халыкның шәригать–мәгыйшәтләре илә якыннан таныштырырга теләде, әгәр мәгыйшәтләрен, бу эшләрне якыннан белсә, ул андагы укыту эшләрен юлга салырга күп ярдәмнәре тиячәк иде. Башта Ильминский фон Кауфманның бу мөрәҗәгатенә зур әһәмият биреп эшкә кереште. 1869 елның башында бер план төзеп Урта Азия сәхрәләрендә акрынлап вә саклык илә рус вә миссионер образованиеләре нәшер итү өчен бик киң планнар күрсәтә, шунда ук Төркестан кыргызларының образованиегә бәйле эшләрен Алтынсарин дигән шәхеснең кулына тапшырганнарын мәгъкүл күрде.

Ул кешенең әүвәл Казанга килеп, ике ел кадәр анда хәзерләнергә тиешлеген белдерә. (Мәзкүр миссияне хәзерләү өчен булган армиянең Баш штабы Казандадыр). Иң әүвәл миссияне хәзерләп, аннан Төркестан чүлләренә күндерергә, һәм моннан рус әлифбасы белән кыргызларны укыту өчен хосусый бер мәктәп ачарга, анда укыган шәкертләргә үзләре тарафыннан икенче урыннарда мәгариф ачып, шул юл илә чүлләрнең һәрбер тарафында образование тарату фараз кылынды. Ул ошбу урында Төркестан тарафы өчен христиан–инородец мәктәпләре ясауны уйлады. Бу миссиянең начальнигы итеп Епископ Алтынсаринны тәкъдим итте, чөнки бу кеше миссионерларның эшләреннән хәбәрдар иде». Менә, Төркестан әтрафындагы образование эшләре нинди хатларга, нинди фикерләргә бина ителеп (нигезләнеп) башланды. Менә шушы фикерләргә нигезләнеп ул тарафларда школалар ачыла башлады. Нәтиҗәләре ничек булып чыкты? Мондый школалар инородецлар арасында авторитет казандылармы, мәзкүр

школалар фараз ителгәнчә, шөһрәт казандыلармы, Төркестанда хәзер мондый мәктәпләр күпме? Мин сезгә бу хакта Сыр–Дәрья областендагы гавам мәктәпләренең директорының рәсми хисапларын күрсәтәм. «Бөтен әтрафта миссионерлык әсасына нигезләнеп салынган русско–туземская школалар бар. Болардан Сыр–Дәрья областенда, Фирганәдә, ундүрте – Җидесу вилаятендә, унбере – Закаспий вилаятендәдер. Җәмгысе – туксан ике».

Бу мәктәпләрнең башка җәһәттән муафәкыяте (уңышы) ни дәрәҗәдә идекене хакында мин үз тарафымнан сезгә бер сүз дә сөйләмим. Мин сезгә бу хакта күптән түгел Ташкентта инородецларның образованиесенең хакында булган Киңәш мәҗлесенең протоколларыннан бер сәхифәсен генә укып күрсәтәм. Мәҗлес ачылгач та генерал–губернатор әйтә, ( – Бу хисле мөһим һәм гаҗәп, сәхидә шул сәбәптән сезнең игътибар илә тыңлавыгызны сорар идем – ): Бу көнге мәҗлес узган елда инородецларның образованиесе хакында булган Киңәш мәҗлесенең дәвамыннан гыйбарәттер. Соңара башка мәсьәләләрнең һәммәсеннән алда, русско–туземсксая школаларны дәвам иттерергә кирәкме, я булмаса, андый школаларны тәмам иттереп җирле халыкларга русча бер дә укымау файдалырак булачакмы? Рәис шул мәсьәлә хакында фикер йөртергә киңәш бирде. Соңара школалар хакында Фирганә областендагы народное училищелар инспекторы әйтә; (ул бу школалар хакында ошбу русча хәбәрне бирә): «Фирганә вилаяте өязләрендә барлыгы егерме русско–туземская школалардагы укыту минем тарафымнан канәгатьләнерлек табылмады. Мин боларны тәгълим вә тәрбия җәһәтләреннән дә, вә хозяйственный җәһәттән дә начар таптым. Шул сәбәптән русско–туземская школалар яхшыландырырга һәм тиешле дәрәҗәләренә кадәр җиткерелергә тиешледер. Гәрчә школалардан өчесендә шәкертләргә торыр өчен урыннар хәзерләнгән һәм ашау–эчү нәрсәләре тәэмин ителгән булса да халык каршында игътибарлары юктыр, чөнки боларның һичберсе күңелгә ятарлык, игътибарга лаек булган нәтиҗәләрне бирмиләр. Күп школалардан, ачылганнарына ничә еллар булса да, имтиханнар биреп, школа тәмам итеп чыккан кешеләр юк. Мәсәлән: 1906 елда 14 мәктәптән, 1907 елда 17 мәктәптән, 1908 елда 11 мәктәптән һичбер мәктәп тәмам итеп

чыккан кеше булмады. Училищеләрнең югарыдагы сыйныфларында укучылар бик аз күренә. Шәкертләр мәктәпкә бер дә калмыйча йөриләр. Бер ел эчендә 72 мең дәрес бирелгән. Яшь шәкертләр школаларда бер–ике ел укыйлар да һичбер нәрсә белмәгән хәлләрендә школаларны ташлыйлар. Школаларның хәлләре шундый булганның соңында, мондый школаларны оештыру эшенә салкын да карыйлар. Яңа школалар ачу өчен рөхсәт бирүдә тыелып торалар. Бу эшләр өяз начальникларының рәсми хатларыннан күренәдер». Менә, әфәнделәр, миссионерлык фикеренә бина кылынган русско–туземская школаларның хәл вә әхвәлләре һәм аларның торышлары ошбулардан гыйбарәттер.

Төркестанга сәяхәт кыйлганда мәгърифәтле русларның, һәркайсы, мөселманнар бик артка калганнар, мәгърифәтсезләр, диләр. Хәлбуки, болардан һичберсенең мөселманнарның ни сәбәптән артка калганнары хакында уйлап та караганнары юк. Әфәнделәр, зур Төркестан әтрафы Русия җөмләсенә керде. Шушы Төркестан өлкәсе Русиягә кушылганнан бирле аның халкының, Русия хөкүмәтенә кәеф китәрлек бер эш тә эшләгәннәре юк.

Мөселманнарның бу садәкатьләренә, турылык һәм яһүд итагатьле мөселманнарның тәкъдиргә иман китерүләреннән генә килгән бер нәрсә, дип карау Русия өчен хата булачактыр. Әфәнделәр, Төркестан мөселманнарының кануни ихтирамнарына, аларның сәдакәтларенә икенче бер хәл сәбәп булды, алар Русия патшалыгының мәдәни бер мәмләкәт икәнен белгәнгә, Русия аларга мәдәният кертер, мәгариф аларның хәятләренә яңа бер яктылык чәчәр, дип уйладылар. Менә шул хисләр, шул өмидләр, гәрчә бәгъзе бер вакытларда камил хаклары булса да, аларны һәрбер төрле ризасызлыклардан туктатып калдырды.

Менә инде ошбу хәрәкәтләр бер–беренә һәм Русия җөмләсенә кергән шушы җирләрдә рус патшалыгы аларга нәрсә бирде? Төр–кестанга аларның хаклары булган мәдәниятне бирдеме?

Яхуд аларның фараз кыйлган мәгърифәтләрен бирдеме? Русия патшалыгы аларга һичнәрсә бирмәде.

Төркестан Русия астына керүдән ике файда күрде: 1) коллык бетте, 2) андагы халыкның берсенең икенчесенә дошманлыгын бетерде.

Алар Русия хөкүмәтенең эчләрен пошыра торган нәрсәләрдән тәмам читтәдер. Максуд шул идемени? Боларны мәдәнияткә кертүгә бернинди план да булмаганлыктан килеп чыккан эшләр бу. Бу өлкәдә планнар хәзерләү урынында алар баштан ук миссионерлыкка бирелделәр. Бу эш мөселманнарның урысларданераклашуына сәбәп булды. (Замисловский урыныннан торган хәлдә: Бу нинди охшамаган сүз? Сез – мәгърифәтсез! – дип кычкыра).

Рәис: Зинһар, урыннан кычкырмагыз.

Максудов: Мин сезгә исбат итеп бирермен. Әфәнделәр, бу хәлләр ни өчен болай? Төркестан мөселманнары хәзерге көннәрендә яшиләр. Ягъни һаман да руслардан бер тарафта булып, рус мәдәниятенең асылын белмиләр. Кыскача гына әйткәндә, рус җәмгыятенең мәдәнияттә тәэсире юк.

Русларның хуҗалыкларына кырык ел узган булса да, Төркестан мөселманнарының бу көндә, әүвәлге шикелле, руслардан ерак торуларының сәбәбе шул. Алар үзләренең иске уйларын уйлауда һәм үзләренең иске фикерләрендә һаман сабит (турылыклы) булачаклардыр. Болар, рус мәдәниятенең алдынгылыгына шик кылмасалар да, һаман да русларга ышанмауларында дәвам итәчәкләрдер.

Бу хәл мәгъкүл булган хәлме? Руслар шулкадәр зур бер өлкәгә хуҗа була торып та үзләренең фагыйльләтьсезлегендә, хәтта үзләренең мөселманнарны исәпкә дә алмауларында һәмишә дәвам итәчәкме?

Без хөкүмәтнең мөселманнарга мөнәсәбәте ни рәвештә булырга тиеш икәнлеген тәмам тәгаен итеп куярга, мөселманнарга үзенең мөнәсәбәтендә Русия хөкүмәте нинди файдалы максудлар вөҗүдкә чыгарырга тырыша, шуларны билгеләргә тиешбез. Безгә бер юлда иттифакый гына очрашкан ике юлчы шикелле барырга кирәкме, я булмаса, безнең арабызда мөгаен бер дустлык һәм карендәшлек мөнәсәбәтләре булырга тиешме? Бу сорауларга, минемчә, хәзердән үк җавап бирергә тиешледер. Без бу мәсьәләне тәмам хәл кылмаганда мәдәният вә тәрәкъкый эшләре, бигрәк тә, хәзер без сөйләгән Төркестан тарафында һичбер алга китәчәк түгел.

Бу асыл мәсьәлә: Русиядә мөселманнарга булыргамы, булмаскамы? Хөкүмәтнең әле мәсьәләне хәл кылганы юк. Бу көнгә кадәр

светская власть, мөселманнарга булыргамы, мөселманнарны тану итәргәме, итмәскәме – белеп җиткерә алганы юк.

Таныргa булса да, ни рәвешле таныргa? Ошбу мәсьәләләрнең һәмишә светская власть тарафыннан хәл кылынганы юк. Әмма миссионерлар җәмгыятьләре ул мәсьәләне күптән хәл кылып куйганнар. Алар Русиядә мөселманнар булмаска тиеш, дип тәмам беркетеп куйганнар һәм алар үзләренең ошбу карарларын хөкүмәтнең колагына тыгып торалар. Бәгъзеләре бу руслаштыручы аталарының сүзләрен тыңлыйлар, бәгъзеләре исә ишетсәләр дә ышанып бетәселәре килми. Ләкин алариың сүзләрен ишетәселәре килмәгән мәэмүрларның (чиновниклар) хәлләре начар булачактыр. Сез, бәлки, миссионерларның «Русиядә мөселманнар булмаска тиеш» дигән сүзләренә ышанмый торгансыздыр, яхуд ышанмаган булып күренә торгансыздыр.

Ышанмасагыз, мин сезгә Казанда узган миссионерлар съездының протоколларын укып чыгарга киңәш итәм. Әгәр дә аны укысагыз, аларның мөселманнар булмаска тиеш дигән сүзләрен бик ачык күрерсез. Әфәнделәр, миссионерлар «Русиядә мөселманнар булмаска тиеш» дип карар биреп куйганнар. Әмма светский хөкүмәт икеләнеп тора. Бер мәртәбә миссионерларча «Мөселманнарга Русиядә булмаска» дип карар биреп куя, икенче мәртәбә, хөкүмәт уларак, мөселманнарга булырга рөхсәт бирә. Хөкүмәт бу турыда һичбер төрле планга хуҗа түгел. Бу исә аның үзенең системасызлыгын, үзенең мәңгелек тирбәнүе, үзенең мәңгелек бер урынны таптап торуын күрсәтә.

Әфәнделәр, мин сезгә, безгә фикерләре мәгълүм булган уңнар, сулларга бүлеп түгел, ә Дәүләт думасының мәркәзендәге кешеләргә мөрәҗәгать итәм. Миссионерлар Русиядә мөселманнарның булмаулары тарафындадыр. Хөкүмәт исә һаман тирбәлә. Бер мәртәбә миссионерларча, икенче мәртәбә падишаһларча итеп карар бирергә телиләр. Падишалыкча булган карарларга бик сирәк очрарга туры килә. Бу падишалыкча булган карарлар хөкүмәтнең әхвалындагы яхшы көннәрдер. Без боларга үз гомеребездә бәхетле заманнар дип саныйбыз.

Әфәнделәр, октябристлар, безнең хакта сезнең фикерегез ничек?

Сез дә миссионерларча фараз кыласызмы? Сез дә шулай Русиядә мөселманнар булмаска тиеш, дисезме? Әллә сезнең карарыгыз бераз башкачамы?

Сезнең фикерегез ничек? Әгәр дә башкача булса, мин сездән җавап эстим: сезнең карарыгыз ничек? Сез безгә үз телебездә укырга мәктәпләр бирәсезме? Сез мәгарифне безгә мәгариф көенчә бирәсезме? Яки сез дә мәгарифне руслаштырырга кирәк дисезме? Сүземне бетермәстән мин сезгә шуны әйтергә мәҗбүрмен. Теләсә нинди партия, теләсә нинди фракцияләр һәм теләсә нинди җәмгыять «Мөселманнар булмасын» дип карар бирсәләр дә, аларның карарлары һичбер вөҗүдкә чыкмаячаклар. Мин бу сүзне ышанып әйтәм. Безнең мәүҗүдемезгә көч бирә торган куәтләр, бездә шундый бер тәкать тота алмаслык иҗтиһад барлыгын күрерләр ки, ул иҗтиһад һәрбер кысуларга, һәрбер изүләргә каршы торачактыр. Изү куәтенең дәрәҗәсенә карап бу модафага (каршылык) куәтенең дә артачагына да шөбһә юктыр. Без бар идек, бүген дә бар, һәм моннан соңара да булачакбыз! (Суллар кул чаба).

«Йолдыз». 1910 ел, 608–610 саннар.

*3. Дәүләт думасының 26 февраль мәҗлесендә сөйләгән нотыгы («Россия» гәзитеннән).*

Халык вәкилләре, әфәнделәр!

Хәзер һәр җирдә мөселманнар арасында тентү вә хәбәсләр дәвам итә. Бик ешланган бу тентүләр һәм хәбәсләрнең сәбәпләрен сөйләмәстән элек соңгы бер ай эчендә бундай вакыйгаларның санын әйтеп китәчәкмен. Бу ай эчендә бер Вятка вилаятендә ун мулла төрмәгә алынды, биш мәдрәсә, биш мәктәп ябылды. Дини мәктәпләрдәге ун мөгаллим кулга алынды. Казанда мөхтәбәр мулла Галиев белән Апанаев, Оренбургта ике–өч мөхәррирдә тентүләр булды.Себердә берничә мулла белән өч мөгаллим төрмәгә алынды. Казанда бер татар матбагасы ябылып, ике мөселман китапханәсендә тентүләр булды, һичбер нәрсә аңламыйча, әллә никадәр китапларны мәсхәрә кылдылар. Казанда «Милләт» китапханәсендә,

Уфада Җантурин белән Килдебәковларда тентү булды. Уфада «Шәрык» матбагасын актардылар.

Әфәнделәр, хәзергәчә хөкүмәт вәкилләре «Мөселманнар иң сәдакатьле бер милләт» диләр иде бит! Бу сүз бик дөрес. Мәмләкәт тынычланган бер чакта мөселманнар кинәт башка милләтләрдән дә артык ихтилалчыга әйләнерме? Һич! Хөкүмәтнең безнең хактагы сәясәтенең үзгәрүенең сәбәбе бездә түгел, мөселманнарның сәяси фикере алышуында да түгел, бәлки хөкүмәтнең сәясәте алышынып рус милли фикере юлы тотылудадыр. Хөкүмәтнең безгә мөнәсәбәте алышынуның берничә сәбәпләре бар. Иң мөһиме мәмләкәт сәясәтендәдер. Бу — Меньшиковлар, бу — Бобрынскийлар вә иярченнәре сәясәтедер. Мөселманнар хакындагы соңгы мөгаләмәләрнең сәбәбе: хөкүмәт сәясәтенең соңгы заманнарда тоткан юлыдыр. Кинәттән булганын искә төшерделәр, вә үз–үзләренә: «Без соң нишләп болар хакында һичбер эш эшләми тордык?» диделәр. Дөрес әйтәләр, чөнки тәгассоблы (шовинистик) милләт сәясәте нинди булса да бер инородец мәсьәләсен куертып кына яши аладыр. Әле яһүд, әле поляк мәсьәләләрен кузгалту белән генә шөһрәт чыгара ала, өскә менә ала.

Фәкать бу ике мәсьәлә бераз искерде, шул сәбәптән нинди булса да яңа милләт вә инородец мәсьәләсе тудырырга лязем күрелде. Хәзер алар бөтен көчләре белән Русиядә мөселман мәсьәләсе тудырырга тырышалар. Әйе, әфәнделәр, сез бу максудыгызга ирешерсез, фәкать бу Ватан өчен файдалы булырмы, граф Бобрынский?

Әйе, әфәнделәр, тентү вә кулга алуларның болай ешлануы, шөбһәсез, мәзкүр даирәләрдә инородецларга дошманлык хөкем сөрүедер.

Икенче сәбәп: груһлар партияседер. Болар һәр даим мөселманнар өстеннән доностар ясыйлар, безнең тәрәкъкый вә нәшер–мәгариф хәрәкәтемезне Ватан вә мәмләкәткә хилаф рәвештә күрсәтергә тырышалар. Пуришкеевичлар, Марковлар партиясе кеби уңнар бу максатларына ирешер өчен мөселманнар арасындагы җәһеллек (наданлык) илә файдаланалар, мөселманнар арасында ук безнең мәгариф вә мәдәният юлында хезмәтебездән нарасый кешеләр бар. Менә бу кешеләр безнең милли хәрәкәтебезне тукта-

тырга көчләре җитмәгәнлектән, хөкүмәт көчен үзләренә хезмәт иттермәкче булалар. Груһлар безнең өстән донослар ясый: мөселманнарның хәрәкәте Ватанга хилаф максаты илә эшләнә, диләр. Безне панисламчылар, тагын әллә кемнәр, диләр. Ләкин мин катгый рәвештә әйтәм: мөселманнар арасында мәмләкәткә хилаф мәсләкле һичбер яшерен оешмалар юктыр.

Ни өчен соң уңнар безгә мондый гаепләр тага? Моның сәбәбе ачык: алар турыдан–туры безнең мәгариф вә тәрәкъкый хәрәкәтебезне туктата алмыйлар, шул сәбәпле, алар безгә яла ягып, безне хөкүмәткә хилаф хәрәкәт итүчеләр дип күрсәтеп, безнең милли хәрәкәтебезне туктатмакчы булалар. Менә, шуның нәтиҗәсе буларак, хәзер безнең арада тентүләр һәм кулга алулар бара. Моның сәбәбе: мөселманнар нинди булса бер–бер эшләре илә хөкүмәтнең шөбһәсе сәбәп булу түгел, бәлки бу юл илә рус җәмгыятенең фикерен бу якка түндереп, монда ышанычлы, тыныч түгел, дигән фикергә китерүгә кыстыйдыр. Болар әйтәчәкләр: «Мәмләкәттә тынычлык дип сөйләмә, хәлбуки, мәмләкәтнең хәле, халыкның бөек бер кисеме (мөселманнар) ниндидер бер усаллык хәзерлиләр» дип. Хәлбуки, мөселманнарда һичбер мондый эш юктыр. Мөселманнарда тентүләрдән, ялалардан без курыкмыйбыз. Чөнки тентүләр никадәр күбәйсә, бозылган кагыйдәләрне яхшылап карау шарты илә мөселманнарда Ватанга хилаф хәрәкәт, я җәмгыять юклык шулкадәр ачык беленер. Без бу яктан курыкмыйбыз, бәлки без бу тәбдирләр мөселманнар арасында урыс дәүләтенә яраклы булмаган фикерләр тудырмасын дип куркабыз. Минем мөнбәргә менүем шуның өчендер. Мөселманнар һичбер вакыт дәүләткә хилаф булмадылар. Без гел тәмам хөррият яклы булдык, фәкать һичбер вакыт дәүләткә каршы фикердә булмадык. Әгәр эшләр уңнар фикере буенча йөреп, хәзерге рухта дәвам итсә, Ватанга муафыйк түгел карашлар мәйданга килер. Сезгә мин моны баштан белдереп куям.

Ни өчен мөселманнар арасында безнең өстән донос ясаучылар бар? Хәзер мөселманнар кадим–җәдид исеме илә икегә бүленделәр. Гасырлардан бирле килгән наданлык фиркасы илә тәрәкъкыйга таба бара торган фирка бер–берсе белән көрештеләр.

Бу тәрәкъкый хәрәкәте арабызда моннан утыз ел элек башланды. Бу хәрәкәт саф мәдәни вә нәшер мәгариф хасиятендәдер. Бу

хәрәкәттә Ватан—дәүләт хилафына һичбер нәрсә юклыкны дәгъва итәм, исбат та итә алам. Бу хәрәкәт мәктәпләргә иҗек урынына ысул соутия (аваз) кертүдән башланды. Безнең, иске муллаларыбыз бу мәктәпләргә бөтен көчләре белән һөҗүм иттеләр. Әүвәл заманда бу искеләр хөкүмәт көче илә файдалана алачакларын уйламый иделәр, үзләре генә җәдидчеләргә әйләнә иделәр. Бара—бара бу, хөкүмәт нәтиҗәсе буларак, һәммә җирләрдә мөселман җәмгыяте хәйрияләр ачыла башлады. Муллалар кесәсенә керә торган акчалар шунда керә һәм шәкертләр файдасына тотыла башлады. Ә бу иске муллаларга ошамады.

Ләкин халкыбызда тәрәккый акрын бара, иске фикер әле тәмам бетерелмәде. Алар һаман бездәге мәгариф вә тәрәккый белән көрәшәләр. Әлегә кадәр әллә ни эшли алмаган ошбу кешеләр, уң фиркаларның котырту сәясәтләрендә бу юлда хезмәт итү өчен башка чараларга керешү мөмкинлеген аңладылар.

Менә минем кулымда татар телендә язылган доносның копиясе, һичбер иске мулла бу рәвештә донос яза алмый. Бу донос исламият хакында Европа голамәсенә генә хас рәвештә язылган, пантюркизм хакында да әйтелгән. Һич шөбһә юк: бу донос мулла тарафыннан түгел, бәлки уң фиркаларның бер әгъзасы тарафыннан язылып надан мулла аркылы хөкүмәткә җибәрелгәндер. Бер яктан тәрәккыйпәрвәр мөселманнар җәһаләт (наданлык) вә тәгассобка (фанатизмга) каршы көрәшәләр. Икенче яктан уң груһлар бу хәрәкәтне үзгәртеп ниндидер пантюркизм, иҗтабә (панисламизм) ислам кыяфәтендә күрсәтәләр. Уңнар моны турыдан—туры үзләре эшләми, бәлки надан муллалар аркылы эшли.

Тентүләр вакытында алынган китаплар алар я дини, я дәрес китаплары. Мин аларның тизрәк тикшерелүләрен сорыйм. Без үзебезгә ягылган зур ялаларны кабул итәргә теләмибез. Мин дәгъва кылам: муллалар арасында каршы организацияләр илә мөнәсәбәттә булган һичберәүне таба алмассыз. Мин моны бик ачык беләм.

Күптән түгел Буби мәдрәсәсендә ун мөгаллимне кулга алган иделәр. Мәдрәсә хуҗасы ун ел элек Буби мәдрәсәсенә яңа фикерне кертте. Моңрачы мәдрәсәләребездә гарәп теле, шәригать вә иске ысулда мантыйк гыйльме укыла иде. Менә тәрәккыйпәрвәр мул-

лаларыбыз хәзерге заманда бу фәннәр илә генә канәгатьләнү ярамаганлыкны, мулла булачак кешеләр җәгъръәфиядән, тарих вә табигать белеменнән дә бераз хәбәрдар булу тиешлекне белеп, мәдрәсәләренә бу фәннәрне дә керттеләр. Программаның болай үзгәртелүе иске муллаларга ошамады, алар моңарчы да донослар ясадылар, ләкин хөкүмәт аларны тыңламады. Ә менә хәзер хөкүмәт бу доносларга игътибар итә.

Мин сорыйм: ник Буби муллаларын гаепләре расланганчы ук төрмәләргә яптылар? Арестовать итүчеләр городовойлар, исправниклар бит, ә алар татарча да, гарәпчә да белмиләр.

Шуңа күрә, кулга алынган мөгаллимнәрнең гаепләре юклыкны мин дәгъва кыла алам.

Бу мәдрәсәдән шөбһәләнү бәгъзе тирә—як авыллардагы муллаларның доносы астында чыкты. Доноска да Буби мәдрәсәсендә программ яңартып, анда бик күп укучылар җыелганы хәлдә иске муллаларның мәдрәсәләре бушап калуы сәбәп булды. Шулай итеп, сез Буби мәдрәсәсендә, ябылмакта булган башкаларда да Ватанга хилаф диярлек һичбер нәрсә таба алмассыз.

Әфәнделәр, сез халык вәкилләре сыйфатында безнең арабыздагы хәлләрне белергә тиешле булганга мин боларны сезгә сөйлим. Ләкин урыслар арасында татар теле вә әдәбиятын белүчеләр бик аз, бәлки юк дәрәҗәсендәдер. Шул сәбәптән урыслар бездән аңламый шөбһәләнәләр. Безнең өчен мәзкүр якларга мөмкин кадәр тиз, татарча белүчеләр җибәрелергә кирәктер. Күптән түгел Уфа—Оренбургта мәдрәсәләр тәфтиш булды. Моны татарча белмәгән бер маэмур — чит телләр департаментындагы чиновник Плотников тикшерде. Аның тәрҗемәчесе дә татарчаны чак—чак кына белә иде. Үзләре һичнәрсә белмәгән кешеләр нинди тэфтиш ясасыннар? Үзләре дә саташып бетәләр, җитмәсә, безнең өстебезгә кара яккан кешеләрдән ярдәм сорарга мәҗбүрләр. Без тәфтишләрдән курыкмыйбыз, милли хәрәкәтебезнең нидән гыйбарәт булганын ачык белүне телибез, хәрәкәтебезне тикшерегез, фәкать һичбер гаебебезне белмәс борын безгә Ватанга һәм хөкүмәткә хилаф кеби зур бер гаеп япмагыз.

Әфәнделәр, нинди генә эшләр кылынса да, арабыздагы тәрәкъкый вә мәдәният хәрәкәтен туктата алмаслар. Чөнки русларның

бик бөек мәдәни катламы безгә мәхәббәттәдер. Гомумән, мәдәнияттә тәрәкъкыйны туктату мөмкин түгел. Бездә милли мәгариф хәрәкәте башланды да нык тамыр да җәйде, инде безнең уннарча матбагаларыбыз, гәҗитләребез, журналларыбыз вөҗүдкә килде. Бу кадәр мәдәният коралларына ия булган бер милләттәге хәрәкәтне басу мөмкин түгелдер. Мондый каты тәдбирләр вә төрмәләр илә хөкүмәтнең кылачак бердән–бер эше бинаның беренче катында булган китап кибетләрен, матбагаларны икенче түбәнрәк (идән астына) төшерү генә булачактыр. Фәкать бу – мәмләкәт өчен мотлуб булган эш түгелдер. Мин нотыгымны тәмамлап әйтәмен: арабызда Ватанга каршы һичбер хәрәкәт юктыр, хөкүмәт бер яктан, уңнарның котыртулары сәбәпле булган доносларга ышанып шикләнсә, икенче яктан, тәме киткән поляк, яһүди мәсьәләләре янына яңа бер мәсьәлә – мөселман мәсьәләсе дә тудырырга теләп йөрүчеләр дә юк түгел. Граф Бобрынский миңа: «Арагызда чуалу һәм хәрәкәт бар. Без моңа туктатырбыз», – дигән иде. Димәк, Бобрынскийныц шушы ялгыш фикере вә хәбәрсезлеге аркасында хәрәкәтне туктатмакчы булалар. Ләкин бездәге милли хәрәкәтне һичберәү туктата алмас, рус милләтенең мәдәни кисеменең ярдәме илә тәрәкъкый хәрәкәтебез алга баруда дәвам итәр.

«Йолдыз». 1911, 655 сан, 10 март.

*4. Садри әфәнде Максудовның Думада исереклеккә каршы закон төзегән вакытта сөйләгән нотыгы («Нур» гәзитеннән).*

Максудов: Әфәнделәр! Мин баштан ахыранача Дума әгъзасы Челышевның поправкасын тәкъвия кылам. Сәбәбе шул: әфәнделәр, барыгыз да беләсез, ислам дине исерткеч эчүне катгый тыя. Шундый тыю аркасында мөселман халкы шушы көнгә кадәр аеклык белән яшәп килә. Шунлыктан әхлак вә гаилә мөнәсәбәтләре дә борынгы ата–бабалардан калган мөкатдәслекләрен ташлаганнары юк. Простой мөселман халкы белән эш итеп күргән кешеләр, хосуса, татар, башкорт солдатларыннан денщик тотып күргән офицерлар, мин уйлыйм, минем сүзләремне сөйләрләр иде. Моңа кадәр мөселман халыклары аек иде, шуннан

әхлак җәһәте дә башка халыкларга караганда өстен иде. Хыянәт дигән нәрсә бик аз була торган иде. Хәзер дә безнең ата—бабаларыбыздан калган садә вә бик нык иске гореф—гадәтләребезгә көннән—көн зәгыйфьлек кыла башлады. Алар ничек тә безне үзләренең шул аракы кочагына өстерәп кертмәкче булалар.

Әфәнделәр, мөселман авылларында аракы кибетләре (кабак) ача башласалар, без җиңел генә разый булып калмаячакбыз. Чөнки ул кабак дигән нәрсәләр халыкны аздырып эштән чыгара торган нәрсәләр.

Мөселман авылларында әле дә сез, шушы көнгә кадәр казенный кабактан башка бер төрле дә мәдәният галәмәте таба алмассыз. Рус мәдәниятенең бердән—бер күренгән нәрсәсе булса, ул да — шул монополия — аракы галәмәтләре.

Башка мәмләкәтләрдә һәрвакыт сәясәт белән мәдәният бик тату баралар. Шунлыктан берсенең зарарын икенчесенең файдасы каплый. Әмма безнең хөкүмәт сәясәт белән мәдәният арасында...

Без, ул кабак башына куя торган «Казенная винная лавка» дигән сүзләрне мөселман авылында күрсәк җыламый түзә алмыйбыз. Чөнки без бик яхшы беләбез: ул кабак дигән нәрсәләр, халыкны аздырып, диннән чыгара торган нәрсәләр генә. Аның барлык әһәмияте дә шунда.

Әфәнделәр, шушы соңгы берничә ел эчендә бер авылдагы яшүсмерләрнең әллә никадәр бозылганнарын мин үз күзем белән күреп беләм. Гомумән, хәзер инде бездә икенче дәвер башланды. Аракы сәясәтенә тәрбия кылынган яңа үсмерләр дәвере.

Мөселман авылларында, хосуса, башкорт авылларында эчкән кешене эчертү бик кыен түгел.

Әфәнделәр, менә шундый бер хәлнең мәйданга килүе бик ярашып бетә торган эш түгел. Без эчми идек. Бу — безнең күңел юата торган бер нәрсәбез инде... Әфәнделәр, мин моны җан ачуым белән генә әйтәм. Юкса, мин үзем асыл рус мәдәниятен бик тәкъдир итәм. Һәм киләчәгенә бик зур ихтирам белән карыйм.

Рәис: Гомуми мәсьәләгә күчмәгез, поправка турында гына сөйләгез.

Максудов: Мин әйтәм: башка мәмләкәтләрдә һәрвакыт сәясәт белән мәдәният бик тату баралар...

Рәис: Мин Сездән икенче мәртәбә үтенәм, поправкалар турысында гына сөйләгез, гомум мәсьәләгә кермәгез.

Максудов: Менә шул фикергә бинаи мин Челышев җәнабләренең бу поправкасып рәд (кире кагу) кылам. Аның өчен бу мәмләкәтләрдә... (Садри әфәндене нотыгын бу урында бераз кыскартырга туры килде). Аракы эчәргә кабак ачканчы мәктәп бирегез, гыйлем, мәгариф бирегез, дим. Бу бит рус халкының бурычы.

Сыра, аракы кибетләрен ачуны туктатырга кирәк, чөнки безнең халык, бу кибетләр ачылганда, һәрвакыт, приговор җыя. Хәзер исә бу кибетләрнең ябылуын сорый, әмма беркайчан да мөселманнарның таләпләре искә алынмый.

Мисал өчен сезгә бер авылда ачылган аракы кибетен ябу хакында мөселман Идарәи Руханиясе тарафыннан бирелгән бер гаризага каршы налог җыя торган идарә тарафыннан бирелгән бер җавап укыйм. Сез шуннан андый гаризага ничек җавап бирелгәнен күрерсез.

«Андый халык аракы эчәргә өйрәнгән җирләрдә без ул кибетләрне яба алмыйбыз. Без тик сату булганлыктан үз расходын үзе күтәрә алмаган җирләрдә генә ябабыз», диләр. Мөфтигә бирелгән җавапта: «Оренбург мөселман Духовное собраниесенең Пермь губернасы Гундер авылындагы аракы, сыра кибетләрен ябу хакындагы таләбе кабул ителә алмыйдыр. Чөнки андагы аракы кибетендә елына 6,800 чиләк аракы сатыла. Авылның, үз халкыннан башка унлап чит авыл кешеләре шуннан аракы ала. Гыйнварның 25 ендәге ярминкәсе, атна саен базары була. Акцезный надзорның хәбәр бирүенә караганда ул авылга елына 100.000 кадәр кеше килә икән. Аннан сон, базар көннәрендә елына 300 чиләк кадәр хәмер (монысы инде аракы өстенә) сатыла икән. Имза: малия министры урынына министр иптәше».

(Садри әфәнде нотыгының ахырында бер доклад укып, анда да мөселманнар өчен мөтлүп булмаган бер фикер барлыгын белдерә).

«Йолдыз». 1911, 764 сан, 6 декабрь.

*5. III Дәүләт думасының 20 февраль мәҗлесендә сөйләгән нотыгы (1910 ел, 20 февраль).*

...Хөкүмәтнең халык вәкилләре, бигрәк тә, мөселман вәкилләре сүзләренә бик аз илтифат иткәнен белгәннән соң миңа чыгып сүз сөйләүдә файда юк.

Әфәнделәр, мин сезнең алдыгызга мөселманнарның тыныч мөнәсәбәтләренә зарар китергән вакыйгаларны санап тормыйм, безнең мәдрәсәләребезнең дә ничек ябырылганнарын, мәктәпләребездән ничек итеп мөгаллимнәрне куганнарын сөйләп тормыйм.

Бу җәфаларның җөмләдән берсе – мөселманнарның миссионерлардан күргән җәберләредер.

Әфәнделәр, әгәр безнең берәребез бу мөнбәргә менеп бу турыда сөйли башласа, иптәшләр тавышлана башлый.

Мөселманнар миссионерларның сәясәткә катнашуларыннан, аларның руслаштыру сәясәтенә катышуларыннан шикаять итәләр. Без, мөселманнар, христианлык хадимнәренең хөкүмәт агентлары булуларыннан шикаять итәбез.

Ошбу соңгы ун ел эчендә хөкүмәтнең мөселманнар хакындагы сәясәте мәшһүр миссионер Ильминскийның киңәше илә йөртелде. Мин инде Победоносцев заманында никадәр мәктәпләрнең ябылганын, мөселманнарга газета–журнал чыгаруга рөхсәт бирелмәгәнлеген сөйләп тормыйм.

17 октябрь манифесты игълан ителгәннән соң миссионерларның золымыннан котылып тыныч кына яшәрбез дип уйлаган идек. Ләкин без ялгыштык. .

17 октябрь манифесты чыкканнан башлап, ошбу көнгә кадәр, хөкүмәт хәзерге көндә халык вәкилләренең бар икәнлегенә карамыйча, православный миссионерлар тарафыннан тәкъдим ителгән фикерләргә иярүен дәвам итә. Шушы көнгә кадәр хөкүмәт мөселманнар хакындагы мәгълүматларны миссионерлар кулыннан ала.

... Күп руханиларның, халык арасында нинди хәрәкәтләр барлыкны күзәтеп торганлыгы безгә мәгълүм.

Казан шәһәре Духовная академиясенең ректоры Алексей җәнабләре:

«Русия мөселманнары арасында панисламизм фикере бик куәтле бара», ди.

Әгәр хөкүмәт, бу әфәнденең сүзенә игътибар итеп, хариҗия департаментының мөселманнарның хәлләрен тәфтиш итү, турысын гына әйткәндә, мөселманнарның милли хәрәкәтләре илә көрәшү өчен хосусый бер комиссия ясаган булмаса, мин андый докладларга күп әһәмият бирмәгән булыр идем. Алексейның фикере шуннан гыйбарәт: «Русиядәге мөселманнар панисламизм белән шөгыльләнәләр. Соңгы заманда мөселманнар бик күп мәктәпләр ача башладылар, гәҗитә–журналлар нәшер итәргә тотындылар, мөселман балалары гимназияләргә вә башка гали мәктәпләргә кереп укый башладылар. Мәгариф эшләренә зур игътибар бирәләр. Димәк, болар иттихаде исламга (панисламизм) тырышалар.

Әфәнделәр, мин аңлый алмыйм: нәрсә соң ул панисламизм?

Мин мәгариф эшенә әһәмият бирү илә иттихаде ислам арасында бер уртаклык булуны аңлый алмыйм.

«Яшьләр исламны искедәге сафлыгына кайтарырга тырыша, чөнки исламның тарихы әүвәлдә кан илә тәмам буялган. Димәк ки, исламны иске хәленә кайтару илә иттихаде мөкаддәсә иҗтиһад итәләр», ди Алексей. Аныңча, исламның эчтәлеге фәкать сугыштан гына гыйбарәттер.

Исламның әүвәлдәге саф тәрәкъкые вә саф мәдәнияты бар.

Русиядәге яшь мөселманнар исламны әүвәлге хәленә кайтарырга теләгәндә, алар аның мәгариф һәм мәдәниятын кайтарырга телиләр. Бу – саф ислам гына.

Алексей: мөселманнар җәмгыяте хәйрия дигән булып, төрле җәмгыятьләр ясадылар, дип тугыз төрле җәмгыять исемнәрен саный.

Әмма бу җәмгыятьләр сәяси җәмгыятьләр дә, панисламизга караган җәмгыятьләр дә түгел. Ләкин үз мәгълүматләрен ул чит ил мөхәррирләреннән җыя. Казан мөселманнары турында бер нәрсә белми.

Әфәнделәр, бу көндә бу департамент мөселманнар белән ничек көрәшергә кирәклеген хәл кылу белән мәшгуль. Алар безне милләт вә диният җәһәтеннән икегә аерып милләтебез илә көрәшергә, диниятебез өчен бер төрле хөррият бирергә фараз итәләр.

Әфәнделәр, Русия мөселманнарының һичбер вакытта милләт илә динне аерганнары юк. Әгәр Русия мөселманы «мин мөселман», дип әйтте исә, аның тәхетенә милләт гадәтләре илә динният һәр икесе керә.

Миңа вә минем иптәшләремә бу мөнбәрдән моңарчы яһүд ислам динендә торучы русиялеләргә, бәлки ислам динендә торучы вә үз гадәтләре, вә үз горефләре илә яшәүче хосуса бер милләт бар икәнлеген игълан итәргә бу көнгә кадәр туры килмәгән иде.

Хәзер менә мин моны әйтәм, һәм безнең авызыбызны томаламыйча моны әйтүдән туктамаячакмын.

Сезнең каршыгызда ислам динендә яшәүче бер милләт бар. Безнең аерым бер милләтемез барга күрә һәрвакытта үзебезнең лисанымызны, үзебезнең әдәбиятымызны нәшер итәргә иҗтиһад итәчәкбез һәм үзебезнең рус гражданы булып торырга никадәр хакыбыз булса, шулкадәр хакыбыздан истифадә (файда) итеп башка милләтләр яшәгән шикелле яшәячәкбез.

Шул сәбәптән мин сезгә игълан итәм һәм хөкүмәткә тәнбиһ кылам; безнең милләтемезгә, әгәр дә мәүҗүд исә безнең милли хәрәкәтләребезгә каршы көрәшергә маташу, пычрату, безнең динебез илә көрәшү, аны пычрату булып күренәчәктер. Хөкүмәтнең, бигрәк тә, хәриҗия департаментының динебезне милләтебездән аеруы булачактыр.

Без, бердән мөселман, икенчедән, хосусан бер милләт булып яши алачак һәм яшәячәкбез. Мин моңа ышанам.

Без Иван Грозный заманындагы кылыч һәм ут илә куркытып православныйга көчләп иҗтиһад кылынган заманнарда чыдап кала алганны, бүгенге көндә департаментның хәйлә вә мәкерләренә генә чыдап кала алырбыз.

Мин әйтәм: без үзебез бер милләт булып Россиядә яшәячәкбез.

«Йолдыз». 1910 ел, 515 сан, 12 март.

*6. Садри әфәнде Максудовның дахилия нәзарәте сметасы каралганда сөйләгән нотыгы (1912 ел, 3 март мәҗлесе).*

Мөхтәрәм халык вәкилләре!

Мин дахилия назәрәтенең мөселман халкына кагылышлы булган эшләре хакында гына сөйләячәкмен.

Без, мөселман фракциясе вәкилләре бу мөнбәрдән өзлексез мөселман халкы турысында сөйли башлагач, сезнең күбегез хөкүмәт миллият вә дин аермасына карамый, һәммә халыкка мөгалләмәсе бертигез, ни өчен мөселманнар хакында булган сәясәтенә генә аерып сөйләргә кирәк, дисез.

Без бөтен Русия халкы күрә торган кысынкылыклардан башка, фәкать мөселманнарга гына махсус кысынкылыклар күрәмез. Һәр халкының кыйммәтле вә мөкатдәс нәрсәләре була. Гадәттә, хөкүмәт никадәр хәрәкәт тарафында булса да халыкның бу мөкатдәс эшләренә катнашмый, аларга тими. Бер халыкның ана теле, әдәбияты, мәктәбе вә башка нәрсәләре ул халыкның мөкатдәс нәрсәләредер. Ләкин соңгы вакытта боларга һөҗүм бара. Безнең мәктәпләребезне, әдәбиятыбызны һәм безнең иң әүвәл дөнья вә гыйлем белән танышкан вә без кечкенә вакыттан ук анабыз сөйләшкән телне кыса башладылар.

Хөкүмәтнең безнең хакта тоткан сәясәтенең сәбәпләрен һәм аның нәтиҗәләрен сөйләүдән тыелам, мин фәкать бер ел эчендә генә (мамурларның) чиновникларның безгә никадәр (законга) хилаф кысынкылыклар ясаганын санап чыгуны үземә бурыч дип беләм.

Фәкать бер ел эчендә ошбу кешеләрдә тентү вә хәбәсләр ясалды: Москва институтында төрки теле мөгаллиме Хөсәен Сабри Айвазовта, әүвәл тентү ясап, соңра кулга алып төрмәгә утырттылар. Соңынан Казан муллаларыннан Г.Апанаев һәм Г.Галиевта тентү ясалып, әллә никадәр язу китаплары алынды. Вятка губернасы Буби авылы мәдрәсәсеннән Габдулла вә Гобәйдулла Нигъмәтуллиннар һәм ун мөгаллим кулга алынды.

Рәис: Кыскарак сөйләсәгез иде.

С.Максуди: Яхшы. Миңа рәис барлык фактларны да санап чыгарга рөхсәт итми, ә алар миндә бер дәфтәр.

Барлыгы бер ел эчендә йөз илле җирдә тентү ясалды, әллә ничә мәктәп, берникадәр матбага, нәшер, мәгариф җәмгыятьләре ябылды.

Йөз илле мөселманда тентү ясалган, җитмештән артык зур мәктәпләр ябылган, иң зур газитә вә журналлар туктатылган. Фәкать шушы бер ел эчендә шулкадәр муллаларны борчып, шулкадәр мәктәпләрне япканны күргәч, ихтыярсыз, түбәндәге ике фикергә киләсең: йә рус хөкүмәте безнең мәдәниятләнүбезне һәм алга барубызны теләмичә, ничек булса да, шуңа каршы тормакчы була, яисә мөселманнар арасында Русия дәүләтенә каршы бер хәрәкәт, бер фикер бар, һәм гадәттән тыш чаралар илә шуңа каршы торурга кирәк дип яңлыша. Минемчә, бу фикернең һәр икесе дөрес. Гомумән, күптәнән бирле хөкүмәт безнең мәдәниятләнүебезне басарга тырыша. Хөкүмәт Русия мөселманнарының тәрәкъкый итүен, алга баруын теләми. Ләкин безнең мәдәни хәрәкәтләремез хәзер бигрәк тә гакыл илә эшләнә. Чөнки безнең бу хәрәкәтемез каршы торур өчен кыйлынган эшләр панисламизм бар дип уйланганлыктандыр.

Хәзер уңнар һәм хөкүмәт, мөселманнар арасында панисламизм дип атала торган куркынычлы бер хәрәкәт булганга күрә, без хәзер мөселманнарны кысу хакында каты эшләр кылабыз, диләр. Мөселманнар арасында шундый куркынычлы хәрәкәт, хөкүмәткә каршы берләшкән бер фирка бармы дигән сөальгә каршы алар: бар, ә без: юк, дибез.

«Бу һәммә мөселманнарны мәдәният вә сәясәт җәһәтеннән берләштерергә тырыша торган бер хәрәкәт». Бу документта панисламизм дип атала торган бу хәрәкәтнең, бигрәк тә Волга–Кама әтрафында таралганлыгы бәян ителгән. Димәк, бездә панисламизм бар дип гаепләү, Волга–Кама татарларын, һәммә мөселманнарны мәдәни вә сәясәт җәһәтеннән берләштерергә тырышалар, дип гаепләү буладыр.

Әфәнделәр, мин белмим, мәдәният җәһәтеннән артта, администрация ягыннан кысылган, икътисади яктан ярлы булган өч–биш миллионлы Волга–Кама буендагы татарларның бөтен җир йөзендәге мөселман халкын берләштерүгә тырышуы мөмкинме? Бөтен мөселман халкын берләштерү ул ни дигән сүз? Бу – Филиппин мөселманнарын, һиндстан мөселманнарын, Азия, Африка вә башка җирдәге мөселманнарны берләштерү дигән сүз. Мәдәният җәһәтеннән артта, икътисади җәһәттән ярлы булган өч–биш мил-

лионлы Волга–Кама мөселманнарының Азия вә Африканы берләштерү шикелле шундый зур берләшмә белән шөгыльләнүе мөмкинме? Бу А.Македонский, Наполеон кебек даһиларга да мөмкин булмаган эш.

Безне, икенчедән, чуалышлар ясарга тырыша торган халык дип тә гаеплиләр. Бу бит нәрсәдән булса да аерылырга тырышу дигән сүз. Димәк, безне Русиядән аерылырга тырышалар, димәкче булалар.

Идел буенда яшәгән өч миллионлы татарның йөз миллион урыс халкына эчендә кысылган һәм 16 нчы гасырда Русия хакимлеген кабул итеп, шул дүрт гасыр эчендә тыныч һәм иттифак илә яшәгән мөселманнарның кинәттән Азия белән Африканы берләштерергә тырышуы мөмкинме соң? Мондый сүзләрне уйнап кына сөйләргә мөмкин, әмма чынлап әйтергә ярамый. Бигрәк тә шул сүз аркасында тыныч кына яшәгән халыкны кыса башласалар.

Әгәр дә панисламизмның барлыгы хакындагы ялгыш фикерләр шул кысуларга сәбәп булмаса, мин һичбер вөҗүде булмаган хыялый панисламизм хакында сөйләп тә тормас идем. Соңгы елларда булган бу кысуларның һәммәсенең баш сәбәбе – панисламизм бар, дип гаепләүдәдер. (Бу вакытта Пуришкевич кычкыра).

Шулай, әфәнделәр, һәммә мөселман халкы мәдәният вә сәясәт ягыннан берләшү–берләштерү мәгънәсендә булган панисламизмны, өч миллионнан гыйбарәт булган Идел–Кама буе мөселманнарына сылтарга һич мөмкин түгел. Мондый зур фикерне без зыялылармы, әллә анда зур фикерләргә һәрвакытта ерак тора торган гавам халкымы уйлап чыгарган? Мөселман зыялылары, эшкә ашмавы күзгә бәрелеп торган мондый фикер илә бер дә мәшгуль була алмыйлар.

Әфәнделәр, панисламизм бер хыял, әүвәл сәясәтләнеп маташкан миссионерларның уйлап чыгарган нәрсәседер. Панисламизмның һич булганы да юк, һәм хәзер дә юк. Бу фәкать әсасе мөселманнарга дошман булган сәяси миссионерларның мәкаләләрендә генә күренә.

Әфәнделәр, сез хәзер панисламизм фикере кайдан чыккан, һәм аның вөҗүде булмагач, ни өчен соңгы вакытларда уң гәзитәләр аның хакында күп яза башладылар? – дип сорый аласыз. Панисламизм – сәясиләнгән рус миссионерлары уйлап чыгарган нәрсә. Бу фикер әүвәлдә дә булган. Ул хакта үзләре мөселман булмаган, шәрык галәмен тикшерүче кешеләр күптән язганнар. Алар: пангерманизм булгач, ни өчен панисламизм гына булмаска тиеш, дип уйлаганнар. Ләкин ачыктан–ачык панисламизм фикере бар димәгәннәр, бәлки булырга кирәк, дип фараз кылганнар.

1908 елга кадәр миссионерлар әдәбиятында панисламизм дигән сүз юк. Алар безнең муллалар христианлыкның таралуына каршы киләләр, диләр.

Миссионерлар, бигрәк тә Казан миссионерлары, Русиядә сәяси роль уйнарга һәм рус хөкүмәтен агрессивный политика юлына кертергә телиләр. Бу максудларына алар үзләре теләгән микъдарда ирештеләр.

Столыпинның миллият сәясәте тотканлыгы мәгълүм булгач та, һәм Думада милләтчеләр партиясе ясалып, Кружинскийлар, Бобрынскийлар баш булганны күргәч тә, безнең сәясәтләнүне миссионерларыбыз үзләренә эш башларга вакыт җиткәнне һәм инородецлар хилафына нинди сүз сөйләсәләр дә Петербургта ышаначакларын аңладылар. Һәм 1908 елдан соң хөкүмәтне куркыта башладылар. Казан миссионерлары хөкүмәткә, татарлар арасында бер хәвефле хәрәкәт бар дип докладлар яза башладылар (копияләре миндә бар).

1910 елда Казанда миссионерларның съезды булды. Түбәндәге резолюция (татарларга каршы чаралар) кабул ителде.

1) Епископ Гурий ярлы булганга күрә, һәр елны хәзинәдән ярдәм бирелүне сорарга. Панисламизмга каршы торыр өчен булган чараларны кулланырга. 2) Вяткадагы миссионерларны тәрбияләү өчен хөкүмәттән ярдәм сорарга. 3) Исламиятка каршы торыр өчен татарлар арасында чиркәү мәктәпләрен күбәйтүне сорарга һәм Казандагы комиссиягә биш мең, Сембернекенә өч мең, Самара, Оренбург, Тобол, Омскка берәр мең сум хәзинәдән ярдәм бирүне хөкүмәттән сорарга. 4) Инородецлар булган епархияләрдә һәр өязгә окружной миссионерлар тәгаен итәргә. 5) Миссионерлар җәмгыя-

тенә руханилардан башка земстволарда һәм хөкүмәт, һәм төрле оешмаларда хезмәт иткән дөньяви кешеләрне чакыру да кирәк. 6) Инородецлар һәм алар арасында тора торган руслар өчен закон бозу турысында христианлыкның әсасе һәм исламиятка каршы дәлилләр бәян ителгән рисаләләр чыгару да бик мөһим. 7) Кырымда, Кавказда һәм кыргызлар арасында бәгъзе фамилияләргә бирелгән артыклыкларны бетерүне югары начальстводан үтенергә. 8) Яшь татар матбугатында панисламизм фикеренә каршы торыр өчен журнал чыгарырга. 9) Русиядәге һәм читтәге мөселман матбугатында нинди фикерләр барлыгын белдерү өчен даими бер газета нәшер итәргә. 10) Татар гәзитә—журналларының татар вә русча да чыгарылуларын хөкүмәттән сорауны Синодтан үтенергә. 11) Сайлау вакытында мөселманнар христианнар илә бер куриягә кермичә, аерым курия ясасыннар иде. 12) Хәзер дә эшләгән мөселман мәктәпләрен хөкүмәт нәзарәтенә тапшырырга.

Панисламизмга каршы торыр өчен җыелган миссионерлар съездының карарлары шушылардыр. Ә менә панисламизмга каршы карарлар түгел бит болар, ә турыдан—туры исламиятнең үзенә каршы. Әгәр миссионерлар съезды ясап, ниндидер карарлар кабул итеп тә, ул карарлар кәгазьдә генә калса, һәм хөкүмәткә мөселманнар хакында нинди сәясәт тотарга кирәклеген тәгаен итмичә, тыныч кына үз фикерләрен таратсалар, бер нәрсә дә булмас иде. Без моңа да риза булыр идек. Ләкин безнең миссионерлар аның илә генә шөгыльләнмиләр, аңа гына канәгать итмиләр. Алар хәзер бигрәк тә хөкүмәтнең сәясәтенә тәэсир итәргә тырышалар, һәм Столыпин вакытында бу максудларының күбесенә ирештеләр дә. Алар Столыпинның инородецлар хакында йомшаклыгын һәм инородецларга каршы төрле эшләр кылырга хәзер икәнлеген күреп, аны агрессивный политика юлына кертмәкче булдылар. Икенче яктан, алар Столыпинның баһадирлыгын да беләләр. Әгәр аңа мөселманнар тыныч тора дисәләр, гәрчә муллалар христианлыкны тарату эшендә миссионерларга каршы торсалар да, Столыпин агрессивный политика юлына кермәс иде. Менә Столыпинны шул юлга кертү өчен дә мөслманнар арасында шундый куркынычлы фикер хәрәкәте бар дип күрсәтергә тиеш тапканнар.

Шуның өчен панисламизм дигән хәятне уйлап чыгарганнар да. Менә миссионерлар съездының шул карарлары һәм дахилия вәзире Столыпинга биргән докларлары аркасында хөкүмәтнең игътибарын җәлеп итеп, дахилия нәзарәтендә панисламизмга каршы эшләр табу өчен махсусый Совещание ясатырга муафыйк булдылар. Бу Совещаниедә әгъзаларның күбрәге шул фикерне уйлап чыгарган Казан миссионерлары иде. Менә шул Совещание панисламизмга каршы бик күп чаралар эшләп чыгарды. Панисламизмга каршы торыр өчен дип зур чаралар, төбендә, бәлки панисламизмга каршы түгел, ә исламиятнең үзенә каршы иде.

Миссионерлар безнең илә башка диндәге халык булганнан түгел, бәлки башка бер милләттән булганга күрә каршы торалар.

Мин хәзер дөньяви чиновниклар тәшкил ителгән Совещаниедә панисламизмга каршы торыр өчен табылган чараларны зекер итәчәкмен. Шул вакытта бу документлар илә миссионерлар съездында бирелгән карарлар арасында аерма юклыкны мин сезгә күрсәтәчәкмен. Дөньяви чиновниклар Совещаниесе илә миссионерлар съездында бирелгән карарлар гына түгел, чарасызлык җәһәтеннән генә, хәтта заһри сүзләре илә үк бер—берсенә охшашлы. Хасыйл миссионерлар съездында панисламизмга каршы тору өчен ясалган чаралар, дөньяви чиновниклар тарафыннан бөтенләй кабул ителгән. Дахилия нәзарәтендәге Совещаниенең башы хәзерге дахилия вәзире Харузин иде. Ул, шаять, үзләре эшләгән нәрсәләрне икрар итәр. Мин Столыпин вә башкалар тарафыннан имза кылынып, панисламизмга каршы тору хакында вәзирләр Шурасында бирелгән докладны бөтенләй укып чыкмаячакмын.

Менә шул документта әйтелә:

«Югарыда зекер ителгән нәрсәләргә корылган (ягъни панисламизның вөҗүденә бинаи) Совещаниедә әйтелә:

1) Мөселман халкы белән аралаш булган Идел буе губернасындагы миссионерлар һәм рухани мәгариф тарату өчен булган җәмгыятьләргә (мисал Казандагы Гурий братствосы шикеллеләр) акча илә ярдәм итәргә. Менә бу дөньяви чиновниклар тарафыннан панисламизмга каршы тору өчен булган беренче чара.

2) Казан Духовная Академиясендә хәзер дә мәүҗүд сүннәи шәркыя дәресеннән башка, укучылар мәхәлли (җирле сөйләш) шивәләр белән шимале рәвештә танышсыннар өчен, мәхәлләи шивәләрне тәгълим кылырга махсусый бүлек арттырырга.

Икенче төрле әйткәндә, бу да шул миссионерлар академиясенә ярдәм бирергә кирәк дигән сүз булачак.

3) Искә алынган бүлеккә керү, гомуми кагыйдәләргә бинаи академиягә керергә хакы булган кешеләрдән башка, икенче вазарәт илә Духовная семинарияләрне һәм Урта мәктәпләрне бетергән кешеләргә дә мөмкин булсын.

4) Академиянең шул бүлеген бетергән кешеләргә инородецлар булган җирләргә христиан руханилар һәм миссионерлар булудан башка Духовная семинарияләрдә тел һәм дин мөгаллиме булуда да артыклык бирелсен.

5) Казанда хәзер мәүҗүд миссионерлар көрсиенә, Идел буенда дини вә әхлакый ихтыяҗларны үтәгәнгә күрә, шуның тәрбиясе өчен ярдәм бирелсен. Менә боларның да һәммәсе иганә бирү тугрысында, бу да панисламизмга каршы тору дип уйланылган чара.

6) Мөселман халкы булган епархияләрдәге Духовная семинарияләрдә, инородецларның телләре мәҗбүри дәресләр шикелле тәгълим ителсен.

7) Православныйларга исламга каршы тору максуды илә: а) мөселман халкы булган җирдәге чиркәү учительская школаларында закон бозу дөрестән дә ислам дине һәм аңа каршы христиан дине ноктаи нәзареннән җавапларда тәгълим ителергә тиеш, б) күркәм мөселманнар тарихын, гакаид һәм ышану исламиягә яраклы нәшер итәргә вә бу иң яхшы язучыга хәдия бирергә кирәк.

8) Инородецларга мәдәни вә дини рәвештә матбугат илә тәэсир итү өчен Казан Духовная Академиясе тарафыннан гавам аңларлык рәвештә православие рухында бер гәзитә, йә журнал чыгарырга рөхсәт бирелергә вә моның өчен ике–өч йөз сум кадәр ярдәм тәгаен итәргә.

9) Мөселман халкы күп булган епархияләрдәге һәм мөһаҗирләр булган җирләрдәге епископлар мөселманнарның һәм мөһаҗирләрнең бигрәк күп утырган җирләрендә торсыннар.

10) Мөселман халкы булган җирләрдә мәдәни вә дин хезмәтен арттыру вә тәкәвия (куәт өстәү) өчен: а) православие руханиларга махсусый ярдәм биреп һәм дини вә дөньяви чиновниклар тарафыннан рөхсәт алып, зурлар һәм балалар өчен православие чиркәү рухания муафыйк дини мәсьәләләр хакында мәсхәбәтләр басылсын, б) мәктәпләр янында китапханә вә уку заллары ясалсын, в) инородецлар бар җирләрдәге авылларда православие руханиларына мөгаен бер микъдарда стипендия тәгаен итеп, икътисади якларын яхшыландырырга. Бу да башкалар шикелле иганә бирү һәм панисламизмга каршы бер чара.

11) Мөселманнарның мәхәллә мәктәп вә мәдрәсәләреннән дингә кагылышлы булмаган гомуми фәннәрне, җөмләдән, рус телен дә чыгарырга, аларда фәкать ислам дине генә тәгълим итәргә һәм бу эшне тикшереп торуны гомуми мәктәпләр нәзарәтенә тапшырырга. (Бу вакытта уңнардан бәгъзеләре: «Җитәр инде, сәгать бер булды», дип кычкыралар).

Максудов: рәис миңа артык сөйләргә рөхсәт итми, шуның өчен мин хәзер туктыйм. (Рәис белән сөйләшәләр). Тагын берничә минут кына рөхсәт итегез инде, әфәнделәр. Шулай, мин ул документларның һәммәсен укып чыкмыйм. Бары зурракларын гына әйтәм.

Казандагы татар мәктәпләрен хәзергечә калдырып, рухани һәм мәктәпләр нәзарияте вәкилләреннән попечительләр советы ясарга.

12) Мөселман халкы күп булган җирләрдәге мондый мәктәпләрне православный духовное ведомствосы нәзарәтендә ясарга (мондый урыннарны санап чыга). Оренбург идарәи руханиясе кул астында бик күп халык булганлыктан һәм бөтен халыкның эшен бер идарәгә генә тапшыру, дәүләт мәнфәгате һәм ислам динендә булган төрле халык мөнафигыioктаи назәреннән муафыйк булмаганлыкларыннан, мөселман идарәи руханиясен төрле җирләрдә ясау өчен ысулынча ислах кыйлу мәсьәләсен тикшерүне дахилия вәзарәтенә тапшырырга.

(Мәҗлескә тәнәфес бирелә).

... Әфәнделәр, панисламизмга каршы чаралар табу хакындагы документларны укыдым. Бу чараларның нәрсәдән гыйбарәтлеген,

шаять, сезнең күңелегез ятлап алгандыр. Совещаниенең панисламизмга каршы торырга ясаган тәдбирләре арасыннан бигрәк бер матдәсенә сезнең игътибарыгызны җәлеп итмәкче булам. Ул — 11 матдә, анда әйтелә:

«Мөселманнарның мәхәллә мәктәп—мәдрәсәләреннән дингә кагылышлы булмаган гомуми фәннәрне, шул җөмләдән, рус телен дә чыгарырга. Аларда фәкать ислам дине генә тәгълим итәргә һәм бу эшне тикшереп торуны гомуми мәктәпләр нәзарәтенә тапшырырга».

Әфәнделәр, бу карардан күренә ки, җентекле бер доклад зекер ителеп, бу эшнең ни өчен кирәклегенә дәлилләр китерелгәне. Ул докладта әйтелә: «Мөселманнар шикелле хосусыятле бер халыкның руханиларына дини мәгълүмәт бирү кирәк табылганлыктан, Совещание андый мәктәп вә мәдрәсәләрне, шөбхәсез, дәвам итәчәк дип белә. Ләкин шуның илә бәрәбәр, бу мәктәп вә мәдрәсәләр фәкать дини халәтләренә генә кайтарылырга тиешле һәм гомум диния белән башка фәннәр арасында ачык чик куюны Совещание тиешле табадыр. Гомум динияне тәгълим эшен мөселман руханилары карамагына тапшырып, бу эшкә хөкүмәт вәкилләре катнашмаячактыр. Ләкин шуның илә бәрәбәр мондый дини мәктәпләрдә гомуми фәннәрне укытуга юл калдырмаска кирәк. 1907 елның 26 нчы мартында патша хәзрәтләре тарафыннан тәсдыйк кыйлынган правила буенча мәктәп—мәдрәсәләрдә рус классы ясау мәҗбүри ясалган иде. Совещание бу мәсьәләне дә искә алды. Мәктәп вә мәдрәсәләрдә рус теле тәгълимен мәҗбүри итү хосусы бер максатка бина кылынган иде, хәзер мәүҗүд мөселман мәктәпләрен гомуми мәктәпләр рәтенә кертеп җибәрер иде. Ләкин бу максатны бик үк дөрәс дип әйтеп булмый. Чөнки шуның аркасында мөселман мәктәпләренең хакыйкә мәгариф бирә торган мәктәпләргә әверелеп китүе ихтимал. Ләкин ул бер дә кирәкле түгел. Аннан соң рус теле тәгълимен мәҗбүри ясау кабул ителмәде дә. Мөселман халкы аңа дингә каршы көрәш һәм көчләп руслаштыру өчен ясалган эш дип карады.

Югарыда зекер ителгән фикерләргә бинаи Совещание мәктәп вә мәдрәсәләрдә хәзер дә мәүҗүд рус классларын бетерүне һәм киләчәктә ачарга рөхсәт бирмәүне кирәк табадыр.

Менә, әфәнделәр, дәүләт мөнафигы файдасы өчен тирәнтен уйлап эшләнгән бу документларны укыгач, ирекле–ирексез, без Русия мөселманнары, безгә дошманлык күзе илә карый торгач, миссионерлар идарәсендә һәм чиновниклар хакта тоткан сәясәтләрендә һәрвакыт миссионерлар теләгенн иткән рәвештә хәрәкәт итәләр дигән фикергә киләбез.

Казанда булган миссионерлар съезды доклады илә хөкүмәт чиновниклары тарафыннан ясалган докладлар һәр икесе бер хакта, боларның һәр икесе миссионерлар җәмгыятенә ярдәм бирү, мөселман мәктәпләрендә җәгъърафия, тарих, рус теле вә башка фәннәрне укытудан, мәктәпләр ачарга рөхсәт бирмәүдән гыйбарәттер. Боларның һәммәсе «панисламизмга каршы тору өчен» дип эшләнә. Әйтсәгез лә, зинһар, бунын кайсы төше панисламизмга каршы тору өчен? Юк, бу бердән, исламияткә каршы тору өчен, икенчедән, мөселманнарның тәрәккыятенә, тәрәккыят хәрәкәтенә каршы тору өчен эшләнгән чаралар.

Менә, әфәнделәр, шушы докладлар һәм миссионерларның теләкләре аркасында дахилия нәзарәте панисламизмның барлыгына эшләде. Һәм губернатор вә башка чиновниклар буңа ничек каршы тору тугрысында юллар күрсәтте, шуннан соң губернаторлар вә башкалар панисламизм эзли башладылар, һәрнәрсәдә панисламизм шәүләсе күрә башладылар. Һәм һәммә губернатор, хәтта һәрбер становой пристав та панисламизмның мәркәзен табуда беренче булырга тырыша башладылар. Тентүләр, хәбәсләр, тыюлар башланды. Хосуса, бу эштә Вятка губернасы чиновниклары күп тырышлык күрсәттеләр. Анлар да панисламизмның мәркәзен эзләделәр, һәм панисламизмның мәркәзен таптылар. Ләкин сез кайда дип уйлар идегез? Алар йөз елдан бирле дини мәдрәсә булган Буби исемле бәхетсез, ярлы бер авылда панисламизмның оясын таптылар. Бу мәдрәсәдә дин белеменнән башка җәгъърафия, тарих һәм рус теле дә тәгълим итәләр. Вятка жандарм идарәсе бу мәдрәсәдә шундый гомуми фәннәр тәгълим ителгәнен ишеткәч, монда нәрсә дә булса булырга кирәк, мөселман мәдрәсәсендә үз ихтыярлары белән, үз акчаларына русча укыталар, җәгъърафия дә укыталар, монда панисламизм булырга кирәк, дип уйлый башладылар. Шуннан соң тирә–як муллардан Буби муллары панисла-

мизм илә маташмыйлармы, дип сораша башладылар. Җәгърәфия һәм рус теле укытуга хилаф булган муллалар да анда панисламизм булырга кирәк, дип җавап бирделәр. Анда җирне Кояш тирәсендә һәм үзенең күчәрендә әйләнә, дип укыталар, җирнең ничек күчәре булмак кирәк, бу, әлбәттә, панисламизм галәмәте, диештеләр. Бу доноста бу сүзләр шул рәвештә зекер ителгән.

Вятка жандармнары, Буби тирә—ягындагы дошман муллаларның сүзләренә ышанып, югары чиновникларны ирештерә башланганнар. Хәзер инде шул бәхетсез Буби муллалары хөкемгә бирелделәр. Иң әүвәл алар, хөкүмә тикшерүләрдән башка, хәбесханәләргә ябылганнар иде.

Аннан соң, инде киңәшсез эш булмасын өчен, хөкем эшен башладылар. Бу зур эш «панисламизм эше» дип аталадыр. Гүя ки, бу бәхетсез муллалар шул Буби авылыннан бөтен Русиягә панисламизм фикере таратып торганнар. Хәзер шуның өчен хөкемгә бирелделәр. Хөкем кайчан булачагы миңа мәгълүм түгел, ләкин алар ел ярымнан бирле Сарапул хәбесханәсендә ябылып яталар. Чиновниклар уйлап чыгарган бу панисламизмның юкка чыгачагына, мөселманнар арасында фәкать рус мәдәниятенә якынаю, тәрәкъкый итүгә тырышу хәрәкәте генә барлыгы мәгълүм булачагына без хәзердән үк ышанып куйган инде. Шиксез, бу хөкемнән соң чиновникларның панисламизм дип тапкан нәрсәләре юкка чыгачак.

Әфәнделәр, вак чиновник һәм бездәге фанатик адәмнәр, хөкүмәтнең панисламизм тикшерүе, безнең алга таба баруларымызны, җәгърәфия, рус теле вә башка шундый нәрсәләр тәгълим итүне тыюдан гыйбарәт дип белеп, зуррак җирләрнең һәммәсендә төрле доносчылар заһир була башлады, һәм ул доносчыларны вак чиновниклар бик яратып кабул иттеләр. Бер нәрсәгә сорау күп булса, аны эшләүчеләр дә күп табыла. Шуның өчен һәр җирдә панисламизм хакында донос ясаучылар бик күбәйде.

Бәлки сез күптән түгел «Речь» газетасында басылган бер хатны укыгансыздыр. Анда әйтелә: «Кубань чиркәсләреннән Хаҗи Талаш исемле кеше Парижда «Мусульманин» исемле газета нәшер итеп, шунда мөселманнарга панисламизм хакында төрле киңәшләр бирә башлаган. Кубань чиркәсләреннән дип йөри тор-

ган шул ук Хаҗи Талаш «Офицерская жизнь» да куркынычлы панисламизм хәрәкәте тугрысында мәкаләләр язган. Бу нәрсәләрне язарга Хаҗи Талашны нәрсә мәҗбүр иткәнлеге миңа мәгълүм түгел. Ләкин шулкадәресе бик ачык мәгълүм ки, Хаҗи Талаш бер гәзитәдә панисламизм хәрәкәте бар, дип куркытып, шул ук вакытта икенче гәзитәдә мөселманнарга панисламизм хакында төрле киңәшләр биреп язган. «Речь» гәзитәсенең үткән сәнә 24 декабрьдә чыккан 257 номерын укыган кешеләр, әлбәттә, буңа ышаначаклар. Әфәнделәр, шундый вак агентлар, төрле фанатик мөселманнар һәм нәмәгълүм адәмнәрнең донослары сәбәпле төрле җирләрдә хәбәсләр, тентүләр, мәктәпләрне ябулар башланды. Бу эшләр хәзергә кадәр дәвам итә. Бу сәясәт Столыпин вакытында башланып хәзергә кадәр дәвам итә. Совещаниедә әйтелгән тәкъдимнәр гыйльми рәвештә һаман әҗра ителә баралар. Бу шулай кирәк, дип эшләнми, бер башлангач, үзеннән–үзе бару тәртибе белән эшләнәме, анысын без белмибез. Ләкин ничек югарыда әйтелсә, шул ялгыш фикер аркасында безне кысулар, мәктәпләремезне ябулар, муллаларны, мөгаллимнәрне куулар, гәзитә вә матбагаларыбызны ябулар бара. Мин үзем дә, бу эшкә битарафлык илә караган кешеләр дә дәүләт мөнафигы ноктаи нәзәреннән бу сәясәтнең ялгышлыгына, ялганлыгына һәм рус дәүләтенең крепостына бик зур зарар китереләчәгенә ышаначаклар! Сез шул панисламизм аркасында яңа гына уянып килә торган мөселманнарның алга баруларына, тәрәккъый вә мәдәният юлларына каршы эш итәсез. Бу сәясәтнең төбе нәрсә икәнен хәзер күп кеше белә.

Күптән түгел миңа бер мулла бу хакта становой–пристав илә сөйләшкән сүзләрен әйтте. Пристав: никадәр тентүләр ясасак та сезнең арада панисламизм дигән нәрсә таба алмадык. Ләкин ул нәрсә безнең рус зыялылары арасында бик күп, дип әйткән. Ягъни, пристав бу сәясәтнең панисламизмга каршы тору өчен түгел, бәлки мөселманнарның тәрәккъый хәрәкәтләренә каршы икәнлеген үзеннән–үзе бик яхшы аңлаган. Һәм ул хаклы да. Ул үзенең аңлауында бер дә ялгышмаган. Әфәндәләр, сез бик зур ялгышлык эшлисез, шуның илә Русиянең киләчәгенә зур зыян китерәсез. Мөселманнарның тынычлык һәм буйсынучанлык ягыннан әллә кайчан артыклыклары мәгълүм булганы билгеле. Бу инде бик ис-

кергән вә шуның илә бик дөрес сүз. Бу шулай булган һәм башка сәясәт тотмасалар, хәзер дә шулай булган булыр иде. Ләкин, әфәнделәр, дөньяда шундый нәрсәләр бар ки, халыкның иң садыйк өлешен дә чуалта, иң тыныч гакылларны да дөрес юлдан ала һәм иң тыныч халык арасында да ышанычсызлык пәйда иттерә аладыр.

Әфәнделәр, һәркөнне күреп торасың, бер авылда һич сәбәпсез бер мулланы кулга алганнар, икенче авылда мәктәпне япканнар, өченчесендә бер дә зарарсыз дини китапны арестовать иткәннәр вә башкалар. Бу эшләр һаман тәкрар ителеп торалар. Ләкин, әфәнделәр, шуның аркасында рус хөкүмәтенең үзе өчен дә һәм без мөселманнар өчен дә бер дә файдалы булмаган хәлләр заһир булачактыр. Бу хәлләр ике елдан бирле һәркөнне тәкрар ителеп киләләр.

Әфәнделәр, мин сезгә ачыктан–ачык әйтәм: Русия мөселманнары арасында Русия дәүләтенә зарар китерерлек һәм аның мәнфәгатенә каршы һичбер төрле хәрәкәт вә теләк юк.

Әгәр дә буның дөрес түгеллеген исбат кыйла алсалар, шушы мөнбәрдән хөкүмәт вәкилләреннән берәрсе, яисә берәр депутат исбат кыйлсын иде.

Бу панисламизм дигән нәрсә хыялый бер нәрсә генә. Аны мөселманнарга дошман миссионерларга чынлап ышанып йөри торган кешеләр генә уйлап чыгарган. Бездә дәүләткә каршы һичбер фикер, һичбер хәрәкәт юк. Фәкать бездә бер теләк бар. Ул – әүвәлдә олуг Русия империясенең камил хокуклы хөр гражданы булуны теләүдән гыйбарәттер.

Без бу максудларга ирешәчәкбез. Чөнки теләсә нинди каршы эшләр кылынса да, егерме миллионлы бер халык гомергә кысылган хәлдә кала алмаячактыр. Кайчан булса да халык өскә чыгачак. Һәм һичбер вакытта халыкка каршы килми торган рус халкына шатлыгы илә бәрабәр камил хокуклы граждан булачакмыз. Моннан бары тик хөкүмәт чиновниклары һәм миссионерлар гына куркалар.

Мин уйлыйм: безнең милли тормышыбыз илә рус дәүләте арасында берсе–берсенә хилаф килерлек эш юк. Без һәрвакыт Русия дәүләтенең алга баруы, зураюы өчен, Русия гражданы уларак,

җәмгыять эшләрендә бергә йөриячәкбез. Безгә, үзебез теләгәнчә, бабаларыбыздан урнашып калган милли рухларыбыз илә үз халкыбыз һәм гаиләбез арасында тыныч яшәргә ирек кенә бирегез! (Суллар кул чаба.)

«Йолдыз» – 1912, 22 март.

## IV. С.Максудиның Милләт мәҗлесе ачылганда сөйләгән нотыгы

20 ноябрьдә Уфада Милли мәҗлес–мохтариятнең, төрек–татар кавеменең иң бөек, иң газиз, иң гали бер бәйрәме булып, көтелгән көн җитте. Бу көнне шанлы бер милләтнең олуг бер вәкилләре, тупланып, мәҗлесне ачты. Ниһаять, мәҗлес башланды. Мохтариятнең рәисе Садри Максудов җәнабләре ошбу рәвештә сүзгә кереште:

– Эчке Русия вә Сибирия мөселман–төрек–татарларның беренче Милләт мәҗлесе вәкилләре!

Моннан 3 ай элек Казанда булган съездлар, милләтнең бөтен эшен үзе идарә итергә дип карар биргән, 16 кешелек бер бюро сайлаган иде, һәм бу бюро да үз тарафыннан шушы өч төрле бу бөек вазыйфаларны йөкләтте:

1. Мохтариятне вәҗүдкә чыгару,
2. Мохтарият фикерен бөтен төбәкләрдә гамәлләтерү,
3. Милли–мәдәни кануннар чыгарачак Милләт мәҗлесен җыю.

Менә мохтарият комитеты шушы өч төрле бөек вазыйфаны үтәргә тырышты һәм үтәде. Мәгариф, малия, нәзарәтләренә җитәкчелек кылып аларга файда булды, милли тәшкиленә керешеп хәзерге, ярдәмчесез милләт фондына миллионнан артык сумма ясалды. Шулай ук, икенче вазыйфалардан булган, мохтарият фикерен бөтен төбәкләрдә гамәлләштерү юлында да тәкатеннән килгән кадәр эшләп, һәр төрле юллар белән мохтарият фикерен халыкка аңлатырга иҗтиһад итте вә хәзергә 6 мең өч йөз мәхәллә каршында мохтарият оешмалары белән аның әсасларын булдырды. Инде өченче вазыйфасы исә хакыйкатьтә бик авыр вә катлаулы булган, тарихта беренче Милләт мәҗлесен җыю, оештыру иде. Хәзер бусы да булды. Моны да җыйды. Менә берничә минутлардан соң мохтарият бюросы инде әзер милләтне, әфәнделәр, сезгә тапшыра. Сезгә тапшыру белән мәсгуд була.

Газиз милләтнең шатлыклы көннәре. Бүген шимал төрекләре өчен бөек бер көн. Бүген тарихта, урманнарга качып, степьләргә яшеренеп фәкыйрьләнгән, хурланган, хакарәтләнгән бер милләт өчен мисле күренмәгән олуг бер бәйрәм! Әфәнделәр! Хакыйкатьтә Казан, Астрахань ханлыкларыннан соң безнең халык бит бер милләт булып яшәүдән тәмам чыккан иде. Ул, хәзер бик олуг бер милләтнең калдыгы, соңы гына иде. Ул милләт терелер дә, бер көн үсәр дип кайсыбыз уйлаган?

Кара куәт безне изде, таптады. Ләкин белми иде ки, без тапталган вә аяк астында калган булсак та, әмма кавем нәҗипнең маңгаена болар язылган истикбали бер баласы идек. Зато, безне изүчеләр хәзер үз җәзаларын күрәдер дә инде. Ул куәт хәзер инде кайтмаска тиешле. Без, төрек–татарлар, бар куәтебез белән шул хакта тырышачакбыз.

Әфәнделәр, хәзер монда бер сөәль килә: без оешабыз, ләкин безнең бу оешуларыбыз яшәрме? Менә бу безгә гарәп галимнәре тарафыннан әйтелгән тавыш. Ләкин бу сөәльгә җавaптан шуны хәтерләргә кирәк, төрек кавеме кеби мәдәнияткә, милләткә омтылулар һичкемдә юк иде. Дөрес, боларның мәдәнияте бәгъзе җимерүчеләре дә, әмма тагын төзүче вә оештыручы исә гел үзебез булдык. Ничә генә төрек хөкүмәтен таптама, кисмә, әмма алар бервакыт мәйданга чыкты. (Моны тарих дәлилләр белән исбат итә). Менә, әфәнделәр, соңгы вакытта да күреклелек хакыйкатьтә түбәндә иде. Европалылар моны күреп сөенә, куана, төреклек бетә дип шатлана иделәр, хәлбуки, бу югалулар бер тынлык кына иде, хәзер ул уяна. Әйе, төрекләр бетмәде, бетми һәм фатыйха, ул бетмәячәктер!

Мөхтәррәм милләт вәкилләре, без бу гасырда хәятка яңа нигез салабыз. Ләкин шуны онытмаска кирәк, безнең күп вакыт хөкүмәтебез оешмый калуда тарихта ике хатабыз бар иде: берсе – без садә булдык, утырдык, алдандык; икенчесе – без иң элек хәлдә максудларны аладыр идек, ләкин шул максудны сакларлык куәтне башта хәзерләмидер идек. Менә шул ике тарихи хата безнең хөкүмәтебезне гел тарката килде. Инде шул хаталарны хәтеребездә тотып эшли башласак, моннан соң милләт, шөбһәсез, алга китәчәк.

Мөхтәррәм милләт вәкилләре! Хәзер берничә минуттан соң Милләт мәҗлесе ачыла. Менә шул тарихи газиз минутларда үткәнне искә төшереп алу да бурычыбыз дип беләм: безне мәдәни түгел диләр иде, ләкин бу сүз никадәр ялган! Мәсхуди сәхифәләрен укыганда мөселманнарыбыз бөтен ниятен күрүчеләр һәм Олуг бәк кеби тәрәкъкый иттерүчеләрне хәтердә тотучылар без, төрек милләтен, мәдәни түгел, дияргә ничек кенә бер батырчылык кылыр? Шулай ук тарихында Арысланнар, Тимерләр булган бер шанлы милләтне каһарман түгел дияргә дә бит һичкемнең генә дә телләре бармас! Ишетә, һичшөбһәсез, һәр яхшы як безнеке, ә һәр җимерү, ватуыбыз дошманнарныкы иде. Ләкин шунлыктан мин берничә минуттан соң ачылачак Милләт Мәҗлесенең олуг фикер белән ышаныч вә өмид, вә гайрәт белән тулган калебләр эчендә ачылуын теләр идем.

Үтмәс 20–30 ел, шушы эшләрне дөрес юл белән алып барганда төрек–татарлар хәйәте без уйламаган кадәр тәрәкъкый итә. Мин күрәм: һәр авылда яхшы мәктәпләр, уку заллары, китапханәләр, мәдрәсәләр, университетлар ачылыр. Мин күрәм: һәр җирдә шифаханәләр, ярдәмханәләр... һәм гүя шул вакыт милләт мохтарият бәйрәмен ясый, гүя шул вакыт, матур чәчәк кебек киенешкән кыз балалар да, милләт әһелләре белән милләтнең шул хәйәтенә нигез салучыларны да хәтер итә. Киләчәгебез якты! Истикбалыбыз якты! Менә шул хәлдә Милләт мәҗлесен ачыйк!

Мөхтәррәм Милләт вәкилләре!

Эчке Русия вә Сибирия төрек–татарларының беренче Милләт мәҗлесен ачтым! (Садри Максудиның бу сүзләре гаять озак вә самими алкышлар эченә күмелә).

«Йолдыз». – 1917, 1 декабрь.

## V. С.Максудиның эмиграциядәге эшчәнлеген чагылдырган материаллар.

*1. Джордж Гомбольт «Триумф Колчака будет приветствием России».*

Господин Максудов – глава 30 миллионов российских мусульман – высказал «Эклер» причины, в связи с которыми он борется с большевизмом.

В России живет около 30 млн. мусульман; в основном они живут в Туркестане или на Кавказе; около десятка находятся в Европейской части России и в Сибири. Они, после большевистской революции, образовали республику, возглавляемую господином С.Максудовым; этот опытный глава государства в данный момент находится в Париже.

Было бы несправедливым описывать этого мусульманина, говоря о подкладках его тюрбана, складках белой шерсти. Его фрак безукоризненного покроя, а усы, побритые на американский манер, позволяют увидеть, что он не отрицает даже самых современных западных привычек. Он весьма разносторонен (его культура разносторонняя) и он чаще цитирует Тэйна, Мольера или Вольтера, чем Коран. Наша цивилизация, как и наш язык — ему знакома.

Господин Максудов выглядит сведущим политиком и его гибкая дипломатия могла бы доставить большевикам много проблем, если бы с ними можно было дискутировать.

— Царизм, заявляет он, — прижимал нас так же, как он репрессировал всех непокорных, особенное давление он уделял культовым действиям и образованию. Когда разразилась революция, мы созвали национальную ассамблею. Она создала администрацию, разделенную на три части: первая занималась делами религии, вторая — образованием и третья — национальным благосостоянием. Мы организовали начальные школы и реальные училища. Есть проект создания университета и музея. По всем религиозным и учебным вопросам мы хотели быть независимыми. Впрочем, мы подчинялись законам Российского государства, чьей составной

частью мы являемся. В действительности нас очень мало, чтобы образовать автономную силу.

«Что касается наших требований, Керенский с ними согласился, но большевики устранят все созданные нами институты. Для них национальные требования – предрассудок, их идеализм считает, что эта стадия уже прошла. Однако существует нация, отрицать ее нельзя, это чувствуется».

Максудов мне объяснил, как большевики возьмут власть в свои руки в регионах Уфы, Казани и Оренбурга. Полки мусульман – всего пятнадцать тысяч человек, будут сначала защищать новый режим, но в течении нескольких месяцев будут распущены, а взамен усилены артиллерией Красной армии.

«Я симпатизирую социализму, – продолжил Максудов, – но большевизм стал чем–то ужасным. Я критикую не их теории, а использование ими силы».

Чтобы лучше понять его мышление, представитель российских мусульман использовал следующее живописное сравнение: «Большевики заставляют меня задуматься о группе, которая пытается натянуть маленькую шляпу на сильную голову. Их теории неприменимы в стране, которая более сельскохозяйственная, чем индустриальная, организация которой, к тому же, примитивна. Почему вы назначаете рецидивистов административными работниками? – спрашивали у Ленина. Он отвечал: «Я не нахожу других». Разве это не является приговором системе и доказательством того, что страна не созрела для ее применения».

К Колчаку.

Итак, что же делать? Максудов – человек решительный. Без колебания он заявил:

– Мы выбираем Колчака. В данный момент есть только две силы: он или Ленин.

– Керенский, в недавнем заявлении сделал высказывание...

– Да, я его читал. Но чего вы хотите? Мы испытали Керенского: он весьма идеалистичен и не сможет установить свой режим. Его опыт поверхностен.

– Но не боитесь ли вы военной диктатуры?

– Российский народ познакомился со свободой и никогда от нее не отречется. Если адмирал Колчак не созовет Конституционное собрание, против него вспыхнет новая революция. Он только инструмент для того, чтобы свергнуть большевиков и установить элементарный порядок, так как большевики устранили любую возможность борьбы для демократических партий. Это будет возможным в новом режиме, который он установит.

Господин Максудов выступает в поддержку Колчака, потому что он надеется, что благодаря ему Россия будет представлена на Мирной конференции. Он этого желает своей стране, к которой он крепко привязан: и мусульманам, чья свобода будет гарантией всего, что касается их религии и их национальной культуры. Эти две вещи он считает наиважнейшими, в то время как ни реакционеры, ни большевики их не гарантируют.

«Эклер». 30 мая 1919 года
Перевод с французского Фархада Фаткуллина

*2. НИЖЕСЛЕДУЮЩЕЕ ЯВЛЯЕТСЯ ВОЗЗВАНИЕМ ЕГО ПРЕВОСХОДИТЕЛЬСТВА САДРИ МАКСУДОВА, ПРЕЗИДЕНТА НАЦИОНАЛЬНОГО СОВЕТА МУСУЛЬМАН ЕВРОПЕЙСКОЙ ЧАСТИ РОССИИ И СИБИРИ К МИРНОЙ КОНФЕРЕНЦИИ: Мусульманский халифат Европейской России и Сибири. Воззвание к мирной конференции.*

В качестве Президента делегации и национального Совета мусульман европейской части России и Сибири (регионы Поволжья, Прикамья и Сибири: Казань, Астрахань, Оренбург, Уфа, Пермь, Челябинск, Омск, Иркутск), я воспользуюсь возможностью адресовать это воззвание Верховному Совету и Мирной Конференции. «Высказывание в этом воззвании мнения мусульман, которых я представляю, относительно мира с Турцией, является для меня обязанностью и честью.

То, что я выскажу вам, относительно участи (судьбы) Султана Турции и Константинополя, не является просто выражением и преданной (верной) интерпретацией (объявлением) мнения и чувств Мусульман Европейской части России и Сибири, но, кроме всего прочего, мусульмане специально обязали нашу делега-

цию передать их мнение и чувства к сведению Мирной Конференции.

До того, как выразить вам суждения вышеотмеченных мусульман, я обязан объяснить вам их намерения, отношения и надежды во время войны. Мусульмане России всегда отличались лояльностью и преданностью Российскому государству. В последней войне, мусульмане были лучшими солдатами Российской армии. Когда в 1914 году Германия объявила войну России, она была очень популярна среди мусульман, как, впрочем, и среди православных христиан. Мобилизация в мусульманских регионах проходила не просто в соответствии с порядком, но даже с радостью. Представители мусульман в Думе и вспомогательном Бюро, образующие национальный совет мусульман, не были вынуждены использовать свое влияние для подготовки мусульман к войне. Но когда Турция, к несчастью, была втянута в войну на стороне Германии, мусульмане России столкнулись с важным психологическим кризисом. Почему? ПОТОМУ ЧТО ТУРЕЦКИЙ СУЛТАН РАССМАТРИВАЕТСЯ МУСУЛЬМАНАМИ КАК ИХ ДУХОВНЫЙ ЛИДЕР. Мусульмане были готовы сражаться против Германии, но не против султана, их халифа. «Как же они будут держать ответ перед Аллахом – Господом Богом?». Это явилось проблемой сознания для истинно верующих. Для европейца, особенно для европейца удаленного от религиозных идей, это смешивание гражданского долга с религиозными чувствами и затруднение выбора между ними может выглядеть непонятным. Но необходимо понять разум мусульман. РЕЛИГИОЗНЫЕ ЧУВСТВА, А СЛЕДОВАТЕЛЬНО И ПРЕДАННОСТЬ ХАЛИФУ ДОСТАТОЧНО СИЛЬНЫ В РОССИЙСКИХ МУСУЛЬМАНАХ, И Я УВЕРЕН, ЧТО ТАКОЕ ЖЕ ЧУВСТВО ПРЕОБЛАДАЕТ В КАЖДОЙ ИСЛАМСКОЙ СТРАНЕ. Мусульманская часть Думы попыталась сделать все возможное, чтобы преодолеть текущее мнение против войны, которое преобладало среди мусульман.

Что же сказали лидеры большинству мусульман? Как они убедили истинно верующих сражаться против подданных халифа? Просто сказав правду. Они сказали: «Турция была втянута в войну Германским влиянием, несмотря на противостояние Султана

и турецкого народа. Султан не желал войны. Наша страна, Россия, сражалась на стороне Англии и Франции (Италия еще не вступила в войну). Эти две страны являются наиболее демократичными, наиболее либеральными в Европе. Ни одна страна не сможет устоять перед объединенными силами Франции, Англии и России, и победа союзников математически предсказуема. Но победа для союзников будет означать триумф либерализма, демократии и права любой страны, большой и малой, на существование.

После победоносной войны с помощью наших союзников, великие реформы произойдут в России: Россия также станет либеральной страной. Мы, мусульмане, не только станем свободными гражданами, но также заслужим уважение нашим национальным объединениям, нашему языку, и они не посмеют удержать это признание народа, которой снабдил их 800000 прекрасными солдатами для Российской армии. Что касается Турции и Халифа, то они потеряют больше в случае победы Германии. Германия вовсе не желает добра Турции и Султану; она использует Турцию сейчас и своих интересах, но победив, она подчинит Турцию и Султана не только экономически, но также политически и административно. Что касается союзников, они не не ведут завоевательную войну, они сражаются за свободу, справедливость и права всех народов.

Союзные государства, Англия, Франция и Россия, являются самыми крупными мусульманскими силами. У Англии более 100 миллионов подданных мусульман, у России – 30 и у Франции – 12 миллионов. Даже если они победят Турцию, Правительства этих стран всегда будут соблюдать уважение к религиозным чувствам своих подданных и не забудут лояльное и действенное участие мусульман каждой исламской страны в войне.

Поведение их подданных–мусульман, во время войны, будет диктовать им после победы уважение к Турции и уважение к человеку и сану их Халифа. Поэтому победа союзников желательна не только мусульманам России, а также и мусульманам Турции.

Эти идеи, которые я здесь кратко изложил, развитые и разъясненные мусульманскими обществами и исламской прессой, имели значительное влияние: ропот против войны прекратился. Мы смогли удержать солдат–мусульман в спокойствии и дисципли-

не, не только вплоть до революции, но и в течение ее. Слова со стороны Национального Совета Мусульман было бы достаточно, чтобы более 800000 человек покинуло фронт. Они смогли бы сделать это вполне безнаказанно из–за дезорганизации, которая превалировала, к сожалению, в Российской армии после революции большевизма. Среди солдат–христиан царило дезертирство, а солдаты–мусульмане остались до конца преданными делу союзников. После демобилизации, насильственно проведенной большевиками, ни один мусульманин не присоединился к Красной Армии, до тех пор, пока не началась насильственная мобилизации под властью большевиков. Но благодаря Национальному Совету мусульман мы поддерживали дисциплину, и мусульмане остались преданными союзникам до конца.

Вот каково было поведение мусульман в течении войны, но чего же ожидали мусульмане после нее? Мусульмане России ожидали от победы, кроме удовлетворения своих патриотических чувств, увидеть свое государство в триумфе, два типа моральной компенсации: больше национальных свобод в России и снисходительного отношения и справедливого обращения с Турцией, уважение Султана со стороны союзников. Они верили, что заслужили этого вознаграждения ценой жизней сотен тысяч своих детей, погибших на полях сражений, защищая интересы союзного дела.

Мусульмане России, во всяком случае в данный момент, лишены первой части своих надежд, вместо свободы они оказались подвергнуты еще более худшему угнетению. Что касается второй их надежды (справедливого обращения с Турцией и Султаном), мусульмане всего мира оказались перед душераздирающим вопросом: было предложено выгнать Султана из Константинополя, города, почитаемого всеми мусульманами как одного из священных мест. Вы найдете везде в России, в доме каждого мусульманина литографию с видом Константинополя в рамке со священными строками. Мусульмане поймут, что силы (союзники) считают Турцию ответственной за свою долю в войне и гарантируют права и свободы иностранцев в Турции. Но мусульмане никогда не поймут необходимость выгонять их Халифа из собственной столицы, «го-

рода тысячи мечетей». Эффект, который данный поступок произведет на мусульман России нанесет огромный и непоправимый удар по престижу и популярности союзников. И неважно с какой осторожностью будут использованы меры по выдворению Султана и турков из Константинополя, и насколько бы смягченными они не были, спровоцируют общее смятение в Исламском мире, в России также как в Европе и Азии. Это будет подлинным трауром (скорбью) для мусульман России. Никогда больше мусульмане не подчинятся такому унижению. Это унижение будет незаживающей раной в груди каждого верующего и послужит причиной недовольства во всем мусульманском мире. Зачем союзники наказывают нас, — спросят они, — нас, помогавших им в войне? Лидеры мусульман, которые привели остальных на сторону союзников во время войны, не смогут объяснить своим братьям по вере необходимосгь изгнания Халифа. Кроме того, ни один мусульманин не постарается объяснить или принять причину изгнания Халифа из столицы, даже если бы они нашли ее, их никто бы не стал слушать.

После такого события (если таковое произойдет) мусульманский мир потеряет любое имевшееся доверие к своим лидерам, бывшим на стороне союзников, но будет готов воспринять что угодно, направленное против союзников. Какая прекрасная ситуация будет таким образом создана в мусульманском мире со всеми видами агитации и большевистской пропагандой, в основном против союзников? Я понимаю, что на данный момент союзники могуг с минимальной силой преодолеть любое движение, направленное против них. Но, даже хотя бы с точки зрения будущего, в чем заключается выгода для Англии, Франции, Италии и других союзнических стран от создания, из простой прихоти, рядом с большевистской агитацией еще одного недовольства в мусульманском мире, даже если оно не является для союзников серьезным? Не является ли это излишним риском в отношении сомнительной для союзников выгоды?

С одной стороны движение недовольства в исламском мире, с другой — удовлетворение агрессивной алчности некоторых империалистически настроенных людей на Балканах, поторопившихся помочь трагедии выдворения Халифа. Я знаю, господа—участни-

ки мирной конференции, что у моего голоса мало шансов быть услышанным. Несмотря на все это, я говорю только из сознательной обязанности как представитель 10 миллионов мусульман европейской России и Сибири, чтобы передать к сведению Конференции в критическое для халифата время мнения и требования тех, кого я представляю.

Говоря об этом болезненном и деликатном вопросе, намереваясь искренне изложить откровенное мнение Национального Совета мусульман Европейской части России и Сибири, я осознаю, что действую не только в интересах мусульман и Халифа, но также, служа в то же время и в той же степени союзникам и цивилизации. Из религиозной обязанности и заботы о спокойствии мира и цивилизации я призываю мусульман страдать в тишине. Однако не обманывайтесь мусульманским молчанием. Бывают виды тишины, которые кричат. Я заканчиваю свое Воззвание, адресованное Конференции, ТРЕБОВАНИЕМ ОТ ИМЕНИ 10 МИЛЛИОНОВ МУСУЛЬМАН ЕВРОПЕЙСКОЙ ЧАСТИ РОССИИ И СИБИРИ БЕСПРОМЕДЛИТЕЛЬНО ОТБРОСИТЬ САМУ ИДЕЮ ИЗГНАНИЯ СУЛТАНА И ТУРКОВ ИЗ КОНСТАНТИНОПОЛЯ И ТУРЕЦКИХ ПРОВИНЦИЙ, ТАК КАК ЭТО БУДЕТ ОШИБОЧНЫМ И НЕСПРАВЕДЛИВЫМ ПОСТУПКОМ НЕ ТОЛЬКО С МУСУЛЬМАНСКОЙ ТОЧКИ ЗРЕНИЯ, НО ТАКЖЕ НЕУДАЧНЫМ И ОПАСНЫМ, ЧРЕВАТЫМ ОГРОМНЫМИ НЕПРЕДСКАЗУЕМЫМИ ПОСЛЕДСТВИЯМИ ПОСТУПКОМ С ТОЧКИ ЗРЕНИЯ МИРОВОЙ ПОЛИТИКИ, ПОРЯДКА И ОБЩЕСТВЕННОГО СПОКОЙСТВИЯ БЫТИЯ.

Садри Максудов. Президент Национального Совета мусульман Европейской части России и Сибири. 10 января 1920 г.

Журнал «Исламский взгляд». 5 февраля 1920 г.
Перевод с английского Фархада Фаткуллина

*3. Воззвание представителей мусульман голодающей России к мусульманам других стран.*

Дорогие единоверцы.

Все восточные провинции европейской России страдают от голода. Засуха все сжигает, миллионы людей не имеют совсем никаких средств к существованию и семян на будущий год. На помощь других регионов России рассчитывать невозможно, так как повсюду урожай был незначителен, и страна полностью истощена войной, революцией и гражданскими беспорядками.

Только иностранная помощь может спасти Россию. Сейчас эта помощь находится на стадии формирования. Народы и правительства всех стран Европы и Америки проявляют трогательную готовность прийти на помощь голодающей России.

Образуются комитеты, идет помощь. Но нищета России огромна, необходимо чтобы весь мир объединился и пришел к нам на помощь.

Мы глубоко взволнованы порывом человечной солидарности, поднявшимся в Европе и Америке.

Однако мы огорчены безразличием мусульманских стран в этом вопросе. До сегодняшнего момента ни в одной мусульманской стране не сформирован, по нашим сведениям, комитет помощи, ни в одной мусульманской газете мы не прочитали призыва о помощи.

Единоверцы, вы не можете, вы не должны оставаться безучастными рядом с огромным страданием десятков миллионов людей.

Миллионы несчастных покинули свои гнезда и пошли во все стороны в родных областях в поисках хлеба! Тщетно! Они проходят сотни километров, чтобы ни найти ничего, кроме иссохшей, истрескавшейся земли, полей, превратившихся в пустыни, высохших колодцев, деревень, покинутых своими такими же голодными честными жителями.

Холера и другие эпидемии, неизменные спутники голода, распространяясь делают обыденным явлением миллионы жертв, которые я сравнил бы с дорогами, заполненными толпами пострадавших.

Происходящее в России, невозможно описать человеческим языком. По страданию, по ужасам это превосходит все, что можно представить себе самым угрюмым воображением.

Единоверцы, вы не можете оставаться безразличными наблюдателями за бедой большой страны и тридцати миллионов голодающих. Зная предписания нашей религии относительно помощи голодающим и чувствительность мусульман к несчастью ближнего, мы не можем поверить, что вы остаетесь бесчувственными к такому несчастью. Мы связываем ваше молчание и ваше нынешнее бездействие с отсутствием информации. Мы уверены, что однажды будучи извещены, вы поторопитесь прийти нам на помощь с таким же чувством чисто человеческой солидарности, с каким хотят нам помочь народы Америки и Европы.

Единоверцы, если для кого–нибудь среди вас понятие голодающего человека не достаточно, чтобы тронуть вас, мы можем вам сказать, что среди тридцати миллионов голодающих около 9 миллионов мусульман, в большинстве провинций, сраженных голодом, мусульмане составляют треть населения, а в некоторых – половину (Казань, Уфа, Астрахань).

Однако мы не хотим, чтобы религиозные и расовые вопросы переплетались в этом акте человеколюбия. Народы Европы и Америки не интересуются вероисповеданием тех, кому помогают, и мы уверены, что и вы будете интересоваться не более. Ваша помощь должна быть адресована всем голодающим россиянам без различия их рас и религий.

Единоверцы, немедленно организуйте комитеты помощи в больших мусульманских городах, начинайте накапливать средства, пишите статьи в ваши газеты, описывайте наше несчастное положение, вступайте в контакт с другими комитетами помощи Парижа, Лондона и Рима. Мы уверены, что в правительствах стран, гражданами которых вы являетесь, вы встретите в этом вопросе всестороннюю поддержку и необходимое содействие.

Для справок относительно голода и организации помощи в Европе, наша делегация находится в вашем распоряжении.

От имени человечества мы обращаемся с просьбой ко всем газетам, имеющих подписчиков среди мусульман, воспроизвести это воззвание.

Президент делегации мусульман Европейской части России Садри Максудофф. Члены: Гаяз Исхакофф, Туктарофф. Париж, улица Блэз Десгофф, 6.

Перевод с французского Фархада Фаткуллина

*4. Аладдин Җәмил. Садри Максуди Сорбоннада.*

*Сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган бу мәкалә 1923 елның 16 декабрендә чыккан «Вакыт» гәзитеннән алынган. Бу мәкаләдә Садри Максудиның Сорбоннадагы эшчәнлеге турында сүз бара. Мәкаләнең теле һәм кайбер сүзләре искергәнгә күрә, яшь буынга тулысынча аңлашылсын өчен, ул бүгенге телгә җайлаштырылды («Төрек культурасы»).*

Заманыбызның бөтен гыйлем тармакларына бәйле булган, белем бирү дәрәҗәсе белән мәшһүр Сорбонна университеты турында ишетмәгән кеше юктыр. Монда, теләгән укучылар иң көчле, иң белемле профессорлар укыткан дәресләргә кереп, аларның лекцияләрен тыңлый алалар. һич арттырмыйча әйтә алам: монда укытылган гомуми гыйлемнәр белән беррәттән, җир йөзендәге бөтен бөек милләтләрнең тарихы һәм әдәбияты атаклы галимнәрнең эзләнүләре һәм тикшеренүләре нигезенә салынып укытыла. Европа милләтләренең тарихы, әдәбияты белән тигез Кытай, гарәп, япон, иранлыларның да тарихлары, әдәбиятлары Сорбоннада күптәннән бирле укытыла, ләкин болар арасында төрки милләтләрнең тарихы укытылмый иде. Әллә төркиләрнең тарихы Европа карашынча, португалияләрнең әдәбиятына, тарихына караганда әһәмиятсезрәкме? Сорбоннаның укыту методикасындагы бу бушлык, ниһаять, капланды: төрки халыклар тарихын укытачак кафедра ачылды. Бу – Садри Максуди һәм башка тарихи шәхесләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсе иде.

Париж университетында безнең өчен бик кадерле булган бу кафедра ачылуына без бик шатланабыз һәм тәбриклибез. Төркиләрнең тарихы укытыла башлавы һәр яктан әһәмиятле вакыйга. Бу – көнбатыш халыкларының безнең белән кызыксына башлавы һәм безне милләт итеп таный башлавыдыр. Икенче яктан, Сорбонна кебек университетта кафедрада бер төркигә урын бирелүе дә горур-

лык хисләре уятырдай вакыйга. Садри Максуди бәй Россия төркиләренең бер вәкиле һәм төрки–татарларның Милли Мәҗлесенең экcрәисе иде. Үзенең төрек–татар халкы тарихында һәм телендә киң мәгълүматле булуы, аның Париж университеты комиссиясе тарафыннан берсүзсез бу урынга сайлануын тәэмин итте дә инде. Мондый сайлау, һичшиксез, беренче. Бер мөселман, бер төркинең Сорбонна кебек университетның кафедрасында эшләве тарихта беренче тапкыр иде. Төрки халыклар Европада бүгенге көнгә хәтле хурланып, тәнкыйтьләнеп килделәр. Шуны да ачык итеп әйтергә кирәктер, без бу хурлауларга каршы бернәрсә дә эшләмәдек. Шулай ук төрки халыкларның үткәнен аңлатуда, Европа халыкларының ялган фикерләренә, ялаларына каршы көрәш тә алып бармадык, ялганнарына каршы эш алып барырдай оешмалар да төземәдек. Шуңа күрә дә, Сорбонна кебек бер олуг белем мәктәбендә төрки халыклар тарихын бер төрки халык вәкиле тарафыннан өйрәнелүе һәм укытылуы бу ялган фикерләрне юкка чыгаруда, дөреслекне торгызудагы бер адым дип уйлыйбыз. Мондый кешеләргә без ышанабыз, аларны хөрмәт итәбез, аларны онытмабыз.

Садри бәй кафедрада эшләгәндә гел хакыйкатьне генә сөйләргә тырышкан, данлы тарихыбызны дөрес итеп укыту белән халкыбыз һәм тарихыбыз өчен бөек хезмәтләр башкарган. Без үз университетларыбызда да мондый дәресләр укытылуын оештырырга тырышырбыз. Дөньяның һәр илендә аз санлы халыклар, беренче эш итеп, үз халкының тарихын һәм географиясен, әдәбиятын өйрәнәләр һәм, шуңа күрә дә, без, беренче эш итеп, үз тарихыбызны, төрки халыклар тарихын башлангыч сыйныфлардан ук укытып килергә, үз милләтенә карата сөю хисләрен кешегә бала, сабый чактан ук сеңдереп калдырырга тиешбез.

1923 елның 4 декабрендә, сишәмбе көнне Сорбоннада Садри бәйнең зур игътибар һәм хөрмәт белән тыңланылган беренче дәресе узды. Аның аудиториясенең өчтән ике өлеше мсье Хаумант тәкьдим итүе, аның чакыруы белән килгән кешеләр иде. Ул Садри Максудины аларга тәкъдим итте, аның хезмәтләре, сәяси һәм милли эшчәнлеге белән таныштырды. Аңың эшчәнлеге ике төркемгә бүленсә дә нәтиҗәсе бер үк, бер үк максатларга юнәлдерелгән эшчәнлек булуын һәм ул эшчәнлекнең, бер тарафтан мил-

ли, сәяси бәйсезлеккә омтылган, икенче яктан төркилек эчендә бүгенге мәдәниятны үстерүгә хезмәт иткәнен сөйләде. Тыңлаучыларның күбесе төрек шәкертләре һәм Россия төркиләре иде, ягъни төрле илләрдән килгән төрки халыкларның вәкилләре иделәр. Садри бәйнең уң ягыннан профессор мистер Хаумант булса, икенче яктан Хөсәен Рәкыйп бәй, аның янында Азәрбайҗан хөкүмәте башлыгы Али Мәрдан, аннан соң кыргыз вәкиле Мостафа Чокай бәй утыра иде. Бу кешеләрнең һәрберсе Садри бәйне, көчле кул чабулар белән тәмамланган дәрестән соң чын күңелләреннән котладылар.

Садри Максуди Арсал Кытайдан Дунайга, Себердән Иран җирләренә кадәр таралган төркиләрнең яшәү урыннарының чикләрен сызып, бу кабиләләрдә илле бер миллионнан артык кеше яшәве турында сөйләде. Бу илле миллионлы халыклар ни өчен яшәгән, ничек яшәгәннәр? Әллә бу халыклар үзләренең үткәннәренең калдыкларына канәгать булып, юкка чыгарга хөкем ителеп бетеп баручы халыклармы? Киресенчә, киләчәктә нык сәяси һәм милли милләт тудырачак, какшатылмас иҗтимагый нигезле, дөньяның иң бөек мәдәниятлары янынада урын алу өчен көрәш алып барачак халыклар алар! Садри бәй исә үзе укытачак дәресләрнең эчтәлеген болай аңлата:

«Дөньяның бөек милләтләре тарихы белән буталып беткән төрки халыклар тарихын падишаһларның, солтаннарның, бөек шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләреннән, аларның алып барган эшчәнлекләреннән, көрәш–сугышларыннан һәм безнең эзләнүләребездән чыгып өйрәнәчәкбез, безнең дәресләр шуннан гыйбарәт булачак. Төрки халыклар милләтен тәшкил иткән төрле төрки халыклар тарихындагы чорларны, дәверләрне билгеләү, аларны өйрәнү дә безнең вазыйфага керә. Бүгенге көнгә кадәр социологик караштан чыгып өйрәнелмәгән төрки халыклар тарихының гомуми күренеше яңадан язылуга мохтаҗ. Төркиләрнең үткәненә һәм милләтләр арасындагы роленә бәйле булган ялгыш төшенчәләрне заманыбызның тарихына, бөтендөнья тарихына яраклаштырып дөресләтеп язу да бик мөһим».

Без Садри бәйгә бу югары дәрәҗәле гыйльми хезмәтләрендә милли мәнфәгатебез өчен уңышлы булуын теләп торырбыз.

Париж. 8 декабрь, 1923 ел.
Төрекчәдән Алмаз Закиров тәрҗемә итте.

*5. Орд.Проф.Садри Максуди Арсал. ДУСТЫМ ЙОСЫФ АКЧУРА.*

«Бөек галим һәм милләтче Садри Максуди Арсал үлүенең егерме еллыгына багышлап, Әнкара Милли китапханәсендә оештырылган «А.Торени» нең күргәзмәсе әзерләнгәндә гаиләсе тарафыннан бастырылмаган мәкаләсе табыла. Былтыр Йосыф Акчура исемле бөек идеалистның тууына йөз ел тулуы белән, аның милләте өчен эшләгән хезмәтләрен чагылдырган бу мәкаләне сезгә бастырып күрсәтәбез» («Тюрк юрду» журналы).

Йосыф Акчура – соңгы илле ел эчендә Төньяк төркиләре арасында балкып чыккан атаклы шәхесләрдән берсе. Икебезнең дә туган ягыбыз, тору шартларыбыз, алган белемебез төрле булган булса да, гомеремдә аның белән күп очраштым, бер үк идеалга хезмәт иттем, милләтем каршында булган бурычларымны бергә үтәдем. Шуңа күрә дә Йосыф бәйнең тормышыннан күп кенә хәтирәләрем дә бар. Аларның берничәсен сезгә сөйләп Йосыф Акчура тормышының билгеле чорларын, аның яшәү идеалларын күзаллавыгызда ярдәмче була алырмын дип өмет итәм. Йосыф бәй белән бергә бер үк хезмәтләр башкарып, уртак кызыксынулар, дуслык хисләре булганга гына түгел, ә бер идеалга хезмәт иткәнгә күрә бер–беребезне яратканбыз, якын күргәнбездер. Бу идеал миллият тойгысы, төркилек идеалы иде. Бөтендөнья тарихына мәлик булган милләтебезне яшәртергә, үстерергә, яратылыштан килгән күркәм сыйфатларында калуын тәэмин итүдә... Йосыф Акчура белән беренче очрашуым 1902 елның башында, Париждагы «Quartier latin» дип йөртелгән җирдә булды. Белем алу өчен Парижга китәр алдыннан Йосыфның, Траблусгарптагы сөргененнән качып, укуын дәвам итү өчен Парижга киткәнен белгән Фатих Кәрими аның белән танышырга киңәш иткән иде. Миңа аның өчен язылган хат та бирде. Парижга килер–килмәс хатны тапшырыр өчен һәм шунда ук танышырга дип Йосыф бәй яшәгән кунакханәгә юл тоттым. Берхолет урамы, 11 йорт – «Hotel du Monte» исемле

кечкенә генә бер гостиница иде бу. Мин парижлашып беткән, купшы бер яшь төрек офицеры белән очрашуымны чамалый идем. Ялгышканымны тиз аңладым. Бүлмәгә кергәч тә башына искергән фәс, өстенә уңган яшел бишмәт кигән, кечкенә генә өстәл каршына утырып, китабын күзенә якын тотып укыган утыз–утыз ике яшендәге бер кеше белән очраштым. Боек кына каршы алган Йосыф бәй, хатны укыгач, җанланып китте, Казандагы дуслары һәм туганнары турында сораштыра башлады. Шулай итеп, беренче очрашуыбыз һәм танышуыбыз берничә сәгатькә сузылды. Моннан соң да бик еш күрешкәли башладык. Йосыф бәй Парижда Сәясәт мәктәбендә (Ecole des Sciences politques), мин исә Хокук факультетында укыдык, ләкин кирәк икән ул, кирәк икән мин, үз дәресләребездән соң, Сорбоннага безне кызыксындыручы дәресләрне тыңларга китә идек. Икебез дә хокук һәм сәясәт белән генә чикләнмәдек, фәлсәфә, тарих һәм социалогияне дә яратып укыдык. Йосыфны бик еш Дуркхейм, Левибрухл, Спиназ, Хаумант, Сей–нобос, Тарде һәм Лерой–Беулисунең дәресләрендә күрә идем. Йосыф бәй көндез укылган лекцияләрне тыңлап мәгълүмат җыя, кич теркәп барганнарын акка күчереп, ишеткәннәрен анализлый, төбенә төшәргә тырыша иде. Ул беркайчанда вакыт уздырырга кафега китми иде. Бөтен буш вакытын китапка багышлый, укыган китапларындагы яшерен фикерләрне эзли, асылына төшенә иде. Аның кызыксынмаган фәне булмагандыр. Шулай булса да үзе – «Минем билгеле бер фәндә туктап калуым һәм аннан чигенмәвем бер авыру» – дип әйтә иде, әмма бу аның инсафлылыгы гына иде. Йосыф бәйнең күп укуы, яңа дәвер тарихында бик белемле кеше булуы авыру түгел иде.

Бер көнне француз дусларыннан берсе Сорбоннада «Ecole des Hautes Eudas» мәктәбендә борынгы төркиләрдән калган язу истәлекләре турында лекция укылачагын әйтте. Беренче эш итеп шул дәрескә киттем. Халеви исемле карт кына профессор Орхон елгасы тирәсендә табылган язулар турында сөйли иде. Аның бөтен тыңлаучылары, ягъни аудиториясе биш–алты кешедән гыйбарәт иде. Карт Халеви минем белән беренче күрүеннән кызыксына башлады. Төрки булганымны белгәч, Орхон язуларын калдырган төркиләр турында күп сөйләде. Икенче көнне шундый дәресләр

булуын Йосыф Акчурага да әйттем. Ул да безгә кушылды. Дәрес атнага бер генә иде. Профессор да, карт булганга күрә, кайбер вакытларны килми дә кала иде. Ул, һәр дәрес соңында, Йосыфка һәм миңа карап, борынгы төркиләр турында кызык, гаҗәеп фактлар китерә иде. Әйткәннәре арасында исемдә калганы шул иде: Орхон таш язулары язылган чорда Европаның бүгенге телләрдән һичберсе дә юк иде, ә бабаларыбызның инде шул вакытта ук һәрнәрсәне аңлатырлык дәрәҗәгә җиткән әдәби теле булган. Лекцияләрдә Йосыф бәй белән бергә булдык һәм мин аның укуны, уйлануны яраткан, дөреслекне эзләгән, тик табачагына бик ышанмаган, бераз пессимист кеше икәнен аңладым. Дөньяда ике төрле күңел төшенкелеге була: берсе һич бернәрсә турында төшендермәгән, дөреслекне эзләргә бирмәгән, фәлсәфи караштан бөтенләй читләшкән кешенең күңел төшенкелеге. Бу күренеш тумыштан килә һәм нәселдән санала. Икенчесе – фәлсәфи пессимистлык. Бу күренеш исә – тормыштагы фән, китаплардан күп әйбер көтеп, өмет иткәннәрне тормышка ашыра алмаганлыктан барлыкка килгәне. Бу төре күбрәк тирән фикерле шәхесләрдә күзәтелә. Бу күңел төшенкелеге табигый да, нәселдән дә түгел, фәлсәфи генә. Йосыф Акчураның тормыштагы күңел төшенкелеге тулысынча шундый иде. Аның яратып укыган фикер ияләренең берсе Паскаль иде. Ул вакытта Йосыф бәй Паскаль кебек динле иде. Тарихта исә өлешчә Тайпенең һәм, әлбәттә, Сорельнең фикерләренә бәйле, Франция инкыйлабына зур әһәмият бирә иде. Революция каһарманнарының тәрҗемәи хәлләрен берәм–берәм өйрәнеп чыккан иде. Аның Париж халкының геройлары белән кызыксынуы укучы чагында башланып гомеренең соңгы минутларына кадәр сакланган. Шулай ук Австрия империясенә буйсындырылган милләтләрнең милли көрәшләре дә аны борчыган. Үзе укыган сәясәт мәктәбендә дипломатика тарихы дәресләрендә Европаның төрле төбәкләрендә күзәтелгән милли көрәшләр турында күп сөйләнгәнен дә әйтә иде. Дини, милли, фәлсәфи темаларга еш бәхәсләшә идек. Бу сөйләшүләребезгә кайвакыт Токио посолы (вәкиле) Фәрит бәй һәм Россия төркиләреннән Курыкмас исемле бер укучы да кушыла иделәр. Әмма Йосыф бәйнең фикерләре белән хәрәкәтләре ике аерым юлдан барды һәм

бер—берсенә тәэсир итмәде. Ул, пессимист кебек, һәрнәрсәгә шикләнеп карый, ләкин оптимист кебек хәрәкәт итә иде. Дөрестән дә, бәхәсләрдә ышанычсыз булып күрегән Йосыф, ышанычлы идеалист кебек хәрәкәт итә иде. Күңел төшенкелегенә ия булган кеше булып күренсә дә, рухының иң түбән катламнарында көчле бер идеаллы, максатларында һәртөрле корбаннарга әзер кеше иде. Аның йөрәгендә төркилеккә карата көчле, һичсүнмәс ялкын янган. Безнең карашларыбызны таркатмас өчен, ул төрле философларның дәлилсез калган фактларын куллана, үзе аларны дәлилләп чыга иде, һәр мәсьәләдә үзенең фикерләрен өсти, үз карашыннан чыгып эшли иде. Хисчән булуы аркасында ул бәхәс кызуында үзе дә борчыла, кыза, бәхәс тотучы кешенең фикерләрен кире кагып һем шуңа таянып җиңү тактикасын сайлый (Esprit de conttadiction), шуңа күрә көлке өчен генә бәхәсләшүчеләр белән кызыксынмыйча гына сөйләшә, ә җитди әңгәмә коручылар белән хөрмәт һәм үзенчәлекле пессимистлыгы белән бәхәскә керешә иде.

Бер көнне Йосыф бәй мине укучылар кафесының берсендә тапты Һәм Гаспыралы Исмәгыйль бәйдән хат алганын, аның берничә айдан соң «Тәрҗемән» гәзитенә егерме яшь тулачагы турында язганын әйтте һәм шуны өстәде: «Башка милләттә булса бу хәл, алар юбилей үткәрерләр, милләт ул адәмгә карата хөрмәт һәм рәхмәтләрен белдерер иде». Мин: – «Без дә үткәрик!» – дидем. Йосыф бәйнең «Яхшы булыр иде. Юбилейне оештыру уен түгел, булдыра алырбызмы, мөмкинлегебез бармы?» – соравына, мин: – «Без тырышып карыйк» – дип җавап бирдем һәмниләр эшләргә мөмкинлеген сөйләдем. Йосыф бәй һәрвакыттагыча үзенең махсус күңел төшенкелеге белән оптимистлыгы арасындагы бер төрле кыяфәт һәм тон белән: «Ясыйк» – диде. Ул көнне икебезнең дә дәресләребез бар иде. Хушлашырга вакыт җиткәч, эшләнәсе эшләрнең исемлеген төзү минем өстә калды. Авыр булмады. Юбилейгә алынасы әйберләрнең, эшләнәсе эшләрнең планы корылды. Анда әлегә Йосыф бәйдән һәм миннән торган оештыру комитеты җыелачак, комитет үз вазифасы итеп Исмәгыйль бәйнең «Тәрҗемане» аша башкарган милли хезмәтләре турында билге бирү, «Тәрҗеманнең» егерменче яшь тулуы уңае белән милләтнең аңа карата саклаган хөрмәтен белдерү өчен юбилей үткәрү кирәклеген аңлаткан

кечкенә генә брошюра чыгару, аны Төркия һәм Россиянең танылган кешеләренә хат итеп җибәрү бурычы куелды. Йосыф бәй планны ошатты, җанланып һәм дәртләнеп, шул ук вакытта көлеп тә: «Болай булгач үзебезне бүгенге көннән оештыру комитеты дип игълан итик» – диде. Моңа мин: «Сез минем абыем, сезнең комитет рәисе булуыгызны үтенәм» – дип әйттем. Йосыф бәй кабул итте, эшне башладык. Беренче мәсьәлә итеп китапчыкны кайда һәм кем тарафыннан бастырылуын, кем тарафыннан һәм кайсы телдә язылуы мәсьәләлсе туды. Мин бөтен төрки төбәкләрдә дә яшәгән белемле кешеләр аңлый торган гомуми әдәби төрек телендә – Истанбул төрекчәсендә, Йосыф бәй тарафыннан язылуын теләдем. Ул исә китапчыкны Төркиягә җибәрмәскә кирәк, диде. Анда җибәрү җайсыз һәм файдасыз диде. Хатларның, бер яктан Габдел Хәмит полициясе тарафыннан ачылып укылачагын, хуҗаларына кыенлыклар тудырачагын, икенче яктан, Исмәгыйль бәйгә тәбрикләр килә башлавы белән Рус хөкүмәтен дә шикләндерәчәген, һәм нәтиҗәдә, бу тәбрикләрнең «Тәрҗемангә» зарар китерәчәген әйтте Мин дә бу аргументларның дөрес булуын аңладым. Китапчыкның Казан сөйләмендә язылырга тиешле дигән карары нәтиҗәсендә язу вазифасы да миңа төште. Кыска гына бер вакыт эчендә брошюраны язып бетердем. Китапчыкта мин миллият мәсьәләләренең әһәмияте, кеше өчен булган кебек, милләтләр өчен дә табигый булган яшәү теләге, милләтләр үсешендә, тел, әдәбият һәм матбугатның роле, халыкара мөнәсәбәтләрнең, милли культураның үсүе, ә Исмәгыйль бәй һәм аның «Тәрҗемане» аркасында бөтен дөнья төркиләре уянуы, бу гәзитнең милли мирасыбызны саклауда әһәмияте һәм ниһаять «Тәрҗеманнең» егерме яшьлеге уңае белән Россия төркиләренең юбилейга бүләкләрен һәм вәкилләрен җибәрү мөмкинлеге турында язган идем. Йосыф бәй, укып чыккач, берничә өстәмә кертте, аларның берсен бик яхшы хәтерлим: Польша әдибе Сенкиевичнең илле яше түлуы уңае белән поляк милләте үзенең бөек әдибенә бер өй бүләк итүләре турында иде.

Китапчыкны Парижда бастыру читен булганлыктан, аны Йосыф Акчураның Женевада хосусый типографиясе булган якын дусты Махир Сәеткә җибәрдек. Ул аны кыска вакыт эчендә бастырып кире кайтарды. Китапчык нәкъ конвертка сыярлык кына

иде: кечкенә форматтаты кәгазьгә басылган, егерме алты битле, саны йөзгә якын иде. Китапчыкларны алыр–алмас, конвертка салып, алдан әзерләнгән исемлек буенча адресатларына җибәрдек. Исмәгыйль бәйгә дә хәбәр иттек. Брошюра юкка гына эшләнмәгән иде. 1902 елының язында Россия төркиләренең белемле, тәрбияле кешеләре – интеллигенциясе Бахчесарайда җыелды. Исмәгыйль бәй өчен «Тәрҗеман»ның егерме яшенә багышлап бик шәп тантана уздырылды. Бу тантана һәм мәҗлес Россия төркиләренең беренче милли конгрессына әверелде. Монда төрле җирләрдән килгән бөек кешеләр беренче тапкыр бөтен төркилекне кызыксындырган милли мәсьәләләр, милли культураны үстерү чаралары турында сөйләштеләр. «Тәрҗеман»ның юбилее Россия төркиләренең милли уяну тарихында мөһим урын алып торучы вакыйга булды. Кайчак кечкенә эшләрдән, бөек нәтиҗәләр туа, безнең Йосыф бәй белән беренче уртак эшебез шундыйлардан булып чыкты. Дәүләтләреннән, туган җирләреннән ерак яшәгән ике студент–укучының бер тырышлыгыннан милли конгресс туды һәм бу конгресстан соң шундый җыелышлар бер–бер артлы үтә башладылар. Йосыф Акчура белән башкарган бу эшнең үзенчәлекләренә һәм нечкәлекләренә туктап калып торуымның сәбәбе шул иде.

Йосыф бәй 1904 иче елларда Төркиягә кайта алмаганга күрә, Россиядәге туганнары янына китте. Мин исә 1906 елның соңында гына кайта алдым. 1905 елда Россиядәге төрки зыялыларының яшерен конгрессы үткәрелде. Парижда «Сәяси белгечләр мәктәбен» тәмамлаган, Австриядә миллиятләрнең милли көрәшләрендә кулланылган ысулларны өйрәнүдә белгеч булган, гадел, тыйнак Йосыф бәй дә бу конгресста мөһим роль уйнаучы кеше булды. 1906 елда минем Россиягә кайтуым, монда яшәүче төркиләрнең икенче конгрессына җыелган көннәргә туры килде. Мин туганнарым яшәгән Казанга кермичә, туры конгрессның җыелу урынына – Нижнийгә киттем. Мин килгәнче җыелуның бер көне үткән иде. Йосыф бәй конгрессның баш советы әгъзасы булды. Катнашучылар ике төркемгә бүленделәр. Либералист һәм социалистлар. Беренче төркем күпчелекне тәшкил итә иде. Социалистлар арасында яшьләр күп булганга күрә алар җыелышны социалистик юнәлештә алып барырга чакырдылар, күп тавышландылар. Либераль

төркиләрнең иң яхшы ораторы Йосыф Акчура, ике ел эчендә Казан телен өйрәнеп, бу телдә җиңел генә һәм ягымлы бер Истанбул акценты белән сөйли иде. Рус мәдәнияты нәтиҗәсендә, социализмның тәэсире аркасында бөтен бер милләтнең таркалып, кол булып яшәве турында, конгрессның милли конгресс булуын аңлатырга тырыша иде ул. Мин, тыңлаучы буларак, аның белән оста оратор буларак таныштым. Йосыф бәйнең социалист ораторларына биргән кискен һәм төгәл җаваплары, аның шәхсенә электән үк булган ярату хисләремне арттырды. Конгресста Гаспыралы Исмәгыйль бәй да бар иде. Алар белән бергә Али Мәрдан бәй Топчибашы, Галимҗан Баруди, Хади Максуди, Рәшит казый Ибраһим, Муса Җәрулла, Габдулла Буби, Гаяз Исхаки, Фуат Туктар һ.б. күбек Россия төркиләре арасында танылган кешеләрнең бөтенесе дә бар иде. Конгресс таралганчы унике кешедән торган даими Үзәк Комитет сайланды. Мондагы әгъзалар әле әйтелгән исем исемләренең беренче җидесе, Йосыф Акчура һәм мин идем.

«Россия мөселманнары иттифагы» исемен алган бу Үзәк комитетта Йосыф бәй белән бергә ике елдан артык эшләдек. Бу вакыт эчендә аның тормышка карашы Париждагыдан караганда тагын да нык үзгәрде. Ахырдан бик каты үсә башлаган таләпчәнлеге, диннән ераклашуы, кайбер очракларда, дусларын үпкәләтүгә дә барып җитә иде. Мин бу чордагы Йосыф Акчураны бераз кырыс, таләпчән, оста фикер йөртүче, тәрбияле, сөю һәм хөрмәткә лаек бер төрек шәхесе буларак бөтен мәгънәсе таныдым. Аннан төркилек өчен күп хезмәтләр күтә башладым һәм ялгышмадым. 1908 елны, Төркиядә зур үзгәрешләр башлангач, Йосыф Акчура үз иленә кайта һәм анда күп хезмәтләр иҗат итә.

...1919 елның дүртенче ае ... Осман дәүләте җиңелгән, Төркия авыр шартларда вакытлы солых төзегән. Аның берничә шәһәре, шәһәрчеге союзник дәүләтләр тарафыннан басылган. Төркиянең сәяси бәйсезлеге куркыныч хәлдә. Россия төркиләренә килсәк, Төркестан, Урта Россия, Себер һәм Кырым төркиләрнең бөтен милли оешмалары таратылган, милләтнең фикер йөртүчеләре кайсы төрмәдә, кайсы чит илгә чыгып качарга мәҗбүри булган. Беренче дөнья сугышыннан соң күтелгән төркилек өчен өметләр бушка чыктылар. Бөтен төркилек милли барлыгына тарихта моңар-

чы булмаган куркыныч тууы сизелде. Менә бу шартларда мин, Урта Россия төркиләренең Милли Идарәсе рәисе буларак, сәяси һәм милли теләкләрне тормышка ашыру өчен Парижда җыелып бетеп барган «Тынычлык конгрессына» бара идем. Парижга китәр алдыннан Стокгольмга килгән идем. Андагы виза мәсьәләсе аркасында бу шәһәрдә тагын бер айга якын калырга туры килде һәм тагын гаҗәеп очрашу! Йосыф та, төрек әсирләрен илләренә кайтару мәсьәләсен хәл итү өчен, Кызыл ай вәкиле буларак, Россиягә киткән һәм анда бер елга якын торып, эшләрен бетереп, Стокгольм аша Төркиягә кайтып баруы иде. Ике атна бер үк шәһәрдә һәм хәтта бер үк отельдә яшәдек, һәркөнне бергә ашадык һәм бөтен төркиләрне әлеге куркыныч хәлдән коткару юлларын, ысулларын эзләдек. Икебез дә төркилекнең коткарылуын тик бер могҗизада, яисә могҗизалы шәхеснең килеп чыгуында гына күрдек. Мондый кеше булса, бәйсез Төркия төрекләре эчендә була алуын өмет итә идек. Шуңа күрә кешелек тарихындагы бөек шәхесләр, каһарманнар турында сөйләшә идек. Үзебез дә, укучы булып йөргән вакытларда ук икебез дә тарихи шәхесләрдән булганбыз. Бу мәсьәләдә дә Йосыф бәй белән арабызда кайбер фикер аермалары барлыкка килүен хис иттем. Ул чакта Йосыф Акчура Россия төркиләре өчен котылу юлын большевикларга иярүдә күрә иде. Мин исә моның мөмкин булмаганын, миллиятне кабул итмәүчеләр белән миллиятне саклап калырга теләүчеләрнең берләшә алмаячагын белә идем, Йосыф бәй Төркиягә, мин Парижга киттем.

...Тагын вакытлар үтте. Мин, 1925 елда аңлатырга кирәкле түгел дип саналган сәбәпләр аркасында, Анкарада ачылган Хокук тарихы кафедрасының профессор исемен алганнан соң, галимнәрнең беренче җыелышына килдем. Анда кафедрада эшли торган кешеләр арасында, сәяси тарих профессоры исемен казанган Йосыф бәй белән тагын очраштым. Йосыф Акчура белән Хокук мәктәбендә тугыз ел һөнәрдәшләр булып эшләдек һәм башка дусларыбыз белән бергә бөек җиңүче Ататөрекнең революция нигезләренә бәйле идеалист, миллиятче, хокукчылар әзерләү өчен гайрәт иттек. Бу чакта Йосыф бәй, 30—40 еллык уку уңышы булган якты дәресләре белән Ататөрекнең принципларын, инкыйлаб нигезлә-

рен аңлату белән, бик чиста, дөрес сөйләве белән галимнәрнең дә, укучыларның да хөрмәтен казанды.

1919 елда Ататөрекнең дөрес булуын күрсәтү өчен, аның тырышлыгыннан, гаделлегеннән үрнәк алып эш итү нәтиҗәсендә тарих җәмгыяте корыла. Ататөрек үзенең җәмгыятьнең әгъзасы булу сөенечен һәм горурлыгын миңа да ачты. Иң борынгы цивилизацияләрне өйрәнеп, төрки культурасының аларга биргән тәэсирен, чын ролен өйрәнүдә хезмәт итәргә тиеш булган бу оешмада Йосыф Акчура белән без тагын очраштык. Ул бу оешманың беренче әгъзасы булып, аннары аның рәисе булып эшләде. Йосыф Акчураның исеме бу оешма белән нык бәйләнештә, чөнки ул Ататөрек хезмәтләрен яхшы аңлаган һәм аңлата белгән, шул ук вакытта җәмгыять, хөкүмәт, һәм гыйльми эшләр белән шөгыльләнгән. Ул идарә иткәндә җәмгыять үскән һәм ныгыган.

1930 елда Бөек Милләт мәҗлесенә милләт вәкилләре сайланды, шуларның берсе мин булдым. Бу бөек җыелыш ачылган көнне коридорда Йосыф бәй каршыма чыкты. Мине бик якын итеп күреп тәбрикләде һәм дуслык хисләрен белдерде. Беренче очрашуыбыздан бирле нәкъ 28 ел үткән икән. Йосыф бәйгә беренче уртак эшебезне искә төшердем. Ул сөйләвеннән туктап бер мизгелгә катып калды, аннары: «Гомер үтә, Садри» – диде. Мин дә «Борчылма, Йосыф, бүгенгә кадәр гомерең бушка сарыф ителмәгән, моннан соң да, иншалла, күп еллар яшәрсең, милләт өчен файдалы эшләрне дәвам итәрсең» – дидем. Йосыф Акчура Мәҗлестә миллият һәм төркичелек карашларыннан чыгып сөйләгәннәре белән идеалист төрки милләт вәкилләре–дусларыбызның хөрмәтен казанды. Вәкил дуслар Йосыф бәйнең сөйләгәнен һәрвакыт зур игътибар һәм хисләр белән тыңлыйлар иде.

Күргәнебезчә, мин Йосыф бәйне, аның гомер китабының һәр битен диярлек беләм, ул битләрдә мин үзем дә бар идем. Тормышның һәр чорында да аны миллият, төркилек, гомуми мәнфәгать өчен эшләгәнен күрдем. Бай гаиләдән булган, тырышлыгын үз шәхесенә юнәлткән очракта, ул үзе дә бай була алыр иде, ләкин бу акыллы, хезмәтсөяр, белемле шәхес, акылын, белемен, көчен шәхси кызыксынуларга кулланмыйча, җәмгыять идеалы, бөек идеал–төркичелек өчен сарыф итүче даһи иде. Йосыф

бәй – 30 елдан артык вакыты белән бер адым артка атламыйча, бер дә туктамыйча, төркилек идеалы өчен хезмәт иткән үз милләте улы. Төркиядә яшәмәгән төркиләр өчен дә бәйсезлек, милли үсеш чоры киләчәк, алар да бөек мәдәни үсешләргә дучар булырлар, тик милләтебез өчен яшәгән шәхесләрнең үлмәс исемнәре һичбер вакыт онытылмас. Йосыф Акчура исеме дә болар арасында шәрәфле урын алып тора. Бернәрсә дә мәңгелек түгел диләр, ләкин мәңгелек булган әйбер бар. Ул – бөтен гомерен бөтенебез өчен дә изге булган бер идеалга хезмәт итү белән яшәгән кешеләрнең исемнәре. Алар хәтирәләребездә, төркилек тарихында һәм төркичә идеалда янган йөрәкләребездә мәңге яшәячәк!

Төрекчәдән Алмаз Закиров тәрҗемә итте.

## *6. СОҢГЫ ДӘРЕС ҮГЕТЛӘРЕ.*

Шулай итеп, уку программасын бетергән булабыз.

Тиздән имтиханнарыгызны бирәчәксез. Күбегез, дипломнарыгызны алып, тормышың авыр юлына чыгачаксыз... Бу авыр юлга чыгарга әзерләнеп беттегезме соң сез? Бу юлга чыгар өчен, дипломнарыгыз гына җитәрлекме?

Юк, газиз укучыларым, дипломыгыз сезнең белемле кеше булуыгызны күрсәтсә дә, бу белем чикле. Һәм сез бу белемне арттырырга тырышмасагыз, җәмгыятьнең сездән көткәнен аңа бирә алмаячаксыз. Күп вакыт та узмас, сез милләтебезнең зыялылары булырсыз, зыялыларның да зөбәрҗәт ташларын тәшкил итәчәксез. Ләкин югары белем дипломы гына кешенең кем икәнен күрсәтмәс. Диплом – кешенең зыялы кеше булачагын белдергән бер документ кына ул.

Интеллигенция – нәрсә ул? Интеллигент – кем ул?

Интеллигент – бер яктан укымышлы, белемле, мәдәниле, икенче яктан, принциплы һәм ныклы фикерле кеше. Шиксез, белемнең, укуның чиге юк. Хәзерге заманда барлык фәннәр дә шулай камилләшә, алга китә ки, кеше хәйран кала. Бөтен нәрсә турында да белеп бетерү мөмкин түгел, әмма чын зыялы, ягъни интеллигент булырга телегән кеше, бер яктан, үзенең эшенә, профессиясенә бәйле булган әдәбиятны күзәтергә тиеш. Шулай ук, икенче

яктан, гомуми культурасын да камилләштерергә тиеш. Шуңа күрә сез бертуктаусыз укырга тиеш буласыз.

Һәр фән, һәр профессия, яңа теорияләр уйлап чыгарыла һәм тәкъдим ителә, яңа оешмалар, предприятиеләр оеша. Һәм юридик университет бетергәннән соң юрист, әгәр дә хокук китапларыннан башка һичбер китап укымаса, үзеннән күп түбән белемле секретарьдән аермасы булмас, һәм алган белеме дә дә калмас, югалыр. Әйбәт хокукчы (юрист) исемен хокук белән бергә тарих, икътисад, фәлсәфә һәм социология кебек фәннәрдән белемгә ия булган кешегә генә бирә алабыз.

Культурагызгы арттырыр өчен, укуны да бер гадәткә әйләндерергә, бер ял һәм рәхәтлек хәленә китерергә кирәк. Уку — иң очсыз һәм иң  файдалы ял ул. Шул ук вакытта бу гадәтегез үзегез һәм милләтебез өчен дә файдалы. Укуны гадәткә әйләндергәннәр генә уку дәртенең иң татлы дәрт булганын беләләр. Ләкин китапны да сайлап ала белергә кирәк. Бу сайлау да — эчке бер сиземләү эше бар. Кешенең рухын күтәргән, хисләрен нечкәрткән, хыял офыкларын киңәйткән, белемен арттырган китаплар булган кебек, кызганычка, бигрәк тә яшьләрнең әхлакый принципларын һәм ышанычларын какшата, рухларын агулый торган зарарлы китаплар  да бар. Кайбер көнбатыш милләтләренә хас булган бозык фикерләрне таратудан  файда алган язучыларның әсәрләре яшьләр өчен наркотиклар кебек үк зарарлы. Шуңа күрә, кулыгызга китап алганда, аның авторы һәм китапның эчтәлеге турында белешмә алырга тырышыгыз. Укыганнарыгызны пассив рәвештә үзләштермәгез, үзегезнең хыял иләгеннән чыгарып, һәр битне, һәр юлны тормышыгыз өчен төзү материалы итеп кулланыгыз.

Хәзер инде зыялы кеше булуның икенче шартын карыйк. Әлбәттә, зыялы — ул акыллы, тәүфыйклы кеше, ягъни үзенең ихтыяр көче, карашлары, принциплары белән тормыш белгән кеше. Тарихта уңай эшләр эшләгән бөек шәхесләрнең какшамас принципларга ия булган кешеләр икәнлеге һәм аларның үзләренең шушы принципларына таянып эш иткәннәре, яшәгәннәре мәгълүм. Зыялы кеше булу өчен тормыш, галәм, кешелек, милләтләр киләчәге, кешеләрнең җәмгыять каршындагы булыч-

лары турында ачык белергә һәм шул ук вакытта үз нәфесеңә һәм теләкләреңә хуҗа була белергә дә кирәк.

Газиз укучыларым, әле бу да җитәрлек түгел. Сезнең вазифаларыгыз, тормышта, җәмгыятьтә уйнарга теләгән ролегез, башкарырга теләгән эшләрегез, ирешергә теләгән максатыгыз турында да ачык һәм төпле фикерләрегез булырга тиеш. Чөнки максаты булмаган зыялы – диңгезгә ташланган рульсез көймә кебек ул.

СЕЗГӘ ТАГЫН БЕР НӘСИХӘТЕМ БАР: үзегезнең төрек (төрки) булганыгызны һичбер вакытта да онытмагыз. Үзегезнең төрек булуыгыздан шатлык һәм горурлык тоегыз. Чөнки төрки халыклар – бөек һәм намуслы халыклар. Без төркиләр – кешелек тарихының һәр дәверендә дөнья сәхнәсендә үз ролен уйнаган милләт. Без төрекләр – кешелек тарихында беркайчан да үзенең бәйсезлеген югалтмаган, һәр дәвердә мөстакыйль дәүләт хуҗасы булган милләт. Төрекнең үзенчәлеге шул башка халыклар белән аралаша белү осталынының, ягъни сәясәтчәнлегенең үлмәве. Безнең дәүләтебезне корган бөекләребез сәясәт мәйданында гына түгел, фикер һәм әхлак мәйданында да бөек шәхесләр иделәр: Мете, Бумин, Тонг Ямгу, Котлыг, Тугрул, Алып Арслан, Нуретдин Зенги, Бабур, Әкбәр, Үзбәк, Архан, Ататөрек – аларның барысы да үзләрендә зиһен белән сәясәткә сәләтне, тирән фикерләү кодрәтен, гаделлек һәм дөреслекне берләштергәннәр, үзләренә җыйганнар. Төркиләр – тарихта үз дәүләтләрен төзегән милләт кенә түгел, ә белгәнебезчә, белем һәм мәдәният мәйданында да бик күп бөек шәхесләр җитештергән милләтер. Ислам мәдәниятын тудыручыларның зур бер өлеше төркиләрдер. Ислам мәдәнияты тарихыннан Фараби, Фәргани, Җәүһәри, Улугбек, Кятиб Челәбиләрне, Сәмәрканди, Төбрәзиләрне алсак, ислам мәдәнияты бик ярлы булып калыр иде. Төрки милләтнең тарихын белгән, өйрәнгән чит ил галимнәре бу милләтнең, әлеге сыйфатларның бөеклегенә хәйран калганнар. Шуңа күрә без үзебезнең төрек булуыбыз белән горурлык кичерергә тиешбез. Бу горурлык хисләре сезгә – яшьләргә төркилекне яшәтергә һәм бөекләтергә, үстерергә теләк һәм шул вакытта аның өчен фидакарьләрчә корәшер өчен көч тә бирәчәк. Арагыздан төрекне бөекләтәчәк кешеләр чыгасына 100 процент ышанам.

Хәзер тагын бер нәрсә турында әйтергә телим. Сез – хокукчы, ягъни намусның, гаделлекнең сакчысы булачаксыз. Хокук, намус, әхлак, белем – болар бер–берсенә бәйле нәрсәләр. Сез, хокукчы буларак, намусның вәкиле һәм аны саклаучы да булачаксыз. Хокукчы сыйфатында сез намуссызлык һәм хаксызлык эшләргә тиеш түгел. Төрле кысулар да – хаксызлыкның бер төре, шуңа күрә хокукчы булып калырга, ягъни эшләргә теләсәгез, сез әхлак кагыйдәләренә буйсынырга тиешсез. Әйе, гаделлек һәм әхлак бергә йөриләр, алар аерылгысыз. Гаделсезлек, хаксызлык, явызлык эшләгән көнне үк инде хокукчы була алмыйсыз, сезнең моңа инде хакыгыз бетә. Явызлык һәм хаксызлык белән хокукчы иң беренче үзенә начарлык эшли, чөнки явызлык эшләү аның рухи тынычлыгын, горурлыгын ала. Эшләгән һәр явызлык, әшәкелек кешенең рухи халәтенә сугу, аның рухи дөньясындагы бер ярык, китеклек ул.

Чын хокукчы хаксызлык һәм гаделсезлектән сакланырга тиеш, әхлак кагыйдәләре буенча яшәүдән ваз кичмәс, башкаларга да хаксызлык һәм явызлык эшләтмәс.

Һәр авылда, шәһәрдә ярлыларны изү, башкаларга зарар китерү белән үзенә дан казану, үзенең көченнән һәм эшләгән урыныннан файдаланып, файда эшләргә, баерга теләгән, башкаларның малына, байлыгына кул сузудан, явызлык һәм хаксызлык эшләүдән чирканмаган кешеләр бардыр. Менә шундый кешеләргә каршы көрәшү вазифасы сезгә – хокукчыларга бирелгән. Кирәк икән, судья буларак, ярлыларны, хаксызлыкка төшерелгән кешеләрне яклау һәм саклау, аларга ярдәм итү сезнең вазифагызга керә. Милләт бу эштә сезгә ышана. Сезнең, хокукчы буларак, үз файдагыз өчен хаксызлык эшләү акылыгызга һәм хәтта төшегезгә дә керергә тиеш түгел.

Шушы урында мин сүземне бетерәм. Барыгызга да намуслы тормыш, максатыгызга ирешү юлында уңышлар, рухи күңел тынычлыгы һәм бәхет телим. Юлыгыз хак булсын!

Төрекчәдән Алмаз Закиров тәрҗемә итте.

## Э Ч Т Ə Л Е К


КЕРЕШ ........................................................................................ 5
I БҮЛЕК. XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ СӘЯСИ–ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫНДА САДРИ МАКСУДИ ...... 17
§ 1. Татар милләтенең сәясәттә уяна башлавы: «Иттифак әл–мөслимин» партиясе төзелү һәм Садри Максуди ............... 17
§ 2. Русиянең III Дәүләт думасында Мөселман фракциясе җитәкчеләренең берсе буларак эшчәнлеге Садри Максудиның «милләтчелек мәсләгенә итәчәк хезмәтенең» беренче адымнары ........................................ 28
§ 3. Садри Максудиның III Дәүләт думасы делегациясе белән Англиягә баруы ........................................ 46
II БҮЛЕК. САДРИ МАКСУДИНЫҢ II – III ДӘҮЛӘТ ДУМАЛАРЫНДАГЫ ЧЫГЫШЛАРЫ ........................................ 57
III БҮЛЕК. САДРИ МАКСУДИНЫҢ ТАТАР МИЛЛИ–АЗАТЛЫК ХӘРӘКӘТЕ ИДЕОЛОГИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУДАГЫ РОЛЕ ........................................ 89
§ 1. Садри Максуди милләтчелек һәм миллият турында ............ 89
§ 2. Садри Максудиның Диния руханиягә булган карашлары һәм аның шул юлдагы эшчәнлеге ......................... 95
IV БҮЛЕК. САДРИ МАКСУДИ ҺӘМ МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ ........................................ 112
§ 1. Садри Максуди – Эчке Русия һәм Себер төрек–татарларының Милли–мәдәни мохтарияты Идарәсе рәисе ........................................ 112
§2. Садри Максудиның эмиграциядә Милли Идарә рәисе буларак эшчәнлеге ........................................ 129
ЙОМГАКЛАУ ........................................ 150

ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ
ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ ........................................................ 155
КУШЫМТА ........................................................................ 165
I. Садри Максудиның кыскача тормыш юлы .......................... 165
II. С.Максуди мәкаләләре..................................................... 175
III. Садри Максудиның III Дума мәҗлесләрендә сөйләгән
нотыклары ........................................................................ 194
IV. С.Максудиның Милләт мәҗлесе ачылганда сөйләгән
нотыгы ................................................................................ 231
V. С.Максудиның эмиграциядәге эшчәнлеген
чагылдырган материаллар .................................................. 234
ЭЧТӘЛЕК.............................................................................. 260

*Гаффарова Фаина Юлдашевна*

САДРИ МАКСУДИ (1906–1924 еллар).

Оригинал – макет *Зигангареевой Л.М.*